# Казан утлары

4.1985

*Бөек Җиңүнең 40 еллыгына*



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

4

1985


## Бу санда


Михаил Сергеевич Горбачев . . . . . . . . . . 4

Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты Пленумы турында информацион белдерү . . . . . . . . . . . . . . . . 5

1985 елның 11 мартында КПСС Үзәк Комитеты Пленумында КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш М. С. Горбачев рече . . . . 6

КПСС Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы, СССР Министрлар Советының Коммунистлар партиясенә, совет халкына мөрәҗәгате . . . . . . . . . . . . . 11

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Р. МИНГАЛИМ. Сагыну. *Шигырь* . . . . . . 13

Т. ХАҖИӘХМӘТОВ. Уральскида Тукай урыннары . . . . . . . . . . . . . . . 14

М. ИКСАНОВ. Зуп-зур Тукай булдым . . . . . 15

Х. КАМАЛОВ. Безне өйдә көтәләр. *Роман* . . . 22

Ә. ИСХАК. Кызыл кошлар. *Шигырьләр* . . . . 85

М. РАФИКОВ. *Шигырьләр* . . . . . . . . . 89

Г. КАШАПОВ. Язмышыңа ышан. *Роман* . . . . 95

Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Сәхипҗамал. *Поэма* . . . . 133

«БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ» КОНКУРСЫНА

К. ЛАТЫЙПОВ. Яшьлек рәхмәте. *Хикәя* . . . . 143

Р. ЗӘЙДУЛЛИН. Ана. *Шигырьләр* . . . . . . 147

В. И. ЛЕНИННЫҢ ТУУЫНА — 115 ЕЛ

Ж. МИНДУБАЕВ. Юлбашчы яшәгән гаиләдә . . 150

В. СКВОРЦОВ. Ленинның беренче шәкерте . . . 155

БӨЕК ЖИҢҮНЕҢ 40 ЕЛЛЫГЫНА

М. ХУЖИН. Ярамый, ярамый! . . . . . . . 157

Г. МӘҖИТОВА. Музалар тын тормады . . . 159

Т. НАСЫЙРОВ. Үзәк нәшриятлар — Казанда . . 163

КПССНЫҢ XXVII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Ф. АБДУЛЛИН. Ышаныч. *Очерк* . . . . . . 166

Ф. МИҢНУЛЛИН. Ягымлы геройлар. *(В. Нуруллинга 50 яшь)* . . . . . . . . . . . . 170



КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

БИБЛИОГРАФИЯ

Ә. СӘХӘПОВ. Яңу . . . . . . . . . . . . . 174

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Я. АБДУЛЛИН. Күренекле мәгърифәтчебез . . 177

ЮБИЛЕЙЛАР

Х. МӘХМҮТОВ. Җырга гашыйк галим . . . . 184
С. ГУРАРИЙ. Халык моңына сарылып . . . . 186

Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары . . . . . . . . . . . . . 189

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . 191

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192



*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**

**ӘХӘТ ГАФФАР**

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**

**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**

**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**

**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**

**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*

**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**

**ФЛҮН МУСИН**

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*

**РӘФЫЙК НӘФЫКОВ**

**НУРИХАН ФӘТТАХ**

**СИБГАТ ХӘКИМ**

**РИЗВАН ХӘМИД**

**НИЛ ЮЗИЕВ**

**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**


## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Биография Генерального секретаря ЦК КПСС товарища Михаила Сергеевича Горбачева.
Информационное сообщение о Пленуме ЦК КПСС. Речь Генерального секретаря ЦК КПСС товарища М. С. ГОРБАЧЕВА на Пленуме ЦК КПСС 11 марта 1985 года.
Обращение Центрального Комитета КПСС, Президиума Верховного Совета СССР, Совета Министров СССР к Коммунистической партии, к советскому народу.
К 100-летию Тукая: статья первого секретаря Уральского обкома партии М. Б. ИКСАНОВА, рисунок Т. ХАЗИАХМЕТОВА из серии «Тукаевские места в Уральске», стихотворение Р. МИНГАЛИМА.
Роман Х. КАМАЛОВА «Нас ждут дома» (начало). Поэма Р. АХМЕТЖАНОВА «Сахипжамал». Стихи А. ИСХАКА, М. РАФИКОВА и молодого поэта Р. ЗАЙДУЛЛИНА.
Роман Г. КАШАПОВА «Поверь судьбе своей» (окончание).
На конкурс «Подвиг продолжается»: рассказ К. ЛАТЫПОВА.
К 115-летию со дня рождения В. И. Ленина: статьи Ж. МИНДУБАЕВА и В. СКВОРЦОВА.
К 40-летию Великой Победы: публицистическое выступление М. ХУЗИНА, статьи Т. НАСЫРОВА «Центральные издательства — в Казани», Г. МАЗИТОВОЙ о фронтовых концертных бригадах, сформированных в Казани.
Навстречу XXVII съезду КПСС. Очерк Ф. АБДУЛЛИНА «Доверие». Статья Ф. МИННУЛЛИНА о творчестве прозаика В. Нуруллина.
В рубрике «Библиография» — рецензия на книгу Н. АРСЛАНОВА. Статья Я. АБДУЛЛИНА о видном татарском просветителе К. Насыри.
В номере также отмечаются юбилеи И. НАДЫРОВА (60 лет) и Ф. АХМЕТОВА (50 лет).
«Дневник культуры», «Вновь принятые члены Союза писателей СССР».
На нашей обложке: творчество художника А. Родионова.


Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.



Техник редактор Р. Сөләйманова. Корректорлар Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.

Производствога бирелде 29.01.1985 ел. Басарга кул куелды 16.04.1985 ел. ПФ 02074. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64049. Заказ Ф-42. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.



© «Казан утлары», 1985 ел.



КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре

**МИХАИЛ СЕРГЕЕВИЧ**

**Г О Р Б А Ч Е В**

# МИХАИЛ СЕРГЕЕВИЧ ГОРБАЧЕВ

Михаил Сергеевич Горбачев 1931 елның 2 мартында Ставрополь краеның Красногвардейский районы, Привольное авылында крестьян семьясында туган.

1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышыннан соң күп тә үтми, 15 яшьтә ул үзенең хезмәт эшчәнлеген башлый. Машина-трактор станциясе механизаторы булып эшли. 1952 елда КПСС сафына керә. 1955 елда М. В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетын (юридик факультет) тәмамлый, ә 1967 елда Ставрополь авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, агроном-экономист белгечлеге ала.

1955 елдан М. С. Горбачев — комсомол һәм партия эшендә. Ставрополь краенда: ВЛКСМның Ставрополь шәһәр комитеты беренче секретаре, комсомолның край комитеты пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире урынбасары, ә аннары комсомол крайкомының икенче һәм беренче секретаре булып эшли.

1962 елның мартында М. С. Горбачев Ставрополь территориаль-производство колхоз-совхоз идарәсе парторгы булып күтәрелә, ә шул ук елның декабрендә КПССның край комитетының партия органнары бүлеге мөдире итеп раслана.

1966 елның сентябрендә ул партиянең Ставрополь шәһәр комитеты беренче секретаре булып сайлана. 1968 елның августыннан М. С. Горбачев КПССның Ставрополь край комитетының икенче секретаре булып эшли, ә 1970 елның апрелендә край комитетының беренче секретаре булып сайлана.

М. С. Горбачев — 1971 елдан КПСС Үзәк Комитеты члены. Партиянең XXII, XXIV, XXV һәм XXVI съездлары делегаты булды. 1978 елда КПСС Үзәк Комитеты секретаре, 1979 елда КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы членлыгына кандидат булып сайланды. 1980 елның октябрендә М. С. Горбачев КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы членлыгына кандидаттан Политбюро члены итеп күтәрелде. СССРның 8—11 чакырылыш Верховный Советы депутаты, Союз Советының чит ил эшләре комиссиясе председателе. РСФСРның 10—11 чакырылыш Верховный Советы депутаты.

Михаил Сергеевич Горбачев — Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләтенең күренекле эшлеклесе. Партия тапшырган барлык постларда ул үзенә хас инициатива, энергия һәм фидакарьлек белән эшли, белемен, бай тәҗрибәсен һәм оештыру талантын партия политикасын тормышка ашыруга бирә, бөек Ленин эшенә, хезмәтчел халык интересларына чын күңелдән бирелеп хезмәт итә.

Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте алдындагы хезмәтләре өчен М. С. Горбачев өч Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет билгесе» орденнары һәм медальләр белән бүләкләнде.

# Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты Пленумы турында

# ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

1985 елның 11 мартында Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының чираттан тыш Пленумы булды.

Үзәк Комитет Политбюросы тапшыруы буенча Пленумны КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, КПСС Үзәк Комитеты секретаре иптәш М. С. Горбачев ачты.

КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе К. У. Черненко вафат булу сәбәпле, Пленумда катнашучылар Константин Устинович Черненконың истәлеген бер минутлык кайгы тынлыгы белән хөрмәтләделәр.

Пленум, Советлар Союзы Коммунистлар партиясе, барлык совет халкы авыр югалтуга дучар булды, дип күрсәтте. Күренекле партия һәм дәүләт эшлеклесе, патриот һәм интернационалист, коммунизм идеаллары тантанасы өчен һәм җирдә тынычлык өчен эзлекле көрәшүче безнең арадан китте.

Константин Устинович Черненко үзенең бөтен тормышын ахырынача Ленин партиясе эшенә, совет халкы интересларына бирде. Партия аны кая гына җибәрмәсен, ул үзенә хас фидакарьлек белән КПСС политикасын тормышка ашыру өчен даими көрәште.

Константин Устинович Черненко нык үскән социализмны камилләштерү, экономик һәм социаль үсешнең зур бурычларын хәл итү, совет халкының тормыш хәлен һәм культура дәрәҗәсен күтәрү, массаларның иҗади активлыгын үстерә бару, идеология эшен яхшырту, дисциплинаны, законлылык һәм тәртипне ныгыту курсын эзлекле үткәрүгә зур игътибар бирде.

Константин Устинович Черненко тугандаш социализм илләре белән һәрьяклы хезмәттәшлекне үстерә баруга, социалистик экономик интеграцияне тормышка ашыруга, социалистик бердәмлекнең позицияләрен ныгытуга зур өлеш кертте. Аның җитәкчелегендә иҗтимагый стройлары төрле булган дәүләтләрнең янәшә тыныч яшәү принциплары нык һәм эзлекле үткәрелеп килде, империализмның агрессив планнарына кискен отпор бирелде, империализм тарафыннан көчләп тагылган ашкынып кораллануны туктату, атом-төш сугышы куркынычын бетерү өчен, халыкларның ышанычлы иминлеген тәэмин итү өчен ару-талусыз көрәш алып барылды.

Константин Устинович Черненко сөекле Коммунистлар партиясенең бердәмлеген, Үзәк Комитет һәм аның Политбюросы эшчәнлегендә коллективлыкны күз карасыдай саклады. Ул һәрвакыт партиянең барлык дәрәҗәләрдә тупланган, бердәм һәм сугышчан организм булып эш итүенә омтылды. Ул барлык уңышларыбызның нигезен, житешсезлекләрне бетерүнең, алга таба хәрәкәт итүнең нигезен коммунистларның фикерләре һәм эшләре бердәмлегендә күрде.

Пленум, бу кайгылы көннәрдә коммунистлар, барлык совет халкы партия Үзәк Комитеты һәм аның Политбюросы тирәсенә тагын да тыгызрак тупланалар, дип басым ясап күрсәтте. Совет кешеләре партия йөзендә бик нигезле рәвештә җәмгыятьнең җитәкче һәм юнәлеш бирүче көчен күрәләр, КПСС үткәрә торган ленинчыл эчке һәм тышкы политиканы тормышка ашыру өчен чын күңелдән бирелеп көрәшергә әзер торалар.

Пленумда катнашучылар мәрхүмнең туганнары һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклашуларын белдерделәр.

Үзәк Комитет Пленумы КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретарен сайлау турындагы мәсьәләне карады.

Политбюро тапшыруы буенча бу мәсьәлә турында Политбюро члены иптәш А. А. Громыко речь белән чыкты. Ул КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре итеп иптәш М. С. Горбачевны сайларга тәкъдим итте.

Пленум КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре итеп бердәм рәвештә иптәш М. С. Горбачевны сайлады.

Аннары Пленумда КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш М. С. Горбачев чыгыш ясады. Ул КПСС Үзәк Комитеты тарафыннан үзенә күрсәтелгән олы ышаныч өчен зур рәхмәт әйтте, бу уңайдан аңа төшкән җаваплылыкның никадәр зур икәнлеген бик яхшы аңлавын белдерде.

Иптәш М. С. Горбачев КПСС Үзәк Комитетын партиябезгә, халкыбызга, бөек Ленин эшенә турылыклы хезмәт итү өчен, КПССның программ күрсәтмәләре тайпылышсыз тормышка ашырылсын өчен, СССРның экономик һәм оборона куәтен ныгыта бару, совет халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү, тынычлыкны ныгыту бурычларын хәл итүдә дәвамчанлык тәэмин ителсен өчен, Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләтенең ленинчыл эчке һәм тышкы политикасы ныклык белән тормышка ашырылсын өчен бөтен көчен бирәчәгенә ышандырды.

Шуның белән КПСС Үзәк Комитеты Пленумы үзенең эшен тәмамлады.

## 1985 елның 11 мартында КПСС Үзәк Комитеты Пленумында КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш М. С. ГОРБАЧЕВ рече

Кадерле иптәшләр!

Безнең барыбызга да, бөтен партиябезгә һәм илебезгә авыр кайгы килде. Турылыклы ленинчы, Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең һәм Совет дәүләтенең, халыкара коммунистлар хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, зур оештыру талантына ия булган олы җанлы кеше — Константин Устинович Черненко безнең арадан китте.

Константин Устинович зур һәм данлы юл үтте. Партия тапшырган һәр участокта аның таланты, кешеләр белән эшли белүе һаман тулырак ачыла барды. КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы председателе постында Константин Устинович Черненко үзенең бөтен көчен һәм белемен илебез экономикасын үстерүгә, халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм культурасын күтәрүгә, Ватаныбыз иминлеген тәэмин итүгә, җирдә тынычлыкны саклау һәм ныгытуга бирде.

Константин Устинович Черненко Коммунистлар партиясенең бердәмлеген, Үзәк Комитет һәм аның Политбюросы эшчәнлегендә коллективлыкны күз карасыдай саклый иде. Ул һәрвакыт партиянең барлык дәрәҗәләрдә тупланган, бердәм һәм сугышчан организм буларак эш итүенә омтылды. Ул уңышларыбызның нигезен, житешсезлекләрне бетерүнең, алга таба хәрәкәт итүебезнең нигезен коммунистлар фикере һәм эше бердәмлегендә күрде.

Партиянең XXVI съездында, Үзәк Комитетның соңгы Пленумнарында Юрий Владимирович Андропов һәм Константин Устинович Черненко-ның эшлекле катнашында эшләнгән стратегик линия даими булды һәм шулай булып кала. Бу — илебезнең социаль-экономик үсешен тизләтү,

җәмгыять тормышының барлык якларын камилләштерү линиясе. Сүз житештерүнең материаль-техник базасын үзгәртеп кору турында бара. Сүз иҗтимагый мөнәсәбәтләр, барыннан да бигрәк экономик мөнәсәбәтләр системасын камилләштерү турында бара. Сүз кешенең үзенең үсүе турында, аның тормыш һәм хезмәтенең материаль шартларын, аның рухи йөзен сыйфат ягыннан яхшырту турында да бара.

Безнең алда халык хуҗалыгын интенсив үсеш юлына күчерүдә хәлиткеч борылышка ирешү бурычы тора. Без кыска вакытта иң алдынгы фән-техника позицияләренә, иҗтимагый хезмәт житештерүчәнлегенең дөньяда иң югары дәрәҗәсенә чыгарга тиешбез, бурычлыбыз.

Бу бурычны уңышлы һәм тизрәк хәл итү өчен киләчәктә дә хуҗалык итү механизмын һәм идарә итүнең бөтен системасын ныклык белән камилләштерергә кирәк. Шушы юлдан барып, оптималь чишелешләрне сайлап, социалистик хуҗалык итүнең төп нигез булып торган принципларын иҗади куллану мөһим. Бу — экономиканы планлы үстерүне туктаусыз тормышка ашыру, социалистик милекне ныгыту, предприятиеләрнең хокукларын киңәйтү, аларның мөстәкыйльлеген һәм җаваплылыган арттыру, эшнең ахыргы нәтиҗәләре өчен кызыксынуларын көчәйтү дигән сүз. Бу — бөтен экономик үсешне ахыр чиктә совет кешеләре интересларына буйсындыру дигән сүз.

Партия үзе эшләгән социаль политиканы тайпылусыз үткәрәчәк. Бар нәрсә кеше хакына, кеше файдасына — бу программ положение һаман тирәнрәк һәм конкретрак эчтәлек белән тулыландырылырга тиеш. Әлбәттә, кешенең тормыш шартларын яхшырту аның гомуми эшкә кертә торган өлеше арта баруга нигезләнергә тиеш. Бу принциптан читкә тайпылуга юл куелган урыннарда социаль гаделлек котылгысыз бозылачак. Ә ул социалистик җәмгыятьнең бердәмлеге һәм тотрыклылыгы өчен гаять мөһим фактор.

Партия демократияне, халыкның социалистик үзидарә системасын камилләштерә бару һәм үстерүне эчке политиканың төп бурычларыннан берсе дип карый. Биредә бурычлар күпкырлы. Бу юнәлештә күп эшләнә дә. Советларның ролен күтәрү, профсоюзларны, комсомолны, халык контролен, хезмәт коллективларын активлаштыру күздә тотыла. Әмма алда инде билгеләнгән юнәлешләр буенча да, яңа юнәлешләр буенча да ныклап эшлисе бар.

Социалистик демократияне тирәнәйтү иҗтимагый аңны күтәрү белән аерылгысыз бәйләнгән. Тәрбия эшенең нәтиҗәлелеге, барыннан да бигрәк, кешеләрнең зур һәм кечкенә проблемаларны хәл итүдә ничек катнашуларында, аларның ничек эшләүләрендә, житешсезлекләргә каршы ничек көрәшүләрендә чагыла. Совет кешеләренең хезмәт һәм социаль активлыгын күтәрү, дисциплинаны ныгыту, патриотизм һәм интернационализм тәрбияләү — бөтен идеология эшчәнлегенең мөһим бурычы.

Киләчәктә дә һәркайда тәртип урнаштыру, тормышыбызны безгә ят күренешләрдән, җәмгыять һәм аның гражданнары интересларына кул сузулардан чистарту буенча кискен чаралар күреләчәк.

Без киләчәктә дә партия, совет, дәүләт һәм җәмәгать оешмалары эшеннән хәбәрдарлыкны киңәйтергә бурычлыбыз. В. И. Ленин, дәүләт массаларның аңлылыгы белән көчле, диде. Безнең практика бу нәтиҗәне тулысынча исбатлады. Кешеләр никадәр яхшырак хәбәрдар булсалар, алар шулкадәр аңлырак эш итәләр, партияне, аның планнарын һәм программ максатларын шулкадәр активрак яклыйлар.

Тышкы политика өлкәсендә безнең курс ачык һәм эзлекле. Бу — тынычлык һәм прогресс курсы.

Партия һәм дәүләтнең беренче бурычы — үзебезнең иң якын көрәштәшләребез һәм союзникларыбыз — бөек социалистик бердәмлек илләре белән туганнарча дуслыкны саклау һәм барлык чаралар белән ныгыту. Социалистик дәүләтләр белән үзара бәйләнешне киңәйтү өчен, дөнья эшләрендә социализмның ролен һәм йогынтысын күтәрү өчен без үзебезгә бәйле булганнарның барысын да эшләрбез. Без Кытай Халык Респуб-

касы белән мөнәсәбәтләрне җитди яхшыртырга теләр идек һәм, үзара аңлашу булганда, бу тулысынча мөмкин эш дип саныйбыз.

СССР халыкларның колониаль изүдән котылу өчен көрәшен һәрвакыт яклап килде. Һәм бүген дә без Азиядә, Африка һәм Латин Америкасында үзләренең бәйсезлеген ныгыту һәм социаль яңарыш юлыннан баручы илләргә ихтирам белән карыйбыз. Безнең өчен алар — ныклы тынычлык өчен, халыклар арасында яхшы, гадел мөнәсәбәтләр өчен көрәштә дуслар һәм партнерлар.

Капиталистик дәүләтләргә килгәндә исә түбәндәгеләрне әйтеп китәргә телим. Без ленинчыл тынычлык һәм янәшә тыныч яшәү курсы белән нык барачакбыз. Яхшы теләккә Советлар Союзы һәрвакыт яхшы теләк белән, ышанычка ышаныч белән җавап бирәчәк. Ләкин һәркем белеп торырга тиеш: Ватаныбыз һәм аның союзниклары мәнфәгатьләреннән без беркайчан да баш тартмаячакбыз.

Без халыкара киеренкелекне йомшартуда 70 нче елларда ирешкән уңышларны уңай бәялибез, һәм тигез хокуклылык, үзара ихтирам һәм бер-береңнең эчке эшләренә катнашмау нигезендә дәүләтләр арасында тыныч, үзара файдалы хезмәттәшлекне җайга салу процессын дәвам иттерүдә катнашырга әзер торабыз. Гитлер фашизмын һәм Япония милитаризмын Бөек Җиңүнең 40 еллыгын лаеклы билгеләп үтү бу юнәлештә яңа адым була алыр иде.

Безнең көннәрдәгедәй коточкыч дәһшәтнең кешелек дөньясы өстенә әле беркайчан да килгәне юк иде. Бу хәлдән чыгуның бердәнбер кулай юлы — каршы торучы көчләрнең җирдә ашкынып кораллануны, барыннан да бигрәк атом-төш өлкәсендә ашкынып кораллануны кичекмәстән туктату һәм аны космоста җәелдерүгә юл куймау турында сөйләшеп килешүләре. Намуслы һәм тигез хокуклы нигездә, башка якны «отарга» һәм аңа үз шартларыңны көчләп тагарга маташулардан башка килешү. Барыбызга да изге максатка таба — атом-төш коралын тулысынча юк итүгә һәм мәңгегә тыюга, атом-төш сугышы куркынычын тулысынча бетерүгә таба алга китәргә ярдәм итә торган килешү. Моңа без нык ышанабыз.

Иртәгә Женевада Советлар Союзы белән Америка Кушма Штатлары арасында сөйләшүләр башланачак. Советлар Союзының бу сөйләшүләргә карашы яхшы мәгълүм. Бары тик тагын бер тапкыр шуны раслый алам: без Кушма Штатлар алдында, НАТО илләре алдында берьяклы өстенлеккә ирешүгә, алардан хәрби өстенлеккә ирешүгә омтылмыйбыз; без ашкынып кораллануны дәвам иттерүне түгел, ә аны туктатуны телибез — һәм шунлыктан атом-төш арсеналларын булган дәрәҗәсендә калдырырга, киләчәктә ракеталарны урнаштыруны туктатырга тәкъдим итәбез; без — космоста яки җирдә булмасын — коралның яңадан-яңа системаларын булдыруны түгел, бәлки корал запасын чын-чынлап һәм күпкә кыскартуны телибез.

Женева сөйләшүләрендәге партнерларыбызның Советлар Союзы позициясен аңлауларын һәм уңай адымнар белән җавап бирүләрен теләр идек. Ул чагында килешү мөмкин эшкә әйләнер иде. Дөнья халыклары җиңел суларлар иде.

КПСС — табигате буенча интернациональ партия. Чит илләрдәге фикердәшләребез ышана алалар: тынычлык һәм социаль прогресс өчен көрәштә Ленин партиясе, һәрвакыттагыча, тугандаш коммунистлар, эшчеләр, революцион-демократик партияләр белән тыгыз хезмәттәшлек итәчәк, барлык революцион көчләрнең бердәмлеген һәм үзара актив бәйләнешен яклаячак.

Иптәшләр! Безнең алда торган катлаулы бурычларны хәл итү партияне ныгыта баруны, аның оештыручы һәм юнәлеш бирүче ролен күтәрүне күздә тота. КПСС һәрвакыт Ленинның, принципиаль политика — бердәнбер дөрес политика, дигән фикереннән чыгып эш итте һәм эш итә. Күмәк рәвештә эшләнгән мондый политика эзлекле һәм тайпылышсыз тормышка ашырылачак. Партия — нәкъ менә барлык сыйныфлар һәм социаль группаларның, илебездә яшәүче барлык милләтләр һәм

халыкларның интересларын исәпкә алырга, аларны бергә тупларга, халык энергиясен коммунистик төзелешнең уртак эшенә тупларга сәләтле көч ул.

Партия политикасы эшчеләр сыйныфы, крестьяннар һәм интеллигенция союзын ныгытуга, күпмилләтле бөек державабыз халыкларының дуслыгын өзлексез ныгытуга юнәлдерелде һәм шуңа юнәлдереләчәк.

КПСС яшьләрнең иҗади инициативасын һәрьяклы үстерәчәк, хатынкызларның хезмәт һәм көнкүреш шартларын яхшырту, сугыш һәм хезмәт ветераннарының ихтыяҗлары турында кайгыртачак.

Потенциаль агрессорлар Советлар иленең һәм аның союзникларының иминлегенә, совет кешеләренең тыныч тормышына кул сузуның җимергеч җавап ударына очраячагын яхшы белсеннәр — катлаулы халыкара шартларда Ватаныбызның оборона сәләтен шундый дәрәҗәдә тоту хәзер кайчандагыга караганда да мөһим: моның өчен безнең данлы Коралды Көчләребездә киләчәктә дә кирәкле бар нәрсә булачак.

Хәзер КПССның XXVII съездына әзерлек киң җәелде. Анда партия Программасының яңа редакциясе каралачак, киләсе бишьеллыкка һәм 2000 елга кадәр илнең үсеш перспективалары билгеләнәчәк.

Вакыт барлык партия оешмаларының югарыдан түбәнгәчә киеренке, иҗади эшләвен таләп итә. Барлык участокларда, һәр җирдә һәм һәркайда коммунистлар гражданлык бурычын үтәүнең, җәмгыять файдасына намуслы хезмәт итүнең үрнәге булырга, һәркайда ленинчыл эш стилен урнаштырырга тиешләр. Бу беренче чиратта партия кадрларына, партия һәм дәүләт житәкчеләренә кагыла. КПСС таләпчәнлекне көчәйтү, тапшырылган эш өчен җаваплылыкны күтәрү линиясен даими үткәрәчәк.

Пленум тәмамлангөннән соң Үзәк Комитет членнары, өлкә комитетларының беренче секретарьлары, биредә катнашучыларның барысы да эшкә яңа энергия белән тотыну өчен урыннарга таралачаклар. Ә алда эшләр күп. Барыннан да бигрәк, экономик һәм социаль үсеш планнарын үтәү буенча быелгы эшләрне уңышлы төгәлләргә һәм шуның белән киләсе бишьеллыкка ышанычлы старт алуны тәэмин итәргә кирәк.

Салкын кыш кайбер тармакларда план заданиеләрен үтәүне өерникадәр тоткарлады. Димәк, эшләнеп бетмәгән эшләрне башкару һәм ел азагына билгеләнгән үрләргә чыгу өчен хәзер оешканрак булырга, резервларны тупларга, бөтен көчне эшкә җигәргә кирәк.

Иптәшләр, бу көннәрдә без коммунистлар сафының никадәр куәтле һәм монолит булуын, совет халкының никадәр тупланган һәм бердәм булуын һаман ныграк тоябыз. Күптән түгел булып үткән сайлауларда совет кешеләре партиябез һәм дәүләтебез курсын бердәм яклауларын яңадан белдерделәр. Бу яклау рухландыра һәм күп бурычлар йөкли.

Бүген Үзәк Комитет Пленумы миңа КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаренең катлаулы һәм зур вазифаларын йөкләде. Миңа күрсәтелгән ышанычның никадәр зур булуын һәм бу уңайдан миңа төшкән җаваплылыкның никадәр зур булуын яхшы аңлыйм. Киләчәк эшемдә Политбюро членнарының, Политбюро членлыгына кандидатларның һәм Үзәк Комитет секретарьларының һәм тулаем партия Үзәк Комитетының булышлыгына, актив ярдәменә исәп тотам. Сезнең күпкырлы тәҗрибәгез — халкыбыз туплаган тарихи тәҗрибәнең каймагы. Партиябезгә, халкыбызга, бөек Ленин эшенә турылыклы хезмәт итү өчен бөтен көчемне куярмын дип вәгъдә бирәм сезгә, иптәшләр.

КПССның XXVII съездын каршылаганда Үзәк Комитет тирәсенә тупланган халкыбыз һәм партиябез үзебезнең Совет Ватаны тагын да баерак һәм куәтлерәк булсын өчен, социализмның иҗади көчләре тагын да тулырак ачылсын өчен барысын да эшләрләр, дигән ышанычы белдерергә рөхсәт итегез.



КОНСТАНТИН УСТИНОВИЧ ЧЕРНЕНКО

# КПСС Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы, СССР Министрлар Советының Коммунистлар партиясенә, совет халкына МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле иптәшләр!

Советлар Союзы Коммунистлар партиясе, Совет дәүләте, барлык совет халкы авыр югалтуга дучар булды. Күренекле партия һәм дәүләт эшлеклесе, патриот һәм интернационалист, коммунизм идеаллары тантанасы өчен һәм җирдә тынычлык өчен эзлекле көрәшүче Константин Устинович Черненконың гомере өзелде.

Константин Устинович Черненконың бөтен тормышы тулысынча Ленин партиясе эшенә, совет халкы интересларына багышланды. Партия аны кая гына җибәрмәсен, ул үзенә хас фидакарьлек белән, армыйталмый КПСС политикасын тормышка ашыру өчен көрәште, бу партия сафларында ул илле елдан артык торды.

Комсомол җитәкчесеннән һәм чик буе заставасы парторгыннан алып КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателенә кадәр — К. У. Черненконың тормыш юлы әнә шундый. Партиядә һәм дәүләттә югары постларда эшләгәндә аның оештыручы, ленинчыл типтагы җитәкче булу таланты бөтен тулылыгы белән ачылды. Партия Үзәк Комитеты, К. У. Черненко җитәкчелегендәге КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы хезмәт ияләрен КПСС-ның XXVI съезды, Үзәк Комитетның аннан соңгы Пленумнары карарларын үтәүгә туплауда зур һәм нәтиҗәле эш алып бардылар.

Нык үскән социализмны камилләштерү, экономик һәм социаль үсешнең зур бурычларын хәл итү, совет халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү, массаларның иҗади активлыгын үстерә бару, идеология эшен яхшырту курсы эзлекле үткәрелде. Дисциплинаны, законлылык һәм тәртипне ныгыту, кадрлар политикасы, Советларның, комсомолның, халык мәгарифенең эшчәнлеген активлаштыру, мәктәп реформасы, әдәбият һәм сәнгатьнең иҗтимагый ролен күтәрү мәсьәләләре партиянең даими игътибар үзәгендә булды. КПССның чираттагы, XXVII съездына әзерләнү, партия Программасының яңа редакциясен эшләү буенча актив эш алып барыла.

Халыкара мәйданда партиянең тырышлыгы тугандаш социализм илләре белән һәрьяклы хезмәттәшлекне үстерә баруга тупланды. Социалистик экономик интеграциянең яңа этабына күчү, социалистик бердәмлек позицияләрен ныгыту К. У. Черненко эшчәнлеге белән бәйле.

КПСС Үзәк Комитеты, Совет дәүләте иҗтимагый стройлары төрле булган дәүләтләрнең янәшә тыныч яшәүләре принцибын нык һәм эзлекле тормышка ашыра бардылар, империализмның аеруча реакцион даирәләренең агрессив планнарына һәм омтылышларына кискен төстә каршы тордылар, империализм тарафыннан көчләп тагылган ашкынып кораллануны туктату, атом-төш сугышы куркынычын бетерү өчен, халыкларның ышанычлы иминлеген тәэмин итү өчен армый-талмый көрәштеләр.

Авыр югалту уңаеннан КПСС Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы, СССР Министрлар Советы коммунистларга, совет халкына партиянең ленинчыл Үзәк Комитеты һәм аның Политбюросы тирәсенә тагын да тыгызрак тупланырга чакыру белән мөраҗәгать итәләр. Илебез хезмәт ияләре Советлар Союзы Коммунистлар партиясен тулы нигез белән совет җәмгыятенең җитәкче һәм юнәлеш бирүче көче итеп саныйлар. Партиянең барлык эшләре һәм уй-фикерлә-

ре совет халкының төп интересларына, коммунизм эшенә чын күңелдән бирелеп хезмәт итүгә юнәлгән.

КПСС үлемсез революцион марксистик-ленинчыл тәгълимат белән коралланды. Ул Ленин күрсәткән юлдан тайпылышсыз бара һәм бу юлдан беркайчан да читкә борылмас.

Партия киләчәктә дә нык үскән социализмны һәрьяклап камилләштерү курсын үткәрәчәк. Ул экономиканы интенсивлаштыру, фән-техника прогрессын барлык чаралар белән тизләтү нигезендә халык тормышының материаль һәм культура дәрәҗәсен күтәрә баруны үз эшчәнлегенең иң югары мәгънәсе дип саный. Социализмга хас социаль гаделлек принцибы тормышыбызның барлык сфераларында бөтен ныклыгы белән тагын да тулырак тормышка ашырылачак, дисциплинаны, тәртипне, оешканлыкны ныгыту линиясе — илебез хезмәт ияләре тарафыннан хупланган һәм якланган линия тайпылышсыз үткәреләчәк. Партия киләчәктә дә эшчеләр сыйныфы, колхозчы крестьяннар һәм интеллигенция союзын, совет халыкларының туганнарча дуслыгын — җәмгыятебез яшәвенең нигезен тәшкил итә торган дуслыкны ныгытачак, социалистик демократияне үстерәчәк. Партия марксистик-ленинчыл инанганлыкны, коллективизмны, патриотизмны, пролетар социалистик интернационализмны совет кешеләренең иң югары рухи байлыгы дип санады һәм саный.

КПСС, Совет дәүләте социалистик бердәмлекне ныгыту, дөнья мәйданында социализм позицияләрен ныгыту, атом-төш һәлакәтен булдырмау һәм ныклы тынычлык тәэмин итү өчен мөмкин һәм кирәк булганнарның барысын да эшләделәр һәм эшлиләр. Без ашкынып кораллануны туктатырга, космосны милитаризацияләүне булдырмаска телибез һәм шуның өчен нык көрәшәбез. Безнең ахыргы максатыбыз — планетада, һәркайда атом-төш коралын тулысынча юк итү, атом-төш сугышы куркынычын тулысынча бетерү. Советлар Союзы һәрвакыт конструктив диалогны яклап чыкты, халыкара киеренкелекне киметүгә, барлык халыклар һәм дәүләтләр арасында ышаныч, хезмәттәшлек һәм үзара аңлашу атмосферасын урнаштыруга алып бара торган практик чараларны яклап чыкты һәм яклый.

Советлар Союзы беркемгә дә янамый һәм хәрби өстенлеккә омтылмый. Әмма ул нинди дә булса башка илнең яки дәүләтләр коалициясенең мондый өстенлек алуына юл куймаячак. Менә ни өчен без киләчәктә дә уяулыкны армый-талмый көчәйтәчәкбез, социалистик Ватаныбызның оборона сәләтен ныгытачакбыз.

Без азатлык һәм милли бәйсезлек өчен көрәшүче халыкларга ихтирам белән карыйбыз, аларны яклыйбыз. КПСС тынычлык һәм социаль прогресс өчен көрәштә халыкара коммунистлар һәм эшчеләр хәрәкәте көчләрен барлык чаралар белән ныгытуга юнәлдерелгән эзлекле курска һәрвакыт турылыклы.

Партиянең максатлары ачык һәм изге. Алар КПССка хезмәт ияләренең иксез-чиксез ышанычын яуларга мөмкинлек бирде. Партиянең көче — халык белән бердәмлектә. Халыкның көче — партия белән бердәмлектә, аның җитәкчелегендә.

Үзенең бөтен тормышын партиягә, совет халкына турылыклы хезмәт итүгә багышлаган Константин Устинович Черненко коммунистлар, барлык совет кешеләре хәтерендә мәңге калыр. Ул безнең хәтеребездә марксистик-ленинчыл идеяләрне ялкынлы пропагандалаучы, игътибарлы һәм таләпчән җитәкче, хезмәт кешеләренең ихтыяҗларына һәм таләпләренә сизгер һәм игътибарлы кеше буларак кереп калыр.

КПСС Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы, СССР Министрлар Советы коммунистларның, барлык совет кешеләренең, югары аңлылык һәм оешканлык күрсәтеп, тагын да зуррак энтузиазм һәм фидакарьлек белән эшләячәкләренә, Ватаныбызның экономик һәм оборона куәтен ныгытачакларына, Бөек Октябрь байрагын лаеклы алып барачакларына ныклы ышаныч белдерәләр.

## Рөстәм Мингалим

### САГЫНУ

Еллар елга охшамый шул,
язлары — үзгә тора.
Үзәкләр өзелә тора —
кемнәрдер сагындыра.
Сагындыра Тукайларың,
Җәлилләр — истә тора.
Гел тулы сагыну дәрьясы
һәр вакыт чиста тора.
Истә Шәрәф, истә Әнвәр —
сагындыра югалган...
Якты безнең күзләребез —
сагынуларда юганга.
Такташны бик сагынганда,
Туфанга карар идек,—
Инде Туфан сагындыра...
Яра күп... Ярар инде,
кемнәрдер безгә карыйсы —
кемнедер сагынганда.
Пакь яшәдек, ак китәбез,
коенып сагынуларда.
Коенып сагынуларда!

Тукайның 100 еллыгына

# УРАЛЬСКИДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ




Уральск (Җаек) шәһәрендә Г. Тукай укыган мәдрәсә хуҗасы һәм мөдәррисе Мотыйгулла Төхфәтуллин йорты (хәзерге Орджоникидзе урамы, 57). Шагыйрь биредә бик еш булган.

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

**М. Б. Иксанов,**

Казахстан Компартиясенең Уральск өлкә комитеты беренче секретаре

# ЗУП-ЗУР ТУКАЙ БУЛДЫМ...

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай үзенең малай чагын, мәктәптә укыган елларын «күңелдән сагынып» язган «Гомер юлына керүчеләргә» исемле шигырен мондый сүзләр белән тәмамлый:

Нигә мин кечкенә-Апуш түгел, зуп-зур Тукай булдым?

«...Зуп-зур Тукай булдым...» Әлеге сүзләрне без, уральскилылар, аеруча горурлану белән укыйбыз, чөнки ул Тукай буларак нәкъ менә Җаекта яшәгән чорда таныла башлый. «Кереп киттем гомер юлына», «Гомер итмәк» димәкнең мәгънәсене аңладым чынлап», «Мин дәү кеше булдым», дип әйтерлек рухи нигез барыннан да элек житлеккәнлек юлында унберунике ел (!) гомер кичергән шушы калада салына. Кыскасы, ул биредә иҗтимагый-политик карашларын шактый дәрәҗәдә камилләштергән көрәшче шагыйрь булып өлгерә.

«...Мең төрле газаплар эчендә,— дип искә ала шагыйрь,—тәмам унсигез көн булды дигәндә, кичкә таба Җаекка барып кердек». Шушы юлларны укыганда, Уральскиның үткәне күз алдына килә. Узган гасыр ахырында ул нинди булган?

Элек-электән Мәскәү дәүләтенең көнчыгыш чиге булып саналучы шушы төбәк тора-бара рус һәм казах халыкларын якынлаштыручы аренага әверелгән. Һәм 250 ел элек бу якларда мондый ант сүзләре тикмәгә генә яңгырамагандыр: «Бергә гомергә!..» Билгеле булганча, 1731 елның 10 октябрендә егерме җиде аксакал әлеге төбәкне Россиягә ирекле рәвештә кушу турындагы актка кул куялар һәм шулай итеп Казахстанның бөтен өлешен дә Рус дәүләтенә кушарга юл ачалар. Әлеге тарихи вакыйга халкыбыз тормышының яңа сәхифәсен ача, һәм без авыр-газаплы юлда ясалган шушы борылышның үзебез яшәгән төбәктә башлануы белән хаклы горурланабыз. Үзенең язмышын рус халкы һәм күпмилләтле илебездәге башка халыклар белән ирекле рәвештә бәйләп, казах халкы ленинчыл идеяләр белән яктыртылган бердәнбер дөрес юлны сайлады. Әмма царизм шартларында фән һәм культура бик тә акрын үсте. Самодержавие колониаль өлкәләрнең экономикасын һәм культурасын үстерү белән кызыксынмады. Һәркемгә дә билгеле: Бөек Октябрьгә кадәр Казахстан ярлылык, кайгы, рәхимсез кысу һәм башбаштаклык төбәге, чын мәгънәсендә «халыклар төрмәсе»нең бер почмагы булды.

Казахстанда яшәүче хезмәт иясе халкы, рус һәм башка халыклар белән иңгә-иң торып, күп еллар буе самодержавие-крепостнойлык строена, феодаль деспотизмга каршы көрәштеләр. Рус һәм казах халыклары язмышының тарихи уртаклыгы Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында, Көнбатыш һәм Төньяк-көнбатыш Казахстан, Урал һәм Идел

буендагы зур-зур районнарны колачлаучы восстаниедә катнашкан чакта аеруча ачык күренә. Феодаль изүгә һәм царизмның колониаль кысуына каршы көрәш тарихына И. Тайманов һәм М. Утемисов җитәкчелегендәге казахлар восстаниесе дә (1836—1837) данлы сәхифә булып язылды.

Көнбатыш Казахстанның Россиягә орынып торуы, рус халкының күренекле вәкилләре белән даими аралашу безнең якларда алдынгы революцион фикернең киң таралуына китерә. Шушы йогынты нәтиҗәсе буларак, 1903 елда Уральскида беренче политик стачка була, марксистик түгәрәкләр оештырыла. Әлеге түгәрәкләр беренче рус революциясеннән соң, Казахстанда беренчеләрдән булып, РСДРПның Уральск оешмасына әверелә.

Алдынгы рус культурасының шифалы йогынтысы казах халкының Россиягә якынаюын хуплап җырлаган данлы уллары Чокан Вәлиханов, Ибрай Алтынсарин һәм Абай Кунанбаевның иҗтимагый-политик карашларын һәм иҗатларындагы идея-эстетик юнәлешләрен формалаштырырга ярдәм итте. Уральскилылар каһарман-шагыйрь Махамбет Утемисов, композиторлар Курмангазы Сагырбаев, Динә Нурпеисова, Мухит Даулеткерейның якташларыбыз булуы белән дә хаклы горурланалар.

Безнең яклар төрле елларда булып киткән һәм казах халкының тормыш-көнкүрешен өйрәнүгә лаеклы өлеш керткән классик язучылар И. Крылов, А. Пушкин, В. Даль, В. Жуковский, Л. Толстой, В. Короленко, Т. Шевченко, атаклы җырчы Ф. Шаляпин, галимнәр П. Паллас, В. Татищев, А. Левшин, П. Семенов-Тяньшанский һәм башка бик күпләрне яхшы хәтерли. Һәм шулар арасында һәрбер халыкка да якын Тукаебыз да бар.

Кечкенә малай гына булуына карамастан, күпме «какканны вә сукканны» күтәргән Апуш Уральскида әтисенең сеңлесе Газизә Зәбирова (Госманова) канаты астына килеп эләгә. Ятим балага, ниһаять, бәхет елмая. Әмма рәхәтлекләр озакка бармый. Сәүдәгәр гаиләсендә кояш акрынлап сүрелә. Җизнәсе Галиәсгар кечкенә Габдулланы үзенең варисы итеп үстерергә омтыла, ә малай мондый дәвамчы булырга бик үк ашкынып тормый. Шулай итеп Галиәсгар бай белән «туры Тукай» арасындагы мөнәсәбәтләр бозыла башлый. Араның начараюын башка сәбәпләр дә көчәйтә. «Җизнәсенә ияләшә» алмаган малай тора-бара бөтенләй артык кашыкка әйләнә. Һәм Габдулла мәдрәсәдә торып укырга мәҗбүр була.

Узган гасыр ахырында Уральскида өч мәдрәсә «гыйлем нуры» тараткан: «Рәкыйбия», «Гайния» һәм «Мотыйгыя». Шулар арасында соңгысы күпмедер дәрәҗәдә «заманча» булуы белән аерылып торган. Биредә өч еллык рус класслары ачылу, шәкертләргә шәрык әдәбияты белән таныштырырга күбрәк мөмкинчелек бүлү әнә шул хакта сөйли. «Мотыйгыя» мәдрәсәсенең мондый классына Габдулла да бик теләп йөри, рус әдәбиятын, тарих фәнен өйрәнә. Малай алдында яңа дөнья ачылып киткәндәй була. Шулай да иске тәртипләр буенча эшләүче схоластик мөселман школасы Апушның яктыга сусаган күңелен канәгатьләндерә алмый. «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» исемле шигырендә ул үзенең «белем эстәү» елларын түбәндәгечә искә төшерә:

Күп яттык без
Мәдрәсәдә,
Аңламадык
Бернәрсә дә;
Селкенмәдек
Таш төсле без,
Җилбер-җилбер
Җил бәрсә дә.

. . . . . . .

Ашсыз-сусыз,
Утын-шәмсез
Тар җирләрдә
Яттык сасып;
Гаетләрдә,
Төш кургәндә,
Коендык без,
Бозга басып...

«Габдулла әфәнде мәдрәсәдә вакыт гаять фәкыйрьлек берлә гомер кичерде...» Ятим шәкертнең авыр тормышы бүтән мәдрәсәдә укыган Г. Кариевның әнә шундый сүзләрендә дә раслана. Шулай да «Кырлай шәкерте» югалып калмый: бай балаларына дәресләр бирә, репетиторлык, язу-сызу белән шөгыльләнә, су ташучы, мәдрәсәдә каравылчы булып эшли һәм шулай итеп яшәр өчен тотыла торган чыгымнарның очын-очка ялгап барырга тырыша.

Мәдрәсәдә укыган елларда ук Габдулла халык җырларын җыеп өйрәнә башлый. Үзенең сабакташлары һәм хәтта укытучылар алдында ул халык җырларын оста башкаручы буларак таныла. «Халык әдәбияты» исемле мәкаләсенең ахырында ул үзенең җыр яратуын болай искәртеп уза: «Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем. Мәдрәсәдә халфәләр, кече атна кичләрендә, бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә дә мине онытмыйлар иде. Мин, самавыр артына гына утырып, алар кушкан көйләрне җырлап бирә идем, шул җырлавым бәрабәренә халфәләрдән берәр уч симәнкә һәдия[1] кыйлына иде. Мин, кулымдагы симәнкәне беткәнче яргач, тагын җырлый идем.

Мәдрәсәдүк мине җырчы диләр иде».

«Ашсыз-сусыз, утын-шәмсез тар җирләрдә» интексә дә, Габдулланың күңел кошы олы дөньяга чыгарга омтылып яши. Замандашлары искәртүенчә, ул мөстәкыйль фикер йөртә белүче һәм тотрыклы аек карашы белән башкалардан нык аерылып торган, мәдрәсәдә иң белемле һәм зирәк шәкерт булып саналган.

XIX гасыр ахырында Уральскида А. Пушкин исемендәге халык йорты ачыла. Биредә китапханә һәм уку залы да була. Әлеге йортта еш кына спектакльләр дә күрсәтелгән, төрле язучыларның, аерым алганда, А. Пушкин, Н. Гоголь, Н. Некрасов, В. Жуковский, Г. Успенский юбилейлары да билгеләп үтелгән. Пушкин йортына Габдулла да йөргән, әдәби кичәләрнең һәм лекцияләрнең берсен дә калдырмаган, рус классиклары иҗатын өйрәнгән.

Үзенең истәлекләрендә Г. Кариев бөек якташын болай күз алдына китерә: «...Рус әдәбиятыннан Лермонтов һәм Пушкинның әсәрләрен бик яратып укый иде. Мин алар мәдрәсәсенә барган вакытта рус китапларыннан ике калын книга күрә идем: ул Лермонтовның һәм Пушкинның мәҗмугаи асаре икән. Мин моны соңыннан гына белдем».

Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов әгәр булса кояш,
Ай кеби, нурны алардан икътибас[2] иткән бу баш...

«Хәзрәти» Пушкин, Лермонтов, Жуковскийга мәхәббәт, күренә ки, Уральскида яшәгән чакта ук башланган. Ә инде 1897—1898 елларда Габдулла Тукай рус язучылары әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү эшенә ныклап тотына. Уральскида 1906—1907 елларда чыккан «Әлгасрел-җәдит» журналында «Мәҗмугаи мөфидә» («Файдалы җыентык») исеме астында аның проза белән язылган 65 мәсәле басыла. Әлеге җыентыкка кертелгән әсәрләрне — И. Крыловтан ирекле тәрҗемәләрне ул нәкъ менә шушы елларда әзерли башлый. Пушкин йортында оештырылган лекцияләрнең берсендә «шагыйре мәшһүр Кольцов» иҗаты белән дә якыннан таныша. «Мужик йокысы» шигыре (1905) нәкъ менә шушы әдипнең әсәренә нигезләнеп языла. Шулай ук ул А. Пушкин әсәрләрен дә, ирекле тәрҗемә итеп, татар телендә яңгырата: «Пушкиннан», «Кемне сөяргә кирәк?», «Мәхбүс», «Вак-төяк», «Мәҗлес», «Җил», «Алтын этәч»...

Реакцион катлауларның каршылык күрсәтүенә карамастан, 1906 елның ноябрендә милләт яшьләре Пушкин йортында әдәби-музыкаль кичә үткәрүгә ирешәләр. Шушы уңайдан, кичәне оештыруга «сыртлары берлә» торган адәмнәргә җавап итеп, шагыйрь «Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләремезгә» исемле шигырь һәм «Әдәбият ахшамы, яки литературно-музыкальный вечер» исемле мәкаләсен язган.

---

[1] һәдия — бүләк.

[2] Икътибас — файдаланып язу.

Революцион күтәрелеш елларына кадәр үк Габдулла Тукай алдынгы карашлы кешеләр белән аралашырга омтыла. «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыган вакытта ул, мәсәлән, Истанбул университеты студенты Габделвәли Әмрулла белән таныша. Төрек солтаны Габделхәмитнең аяусыз режимына каршы юнәлдерелгән хәрәкәттә катнашканлыгы өчен кулга алыну куркынычы тугач, Габделвәли 1902 елда Төркиядән Россиягә качарга мәҗбүр була һәм ничектер Уральскига килеп эләгә. Әдәбиятны ярату аларны дуслаштыра. «Шул шәкерт берлә алар җәй буе бергә җырлап, бергә йөреп, ач булсалар да, рәхәт, хозур үткәргәннәр» (Г. Кариев). Мәдрәсәдә кайбер шәкертләр тарафыннан кагылып-сугылып йөртелгән Габделвәли дусты Габдуллага төрек һәм француз әдәбиятлары буенча «дәрес биргән» һәм, әлбәттә, үзенең шигырьләрен дә укыган.

Якынлашып килүче революцион вакыйгалар җиле Уральск мәдрәсәләренең дә караңгы тәрәзәләренә кагылган. Алдынгы идеяләр белән канатланган шәкертләр «милләт өчен сынмас терәк» булган татар яшьләренең бөтен гайрәт-көчен буып ятучы үлек схоластикага каршы күтәреләләр. Күп кенә шәкертләр мәдрәсәдән куыла, ә бүтәннәре «Хуш! хуш! хәзрәтләр, без киттек», дип, «Мотыйгыя»ны үзләре үк ташлап чыгалар. Шулай ук Габдулла да мәдрәсә белән араны өзә һәм «Уралец» газетасы типографиясенә наборщиклыкка өйрәнчек булып керә. (Хәзер элеге типография бинасында бөек татар шагыйре Г. Тукайның хәреф җыючы булып эшләгәнлеге турында сөйләүче мемориаль такта тора.) Әлеге матбагада Уральск социал-демократлар оешмасының революцион рухлы эшчеләре белән аралашу шагыйрьгә иҗтимагый-политик аңын үстерергә ярдәм итә. Биредә ул хәреф җыю буенча шактый тәҗрибә тупларга өлгергән Александр Гладышев белән таныша, аннан шушы һөнәрнең серләрен өйрәнә. Уральскиның мөхтәрәм эшчесе коммунист А. К. Гладышевның истәлекләрендә мондый юлларны укыйбыз: «Өлкән иптәшләрнең кушуы буенча, мин һәм Апуш кәгазьләр, прокламацияләр, басылган революцион җырлар, мәсәлән, «Старый вахмистр» листовкасын, «Варшавянка», «Смело, товарищи, в ногу»... һ. б. ларны тараттык.

Тукай әлеге революцион җырларның бөтенесен дә белә иде һәм башкаларны да өйрәтте. Безне җыелышларга да үткәрделәр, әмма хәлиткеч тавышны бирү хокукына ия булмаган хәлдә. Безгә укырга әдәбият бирәләр иде.

...Без Тукай белән Зур Михайловская урамында һәм башка урыннарда прокламацияләр ябыштырдык. Якшәмбе алдыннан без кармак салучыларның яраткан урыны — Анисимов күлләренә бара идек. Биредә слесарьлар, итекчеләр, гомумән, мастеровойлар була. Алар янына листовкалар куеп китәбез; җантимерләр (полиция) күренми, ә балыкчылар, эшнең ни икәненә төшенсәләр дә, алай ук куркыныч түгелләр: эшче халкы сатмаячак!»

Беренче рус революциясе елларында Габдулла Тукай революцион демонстрацияләрдә һәм митингларда катнаша. Социал-демократлар оешмасы 1906 елның 1 маенда Ханская рощада (хәзер М. Горький исемендә) Уральск эшчеләренең беренче маевкасын оештыра. Майның беренче көне эшләми торган көн дип игълан ителә. Иртәгесен шәһәрнең 300 ләп эшчесе, укучы яшьләре һәм алдынгы карашлы интеллигенция вәкилләре рощага таба юнәлә. Алар арасында Габдулла да була. Митингта җирле большевиклар һәм РСДРПның Саратов комитеты вәкилләре речь белән чыгалар. (Уральск эшчеләренең беренче маевкасы булган урында 1956 елда безнең як скульпторы Х. Шәмсетдинов проекты буенча обелиск куелды.)

Революция дулкыны Г. Тукайның «телен чишеп» җибәрә. Шушы елларда (1905 ел, ноябрь) Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин наширлегендә «Фикер» газетасы чыга башлый. Типографияне мөхәррир үзенең ишегалдындагы ике катлы бинага урнаштыра. Казаннан хәрефләр кайтарта һәм шуннан ук хәреф җыючы Сафиулла Насыйбуллинны чакыра. «1905 ел-

да мин Уральскида матбага алып, татарча газеталар чыгарырга уйлагач,— дип яза К. Мотыйгый,— Габдулла әфәнде, үзенең үтенүе буенча, минем матбагама хәреф тезәргә (наборщиклыкка) керде...» «Фикер» газетасы чыга башлагач, Габдулла корректор итеп билгеләнгән.

Бераз вакыт үткәч, шушы ук типографиядә иҗтимагый-политик «Әльгасрел-җәдит» һәм юмористик-сатирик «Уклар» журналлары чыга башлый. Шагыйрь иҗатына, ниһаять, мәйдан ачыла. Шигырь, мәкалә һәм фельетоннарны язып кына өлгер. Әлеге газета һәм журналларның әчтәлеген сугышчан демократик максатка юнәлдерү өчен шагыйрь үзенең көчен дә, вакытын да кызганмый. «Уклар» журналын ул аеруча якын күрә, күп кенә саннарын үзе әзерли һәм редакцияләп үзе дөньяга чыгара.

1906 ел... Шушы елда Г. Тукай иҗаты аеруча киң колач ала. Шигырьләр, публицистик әсәрләр агылып кына торалар. Унтугыз яшьлек шагыйрь җаны-тәне белән халык бәхете өчен көрәшүен дәвам иттерә: «Бөтен уем кичен дә, көндез дә сиңа гына кагылышлы, милләтем. Синең саулык — минем саулык, синең авыру — минем авыру».

Карагруһчыл һәм либераль буржуазия вәкилләре, Тукайның сугышчан каләме, «Фикер» һәм «Әльгасрел-җәдит»тәге «тешле-тешле» чыгышлар белән килешеп тора алмыйча, алдынгы карашлы кешеләргә каршы агу чәчә башлыйлар. Нашир һәм мөхәррир К. Мотыйгый өстеннән алар донослар язалар, прогрессив газета һәм журналларны яптырырга йөриләр. Мәкерлек үзенекен эшли: Камил, әтисе Мотыйгулла хәзрәт белән берлектә, судка бирелә һәм бераздан соң ул матбага тоту хокукыннан мәхрүм ителә. Типография шәһәр байларының берсе Мортаза Гобәйдуллин тарафыннан сатып алына. Әмма газета һәм журнал чыгу озакка бармый — 1907 елның маенда алар бөтенләй туктап калалар.

Төхфәтуллиннар соңыннан шактый кызыклы язмыш кичерәләр. Аларны хөкем итү карары юкка чыгарыла, әмма Камилгә Уральскида яшәргә рөхсәт ителми. Шуннан соң ул җырчы булып танылa, Россиянең күп кенә шәһәрләрендә чыгыш ясый. Концертларда Тукай сүзләренә язылган җырларны аеруча яратып башкара. Әтисе Мотыйгулла исә мәдрәсәдә дәресләр бирү һәм мәчеттә хезмәт итү хокукларыннан мәхрүм ителә. Шулай да ул соңрак татар кызлары өчен кечкенә мәктәп ачуга ирешә. Шушы урында Мотыйгулла кызының, ягъни Галия Кайбицкаяның атаклы җырчы дәрәҗәсенә күтәрелүен дә әйтеп үтәргә кирәк. Ә Камилнең улы Хәмит Төхфәтуллин унбиш яшендә Чапаев дивизиясенә Совет власте өчен көрәшергә китә.

Иҗат мәйданының тараюы һәм ипилек акча эшләргә мөмкинлек калмау Габдуллага бер-бер артлы өстәмә кыенлыклар китерә. Революция дулкыны сүнүгә якынлаша. Дәүләт думасы таратыла. Матбугат һәм культура «үсеше»нә күзәтчелек итү тулысынча полиция һәм жандармерия карамагына күчерелә. Берсеннән-берсе күңелсезрәк вакыйгалар шагыйрь күңелендәге җирсү сагышын тагын да тирәнәйтеп җибәрә. Уральск кебек кечкенә шәһәр тормышының чикләнгән булуын ул инде ап-ачык итеп аңлый башлый. Шагыйрьлек талантына нык ышанган Габдулла яңа дәрт белән зур милли культура учагына тартыла.

Айрылып китсәм дә синнән, гомеремнең таңында мин,
И Казан арты! сиңа кайттым сөеп тагын да мин.
Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл хиссеми,
Тарта торгач, куймады, кайтарды ахыр җисмеми.

1907 ел, сентябрь. Унике ел «гомер иткән шәһәр» белән аерылышыр мизгел якынлаша. Җаекка «ябык чана зинданында, мең төрле газаплар эчендә» килгән ятим Апуш дәртле, моңлы, нурлы Казанына, зуп-зур Тукай булган хәлдә, татар халкының бөек Тукае дәрәҗәсенә күтәрелергә кайтып китә.

* * *

Уральскида яшәгән елларда, билгеле, Габдулла күп кенә авырлыклар кичерә. Зуп-зур Тукай булу җиңел генә бирелми. Шагыйрьнең канын агуларга омтылучы бәндәләр дә шактый күпләп җыела. Апасына язган бер хатында аның мондый сүзләр әйтүе бик табигый: «Казанда тору күңелле. Уральск бик сирәк искә төшә...» Шулай да тора-бара шагыйрь күңеле йомшара, «Җаек университетлары»н ул үзенчә бәһали башлый. «Язга Уральскига кайтып, андагы хәлләрне карап килергә дә исәбем юк түгел...» Хатларында ул әнә шундый ниятен дә белдерә. Хәтта ки «чабата, ыштыр»ына кадәр сагынылган туган җиренә кайту турындагы «Пар ат» шигырендә мондый юллар дуслары һәм кардәшләре белән еракта калган Уральскига да күпмедер кагыла төсле:

> Сездән айрылып, туганнар! — җайсыз, уңайсыз тору;
> Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш, айсыз тору.

Тукайның икенче туган җире булган Уральск үзе дә шактый катлаулы язмыш кичерде.

Казах халкы Совет властен бөтен йөрәге белән кабул итте һәм аны башка тугандаш халыклар белән иңгә-иң торып яклады. Казахстанда халык власте иң элек безнең төбәктә, төгәлрәк әйткәндә, Урдада урнашты. Моның белән без хаклы горурланабыз. Шушында ук А. Джангильдин командалыгында беренче үрнәк казах кавалерия полкы оештырыла. Гражданнар сугышы фронтларында әлеге атлы полкның батырларча көрәшүе һәркемгә яхшы билгеле. Гомумән, өлкәдәге коммунистлар һәм барлык хезмәт ияләре Совет властен урнаштыру һәм ныгыту буенча күрсәткән фидакарьлекләре белән гражданнар сугышы тарихының данлы сәхифәсенә кереп калдылар. Советлар республикасы дошманнарына каршы көрәшкән легендар чапаевчыларның каһарманлыгына иң беренче чиратта безнең яклар шаһиттер. Революцион көрәш елъязмабызда Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләтенең күренекле эшлеклеләреннән С. М. Киров, В. В. Куйбышев, М. В. Фрунзе һ.б.ларның исемнәрен аеруча горурлану белән укыйбыз.

Бөек Ватан сугышы елларында Урал ягы Сталинград фронтының якын тылы булды. Әлеге төбәктә тугандаш халыклар вәкилләренең Ватан-ана чакыруына бердәм рәвештә сугышчан һәм хезмәт батырлыклары белән җавап бирүе, ирексездән, Г. Тукайның түбәндәге шигъри юлларын искә төшерә:

> Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? —
> Без туган бер җепкә бергә тezkәлеп.
> Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
> Без тынычта аттан артык эшлибез.

Ватанызбызның иң югары сугышчан бүләге 35 каһарман якташыбызга бирелде. Советлар Союзы Герое исеменә лаек булганнар арасында, Көнчыгышның беренче шундый хатын-кызы буларак, Маншук Маметова да бар.

Сугыш елларында шәһәр читендәге Дарьинское авылында бөек рус совет язучысы М. Шолоховның гаиләсе яшәде. Соңыннан Михаил Александрович бирегә утыз ел дәвамында кайткалап йөрде, шушы авылда «Күтәрелгән чирәм» әсәренең яңа бүлекләре өстендә эшләде.

Безнең якларның героик үткәне һәм данлы бүгенгесе бик күп күренекле язучыларның игътибарын үзенә тартып тора. Бирелә К. Федин, Д. Фурманов, В. Иванов, А. Толстой, Л. Сейфуллина, А. Гайдар булып китәләр. Көнбатыш Казахстанда булу соңыннан аларның иҗатларында да чагыла. Менә шундый бәрәкәтле төбәктә Хәмзә Есенжанов, Таир Жароков, Жубан Мулдагалиев кебек күренекле язучыларның тууын табигый күренеш буларак кабул итәсе килә.

Сугыштан соңгы елларда өлкә партия оешмасы экономиканы һәм куль-

тураны үстерү юнәлешендә зур эш башкарды. Чирәм җирләрне үзләштерү авыл хуҗалыгын кызу темплар белән үстерергә ярдәм итте. Бүгенге көндә өлкәдәге промышленность предприятиеләре һәр өч көн саен революциягә кадәр бер ел дәвамында чыгарылган кадәр продукция җитештерәләр. Капиталь төзелеш күләмнәре күзгә күренеп үсте. Хәзер шәһәр һәм авылларыбызның архитектур һәм социаль-культура йөзе бөтенләй яңача төс алды. Әлеге яңарыш Уральск мисалында аеруча ачык күренә. Революциягә кадәрге аулак провинциаль кала хәзер республика өлкәләренең иң матур үзәкләреннән берсенә әверелде.

Хезмәт ияләренең үсә баручы рухи ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү бурычын өлкә партия оешмасы һәрвакыт игътибар үзәгендә тотарга омтыла. Өлкәдә культура учреждениеләренең киң челтәре эшли: драма театры (республикада иң өлкәннәреннән санала), филармония, 15 халык коллективы, 525 клуб, 522 китапханә, 4 музей, 6 культура һәм ял паркы... Күптән түгел шәһәребезнең Ленин проспектында заманча комплекс — Матбугат йорты калкып чыкты. Биредә «Орал онири» һәм «Приуралье» өлкә газеталары редакцияләре, шулай ук Г. Тукай исемен йөртүче өлкә типографиясе урнашты.

КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш К. У. Черненко СССР Язучылар союзы идарәсенең юбилей Пленумында ясаган докладында болай диде: «Совет культурасы бүген илебездәге барлык милләтләр һәм халыклар тарафыннан тудырылган рухи кыйммәтләрнең органик эретмәсе буларак гәүдәләнә. Шуңа күрә дә язучы һәм художникның, музыкант һәм архитекторның үз халкы хәзинәсендәге күпгасырлык культура традицияләренә таянырга, үз республикасы тормышын тирәнрәк һәм тулырак чагылдырырга омтылуы бик аңлашыла. Шуның белән бергә, художество практикасы ышандыра: милли культура башка культуралар белән тыгызрак бәйләнгән саен, ул тугандаш халыкларның интернациональ әһәмияткә ия булган рухи һәм художество тәҗрибәсе үзенчәлекләрен көчлерәк үзләштерә, тизрәк һәм нәтиҗәлерәк үсә. Шуның белән ул барлык совет халкы, бөтен җәмгыятебезнең рухи тормышын баетуга зуррак өлеш кертә».

Тугандаш халыкларның һәрберсенә дә якын булган интернациональ рухлы татар шагыйре Габдулла Тукай мисалында без мондый иҗади хезмәттәшлекнең классик үрнәген күрәбез.



# Хисам Камалов

# БЕЗНЕ ӨЙДӘ КӨТӘЛӘР

РОМАН

## Беренче бүлек

### 1



Мең тугыз йөз кырык дүртенче елның көзе иде. Балтик буе фронты гаскәрләре Латвия җирләрен азат итә-итә алга бара. Күптән түгел генә латышларның иң зур каласы Рига азат ителде. Әмма Рига өчен сугышта дошман шул чаклы нык каршылык күрсәтте, хәтта күпне күргән азау сугышчыларның да моңа исләре китте. Чөнки моннан көньяктарак безнең гаскәрләр Германиянең үз җирләренә якынаеп киләләр һәм бик уңышлы алга баралар иде. Гади исәп буенча, фриц үз оясын саклауны күбрәк кайгыртырга тиеш югыйсә, ә юк, биредә ни өчен үлгәнен дә белми сугыша! Сәбәбе нәрсәдә? Фронт халкы телендә шул канлы бәрелеш кенә хәзер. Немец мәкерлеген җитәрлек татыган кешеләр дә, Риганы алганда күп кан коелуга исләре китеп, баш селкиләр.

Һаман бер нәрсәне сөйлиләр: дошман шәһәрне тимер-бетон ныгытмалар белән уратып алган булган. Сажин саен дзот та дзот. Аларга пулеметлар куелган, танкка каршы фаустниклар утыра. Безнекеләр шуны алдан белеп бик көчле артхәзерлек ясыйлар, дошман позициясенең тәмам асты-өскә килгәч, һөҗүмгә укчылар күтәрелә. Әмма дүрт-биш адым китәргә өлгермиләр, немец пулеметлары ата башлый, танкларны көчле туплар туктата, һөҗүм тончыга. Бераздан безнең бомбардировщиклар яңадан эшкә керешә. Аннары бөтен көпшәләрдән атып, немец ягын тетәләр. Ут нокталарын берәм-берәм юк итеп бетерәләр. Шушы хәстәрдән соң, укчылар траншеяларыннан чыгып алга китә. Тик илле-алтмыш адым үтүгә, немецның әллә ничек исән калган ут нокталары җанланып, тагын ата башлый. Укчылар җиргә ятарга мәҗбүр булалар. Авыр тупларны, бомбовозларны тагы эшкә кушарга туры килә. Җир тетри, гел селкенеп тора, судагы көймә кебек чайкалып-чайкалып китә. Дошман ягын кара төтен болыты каплый. Анда бер җан иясе дә калмагандыр шикелле тоела: «Җитте, алга, бөркетләр!» — дигән әче команда тавышы яңгырый. Укчылар, җирдән торып, алга таба иелә-иелә атлый башлыйлар. Ләкин каһәр генә суккан икән, немец тагын ут яудырырга тотына. Нәрсә

бу? Хикмәт нәрсәдә? Укчыларның тагын жиргә елышудан бүтән чаралары калмый... Безнекеләр һөҗүмне туктатырга ярамаганлыгын белеп, дошманга бер сәгать тә тын алырга бирмиләр, һаман атакалап торалар. Көне буе шулай... Бары караңгы төшкәч, алтынчы тапкыр атакага күтәрелгәч кенә укчылар шәһәр кырыеның беренче йортларына барып ябышалар һәм чигенмиләр. Аннары һәр йорт өчен көрәш атна буе дәвам итә.

Ә шәһәрнең Юрге бистәсе елганың теге ягында. Елганы кичү сират күперен кичүгә әйләнә. Дегеттәй куе кара төн, яр кырыенда миналар шартлап тора, пулялар күче сызгырып-сызгырып уза. Немец пулеметының утлы тамагы күзгә чалынып китә. Ә бу якта сугышчылар елганы кичәр өчен көймәләргә төяләләр. Бик шыпырт кына: «Хәерле юл, сау булыгыз!» — ди командир, ике көймәне ярдан этеп җибәрә-җибәрә. «Юк, иптәш командир, бәхил булыгыз!» — дип пышылдыйлар сугышчылар. Нинди куркыныч тәмугка керүләрен алар сизеналәр һәм аңлыйлар. Көймәләр елга уртасынарак житкәч, немец су өстенә парашютлы ракеталар асып куя. Яп-якты. Көймәләр уч төбендәге кебек. Шунда көймәләргә туп-туры миналар килеп төшә...

Яр буендагы окобыннан моны күзәтеп торган командир ике куллап башына тотына һәм яраланган кеше кебек ухылдый, тыпырдана, тар траншеяда бәргәләнә-суккалана. Ләкин нишләмәк кирәк. Приказны үтәми мөмкин түгел. Калтыранган куллары белән телефонга тотынып, тупчыларга шалтырата, ут нокталарының цельләрен әйтә. Ул арада безнең ерактан ата торган туплар кирәкле төшне тетәргә, астын-өскә китерергә тотына. Шартлау утлары гына төн караңгылыгында зилзиләнең кай төштә икәнен белгертеп тора... Төн урталарында командир сугышчыларны тагы көймәгә төйи. Үзенчә дәртләндерә, саклану әмәлләрен өйрәтә. «Инде исән булыгыз!» — дип ишкәкләрен бирә. Көймәдәгеләр тыенкы гына: «Юк инде, иптәш командир, бәхил бул! Әллә күрешәбез, әллә юк, эх!» — диләр һәм ишә-ишә караңгылыкка кереп китәләр. Елга уртасына чаклырак исән-сау баралар, ләкин немец бик уяу, яктыртып кына тора. Диңгездәге эсминецлардан авыр снарядлар белән ата. Аларның туплары шартлаганда су бер ярыннан икенче ярына кадәр һавага эленеп куелган кебек өскә күтәрелә, ул мәхшәрдә йомычка сыман гына калган көймә ничек чыдасын!

Тылдан шалтыраталар: елганы кичтеңме әле, шуны һаман хәл итә алмыйсың, нигә йоклыйсың? Командир аңа диңгездәге эсминецлар турында әйтә. Шуларны бастырмыйча торып кичү һич мөмкин түгел, дип ышандыра. Ярый әле хәлне аңлады, әйбәт, реалист кеше икән, дип сөенә командир, үзенең начальнигы турында уйлап.

Ике сәгатьләп вакыт уза. Төнге бомбардировщиклар диңгез пиратларына бомба ташлап кайталар. Командир таң алдыннан тагы бәхет сынап карамакчы була, сугышчылар көймәгә төялә. Үзләре артыннан элемтә чыбыгы суза-суза баралар, берәздән кара шәүләләрен куе томан кебек эңгер-меңгер йота. Тып-тын, эх, уңышлы гына булсачы! Берәздән сугышчылар исән-сау теге ярга чыгып житүләре турында телефоннан әйтәләр. Йа алла, дип жиңел сулап куя командир. Әмма ярты сәгать үтми, немецлар боларны чолгап алалар. Кул сугышында сугышчылар барысы да батырларча һәлак була.

Өч төн буе шул хәл кабатлана. Тик дүртенче төндә генә зур көймәгә утырып чыккан сугышчылар ярга чыгып, искәрмәстән дошман дотына бәреп керә һәм шунда ныгып калырга ирешә. Аларга яңа көчләр килеп житә, шулай һөҗүм мәйданын киңәйткәннән-киңәйтә баралар. Ниһаять, немецлар Юрге бистәсеннән бәреп чыгарыла.

Бу төштә елганы кичү Днепрны кичүгә караганда берничә мәртәбә канлырак һәм аяусызрак булды, диләр исән калганнар. Алар бергә Днепрдан китерелгән данлы сугышчылар булган икән. Гаять зур тәҗрибә туплаган сугышчы, командирларның шушы су барьерын артык күп көч куеп кына жиңә алуы һәм моңа хәтле булган сугышлар немецның үтә зәһәрләнүенә ачык мисал иде. Шуңа бу хакта солдат арасында сүз күп йөрде.

Немецлар Ригадан чигенгәч, Курляндия дип атала торган җиргә, диңгез яры буена кереп бикләнделәр. Моның чын мәгънәсендә бикләнү булуы бераз соңрак беленде. Безнең частьлар, әүвәлгечәрәк исәпләп, бу группировканы тәмам бетереп ташларга дигән ният белән һөҗүм башлаганнар иде. Бернечә тарафтан төшеп, өч-дүрт көн буе фрицны дөмбәсләделәр, әмма шуңа карамастан дошман дүрт чакрымнан ары чигенмәде. Оборонаны өч катлы итеп корган булып чыкты. Кая ул, әүвәлгедәй оборонаны өзеп, 10—15 километр алга китүләр, бетте ул хәзер.

Әйтергә кирәк, бирегә Ленинград яныннан чигенгән һәм Эстония, Латвиядән сөрелгән гаскәрләр килеп тупланган. Болар гитлерчыларның бик атаклы кадровый частьлары. Кораллары бик шәп һәм бик күп. Әмма немецлар, бетәселәрен эчтән сизенеп, үзләрен дәртләндерергә тырышалар. Кай көннәрне алгы сызыкта динамиктан кычкырганнары ишетелә: Жуков Берлинны алса да без моннан чигенмибез, янәсе, безнең яңа самоходкаларны җимерә алырлык түгел, имеш... Бу, билгеле, бушка өмет тоту, суга таяну. Шулай да соңгы каты һөҗүмнәрнең аз нәтиҗәле булуы командирларны уйга төшергән иде. Анда шул нәрсә ачык күренде: немецлар безнең тактиканы шул чаклы нык өйрәнгәннәр, аңа тәмам җайлашканнар, кечкенә генә алдан уйланылмаган нәрсәне дә шунда ук үзләре өчен файдаланалар. Әмма алгы сызыкта гына беленгән, һөҗүмне уңышсыз иткән бу нәрсәләр гомумиләштерелмәгән, бары сөйләнү генә булып кала бирә иде шикелле. Шуңа ул өстәрәк торган башлыкларга да барып җитмәгән булса кирәк әле. Давай, давай һөҗүмгә дип, приказ төшереп кенә торалар. Алар да хаклы, бөтен фронтларда алга барганда монда артта калырга ярамый, чөнки фронт сызыгы тигезсезләнә һәм бөтен шартын китереп приказны үтәргә тотыналар. Дошман позициясе квадратларга бүленеп бомба белән, туплар белән бик каты тетелә, таш өстендә таш калмый. Ләкин һаман да бер үк күренеш кабатлана, көне буе тоташ һөҗүм итеп бары беренче траншея гына алына, тегенең обороносы күп эшелонлы икән. Приказ бу юлы да үтәлеп җитми. Моның өчен җавап тотарга кирәк. Шуннан тикшерү китә: нигә болай, нигә тегеләй...

Һөҗүмдә катнашкан төп подразделениеләр арасында капитан Мамакның укчы батальоны һәм аңа беркетелгән тупчылар — майор Мостафин дивизионы да бар иде. Алар һөҗүмнең һәр минутын-сәгатен исәпләп, укчылар кайчан, күпме алга үрмәләргә, шул вакытта тупчылар нәрсә эшләргә кирәклеген бик нык алдан уйлап һәм планлаштырып тотынганнар иде. Кичкә таба укчылар көч-хәл белән дошманның беренче траншеясына бәреп керделәр. Бу хәрәкәтне суындырмыйча бик тиз дәвам итәргә кирәк иде. Шуңа Мостафин үз дивизионының ике батареясына укчылар янына күчәргә приказ бирде. Бу дистәдән артык пушка дигән сүз. Иртә уңмаган кич уңмас дигәндәй, пушкаларны ашык-пошык урнаштырып маташканда немец танклары килгәне күренде. Алар ата-ата килә, нәкъ шул мәлне фрицлар бөтен кораллардан өермәле ут ачтылар һәм укчылар биләгән окоп-траншеяларның астын-өскә китереп ташладылар. Сул флангта Мамакның ачы итеп сүгенгәне, кемгәдер янаганы ишетелеп китә. Баксаң, сирәк карачкыл куаклар артындагы укчыларның исәннәре һәм яралылары чигенгән, кайсылары артка сыпыртып маташа икән. Менә шунда Мостафин тупчылары немец танклары белән бергә-бер калды. Бәрелеш бик кискен төстә барды. Бәхеткә, Мостафин үзе тупчылары янында иде, артка карарга вакыт бирмәде. Сафтан чыккан расчет урынына үзенә дә эшләргә туры килде. Хәл кыл өстендә тирбәнде. Йә без, йә алар. Тагы бер ярты гына сәгать чыдасак... Тагы әнә теге танкны гына яндыра алсак... Мостафин үзенең башында шушы үлем алып килгән минутларны эчтән генә санап торучы нәрсәдер барлыгын тойды... Бәхеткә, шул кискен моментта батареяга яңарак килгән бер кече лейтенант искиткеч салкын канлылык белән һәм акыллы хәрәкәт итте. Әллә каян пулемет табып, танк артыннан килгән фрицларны кырдырып торды. Шул коткарды. Фамилиясе Идрисов икән. Ул арада Мамак тоташ туп шартлаудан исәнгерәгән укчыларын һәм пәтыэр-

чыларын жыеп килеп житте. Алган позицияләрен бирмәделәр, гитлерчылар чигенде. Шулай да приказ жиренә житкерелмәде, үтәлмәде.

Ә төнлә белән алмашка яңа көчләр килде, аларны тылга чыгардылар. Бер бәрелештә частьлар бик өтелеп калган иде.

Өченче көн исә күп кенә вазифалы кешеләр катнашында оперативка жыелды. Анда һөжүмнең алга таба җәелдерелмәве мәсьәләләрен карадылар. Мамак та, Мостафин да, мөстәкыйль рәвештә рапорт язып, командирлар буларак, үзләренең фикерләрен әйткәннәр иде. Шуларны алга алып куеп, һәр пунктын тикшерергә, ачыкларга тотындылар.

Озын өстәлнең бер башында Мамак юаш кына, йончыган төстәрәк утыра. Ул түгәрәк каратут йөзле, калын кашлы һәм рәтләп йокы, ял күрмәгәнгә җыерчыкланган, җил каклаган битле. Төптән таза гәүдәле булуы һәм тышкы кыяфәтенең бүтән чалымнары, сөйләгәндә «г» хәрефен «һ» итеп әйтүе аның украинлы икәнен әйтеп тора. Сабыр гына тыңлый, эчтән кичерә, ләкин кайбер тәнкыйть сүзләрен ишеткәндә кашлары җыерылып китә дә чыраена дәһшәт чыга. Ул бер дә үзендә гаеп тойган халдә утырмый шикелле. Аның шәхсән тәвәккәл командир икәнен беләләр. Батырлыгы турында сүзләр күп йөри иде. Ул штабта эшләгәндә батальон командиры алга сызыктан хәбәр итә: ике ротамны атакага күтәрә алмыйм, дип. Мамакны җибәрәләр. Роталарны һөҗүмгә күтәрә һәм немец траншеяларына чаклы алып бара. Икенче бервакыт тагы шундый тоткарлык килеп чыга. Кайсыдыр командир сугышчыларын атакага күтәрә алмый. Тагы Мамакка кушалар. Булдырып чыга. Күп мәртәбәләр шундый куркыныч эшләрне башкара. Сугышчылар аның Мамак дигән фамилиясен ни өчендер Мамай дип тә йөртә башлыйлар. Шулай да мәсьәлә җитди, бер дә баштан сыйпамыйлар. Ул рапортында, ут нокталарын җимереп бетермәделәр дип, бар гаепне тупчыларга аударган икән. Ләкин укчыларның ничек хәрәкәт итүен күзәтеп торганнар. Артхәзерлек дошманның өченче траншеяларына күчерелгән чакта алга кузгалырга кирәк иде, син шул моментны ычкындырдың, менә бөтен бәла шуннан башланды, дип күзне дә ачырмыйлар. Бик хаклы әйтәләр. Мостафин да нәкъ шулай уйлый иде. Әмма Мамак бу тәнкыйтькә дә җавабын тапты. Ул солдатларның карт-коры, ә яшьләренең начар өйрәтелүләрен, өлкәннәрне кыймшату авыр булуыннан зарланды. Тагы ниндидер сәбәпләр әйтә башлаган иде, аны бер киң битле, зур башлы оперативник бүлдерде:

— Кайсы көчле — арыслан командалыгындагы бер көтү сарыкмы, әллә сарык командалыгындагы бер көтү арысланмы? Кайсы көчлерәк?— Эффект өчен тынып торды да өстәде:— Әлбәттә, арыслан командалыгындагы бер көтү сарык көчлерәк...

Кемдер кисәк кенә көлеп алды, тик тыелып тынды, киеренкелек йомшамады. Мамак оперативникка кыю карады, ачуы да килмәде шикелле. Барысын да: мондый чакта була торган сүзләрнең чәнечкелесен дә, ачысын да эченә сеңдерә барырга күнеккән иде булса кирәк. Мостафин аның сабырлыгына сокланды. Мамакның соңгы сүздән баш тартуы үзенең гаебен тану кебек булды. Аннары Мостафинга күчтеләр. Мостафин оперативкага бик пошынып килгән иде. Сәбәп шунда, кичә чирләп полк командиры Кимбр госпитальгә ятты. Ул булмагач мине бутарлар, дип курка иде. Чынлап та теге, битенең киңлегеннән колагы да күренми торган оперативник:

— Пехотага ярдәмгә нигә ике батареяны гына китердең?— дип тотынды. Мостафин алгы сызыкка машина белән барырлык түгел иде, бу пушкаларны да җилкәдә китердек әле, диде. Бу обстановкада бары шулай гына эшләргә мөмкин икәнен бүтәннәр дә расладылар. Мостафин җиңел сулап куйды. Ләкин ул рапортында безнең 76 мм пушкалар «Тигр»ның алгы бронясын җимерергә көчсезрәк дигән ялгыш бер җөмлә язган иде, шул сүзләргә бәйләнделәр. Аеруча күкрәгенә орденнар тезгән бер капитан бу фикергә бүтән төс биреп гаепләп маташты. Бик нык сизгерлек күрсәт-

кән кебек сөйли иде. Мостафинның кинәт ачуы кайнады, катыргы кәгазь өстендәге бармаклары калтыранганын күрде ул, тик тыелып кала алмады:

— Мин үзем практикада сынаганны күрсәттем,— диде.— Әгәр сезгә кирәк булса, 76 мм пушкалар «Тигр»ларны пыяла урынына челпәрәмә китерәләр дияргә мөмкин...

— Юк, юк,— дип кул селтәде теге нигәдер. Ләкин Мостафинның тупас кыланышы киң битлегә дә барып тигән икән, ул устав параграфлары белән суктырырга тотынды. Үзенең булдыксызлыгын пушкаларга сылтаган командир пустяк кеше ул, диде. Тагы ике-өч оперативник аны талкып алдылар. Каты гына сүзләр әйттеләр. Кинәт Мостафинның язмыш үлчәве тәлинкәсе түбәнгә киткән шикелле була башлады. Мостафин мине урыннан алалар икән, дип уйлап алды. Әмма шул мәл күкрәгенә Герой йолдызы таккан, ничектер крестьян чырайлы, таза базык гәүдәле лейтенант сүз сорады. Бетереп ташлый икән, дип Мостафинның йөрәге дөп-дөп типте. Ләкин нигәдер Мостафинга бик текәлеп, хәерхаһ йөз белән карый иде. Мостафин шуннан: «Әллә берәр таныш микән?»— дип уйлап куйды. Ләкин үзе бу кешене кайда да булса күргәнен хәтерләми, юк.

— Сугыш устав буенча бармаганын барыбыз да бик яхшы беләбез,— дип башлады ул. Бу җылы сүз иде.— Ә пушкалар турында майорның фикере дөрес. Мәгълүм факт. Фактка реаль карарга өйрәнергә кирәк. Командование шулай эшли дә, хәзер зисларны 85 мм итеп чыгаралар. Уставча гына бармый дигәннән, бер нәрсә сөйлим әле. Узган ел апрель азакларында Великая елгасын кичкәндә мин бик хәтәр хәлдә калдым. Таң беленеп килә иде. Минем отделение елгага кереп, алга йөзеп китте, ә мин йөзә белми идем. Куркып ярда калганмын. Суга сикерергә итеп ыргылам, куркып, тагы артка чигенәм. Үзем эчтән елыйм, көчектәй шыңшыйм, яр кырыенда әрле-бирле чабып йөрим. Әллә кайдан бер капитан килеп чыкты. Тотып алды да сораша, мин барысын да әйтеп бирдем, күземнән яшь атылып чыкты. Шуннан, капитан: «Баграков, суга сикер, ротаңны куып җит!»— дип кычкырып җибәрде. Мин дә яңа көч белән ярга йөгереп килдем, ләкин тагы суга сикерә алмадым. Капитанның ачуы килде, минем хәлне дә аңлады бугай, мине тотты да ярдан суга ыргытты. Мин эт шикелле кулларым белән чәпелди-чәпелди йөзеп киттем, батмадым. Теге ярга тәки барып чыктым бит. Анда сугыш бик каты бара,— мәхшәр иде. Ротадан бик әз кеше калган. Командир һәлак булган, пулеметчы үлгән, немец һаман атакага килә. Мин калкудагы максимканы чамалап алдым да шуның артына яттым... Тегендәрәк тагы бер пулемет ата. Ләкин бераздан ул тынып калды. Траншея буйлап чабып барсам, ике иптәш тә үлгән. Бераз бу пулеметтан атып торам да аннан үземнекенә йөгерәм, әле анда, әле монда...

Шул чак аның сүзе бүленде, җыелыш алып баручы оперативникны нindидер начальник чакыра дип, алып чыгып киттеләр. Ничектер киеренкелек йомшагандай булды, Баграковның мәсьәләдән читкә китүенә эчләре кырып утырганнар да аңа ригая белгерттеләр, сөйләп бетерергә куштылар.

— Көне буе шулай ике пулеметтан атып, түбәне немецларга бирмәдем. Кичкә яңа көчләр елганы кичте. Фрицны шөшкенләп куа китте, ә миңа шушы йолдызны госпитальдә бирделәр, кулбашым яраланган иде. Дәваланып ятканда һаман теге мине суга атып бәргән капитанны уйладым. Мең рәхмәт укыйм үзенә. Каян гына табарга үзен? Терелеп чыккач та мин аны эзләп карадым. Юк та юк. Ләкин менә хәзер мин аны күрү бәхетенә ирештем. Ул — әнә майор Мостафин. Бик тиз танып алдым...

Өстәл артындагыларның кайсыдыр ышанмыйча: «Ну?!»— дип ычкындырды, кайсы исә: герой әкәмәтләр эшләсә дә килешә, дигән төче караш белән елмайды. Баграков Мостафинга таба килә иде, Мостафинның маңгае тирләп юешләнде, герой сөйләгәннәр җете төстә күз алдында гәүдәләнде.

— Сез мине, бәлки, оныткансыздыр?— Баграков аның кулларына килеп тотынды һәм нурланып карап тора башлады.

— Менә хәзер хәтергә төште. Ул сез идегезмени? Кара, нинди очрашу, ә?— дип, Мостафин да аның беләгеннән тотты. Ләкин шатлыгын артык белгертмәде, сүрән генә елмаеп торды. Ул арада начальникның вакыты булмау сәбәпле җыелышның бүгенгә беткәнлеген әйттеләр. Оперативниклар кузгалышып Баграков белән Мостафинны чолгап алдылар. Аңлашу, белешү, детальләп сорау, төгәлләү һәм өстәүләр китте. Бу хәлнең чын булуына тәмам ышанып җиткәч, елмаеша-елмаеша: «Баграков синнән бүген тиеш»,— дип шаяртkалап таралыштылар.

Баграков Мостафинны үзенә алып кайтты. Бай гына латышның бер як бүлмәсендә тора икән. Алар төне буе сөйләшеп утырдылар. Баштан кичкән хәлләрнең бөтенесен тәфсилләп искә төшерделәр. Күбрәк Баграков сөйләде. Ләкин мактану аның бер сүзендә дә чагылмады. Тәпле кеше икән бу, дип сөенеп утырды Мостафин. Ә бит бер мактанчык шыр кеше булса да берни эшли алмас иде.

— Бәхетең бар икән, Баграков,— диде Мостафин, герой куйган сыйдан сәрхушләнеп.

— Әйе, бәхет миңа чыкты,— диде ул моңсу гына, яңакларын батырып тәмәкесен суырды.— Ә бит моның өчен күпме баш салынды. Күпме башлар! Иптәшләр жәл!— һәм, бу хакта искә төшерәсе килмәгәндәй, кулын селекте. Мостафин аның бу сүзләренә сәерсенеп карады: геройлыгын бары үзе күрсәткән батырлык өчен генә түгел, ә барча сугышчан иптәшләренең көче, каны белән ирешелгән нәрсә итеп каравы соклану уятты. Уйлап карасаң, бу дөрестән дә шулай бит. Алтынга лаек булмасалар да, батырлык эшләгән кешеләрне күргәне бар аның, әмма берсеннән дә мондый сүзләр ишеткәне юк иде әле. Бу ничектер яңача, ахры, фикердә кешенең холык-фигыле чагыладыр. Баграков чын рус кешесе иде, үзенең шундый дан алуына намуссынган, үлгән иптәшләре каршында уңайсызланган кебек иде. Бик чисрлыклы кеше булса кирәк, дип үзенчә нәтиҗә чыгарды Мостафин. Шул фикерен ныгыту өчен, Баграковның аны яклап чыгуын исенә китерде. Югыйсә җыелышта ул сөйләгән нәрсәләр хакында соңыннан да әйтергә мөмкин иде. Баграков хәзер дивизия оперативкасында эшләп йөри икән. Тегенди-мондый мәсьәләдә кирәгең чыкса, туптуры миңа кил, дип тә әйтүдән тайчанмады. Аның сүзләре эшкә тора торган икәне Мостафинда шик тудырмый иде инде. Сизелә, абруе бар, аның белән санашалар шикелле.

— Хәзер инде судан курыкмыйсызмы?— дип куйды Мостафин көлә-көлә һәм герой да көлер дип белеп. Ләкин Баграков көлмәде, моңсуланып кына китте.

— Юк, куркам әле,— диде ул җитди генә.— Су күрмичә кечкенә шәһәрдә үскән кеше мин, әллә шуңа...— Сүзен әйтеп бетермәде, йөзеннән шул сизелеп калды: бу халәт тагы нинди дер бер фаҗига белән дә бәйләнгән шикелле иде.

Мостафин таң алдыннан гына китте. Эчендә бу очрашудан туган куаныч һәм яшисе килү уянган иде.

Шуннан соң Мостафин белән Мамакны бүтән дәрәҗәдәге утырышларда тагы берничә тапкыр карадылар. Бердә инде карулашып, үз фикереңне җопләү мөмкин түгел иде. Барысын да эчкә йотып кына барырга туры килә. Шулай да бетереп ташламадылар: Мостафинга үзенең шактый нык өтелеп калган дивизионын яңа көчләр белән тулыландырырга боерылды. Частьны таратмауда, икенче частька ямаулык итмәүдә полк командиры Кимбриның да авторитеты роль уйнады бугай, әмма Мостафин да моны үзе өчен уңыш санады.

Хәзер ул үз частена кирәк-ярак юнәтү өчен көн-төн чаба иде. Аның хуҗалыгы Петермуйжа дигән кечкенә бер латыш шәһәрчегеннән ерак түгел урман кырыена урнашты. Блиндажларны таза итеп төзеделәр. Зур «оя»лар казып, пушкалар да позициягә куелды. Батареяларга яңа «пополнение» килә башлады. Барчасы госпитальдән иде, әлек төрлесе төрле частьта

булганнар. Аларга пушка әлифбасын өйрәтмичә ярамый. Шуңа командирларның өлкәне, кечесе шушы эшкә җигелделәр.

Эшләр белән йөргәндә Мостафин Петермуйжага барып чыкты. Шәһәр димәсәң хәтере калыр. Асфальт юлның ике ягына тигез ара белән тезелеп киткән бер катлы, ике катлы таш йортлар. Тирә-ягы куе нарат, чыршы урманы. Күзгә нык ташланган нәрсә — йортлар кызыл чирәп түбәле булып, кыекларын бик текә очлы итеп биек эшләгән. Чардакларында да торак бүлмәләр шикелле. Төп урам сирәк агачлык эченә кереп китә дә кызыл кирпечтән сырлап-бизәкләп салынган зур гына костелга барып туктый. Костел буенда өсте гөмбәзләп ябылган сәхнә сыман корылма. Анда орган музыкасы уйный имеш, дип ишеткән иде Мостафин. Мәйданга халык шактый җыелган, нәрсә булыр бу, әллә чынлап та орган уйнаталармы? Ул, кызыксынып, бер кырыйга килеп басты да, сәхнәгә таба карады. Кара пальто кигән яланбаш өч кеше сәхнәгә күтәрелә иде. Алар артыннан сак астында күксел шинельле берәүне керттеләр. Мостафин эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алды. Күксел шинельле адәм немец булып, хәзер аңа монда суд ясалачак, халык шуның өчен җыелган икән. Катыргы тыш тоткан берсе кечкенә өстәл артына барып утырды. Кара пальто кигәннең икенчесе, халыкка йөзе белән борылып, бер кулын өскә күтәрде, ягъни игътибар, башлыйбыз. Халык тынып калды. Өстәл артындагы судья кәгазьләрен ачты да немецка пунктлап сораулар бирә башлады. Калын гына муенлы фриц баш кагып, яки бер сүз белән кыска гына җавап биреп, раслап бара иде. Мостафин аның йөзен күзәтте. Таштай җансыз, керфеге дә селкенми, ияге алга чыгып тора торган йөз. Сорауларга җавап алынып беткәч, фрицның үзенә сүз бирелде. Сөйләгәндә сүзләрен ятлаган кебек сөйләде, ниндидер автоматтан аткан сыман иде. Мостафин әз-мәз аңлаган немецчасы белән дә сүзләренең мәгънәсен тотып ала алды.

— Әсирләрне атарга мин үзем теләп керештем,— диде ул.— Чөнки мин бу эшне бүтәннәрдән остарак башкара идем. Бер атуда кешене газаптан коткарам. Мин Кемери янында 60 кешене аттым. Фәлән төштә 115 әсирне.

Мостафин шул сүзләрне ишеткәч, үзенең монда бүтән чыдый алмаслыгын сизеп китеп барды. Судьяның асарга дигән хөкем карары укуын колак очы белән генә ишетеп калды. Чынлап та, бу фриц — ерткычтан да әшәкерәк, чөнки шушы эшләрне аңлы рәвештә эшләгән бит. Югыйсә, үзе адәм затыннан. Кайчандыр аны ана тудырган, ул бик зәгыйфь, кечкенә булган. Ана үзенең күкрәк сөтен имезеп аны аякка бастырган, чиксез сөенгән, күзләренең ак, йомшак нурларын аңа койган...

Ул, штабка кереп тормыйча, туры үз фатирына кайтырга булды. Бик йончылган иде, бу арада ыгы-зыгыдан башы тәмам күпте, фикер йөртә алмас хәлгә килде. Бар хыялы ничек тә йоклап алу. Аяклары шундый авырайдылар, нәкъ гер таккан кебек. Тез буыннары ниндидер бер җансыз механизм сыман көчкә генә бөгеләләр һәм язылалар. Күн итегенең йөзен тегермәндәге сыман аксыл тузан каплаган. Биредә балчык нәкъ көл төсле, ничек иген үсә бу җирдә? Шундый аксыл көлдән әнисе мунчага селте кайнатып куя торган иде. Әй ул селтенең баштагы бетчәләрне рәхәт ачыттыруын, чәчне ефәктәй итеп йомшартуын күрсәң...

Юк, бүген бер өч-дүрт сәгать йокламыйча булмас. Хәзер ярдәмче бирделәр, артык бетеренмәскә кирәк. Ә помпотех капитан Асоев болай җилле күренә. Базык, төеп тутырган кебек нык гәүдәле, кыска юан муенлы, зур гына башлы. Бар тәэминат эшләрен үз кулына алды, башка эшләрне дә читкә какмый. Килгән көнне үк кемлеген күрсәтәсе иттеме: «Мин эш аты,— диде.— Мин эшсез яши алмыйм,»— дип шаяртып сөйләнде. Анысы барыбыз да атлар инде без, дип Мостафин да шаяруга шаяру белән әйтеп куйды. Тик камыт кына сукмасын. Сукмас, диде Асоев һәм кырында басып торган үзеннән буйга озын, таза гәүдәле, бераз шадраrак йөзле ординарецына карап алды, янәсе, әнә нинди егет, бирешә торганнардан түгел. Ул аңы үзе белән алып килгән иде. Гадәттә, офицер яңа эш урынына

үзе генә килә, бирелә аңа ординарец билгелиләр. Ә бу алып килгән. Мондый хокукка ия булу өчен югарыда бик зур танышлыгың булырга тиеш. Асоев өстә кайдадыр бик җылы урында эшләгән булса кирәк, сөйләшүеннән шул сизелә, үзен бик иркен тота. Начальникның кайсысыннан да шүрләп-өркеп тормый. Элекке урындагы бәйсезлеген биредә дә норма итәсе килә һәм шуның белән әз генә масая да иде шикелле. Беренче көнне үк үзенең элемтәләре гаять күп, теләсә нинди әйберне җир астыннан булса да таба алуын күрсәтте. Мостафин бер атна йөреп очына чыга алмаган запчастьларны бер баруда алды да кайтты. Әмма кая гына барса да ординарецы белән йөри. Алар бер-берсен ярты сүздән аңлаган дуслар сыман. Берәр эш кушсаң, Асоев иң элек ординарецына карый. «Ну, ничек, Зангир, син ни дисең?»— ди. Теге ничек әйтсә, әйе, дөрес, дип җөпли һәм ул әйткәнчә эшли. Мондый хәл Мостафинга сәер тоелды. Бәлки, шуңа күрә генә бу нәрсә аның игътибарына кагылгандыр. Ә болай Асоев та, Зангир да әйбәт күренәләр. Мостафин кешене бары эше буенча гына бәяләргә омтыла иде, шунлыктан кайберәүләргә аның бу гадәте ярап бетми иде...

* * *

Мостафин йорт хуҗасын исенә төшерде, менә күпме яши, ә аны юньләп күргәне дә юк. Ниндирәк кеше икән ул? Очраганда да ничектер битараф кыяфәт белән тизрәк күздән китү ягын карый шикелле. Чырае да аның бер дә ачык булмый, нәрсәсендер югалткан кебек караңгы-моңсу. Сөйләшеп карыйсы иде үзе белән. Мондагы урманнарда җыен калдык-постык әтрәк-әләмнәрдән оешкан бандалар чуала, ди. Бигрәк тә командирларга төнлә һөҗүм итәләр икән. Берничә очрак булган инде. Ялгыз гына йөрмәскә дип, оперативкада кисәтү ясадылар.

Немецлар бик мәкерле рәвештә латышларга әйбәт караган тәэсир калдырганнар. Җирләренә тимичә икмәкләрен, малларын юк-бар әйбер бәрабәренә алдап алып бетерә язганнар. Бик нечкә итеп, астыртын талап, чишендергәннәр. Монда күпчелек крестьян халкы. Аның мәңгелек психологиясе билгеле бит. Хезмәте авыр, һәр нәрсәне тир түгеп кенә таба. Шуңа бик исәпле-хисаплы һәм кысан. Җирен җаны белән тиң күрә. Җиренә тимәсәң — дус, тисәң — дошман итә ул сине. Һәр тарафта межа да межа, аның сугышлары да биредә әз булмагандыр?

Хуҗаның йорты тыштан шактый бай күренә. Эре бүрәнәдән, биек таш нигезгә утыртылган. Ян-яннарына тагы кушып бүлмәләр эшләнгән, тәрәзә уелган. Эчтә бүлмәләр күп булырга тиеш. Хуҗа Мостафин верандадан туры керә торган кырый бүлмәне бирде. Хуҗа өйдәге бар җиһазны җыеп яшергән. Аның ягында кулдан эшләнгән тупас өстәл һәм искереп, «кабыргалары» ямалып беткән диван сыман нәрсә. Өйдә һәрчак ничектер бик тын, бала-чага барлыгы сизелми. Әлбәттә, балалы йорт куркынычсызрак булыр иде...

Ул, капканың кече ишеген ачып, эчкә керде. Шул мәл кинәт болдырда буш чиләкләрнең идәнгә төшеп шалтыраганы ишетелде. Ишектән шакмаклы юбка кигән, чәчләрен баш артына төйнәгән, яшь, матур йөзле уртачарак буйлы бер кыз атылып чыкты. Кулларын як-якка җәйгән килеш, тиз-тиз баскычтан төшә. Ә баскыч өстендә түгәрәк битле, старшина погонлы кеше күренде. Баскыч күтәрмәләрендә ул, чайкалып, егыла язды, шуңа бик сакланып кына аягын аскы баскычка куя иде. Чәче тузган, каешы бушап, наганы тезенә чаклы асылынып төшкән. Бу минутта теге кыз Мостафинның беләгенә килеп ябышты, еш-еш тын ала, куллары дерелди иде, артка поскандай итте:

— Иптәш майор, иптәш майор,— дип өзгәләнде.— Әнә теге кеше мине капшый!

Мостафин ситуацияне аңлап алды һәм старшинага кычкырды:

— Тукта! Сез кем? Нигә тәртип бозасыз?

Теге томырылып килгән шәпкә башын күтәрде, алдында майор басып торганын күргәч, күз аклары зураеп китте, ләкин шунда ук, батырланып, күкрәген киерде:

— Мин аңа өйләнергә телим!— дип кычкырды, үз сүзендә нык торачагын белгертеп, ике йодрыгын өскә күтәрде. Мостафин аның нык исерек икәнен күреп алды.

— Юк, юк! Мин аны белмим!— диде кыз каушаудан тыпырчына-тыпырчына.

Хәл көн кебек ачык иде, Мостафин боерды:

— Отставить! Тукта!

Әмма теге приказны чүпкә дә санамаган кыяфәт белән һаман килә.

— Командованиедән рөхсәтем бар!

— Нинди рөхсәт! Кая документларыгыз?! Стой!— диде Мостафин тимер тавыш белән. Теге атлаганда тагы егыла язды, күзләрендә ак шарлар тәгәрәште.

— Китегез юлымнан!— дип, хәтәр җикеренде һәм чәбәләнә-чәбәләнә кабурасыннан пистолетын тартып чыгарды:— Менә документ!

Хәл кискен иде, Мостафинның аркасы чымырдап куйды. Старшина исерек, атып җибәрүе дә бик ихтимал, исереккә диңгез тубыктан.

— Сез исерек, старшина, тыңлагыз!— диде Мостафин тегене акылга китерердәй гозерле рәвештә. Ләкин старшина ишетергә дә теләми иде, авызы канәгатьлек белән ерылды. Ул бер унбиш адым кала туктады да пистолетын предохранительдән ычкындыра башлады. Әмма бармаклары аны тыңламый иде, ул пистолетын тезенә куеп — аңа ике куллап ябышты. Тиз генә барып кулына сукмакчы булды Мостафин, ләкин тегенең атып өлгерүеннән шигәйде һәм үзенең пистолетыннан һавага атты.

— Әһә, сез шулаймы әле?!— диде старшина, хәтәр кыҗрап, пистолетын һаман рәтли алмый маташа иде. Ул да түгел, ишегалдына ике патруль солдат килеп керде. Мостафин аларга ымлап старшинаны күрсәтте. Тегенең янына атылып бардылар. Старшина пистолетыннан күтәрелеп боларга төбәлде. Әллә күземә күренәләрме дигәндәй, учы белән йөзен сыпырып алды. Аның исерек икәне патрульләргә дә барып җитте. Берсе старшинаның пистолетына үрелгән иде, теге кинәт калкынып артка каерылды, бирмәскә итте. Тик икенче патруль аның артына баскан иде, шуннан югарыга күтәрелгән кулын бөгеп тиз генә алды.

Коралсыз калгач, ул бераз айнып киткән кебек булды, мыскыллы елмаеп, чәчләрен учы белән сыпыргалады. Мостафинның тылда ятып чаманы югалта башлаган старшиналар хакында ишеткәне бар иде, бу да шундый нәрсә ахры дип уйлады. Солдат патрульләр аңардан боерык көтеп текәлгәннәр иде:

— Комендатурага!— диде ул коры гына. Як-ягына күпме карангаласа да, теге кыз күренмәде. Кем булды икән соң ул? Әллә хуҗа кызымы?

Барганда старшина, исенә килеп, ләкин кәпәренүен җуймыйча, сөйләнде:

— Безнең генерал белсә моны, иманыгызны укытачак бит. Ташлагыз, майор! Ну, ярар, минем өстә әз булса да власть рәхәтен татып калыгыз, мескеннәр. Рөхсәт итәм...

Комендатурада Асоев дежур икән. Ул старшинага бик каты тотынды, телгә бик зәһәр, тегенең бәгыренә тиярлек итеп әйтә. Зангир да чәнчепчәнчеп ала иде. Старшинаның пистолетын өстәл тартмасына нииндидер өстенлек масаюы белән салып куйды. Асоев протокол язарга кәгазь-каләм әзерли башлады. Шунда старшина, кабартылган резинаның һавасы чыгарылгандай, кинәт шиңде. Әтәчләнүе юнып төшергәндәй бетте. Эшнең начар якка авышуын тиз сизеп алды. Ихласлыгын күрсәтергә теләп һәм шуның белән боларны йомшартырга өмет итеп, барысын да ачыктан-ачык сөйләп бирде. Ул РС батареясының расчет командиры икән. Кичә генә «Кызыл йолдыз» ордены алырга шәһәргә барган һәм, билгеле, бу хәлне

«юмыйча» булмый инде. Кызга тимәгән, ягылмаган, бары чын күңелдән сөйләшергә генә теләгән...

— Ярар, анда карарлар, гаебең булмаса...— дип Асоев каләм алды. Ләкин кәгазь рәсми төс алып китсә, бик хәтәр буласын ул яхшы белә иде. Старшинаны болай гына калдырмаячаклар, абруена тап төшәчәк. Ә үзе беркатлы, гади кеше күренә. Мондыйлар иң авыр эшкә дә карусыз баралар. Хәл, обстановка ышыгына кереп посмыйлар.

— Уставны бозганмы — бозган! Соң нәрсә нәнкәләнеп торырга, язарга да и бетте!— диде Зангир каты тавыш белән Асоевка әмер биргәндәй. Теге шунда ук язарга да тотынды. Мостафин бер сүз дәшми генә утыра иде, Зангирның шушыннан ниндидер канәгатьлек тапкан кебек кыяфәте, Асоевның да әйтү белән яза башлавы аның күңелен тырнап узды. Кара, ничек тырышалар! Бу бит ут эчендә булган, тагы утка керәчәк кеше!

— Зинһар, гафу итегез, актык каным белән...— дип старшина ялварырга тотынды. Зангирның карашына ишарәле сызыклар чыкты. Мостафинның эчендә яңа карар төенләнде.

— Озакламый комендант килер,— диде Асоев, актны Мостафинга кул куярга сузып. Старшина аска төбәлгән килеш, сабыр гына көтә. Үзен түбәнсетми. Мостафин иплап кенә кәгазьне учына алып йомарлады һәм үтенгән тавыш белән:

— Старшинаның корал-ярагын үзенә кайтарыгыз,— диде һәм туры Асоевка карады. Аның дәрәҗәсен төшермәс өчен йомшак әйтте.

— Юк, булмый!— диде Асоев, Мостафиннан карашын алып. Монда үзара чәрпәләшергә һич ярамый иде, Мостафин ачылып елмайды, Асоевның җилкәсенә учын куйды. Зангир майорны тизрәк аңлады, пистолетны тартмадан алып старшинага сузды. Асоевның ачулы йөзе шунда ук мөлаемланып китте. Зангир карышса, ул да үзсүзләнеп торган булыр иде әле.

Мостафин комендатурадан старшина белән бергә чыкты.

— Мәңге онытмам, иптәш майор!— дип, нишләргә белмәде старшина. Мостафин актны ертып ташлагач, теге тагын да рәхмәтләр укыды, тәүбәгә килеп, әз генә эчсә, буйга сеңдерә алмавыннан зарланды. Үзен-үзе тетә иде, ну шушы характерым, мине харап итә дә тора. Шабаш!... Каршыга бишенче батареядан кичке дежурга чыккан сугышчылар килә иде, Мостафин аларга старшинаны частена озатып куярга кушты.

Өйгә кайткач, хуҗа аңа баскыч төбендә очрады. Әле генә булып узган хәлне ул күргәндер һәм шул хакта зарланасы килгәндер ахрысы, дип уйлады Мостафин аның бүген нигәдер ясалма-ачык йөзле булуын шәйләп. Зарланса җавап та әзерләде: үлемнән котылып чыккан һәм, тагы үлем авызына керәсе солдат кайчак чыгырдан ычкынып куючан. Үлем каршында аның өчен дөньядагы әйберләрнең бәясе үзгәрә, бәясе төшә, бар нәрсәгә дә үзгә бәя белән карый башлый. Гомер барыннан да кадерлерәк, үлем белән күзгә-күз килгәндә әйберләрнең бер хакы да калмый. Алгы сызыкка барасы кеше дөньяга шул ноктадан караучан. Менә бу старшина да... Нишләмәк кирәк, һәркемнән корбан сорала торган вакыт...

Хуҗа аның артыннан ияреп бүлмәгә керде, ләкин бер сүз дә дәшми басып торды. Чиста кырынган кызгылт озынча битле, саргылт мыеклы, эчкә баткан күзле бу кешенең карашы ничектер киеренке иде.

— Сезнең кызыгыз идеме ул?— диде Мостафин аңа «Беломор» сузып.

— Юк, абый кызы. Э-э, бездә тора хәзер...— Хуҗа тагы нәрсәдер әйтергә иткән иде, үзен-үзе тыеп калды. Сүзгә сак кеше, ахрысы. Мостафин аңа текәлеп карады, күзләрендә сорау иде.

— Э — э, мм, ул Елгавага барган иде, шунда старшина үз машинасына утыртып кайткан. Бәйләнә-бәйләнә өйгә керде...— дип, хуҗа папирос кабызды һәм сынаулы карашын төбәп, нидер көткәндәй карады.

— Старшина тиешлесен алды,— диде Мостафин һәм иссереккә карата берничә тозлы сүз әйтте. Аннары үлемгә бара торган солдат хакында сөйләп китте. Хуҗа ышангандай, аның белән килешкән шикелле иягән

каккалап торды. Йөзендә һаман киеренке — моңсулык иде. Ул шыпырт кына ишеккә таба атлады. Аның аяк тавышы бер дә ишетелми, гүя ул һавадан бара диярсең. Сугыш боларны да тәмам сукыр тычканга әйләндереп бетергән икән, дип уйлап куйды Мостафин.

Чишенмичә генә диванга янтаеп башын куйган иде, изрәп йоклап та киткән. Бервакыт бомба шартлаган, тәрәзәләр зеңгелдәгән тавышка уянып китте һәм фосфор цифрлы сәгатенә карады. Төнге сәгать өч иде. Ничек болай немецның төнге мессерлары бу якын тирәне бомбалый әле? Биредә бит күп кенә яңа частьлар килеп урнашты. Шулай ук сизенгәннәр микәнни? Дошманга яшерен сигнал бирүче диверсантлар да бар бугай дип сөйләнгәннәр иде, хак ахрысы. Югыйсә каян килеп алар бомбаларын шулай төгәл ташларлар иде? Әллә бу фатирдан. Асоев янына күчәсе инде? Өйдәге шомлы, нииндидер сагалап торган тынлык һәм хуҗаның киеренке, эчке уйга тартылган йөзе шикләндерә аны...

Мостафин иртән юынырга чыкканда, теге кыз кисмәктән чүмеч белән су алып тора иде. Төз, озын аяклы, эчкә батыбрак торган билле, тулы, килешле гәүдәле. Мостафинның сәламенә кыз аңа таба йөзен борып елмайды һәм әз генә башын иде. Ләкин шул моментта Мостафин өчен гаҗәп һәм сәер күренеш пәйда булды: кинәт аның күз алды яп-якты булып торды, көчле лампа кабынган шикелле. Нәрсә бу? Каян болай? Кызның күрәнсу битеннән, дымсу соры күзләреннән, кыскасы, бөтен гәүдәсеннән нииндидер нур дулкыны аккан сыман иде. Күк капусы ачылганда кинәт шулай бар төш яктырып ала, имеш, дип ишеткәне хәтеренә килде. Ләкин монда нинди күк капусы булсын?

— Төнлә бик курыкмадыгызмы?— диде Мостафин каушавын яшерер өчен.

— Булды әзрәк,— дип кыз, аңа тагы әз генә йөзен борып, тутырып карап алды. Кулы чүмеч белән су чумыра, ә үзенең тагы нәрсәдер әйтергә теләве ирен өстендәге нурлы сызыклардан беленеп тора. Ләкин шул чак эчкәрге бүлмәләрнең берсеннән:

— Зитта, Зитта!— дип өзеп-өзеп әйткән нечкә тавыш ишетелде. Бу һичшиксез карчык кеше тавышы иде. Кызның кашлары җыерылды, ләкин һичнинди кәефе кырылу сизелмәде. Ул, кастрюлен ике кулы белән алдына тоткан килеш, тиз-тиз атлап коридордан эчкә таба китте.

Учы белән битенә салкын су бөркегәндә, стенадагы көзге алдында гимнастеркасын киеп төзәтенгәндә, Мостафин әле генә үзе тойган, кичергән хәл турында уйлады. Ничек алай күз алды кинәт ак нур белән тулды? Шул кыздан килгән нурмы бу, әллә бүтән нәрсәме? Кызларны күргәне бар аның, көн саен штабларда очратырга туры килә, ләкин берсе янында да болай яктылык, нур уртасында калганы булмады. Аңа күзе-өне төшеп, хат аша үзләренең хисләрен белдерүчеләр дә булды. Алар белән очрашып сөйләшкәндә, аңлашканда да мондый әкәмәт нәрсә сизмәде ул. Әллә тылга чыккач үземә тугарылырга ирек бирә башладыммы? Алгы сызыкта киеренке нервылар биредә шулай бушый микән әллә?

Нишләптер Мөнирдән хат юк әле, дип энесе турында уйланды ул офицерлар ашханәсенә барышлый. Алар Польша җирендә бик нык алга баралар булыр, ә без биредә бүленеп дигәндәй калырбыз ахрысы, хәерсез...

Икенче көнне иртән хуҗа Мостафинны чәйгә дәште. Теге кызлары белән булган хәл турында сөйләшәселәре килә микән әллә, дип уйлады ул. Үзе дә белмәстән кызларын яклаган кебек булып чыкты түгелме соң?

Коридордан барып, зур гына бүлмәгә килеп керделәр. Уртада озынча өстәл, кызыл чиккән парчалы эскәтер ябылган. Өстәл башында мәһабәт чырайлы бер карчык утыра иде. Ул, урыныннан тора биреп, Мостафинны сүзсез генә баш кагып, ачык чырай белән сәламләде. Карчык кара бәрхет күлмәктән, якасына ак челтәр япкан.

— Майор әфәнде, өстәлгә рәхим итегез,— диде ул, алдындагы әйберләрне күчергәләп һәм аңа урындык күрсәтеп. Хуҗа исә ничектер песи кебек шыпырт кына килеп өстәлнең икенче башына утырды.

— Зитта, кая югалдың инде?— дип, карчык тавышын күтәребрәк кычкырды. Монда барысына да карчык баш сыман иде. Шул минутта ук кыз да килеп керде. Тагы теге гаҗәп хәл кабатланды: ул күренүгә өй эче гөлт итеп нурга тулды. Зитта бүген бигрәк ягымлы, нурлы иде. Әмма бик тыйнак, ничектер битараф сыман.

— Җитешегез!— дип кыстады карчык. Һәм үз тәлинкәсенә чәнечке белән алып ризыклар салгалады. Өстәл болай ярыйсы гына. Кызыл балык, майлы селедка, ак балыклар турап куелган. Үзләре пешергән саргылт ипи һәм зур табада кыздырылган бәрәңге. Мостафин бәрәңгене бик сагынган иде, шуны тәлинкәсенә бүлеп алып капкаларга тотынды. Ул үзенең йөзендә ничектер Зиттаның карашын тойган кебек була, ихтыярсыздан аңа күз төшерә, ләкин кыз бар нәрсәгә дә илтифатсыз төстә утыра иде. Шунда кинәт, ике тәрәзә арасына куелган Ленин портретын күреп, сәерсенеп калды. Карчык шуны гына көтеп торгандай:

— Майор әфәнде, Ленинны без дә хөрмәт итәбез!— дип елмайды. Болар ни җитте генә аерым хуҗалар түгел, укымышлы һәм безгә хәерхаһ кешеләр булсалар кирәк, дигән уй килде Мостафинга.

— Яхшы, яхшы,— диде аларны хуплап — фрицлардан ничек саклап кала алдыгыз?

— Энә өстендә торылды инде,— дип, карчык агарган чәчләрен чигәсеннән сыпырды. Мостафинның уйлары йөгерешле: яңа тормышны теләп, көтеп алгангамы, Ленин рәсемен куйганнар? Әллә ярарга тырышыпмы? Кайдадыр ишеткәне бар: патшаны тәхетеннән төшерергә була, ләкин кеше күңелендәге патшаны тиз генә бәреп төшерәм димә... Боларда да хәзер зур алмашыну бара, ә күңелләре тиз генә алмашынып, тиз генә яңача булып китәрме?

— Сезнең патша Ульманис дәүләтенең бар байлыгын алып качкан диме?

— Әйе, сыпырткан, имансыз!— ләкин хуҗаның сүзендә бер дә ачу-нәфрәт сизелмәде. Аның яңаклары кызу-кызу селкенә иде.

— Ленин акыллы кеше булган,— диде карчык, тагы Мостафинга төбәп.— Брест солыхын хәтерлисезме?

— Укыганым бар.

— Әби онытылган нәрсәләрне туфрак астыннан чыгара,— диде Зитта, карчык сүзләрен өнәмәгәндәй.

— Нигә онытылган булсын?!— Карчыкның авыз кырыендагы сызыкларына үпкәләү билгеләре чыкты.— Алай гына онытылмый ул.

— Оныттырырга теләсәләр, бигрәк тә онытылмый,— дип хуҗа сүз кыстырды. Брест солыхын нигә онытмауларын Мостафин аңлап җитми иде. Юк, бу җирдә генә казынып ятучы, шуннан башкага исе китмәүче семья түгел, ә ил мәнфәгатен уйлаучы, кызыксынучан кешеләр, ахрысы. Карчык тагы мөлаем йөзен Мостафинга борды.

— Майор әфәнде, сез әллә рус милләтеннән түгелме?— диде ул. Бу сүзгә Зитта, башын күтәреп, Мостафинга елмайды, әбинең төпчемүеннән уңайсызланган кебек иде.

— Безнең әбигә эләксәң инде!

Телемдәге акцент беленде микәнни дип читенсенде Мостафин. Хуҗалар да русча әйбәт сөйләшәләр, әмма акцентлары барыбер сизелә иде.

— Мин татар, әбекәй.

— Ничек татар?— дип, карчык аптырап китте, күзләре зур булып ачылды.— Юк, сез йә рус, йә литвалы...

— Нигә син, әби, кешегә ышанмыйсың?— дип Зитта, тагын карчык өчен гафу үтенгәндәй, Мостафинга карап гаепле елмайды.

— Чөнки татарлар, азиатлар, алар кыргый халык,— диде карчык, сүзендә нык торып. Мостафин ни әйтергә белмичә елмайды. Хуҗа да, Зитта да уңайсызланыбрак калдылар. Хуҗа, әбине акларга итеп, әйтә куйды.

— Безнең әни католичка, чиркәү шулай тәрбияләгән инде...

— Аңлашыла,— диде Мостафин ригая белән.— Дин халыкларны бер-берсенә каршы куйган.

Карчык бу фикер белән килешергә теләмичә кулын селтәде. Аның тагы майорны аптыраштa калдыра торган сүз әйтергә җыенганлыгы күзләренең хәйләле кысылуыннан шәйләнә иде.

— Чынын гына әйтегез әле,— диде ул, кинәнүен алдан сизгән һәм шуңардан канәгатьлек тапкан кебек.— Сездә милли горурлык бармы?

Бу чыннан да четерекле сорау иде. Алар төрле халыклар белән аралашып яшәделәр. Әтисе тегермәнче булгач, русы, чувашы, мукшысы бергә аларда куна-төнә яталар иде. Берәр халыкны кимсетеп, аның начар ягын әйткән сүзне әтисеннән дә, әнисеннән дә ишетмәде. Әнисе табигатьтән сәләтле иде. (Мостафин әнисенең ул сыйфатын фронтка күп авырлыклар кичергәч, төрле начар һәм яхшы кешеләр белән капма-каршы килгәндә тагы да ныграк аңлады.) Динне бик санга сукмый иде, озак вакытлар ликбезда эшләде. Аның төп хикмәте, зирәклеге кешегә әйбәт мөгамәләдә булу иде. Магнитогорскиның Березовка бистәсендә күп халыклы баракта яшәгәндә дә ул күп кыенлыкларны сабырлыгы һәм кешегә әйбәт мөнәсәбәте белән җиңә иде. Яхшылыкны бер кеше дә аяк астына салып таптамый.

Әбигә боларны ничек итеп аңлатасың? Һәм ул ничек тә аңлаешлы булсын өчен болай диде:

— Без һәр милләткә хөрмәт белән карыйбыз, әбекәй! Ә инде шәхсән миңа килгәндә, мин аерма күрмим.

— Ничек инде алай?— диде карчык, шаккатудан тавышын күтәреп. Зитта да, хуҗа да Мостафинга сәерсенеп, ышанмыйча карадылар.

— Андый хисле кеше бүтән һәр кешене милләтенә карап кына бәяләр иде, ә бу гаделсезлекне китереп чыгара. Без кешене хезмәтенә һәм илгә тугрылыгына карап бәялибез. Кайсы латышның, әйтик, латыш булган өчен генә начар булып йөрисе килсен? Йә?

— Әлбәттә, шулай!— диде Зитта, кинәт яктырып. Ничектер аның майорны хуплыйсы гына килеп тора сыман иде. Мостафин моны үзе дә сизде. Ләкин карчык иягенә таянып уйга талган, хуҗа да алдына гына карап уйланып утыра. Бу фикер аларга барып җиттеме, юкмы, билгесез иде. Үзләрендә дә кешеләрне милләтенә карабрак бәһаләү бар иде микән әллә? Нindидер бер үзләренә кагылган дөреслекне аңлап та иманнарына кабул итә алмыйлар сыман иде. Ләкин кешенең эчендә нәрсә ятканын каян беләсең. Кеше фәкать эше, фигылендә генә беленә ул. Мостафин тагы елмаеп Зиттага карады. Зитта да елмаеп, нурланып, картлар шулай катып калганрак уйлыйлар инде, дигән шикелле булды. Мостафинның, аны аңлагандай, керфек очлары селкенде һәм аларның икесе арасында шушы картларга каршы ниндидер сер төйнәлгәндәй булды.

— Әйе, әйе,— дип куйды карчык уйланып торганнан соң. Майор сүзләренә кушылыпмы, әллә үзенең эчтәге фикерләренә куәт бирепме әйтте, билгесез иде. Зитта, кунакчыл яктырып, яшел чәйнектән чынаякларга чәй бүлә башлады. Нәкъ шул мәлдә болдырда аяк тавышлары ишетелде. Мостафин, сизенеп, урыныннан кузгалды.

— Гафу итегез, дәшә килделәр,— диде һәм хуҗаларга, аеруча Зиттага кат-кат рәхмәт белдереп, ишеккә таба атлады.

Үз эшенә турыдан-туры кагылмаган киңәшмәдә дә аның уйлары хуҗалар тирәсендә бөтерелде. Нинди кешеләр алар? Ә кыз исә, монда сөйләгән сүзләр, кешеләр белән һич тә санашырга теләмәгәндәй, аның күз алдына килеп басты да китми дә китми иде. Нидән бу шулай әле, тукта, дип Мостафин үзен контрольгә алырга итеп уйлый һәм уңайсызланудан маңгаена бәреп чыккан тирләрне кулъяулыгы белән сөртеп-сөртеп ала. Бүген дә йокы әз эләкте, артык арылганнан инде бу дия-дия үзен тынычландырырга итә ул.

Зитта да майорга ошаганын сизмичә калмады, шуңа ничектер канәгать тә иде. Ләкин майорның әллә нинди йөрәккә үтә торган йомшак

ягымлылыгы һәм чибәрлеге аның уйларын чуалтты. Майор турында уйлаганда, ни өчендер үткәне исенә төште. Эш шунда, ул кайчандыр буржуаз яшьләр оешмасы — айзсоргларга член булып язылган булган. Ул хакта бөтенләй онытканн иде. Сугыш тапавы астында ул гына түгел, күп нәрсәләр истән чыга. Алар Елгава шәһәрендә әбисе, әнисе — бергә яшиләр иде. Бер бомбага тоту вакытында әнисе кибеткә киткән җирдән кайтмады. Гәүдәсен дә тапмадылар. Шәһәрне бомбага тотулар еш булып торды. Үз җаның кайгысы күңелдән барча нәрсәләрне көчле давылдай бәреп чыгара икән. Кайгы артык нык өзгәләсә дә эчтә генә йомылды. Алар әбисе белән көчкә-көчкә генә, ниндидер могҗиза аркасында гына исән калдылар. Бу бәхетле очрак булгандыр. Торган йортларына бомба төшмәде, җимерелмәде. Шәһәрне немецлардан азат иткәч, сугыш алга күчте, ерак китте. Совет органнары килеп житте, тәртип урнашты, тәэминат җайга салынды. Баш-күз алып, исән калганнарына шөкерана кылып кына яши башлаганнар иде. Бер яңгырлы төндә аларга кораллы ике кеше килеп керде һәм, пистолетларын Зиттага терәп, боерык бирергә тотындылар. «Син айзсорг члены, Ватан каршындагы бурычыңны үтәргә әзерме син?»— диделәр. Пистолет көпшәсе күкрәгенә терәлгәндә нәрсә әйтәсең инде: «Әзер»,— диде Зитта. Аның бөтен тәне эчтән калтырап, уй-фикерләре үзләренең логикасын җуйган иде. «Әзер булсаң, менә сиңа задание: Петермуйжа янында нинди совет частьлары тупланган, күпме, нинди корал-ярак белән коралланган? Берәр офицер белән танышып, тычканлы-мәчеле уенын уйнасаң, үзеңә җиңелрәк булачак. Моның өчен синең бөтен данныйларың бар. Менә шул. Абыең утарына кайтып яшәргә туры киләчәк. Беренче явка да шул тирәдә булыр. Икебезнең беребез көнен әйтер. Булдымы? Приказны үтәмәсәң, нәрсә буласын аңлыйсыңдыр инде! Гуд бай!»— дип, хәтәр янады калун балта йөзедәй рәхимсез йөзле, зур борынлы латыш һәм куркытып чыгып та киттеләр...

Зиттаның бар уй-фикерләрен, хәрәкәтләрен бары курку идарә итә, шул хис кенә йөртә иде. Бер үк вакытта ватан каршындагы бурыч дигән нәрсә дә ничектер намусына кагыла иде. Зитта ике көн, ике төн уйланды. Бер фикеренең дә очына чыга алмады. Бөтен нәрсә буталып бетте. Айзсоргларның җанлануын һәм үзләрен тыңламаганнарны нәрсә эшләтүләрен аның ишеткәләгәне булды. Аларның ишегалдында яшәүче бер яшь кенә хатынны үтереп киткәннәрен үз күзе белән дә күргән иде.

Хуторга килеп яши башлагач, теге куркулар үткән, беткән шикелле булып калды. Биредә гаскәрләр бик күп килеп тупланган. Ул кансыз айзсоргларның бирегә кулы җитмәс. Бәлки аларны тотып та бетергәннәрдер инде дип тынычлангандай була иде.

Зитта үз бүлмәсенә чыгып, көзге алдына килеп басты. Аның ни өчендер үзенә карыйсы, сокланасы килә. Әйе, ул матур гына бит! Майорны күргәннән соң туган бу сәер тойгыга ул үзе дә аптырап калды...Һаман үзенә карыйсы килеп кенә тора. Элек бер дә алай булганы юк иде.

## 2

Кадрлар җитмәү аркасында һәм хәлләр бик кысрыклангач, Зангирны дивизионның кирәк-ярак складына куйдылар. Эш өчен кирәк дип, моны Асоев үзе шулай итте. Тупчы батареялар корал ягыннан да, кием-салым ягыннан да бик өтелгән. Тылдагы базалардан әйбер-кара табу чиксез кыен. Теләсә нинди киртәне төрле юл белән үтә алырдай бер үткен кешесез мөмкин түгел иде. Мостафин бу эшнең бик зарури икәнен белеп, Асоев ниятен хуп күрде. Зангир исә ординарец вазифасын да куймый, барысына да житешә. Алар Асоев белән бергә яшиләр, бөтенесе бергә. Асоевның чин-дәрәҗә өстенлеге ике арадагы аерымлылыкны белгертеп тормый иде. Бу факт Асоевның үз хакын яхшы белүче, эшлекле, кешене погонына карап кына бәяләми торган әйбәт күңелле булуы турында сөйли иде.

Зангир, буага җибәрелгән чуртан сыман, хезмәтенә аеруча ныклап кереште. Сәбәбе булса, сәдәбе табыла, ди ул авызын ерып. Аңа сәбәп, бер сылтау гына булсын, шуңа таянып, бар нәрсәне хәстәрли. Каяндыр бишекле трофей мотоцикл да кулга төшергән, кирәк җиргә шуның белән генә чаба. Әкренләп тәэминат эшен җайга сала башлады. Әллә кайлардан запчастьлар, кием-салым әйберләре табып алып кайта. Ләкин Зангир үзен дә онытмый иде. Кыскасы, бу урын аңа бик ошап китте әле. Аңа гозерләнеп киләләр, Зангир дип, комсостав та хөрмәт белән карый, игелегенә рәхмәт әйтәләр. Ни дисәң дә башрак кеше ул хәзер. Зангир шулардан үзе дә аңлап җиткермәгән бер рәхәтлек таба иде. Шушы хис аны үсендерә, Асоевның да аңа булган йомшак мөгамәләсе аркасында, кайчак үзен артык зур санарга, бәйлелеген онытырга этәргәли иде шикелле.

Ул үзләре фатирда торган латышның таш кладовоен склад иткән иде. Бар нәрсәне иң элек шунда кайтара, кәгазь белән генә батареяларга җибәрә. Иртән бер ерактагы базага барырга, дип мотоциклны рәтләп маташканда бишенче батарея командиры Идрисов килеп керде. Алар болай гына танышлар иде, Зангир аны йөзенә хәерхаһлык чыгармыйча гына каршылады. Идрисов пушка өчен яңа прицел кирәк дип килгән икән, шуның накладноен Зангирга сузды. Кәгазьгә күз йөртеп чыккач, Зангир акыллы һәм хәстәрле хуҗа кебек кашларын җыерып торды.

— Юк бит,— диде ул сораучының хәленә керергә теләгән чырай белән.
— Ничек юк?!— Идрисовның ягымлы битендәге нурлар кинәт сүнде.
— Приборлар кайтып җитмәде әле.
— Соң Асоев бар дип, үзе язып бирде бит?
— Алып бетерделәр.
— Юк, шаяртма инде, брат,— дип Идрисов елмайды, өске аксыл шадра тешләре күренеп калды.— Келәтеңдә качып калгандыр әле?
— Бетте дим, әллә кешечә әйткәнне аңламыйсыңмы?— Зангирның майлы сыман киң шадра битенә ачуы килү кызаруы чыкты. Һәм бүтән сөйләшергә дә теләмәгәндәй, ул, мотоциклы кырыена чүгәләп, нәрсәдер боргалый башлады. Идрисовның басып торуын онытты да шикелле. «Нәрсә әле бу бик кукрайган?»— дип уйлады Идрисов, үз командирының кәгазен дә санга сукмый. Ә прибор үлеп кирәк. Зангирның болай бик эре сөйләшүе аның үҗәтлеген кабындырып, көчәйтеп җибәрде. Шул кызу белән ул туп-туры Асоевның үзе янына китте. Штаб ерак түгел, ярты чакрым урман аша гына иде.

Бераздан алар икәүләп Зангир янына килделәр. Теге һаман мотоцикл кырыена җиргә утырып нидер төзәтә иде. Боларны күрүгә:

— Нигә судан май язып йөрергә, юк, димәк, юк!— дип кычкырды. Асоев, берни булмаган кебек, аның янына барды, теге тиз генә торып басты, алар бер-берсенә карашып алдылар. Идрисов аларның күз белән генә сөйләшүеннән складта приборның барлыгын сизгән кебек булды. Шайтан алгыры, нигә бу Зангир аңа кәҗәләнә әле? Асоев исә Идрисовка таба борылды да, гафу үтенгән чырай белән ике кулын ике якка җәеп, җилкәләрен җыерды. Юк икән бит, юк.

— Тиздән булыр, менә база күчкән, понимаешь, табарга кирәк,— диде һәм тәбәнәк юан гәүдәсе белән җиңел генә борылды да капкага таба атлады. Идрисовта исә мине алдыйлар дигән фикер туды, ләкин аның алданып каласы килми иде. Нәрсә мин аларга кода буласым юк ла, дип, бу хәлне туры Мостафинга әйтергә булды. Теге уңышсыз һөҗүмнән соң, хәлне коткарып калуын искә алып, ул Идрисовны комбат итеп билгеләде. Идрисов артиллерист түгел иде, шуңа карамастан башы эшли торган салкын канлы егет дипмедер, җаваплы эшкә куйды. Моны үз җаваплылыгына алып эшләгәнлеге сизелә иде. Шунлыктан Идрисов үзенең начар ягы белән аңа күренергә ояла иде. Ояла-ояла булса да барды, чөнки прибор яңа килгән солдатларны өйрәтер өчен бик кирәк иде.

Мостафин Идрисовны тыңлап бетергәч:

— Тагы Мөхәммәтҗанов!— дип куйды. (Зангирның фамилиясе шулай иде.) Шунда ук Асоевны чакыртты. Теге ачык чырай белән килеп керде.

— Петр Петрович, нигә базар корасыз?

— Нинди базар?— дип әсәрләнеп карады Асоев һәм, Идрисовны күреп, сүзнең ни хакында барганын шәйләде.

— Складта прибор бармы, юкмы?

— Юк ди бит Зангир!— дип Асоев базаның каядыр күченүен, тагы әллә ниләрне сәбәп итеп сөйләп китте. Зангирны ничек тә ышыкларга тырыша иде. Мостафинны аның сүзләре ышандырып җитмәде бугай, ул, тиз генә өстәл янынннан торып, кәгазьләрен тартмага бикләде, шинелен киде, каешын бәйләде һәм ишеккә атлады. Йөзендәниндидер катгыйлык иде.

Капкада Мостафин күренүгә, Зангир мотоцикл янынннан тиз генә кузгалды һәм сул кулын бот буенарак тотып доложить итәргә килде. Бер ун адымнар калгач, Мостафин аңа команда бирде:

— Кругом! Ложись!

Зангир хәлнең болайга борыласын һич көтмәгәнгә, җалт итеп Асоевка күз сирпеде, янәсе, син мине нигә якламыйсың. Ләкин йөзенә һичнинди ачулану билгеләре чыкмады, җиргә бик теләп аугандай булды.

— По-пластунски... вперед!— диде Мостафин коры гына. Зангир терсәкләрен бөгә-бөгә, тез башларын җиргә кадый-кадый шуыша иде. Колаклары әтәч кикриге кебек кызарды, үзе мышкылдап бетте. Келәткә җиткәч, Мостафин аңа торырга һәм тиешле приборны комбатка бирергә кушты. Торганда ул Идрисовка астыртын янаулы күзләренең агы белән карап алды, тегенең битендә кинаяле көлемсерәү иде.

Мостафин Асоевка Зангир турында нәрсәдер әйтә-әйтә чыгып китте. Ул синең сүзне тыңларга тиеш, ә син аныкын түгел, дигән сүзләре ишетелеп калды. Зангир шым гына булып, гаепле көлемсерәгән йөз белән яшел брезент чехолга салынган прицел приборын Идрисовка чыгарып бирде.

— Рәхмәт,— диде Идрисов, Зангирга карамыйча гына, тизрәк таю ягын карады.

Идрисов юлдан кайтмыйча, межалар белән бәрәңге бакчаларыдай бүленгән басулар аша элдерә иде. Межаларда калган үлән сабаклары ябык малның ябагалы сырты сыман булып тырпаеп торалар. Авылда колхоз елларында динчеләр: межалар бетә, Хөзер Ильяс кайдан йөрер дип коткы таратталар иде. Идрисов үзешчән агитбригадада йөргәндә шул хакта шигырь дә чыгарып сөйләгән иде. Ул гел шигырь яза иде, ул шигырь тулы дәфтәрләре кайда икән хәзер? Баулыдагы апаларда калды микән? Кайсыларының бер-ике юлы гына истә калган: «Хөзер-Ильясны кызганып, Шакир мулла яшь түгә...» Ә үзен кызганмадылар, кертмәделәр ястүгә.

Арттан үзенең исемен ишетеп, борылып караса, әле үзе яңа гына үткән урман буеннан аңа таба берәү йөгерә. Идрисов аны яшел шинель һәм кара беретыннан танып алды. Фая икән. Фронтка барганда, сортировочныйда бергә туры килеп, танышып киткәннәр иде.

— И-и, Фая, син дә бирегә эләктеңмени?— диде Идрисов, чиксез шатланып. Ашыгудан кыз еш-еш сулый иде.

— Әйе, менә бүтән очрашып булмас дигән идең?— дип, Фая да яктырып, шат булып карады.

— Язмыш үзенең адәмчекләрен онытып бетерми икән әле. Ну, син кайсы частьта соң?

— Саперларда радист,— дип, Фая урман ягына карады. Анда аркасына РГ рациясе аскан солдат басып тора иде. Идрисов аның Фаяны көткәнен чамалап алды.

— Әле кая болай?

— Пеленг белән маташабыз. Яшеренеп ятучы дошман радисты юкмы икән, диләр.— Фая ашыга иде, ул тагы теге солдат ягына борылды.

— Теге ни... кара...— дип каушады Идрисов.— Без әнә анда гына, пушкаларны күрәсеңме? Ничек шулай килеп чыктың? Язмыштыр мөгаен! Кил!

Фая башын ия төшеп ым какты да елмаюлы чырай белән теге солдат артыннан йөгерде. Идрисовта Фаяны ул солдаттан көнләүгә охшаш бер уй кузгалып куйды һәм кыз белән ничек танышуы, рәхәт хис булып, хәтерендә җанланды, барысы ап-ачык күз алдына килеп басты. Ул чакта Идрисов сортировочный пунктка караңгы төшкәч кенә килеп җиткән иде.

— Кунарга туры килер,— диде комендант, частька билгеләнгән кәгазьгә пичәт сугып.— Әнә люкс землянкалар.— Ул тышка ымлады. Эшне тиз тота торган кеше иде бугай, юан гәүдәле булса да, җиңел генә кузгалып, тәрәзә янына килде. Анда сержант погонлы бер кеше арты белән басып тора иде. Комендант аның җилкәсенә бармак очы белән кагылуга теге борылды, кыз кеше икән, юаш кына чырайлы иде.

— Кызым, сезгә юлдаш табылды,— диде комендант, Идрисовны күрсәтеп. Түгәрәк битле, үпкәләгән сыман салмаграк иренле кыз өнәмичә генә күз кырые белән Идрисовка карап алды.

— Сез дә Елгавагамыни?— Идрисов исе китми генә карады.

— Әйе.

— Менә таныштыгыз да...— Комендант, үз өстеннән бурычын төшергәндәй, әйтте дә көтеп торучылар янына китте. Идрисовның башы шаулый, колагы авырта иде, үз хәле хәл. Госпитальдә яралары төзәлде, әмма контузиясе узмаган иде. Шуңа күрә кызга илтифат итәрлек кәефе дә юк иде, битараф кыяфәт белән ишеккә таба атлады. Әллә ни уйлар дип, чакырмады да. Кыз чарасыз — гаҗиз төс белән, бәйләп алып баргандай, әкрен генә аңа иярде.

Бер землянканың ак такта ишеге караңгыда аксылланып күренә иде, шуңа бардылар. Идрисов ишектән керүгә шырпы сызды, ике-өч адым китүгә тагы кабызды. Сәкеләр күренде, сәке баганасында китек куыклы лампа да бар икән, ут элдереп җибәрде. Бар җире такта белән тышланган, чиста гына. Ләкин арттан килүче:

— Абау!— дип, коты алынып әче итеп кычкырып куйды. Сәкедәге печән эченнән, зур гына күсе сикереп чыгып, чожт кына аска чумды.

— Курыкмагыз, тешләми ул.

— Ой! Ой!— дип кыз кулындагы капчыгы белән селтәнде. Күселәр кисәк атылып чыгып йөгерәләр иде. Икенче лампага ут кабызгач, бераз тынган кебек булдылар.

— Исемегез ничек?— диде Идрисов, бераз капкалап алырга капчыгын чишеп.

— Кеше,— диде кыз төксе-ачулы гына. Аның бөтен кыяфәте бу адәм хәзер бәйләнә башлар дигән сагаю белән тулган, тартылган иде. Ул белә инде: ир-ат башта шаярган булып сөйләнә, кызык сүзләр сибә. Алар моны «артхәзерлек» диләр үзләренчә. Юк, алып бармый тор әле... Әмма лейтенантның андый нәрсә гамендә дә юк иде. Ул сәкегә плащпалаткасын бөкләп җәйде һәм, капчыгыннан ипи, колбаса алып, турап куйды.

— Әйдәгез, кеше иптәш, җирәнмәсәгез,— диде кызны кыстап. Кыз курка-курка гына бер сынык ипи белән колбаса алды да читкә карап кына капкалады. Идрисов, аның куркуын күреп, бер сүз дә катмады. Капчыгын төйнәп баш астына куйды да ятты. Кыз сәкенең икенче кырыендарак иде. Бераз тын гына ята торгач, кыз тагы:

— Ай! Ай!— дип кычкырып җибәрде, ул Идрисовка таба шуыша иде. Үзе бик горур икән, лейтенанттан ярдәм сорамый, ә теге ишетмәмешкә салышыпмы һаман тын гына ята бирә. Ләкин ул йокламаган иде. Сүзсез генә кузгалды да кызга үз урынына ятарга кушты. Бүлем тактасы кырые бер яктан ышык иде. Ә үзе икенче яктан ышыклап ятты. Күселәр бераз тынып калгач, Идрисов йокыга киткән генә иде, кызның куркып: ой, ой, дип җан авазы белән пышылдавы аны уятты. Юк, йоклап булмас, ахрысы.

Ул утырды да баш авыртудан врачлар биргән даруны авызына капты. Кызның үзен гаепле һәм уңайсыз сизгән күзләре күмердәй янып аңа карап тора иде.

— Мин куркам, якынрак килеп ятыгыз, иптәш лейтенант,— диде кыз аны да, үзен дә кызганган чырай белән. Идрисов аның кемлеген шунда белеп алды һәм татарча:

— Миннән куркасызмы, күседәнме?— диде. Кызның кырыена ук барып ятты.

— Сездән дә, күседән дә,— дип, кыз, шинелен баштан бөркәнеп, икенче якка әйләнде, аңа аркасын куйды. Бу сүздән ничектер җылы дулкын килеп кагылгандай булды лейтенантка. Милләттәшең булу да җанда нindидер хис уята иде. Ул хәзер кызның сулыш алганын да ишетә, тик исемен булса да беләсе иде, бая әйтмәде.

— Исемегез ничек?

— Фая.

— Ярар, йоклыйк,— диде Идрисов, озын-озын сулыш ала башлады, күзләре йомылган иде. Йокының изрәткеч тәме бар зиһенен, тәнен оеткан кебек итте. Һәр кыштырдау саен кыз да чәүчәләкләнмәде.

Күпме йоклангандыр, бервакыт күзенә якты төшкәнгә уянып китте. Лампалар керосин бетеп сүнгән, таң сызылып килә икән, бердәнбер тәрәзәдән алсу нурлар сузылган. Башы нишләптер гаҗәп җиңеләеп, ачылып калган. Ә кыз аның куенында ук диярлек ята иде. Нәрсәдерияген рәхәт кытыклаган иде, кызның чәчләре булган икән. Бер яны белән ятып, борыны белән тәмле генә сулый, күкрәк турындагы күлмәк сәдәфләре калкавычтай бер менә, бер төшә. Нindидер бер гөнаһсыз сафлык бар сыман кызның әчтән нур белән өртелгән иреннәрендә, битләрендә. Лейтенантның кинәт зиһене кузгалды: хәзер менә икебез ике тарафка китәчәкбез, мин аны бүтән очратмаячакмын, ә бит танышасы, сөйләшәсе килгән иде. Әйдә, яңакка сукса сугар бер, дип үз-үзенә кыюлык бирде ул һәм иплән кенә кызның иңе турыннан тотып үзенә таба кысты. Фая кинәт, күсе төшләгәндәй, лейтенантның кулын чайкап атып, сәчрәп торып утырды.

— Менә моны күрдеңме?— диде ике йодрыгын Идрисов йөзенә китереп. Лейтенант тәмам каушап калды, ни әйтергә белмәде, начар ният исендә дә юк иде бит.

— Фая, гафу ит инде!— диде, күзләре зур булып, әсәрләнеп ачылып, бу саксызлыгын кичерүне сорый шикелле иде.— Мин танышыр өчен генә... Бетте, бетте.

— Алай танышмыйлар аны...

— Без бит кабат күрешмәячәкбез, шуңа дус булып аерылыйк.

— Әй, юкка юаныч, нәрсәгә?

— Дөнья хәлен белеп булмый, бәлки... Дуслашсаң, искә алыр нәрсәң була...

— Күкерт белән тоз дуслаша алмый.

— Кем күкерт монда, кем тоз?

— Мин күкерт, син тоз...— дип кыз, шпилькаларен чәченнән алып кадап, төзәтенә башлады. Аның баштагы тырпаюы әзрәк йомшаган кебек иде.

— Ә тоз күкертне эретә. Химиядән тәҗрибә ясаган бар,— диде лейтенант күңелләнеп. Болай сөйләшү`дә аңа рәхәт иде.

— Син мине эретергә маташма. Вәт.

— Юк, Фая, юк. Бу санаулы моментны тәмсезлисе килми.

Бер почмакта юынгыч бар икән, ул шунда барып юынып алды, кулъяулыгы белән сөртенде. Кыз да сәкедән төшеп, итекләрен киеп, каешын буды, сөлге чыгарып, юынгычка китте. Лейтенант күпертмәле ак сөлгегә төргән ашамлыкларны плащпалатка өстенә куйды. Ул моңсу, төшенке кыяфәттә иде. Аның шул өметсезлек белән өретелгән төсе кызның күңеленә барып тиде булса кирәк, лейтенант аны ашарга кыстаганда, Фая:

— Син кайсы якныкы соң?— дип сорады.
— Чирмешән-Биләрне ишеткәнең бармы? Шүл тирәдән. Ә син?
— Ык буеннан. Димескәйдән.
— Бәрәч, минем апам Баулыда яши.
— Без энем белән бик кечкенә вакытта әти-әнидән калганбыз, безне ерак туганнарыбыз аерым алып үстергән.
— Һи, шулаймыни? Лаеш шулпасын эчәргә туры килгән алайса? Шуңа чибәр булгансың син.
— Мин чибәр түгел, ялганлама!— Шул сүздә Фаяның читләшүе бетә барганы сизелде.
— Ярты сәгатьтән аерылып китәр кешегә нигә ялганлыйм инде?! Сине ошатканымны гына әйтәм.
— Ходаем, кешене бер күрүдә ничек ошатырга мөмкин? Кызлар ныклыгы — чынаяк ныклыгы дип санийсың булыр?
— Синдә әллә нинди бер сер бар.
— Кара, хәйләкәр дә икәнсең! Мине мактап йомшартмакчы буласың. Андый номер үтмәс!
— Юк. Сер бит беләсене китерә...
— Өйдә бәбәйләрең елап утырадыр әле.
— Ул як чиста, койрыгым юк.
— Капкадан чыгуга сез барыгыз да егетләр инде.
— Менә юллар очраштырды, сөйләштек, рәхәт булып китте. Кабат очрашып та булмас. Уйласаң, коточкыч бит!
— Анысы бездән тормый инде.
— Бездән торса, мин сине тагы бер тапкыр күрер идем?
— Нигә?
— Мин күкерт дидең, әзрәк эри башламаганмы дип.
— Һәй, коры куаныч, нәрсәгә?
— Бер кеше икенче кешегә кирәк була ул!
— Сугышта бар нәрсә бик тиз була, бик тиз бетә...
— Бөтен нәрсә бетсә дә, дуслык кала. Чөнки сугыш — утлы горн, тимерче учагы, кешеләр бер-берсенә паять ителә монда...
— Мине дә үзеңә ябыштырмакчы буласыңмы, иптәш лейтенант? Тик канифолең юк...
— Канифолем юграк шул,— дип, Идрисов көлеп җибәрде, сөлгесен җыеп, ашамлык валчыкларын чүп чиләгенә салды. Кыз да шинелен киде.
— Номерыңны гына бир инде, хат язармын,— диде лейтенант үтенечле итеп.
— Чисти чегән булдың,— дип, Фая да көлеп куйды һәм шинель кесәсеннән блокнот алып язып та бирде. Тышта машиналар, солдатларны төяп, кычкырта иде инде. Икесе ике машинага утырып киттеләр.

Алгы сызыкка килү белән Идрисов һөҗүм итү моментына эләкте, бөтен эчке халәте тар-мар килде. Бәрелеш бик аяусыз, кискен булды. Күпләр кан эчендә һәлак булганда, ул ниндидер очрак белән исән кала. Тәне исән булса да күңелендәге бөтен нәрсә көеп-янып беткән иде. Анда хәзер бәрелеш вакытында кичергән хәлләр, җирдәге канлы гәүдәләр, кемнәрнеңдер соңгы авазлары колак төбендә яңгырап тора, әрнү, ниндидер үч ачысы тулган. Истә дә шул, күзне йомсаң, бер солдатның газапланып җан бирүе күз алдына килеп җәфалый. Элеккеләр барысы да онытылды.

Идрисов кызны да оныткан иде, менә көтмәгәндә очравы күктән төшкән сөенеч кебек булды. Ул үзен элеккеге нормаль халәтенә кире кайткан сыман бер хис кичереп алды һәм хыялый рәхәт уйларга чумып атлады.

Кайту белән приборны өченче орудие командиры һәм төзәүчесе Кардәшевка бирде. Бу иң уңган сержант, тынгысыз, эшлекле кеше. Русча начар аңлаучы үзбәк, казах һәм шуның ишеләрне җыеп, тупчы хезмәтенә өйрәтә. Сугышта берең урынына икенчең кала, шуңа күрә һәркемгә прицел приборын белү бик мөһим иде.

Төн урталарында Идрисов, постларны тикшереп, блиндажына кереп ятты һәм шунда ук йоклап та киткән. Күпме вакыт узгандыр, аны бик каты тавышлар уятты. Чыраена блиндаж түшәменнән балчык коела иде. Батарея урнашкан җиргә немец мессерлары бомба ташлый икән. Ул шатыр-шотыр килеп селкенгән блиндаждан атылып чыкты, чокырда ятырга кирәклеген онытып, солдатлар урнашкан блиндажга таба чапмакчы булды. Әмма каушауданмы аяклары хыянәтчел рәвештә камыр кебек булып калган иде, ул кинәт йөзтүбән барып төште. Кемдер бик ачы тавыш белән йөрәк ярып кычкырды. Идрисов сикереп торып шунда йөгерде, аякларының җегәрсезлеге беткән иде. Барса, батарея санитары Латышев җимерелгән блиндаж янында акыра-акыра бөтерелә. Блиндажга бомба эләккән һәм сугышчылар шунда күмелеп калган икән. Идрисов тизрәк казырга команда бирде һәм үзе дә көрәк алды. Мышный-мышный тиз-тиз хәрәкәт иттеләр. Биш минут үтмәгәндер, түшәм агачлары арасыннан берсенең ботинка табаннары күренде. Яктырып килә иде инде, гәүдәсе дә ачык шәйләнде. Тизрәк башын да балчык астыннан алдылар. Латышев аның пульсын капшарга тотынды, шинелен аергалап, күкрәгенә колагын куйды. Әмма бер мәлдән: «Юк!»— дип торып басты. Ул арада икенче солдатны да казып чыгардылар. Латышев аның кулларын бер күтәреп, бер төшерде, ясалма сулыш алдырып маташты. Борынына нәрсәдер иснәтте. Аннары, күкрәге турына тезләнеп, йөрәген капшап торды да:

— Милашкин исән!— дип кычкырып куйды. Спиртлы мамык белән һаман чигәләрен уды да уды. Мескеннең күкрәк туры селкенә башлады, эчендәге тыны чыжылдап чыга иде. Дусты Гыйльманов килеп аның кара көйгән иреннәре арасына кашык белән вино салгалады. Ләкин Милашкин күзен һаман ача алмады.

Аны иплэп кенә күтәреп икенче блиндаж сәкесенә кертеп яткырдылар. Кайсыдыр санчастька озатырга кирәк, диде. Кайсыдыр болай да үтәр, дип тынычландырды. Милашкин кич белән генә, күз кабакларын көчкә күтәреп, җансыз караш белән күзен ачты. Гыйльманов тагы трофей вино эчерде. Шуннан соң гына Милашкин иреннәрен авыр гына кыймылдатып сөйләшә башлады. Кулларына таянып кына тора алды, ни өченлер аска җәйгән чыршы ботагын борынына китереп иснәп торды, аннары ике куллап башын учлады. Ул һаман үзенең исән булуына ышанып җитми иде бугай. Ә кичке ботканы трофей эчемлек белән сиплэп алган солдатлар телләрен худка җибәрәләр. Аларның кайберләре әнә шулай әллә ничә үлеп терелгән, уйлап та бирмиләр.

— Ну парин, теге дөньяда ничегрәк?— дип шаярта берсе.
— Ичмаса хур кызларын коча алдыңмы?— ди икенчесе. Шуннан китә.
— Анда да налог сорыйлармы?
— Шонкир-монкир ничә тапкыр башыңа гөрзи белән кундырды?
— Нинди сораулар бирәләр, шулай да?
— Хатынга хыянәт иткәнеңне әйттеңме?
— Юк, Милашкин андый түгел, тәкъва ул.
— Хатыныннан куркып torгандыр әле.
— Ә кем хатыныннан курыкмый, ә? Сөйләсен!
— Курыккач, ничек ярату булсын, тиле!— дип, Латышев кулын селтәде.
— Куркасың да, яратасың да! Нигә исегез китте!
— Минем хатын шикәр кебек ак, шәп тә инде, ну исән генә кайтыйм...
— Хатын-кызны яманларга яратабыз, ә үзебез?
— Юк, хатын-кыз тугры булырга тиеш, ул бит бар нәрсәнең башы...
— Ир-атка бераз гөнаһ та ярый. Хатын-кызлар безне гөнаһлы күе дә яраталар.

— Үзебез хатын-кыз гөнаһын бер дә инде гафу итмибез.
— Гафу иткәнеңне бәяләми бит ул, юк!
— Акыллы булса, кадерен белә.
— Нинди хатынга туры киләсең бит, анысы бәхет эше.

— Каян беләсең акыллымы, түгелме икәнен?

— Йөргәндә чамаларга кирәк.

— Кызлар кырык карта, башта ал да гөл, татлы-тәмле, аннары убырга әйләнәләр.

— Гашыйк булып өйләнергә ярамый,— диде Латышев, яшьләргә үгет биргәндәй, Мирхасның җилкәсенә төртеп.— Андый чакта күзең сукырая, колагың чукраклана, берни күрми капкынга килеп эләгәсең.

— Ну әйттең син дә, капкын, имеш?— дип кемдер өлкәнрәк берәү аңа каршы төште һәм күләргә тотынды. Бу караңгы почмактагы, һәрчак Латышевка каршы төшәргә яратучы Маламишкин икән. Латышев аның ягына кул гына селтәде һәм бу сөйләшү мәгънәсез, дигән кыяфәт белән блиндаждан чыгып китте. Күбрәк үзе сөйләргә ярата, сүзен җөпләмәгәнне өнәп бетерми иде ул.

— Яхшы хатыннан да яхшы нәрсә юк, начар хатыннан да начар нәрсә юк,— дип кайсыдыр авыр итеп уфтанды. Милашкин йоклап киткән иде, Гыйльманов сөйләшүчеләргә кулы белән ишарәләп, барыгыз да эшегездә булыгыз, диде һәм чыгып торырга кушты. Кайсыдыр үзенең шулай Курск сугышы вакытында күмелеп калуын, шулай казып алып, үлемнән коткаруларын сөйли иде. Ләкин беркемнең дә исе китми, һәр солдат җанына үлем бер-ике мәртәбә кереп чыккан инде, аның белән танышлык бар, шөкер, дип, кулларын гына селтиләр.

Батареяга берәм-берәм булса да яңа «пополнение» килә иде. Аларны кайсын кая эшкә кушып, госпитальдә ята-ята катып беткән буыннарын яздырырга, онытылган службасын хәтеренә төшерергә туры килә. Кайберләре госпитальдән алгы сызыкка, ә алгы сызыктан госпитальгә эләгә-эләгә тәмам хәйләкәрләнеп беткән, үзен күбрәк кайгырту ягын карый. Дөрес, берсе дә үз бурычын онытмый, шулай да әйтә тормасаң, тезгенне бушата, якындагы хуторларга таба караштыргалый башлый. Сугыштагы солдатның психологиясе үзгәрәк була, хуторга барса, кайбер тыныч тормыш тәртипләре белән хисаплашып та тормый ул. Бу яктан Урта Азия халкы бик тәртипле, яралы атны суеп, аш пешерсә пешерә, әмма утарлар тирәсенә әйләнеп тә карамый. Ләкин пушканы өйрәткәндә үзләре белән чиләнергә туры килә: русчалары юк, ә белергә кирәк, шунсыз мөмкин түгел. Өчмөхәммәтов һәм Дүртмөхәммәтов фамилияле ике шул як кешесе килгән иде. Казакъмы, кыргызмы алар, белмәссең. Идрисов шуларга өч көн буе прицел приборын өйрәтеп азапланды, тик бернигә ирешә алмады. Өченче номер итеп снаряд ташырга куярга туры килде. Ә бит үзләре бик тырыш, авыздан чыккан һәр сүзне үтәргә генә торучы ягымлы кыяфәтле егетләр. Идрисов элек үзенең русчасыз җәфа чигүен исенә төшерде дә егетләрне артык газапламады, әкренләп сугыш өйрәтер әле, диде.

Ике-өч көн үтте микән, тагын немец «мессеры» төнлә килеп батарея урнашкан җиргә бомба ташлап китте. Бу юлы постта торган бер солдат кына яраланган иде. Ул шул хәтле каты кычкырды, ә ярасы аллә ни түгел, балтыр итенә ярчык кергән икән, әмма артык каты курыккан булса кирәк. Бәйләргә санитар Латышевны чакыралар, эзлиләр, ә ул юк та юк. Ахырда бинтны сүтеп чалбары өстеннән генә урап куйдылар да тизрәк машинага утыртып санбатка озаттылар. Ә Латышев иртән дә, көндез дә күренмәде. Ачыклый башлагач, тагы шул беленде: ул өч көн инде батареяда юк икән. Аның белән карулашырга яраткан Маламишкин әйтеп тора: өченче көн инструктажга дип эвакогоспитальгә киткән дә шуннан кайтмаган әле. Берәр сестрага кармак салган булса кирәк, бер дә бүтән түгел, кайтыр, ди көлемсерәп. Алла алмас, эт ашамас үткен кеше ул Латышев дип, аның холык-фигылен сөйләп куя. Әйе, Латышев күпне күргән шомарган таш, үзе чи рус булса да казакъча да, үзбәкчә дә, тагы җитмәсә — чувашча да сөйләшә белә икән. Монысы тагы да гаҗәбрәк һәм Латышевны сергә төрә иде. Машина белән якын-тирә хуторларга барып эзләп кайттылар, ләкин суга төшкән кебек бер җирдән дә табылмады. Бу бик

хәтәр нәрсә иде, бөтен биографияң пычранып куюы ихтимал, дип Идрисов чын борчуга төште. Аннары Мостафин каршында да оят. Ерак бара ала торган адәм түгел икән, дияр, ышанычын аклап булмады, шайтан алгыры! Каян гына килеп чыкты соң бу бәла? Фаяны үзебезнең батареяга, йә булмаса берәр җайлырак җиргә урнаштырып булмасмы, дип хыялланып йөргәндә генә бит...

Озакламый тикшерүче дә килеп житте. Иң элек Латышев белән аралашкан сугышчылардан белешә башлады. «Нәрсәләр сөйләде ул, ни сәбәпле шулай әйтте?» — дип төпченде. Өчмөхәммәтовка үзбәкләрнең базарда этәч сугыштырырга яратуларын сөйләгән. Акчалы уен икән ул. Җиңгән этәч хуҗасы җиңелгәннекеннән түләү ала. Тәмам канга батып, хәлдән таеп егылганчы этәчләр сугыша икән... Тикшерүче өчен болар яңа һәм кызыклы иде, юк, Латышевның сере ачылу ягыннан түгел, ә үзбәкләрдә шундый гадәтләр барын беренче тапкыр ишетүе булганга кызыклы. Ул, гаҗәпләнүен чыраенда яшермичә, әле үзбәк сөйләгәннәрне тәрҗемә итүче Идрисовка, әле Өчмөхәммәтнең үзенә карап, башын як-якка болгый иде.

Ә казакъ Кылычбаевка Латышев даладагы Елан дигән кышлакта яшәвен һәм аны бик чибәр бер казакъ кызының үзен яратып йөрүен сөйләгән. Тик анда кызларны калым дип атала торган акчага сатып кына алып була икән. Юк, дигән Кылычбай, казакъ кызы үзенең яратуын чит кешегә белгертмәс. Кояштыр, дип ант иткән Латышев һәм Ләйлә исемле кызның гүзәллеге, чаялыгы, иң кыргый аттан да курыкмавы турында сөйләп утырган.

Чувашларның да кайбер гореф-гадәтләрен белгән Латышев. Бу хакта Даниловка сөйләгән. Бер карт чуваш үләргә ята, ди. Инда өмет юк. Аның берүзен генә өйдә калдырып, барысы да тышка чыгып киталәр икән дә тәрәзәдән күзәтеп торалар. Берсе тәрәзәгә килә дә: «Иван, пирешмә», — дип пышылдый. Аннан икенчесе килеп: «Пирешмә, пирешмә», — дип кычкырыбрак әйтеп җибәрә. Шулай тегенең җаны чыкканчы тәрәзә аша кычкырып торалар икән.

— Шундый йола бармы? — диде тикшерүче, кызгылт йөзле Даниловка төбәлеп.

— Борынгы картлар гына тоткан андый йоланы, хәзер ул юк, — дип, Данилов шикләнгән сыман тикшерүчегә күз кырые белән генә сынап карап торды.

Латышев Маламишкин белән дә еш бәхәсләшергә яраткан. Бу юлы Германиядә унсигезенче елда булган революцияне искә төшереп акыл саткан. Гитлер безгә сугыш башлагач та, анда менә-менә революция чыгар һәм сугыш бик тиз бетәр, дип өметләнеп йөргән икән. Андый өмет белән йөрүчеләр ул вакытта бер мин генә түгел, күпләр иде, дигән.

— Герман революциясе җиңсә, мондый мәхшәр булмаган булыр иде, — дип уфтанган Маламишкин.

— Ни өчен җиңмәгән ул? — дигән кемдер. Латышев озак кына уйга калып торган, аннары әйткән:

— Нык куллы, нык башлы җитәкчеләре булмаган, — дигән.

Шуннан җитәкчеләр хакында сөйләшә башлаганнар. Акыллы булмаган кеше командир булырга тиеш түгел, дип раслаган Маламишкин. Аның акыллымы, дуракмы икәнен каян беләсең? — дип, Латышев аңа каршы төшкән. Бәхәсләшеп киткәннәр.

— Кешене эше буенча гына бәяләргә кирәк, сүзе буенча түгел.

— Гамәлдә алай гына булмый шул. Сүзенә дә карыйлар. Акыллы сүзләр сөйли, сүздә арыслан, ә эштә чыпчык.

— Менә шундыйны командир итеп куялар һәм син аның приказын үтәмичә кара...

— Иң ахмак приказын да үтәргә мәҗбүрсең...

— Юк, командир акыллы кеше булырга тиеш!

— Башлы булу әбәзәтелни түгел, каты куллы булу кирәк,— дип, сүз кыстыра Гыйльманов, бераз тыңлап утыргач. Шул чак Латышев кызып китә, Гыйльмановка әллә бер шөребең бушаганмы синең, дип әйтеп ташлый.

— Соң әнә Гитлер дурак каты куллы булып немец халкын нишләтте, ә? Хәзер Гитлерның чын мисез адәм икәнен әйтергә була инде, шөкер.

— Немецлар шуны һаман әле аңламыйлар...

— Һе, аңлап нишли аласың, Гитлер власте зур, көчле гигант машина әле, кандала урынына сыта ул сине.

— Ул пропаганда ярдәмендә алла кебек итеп халык миенә сеңдерелгән, аны тиз генә бетереп булмас,— дип, Кардәшев тә сүзгә килеп кушыла.— Гитлер үзе дөмеккәч тә әле дәвам итәчәк...

— Юк, беткәч бетә инде ул, точка!— диешәләр солдатлар.

Аннары тагы акыл мәсьәләсенә әйләнеп кайталар.

— Командир акыллы булырга тиеш дисең син, Маламишкин,— дип уйчан кыяфәт белән әйтә Кардәшев.— Мин дә шулай уйлыйм. Ләкин кеше дигәнең үзенең акыллымы, түгелме икәнен белми бит! Менә син акыллымы, юкмы?

— Ул акыллы икәнен белә, әнә бит җыелыш саен каршы сорау бирмичә калмый,— дигән булып, Латышев сүзне кинаягә бора.

— Нигә, ул бәлки шулардан рәхәт табадыр.

— Юк ла,— ди Маламишкин кулын селкеп,— мин фикер аңлаешлырак булсын өчен, уйны үткенләр өчен генә шулай итәм. Каршы фикер икенче фикерне китереп чыгара...

— Һәм сине медаль исемлегеннән төшереп калдыра,— дип, Латышев көлеп җибәрә.

— Каршы фикер әйтү аның өчен медаль алу белән бер,— дип, кайсыдыр тагы кеткелдәп куя...

Бу сүзләрне ишетү ничектер тикшерүчегә дә, Идрисовка да гыйбрәтле иде. Эчләрен күпме яшерергә, белгертмәскә тырышып тыңласалар да, күзләрендә кабынып киткән яки кинәт сүнгән очкыннан барысын чамаларга була иде.

Латышев тагы Мирхас белән Мөслимов урнашкан блиндажга килеп, мин татарларны яратам, дип икра чәчеп йөргән. Әллә нинди генә сәер халык ул татарлар ди-ди сөйләнгән.

Сөйләргә, аралашырга ярата торган булган Латышев. Әзрәк көмешкәмазар тамагына эләксә, төн буе сөйләп тә арымаган. Билгеле, ул сөйләгәннәрнең барысын да белү мөмкин түгел хәзер, ә сугышчыларның тикшерүчегә аның сүзләре итеп әйткән фикерләрдә сагаюлары, үзләрен ак калдырырга тырышулары да сизелә. Бер кешенең сүзләрен икенче берәүгә җиткергәндә төгәллек булуы мөмкин дә түгел. Хәтта җир белән күк шикелле аерма ихтимал. Чөнки кешенең (бу очракта Латышевның) теге яки бу сүзне нинди җәһәттән, нинди мәгънә салып әйтүе тикшерүчегә төгәл килеп җитә алмый. Шундый хәлнең корбаны булган кешеләрне күрергә, белергә туры килгәне бар Идрисовка. Латышев болай батареядагы тупчыларның күпчелегенә ошаган, ачык йөзле, хәлгә керә торган кеше иде диләр. Ә Милашкин исә аны нигәдер яратмаган, әз генә төшереп алса бик мактана иде, шуңа күрә ошатмадым, ди. Мактанчыкны берәү дә өнәми, ә күпләр мактанырга ярата, дип уйлады Идрисов.

Ниһаять, Латышев белән аралашкан сугышчылардан мәгълүмат алынып бетте. Бу эш вакытында Идрисов тикшерүченең вакчыл булмавын, кеше бәласеннән үзенә уңыш алырга омтылучы түгел икәнен чамалап алган иде. Блиндажда икәүдән-икәү генә калгач, тикшерүче болай сүз башлады.

— Теге якка сызмадымы икән?— дип, туп-туры Идрисовка текәлде.

— Юк, булмас!— диде Идрисов каты гына. Ул кемнең дә булса шундый эш эшләвен башына да китерә алмый иде.

— Сез аны яхшы беләсезме?

— Беләм дип әйтә алмыйм. Андый начарлыкны эшләмәс!

— Бу җавап түгел!

— Монда ниндидер аңлашылмаучылык бардыр.

— Бу җавап та безне канәгатьләндерми. Конкрет җавап бирегез: йә «бар», йә «юк».

— Юк, дим, Латышев тугры кеше булырга тиеш.

— Өстегезгә күбрәк алмыйсызмы?— диде тикшерүче һәм, кәгазьләрен портфеленә тыккалап, урыныннан торды. Йөзе үзгәреп китте, житди, пошаман сала торган кыяфәт белән Идрисовка кулын бирде дә, уңышлар теләп, чыгарга борылды.

Тикшерүченең шулай үзгәреп, ачулы төстә китүе Идрисовны тагы да борчуга төшерде. Нинди кеше булган ул Латышев? Эт еккыры, нигә ул аны бер дә чамалый алмады? Менә шуның өчен генә җык күр, комбат итеп тә расламаслар инде, мондый җаваплы эшкә башың сай, җилкаң кәй, диярләр...

Эчтән үзен һаман гаепле итеп танийсы килми иде. Ә танырга һәм ниндидер чара табарга кирәк. Күңелендә китеклек борчып тора, шуны томалар өчен ул: юк, Латышев алай начар ниятле кеше булмаска тиеш, дип тукый да тукый. Якын-тирәдәге урманнар ничә тапкыр «тарап» чыгылса да, тагы шунда барып, эзләп йөри, үлеп-нитеп ятмыймы, дигән уй аңа тынгы бирми иде.

Латышев ни тере килеш, ни үле килеш дигәндәй, бер җирдән дә табылмады. Оперативниклар Идрисовны тагы чакырттылар. Бу хәл буенча ниндидер карарга киленергә тиеш иде.

Башта теге тикшерүче эшне аңлатты, Латышев хакында сорашып белгәннәрен тасвирлады. Шактый гадел булырга тырышып сөйләде шикелле. Артык сизгерлек күрсәтеп, тискәре якларга басым ясамады. Шулай да Латышев бик үк тотрыклы кеше булмаса кирәк, диде. Чөнки күп сөйләүчән булган. Ләкин аның серле рәвештә югалуында берәр бәхетсез очрак юкмы икән? Билгеле, комбатның күзе житмәгән, бәлки бу тәҗрибәсезлектән киләдер, дип Идрисовка да тиеп үтте.

Тикшерү Идрисовка (карточкасына язып) шелтә бирү белән тәмамланды. Монда карулашып торырга ярамый иде. Кайчак гаепсезлегеңне исбат итеп булмый торган гаепләр башка төшә, бернишли дә алмыйсың. Бары эчкә йотарга өйрәнергә һәм түзәргә кирәк. «Түз, йөрәгем, түз, бүләк бирермен»,— дип юанган ди берәү.

Чыгуга аны каядыр үтеп баручы Мостафин очратты. Идрисовның борчылганлыгы борынының ике ягы кызарып торудан беленә иде.

— Каты пешерделәрме?— диде шаян тавыш белән Мостафин. Үзе аңа елмаеп карап торды. Әллә мине көтеп торган инде, дип уйлады Идрисов һәм елмаеп җавап кайтарды.

— Тозлап, борычлап, кимен куймыйлар...— һәм тынычланыр өчен тизрәк папирос алып капты.

— Командир авырлыкны да күтәрә белергә тиеш. Моңа алдан үзеңне хәзерләп куярга кирәк. Әнә, ата-ана күпме җәфа кичерә, ә берсен дә балаларына белгертми бит...

— Юк, мин болай ярыйсы,— дип, Идрисов Мостафинга күз төшерде, нәрсәгә ишарә итә икән бу, дигән уй миен бимазалап торды. Бераздан командиры нәрсәне күз алдында тотканын аңлагандай булды: шелтә синең ачуыңны китерергә тиеш түгел һәм ачуың үзеңнең кул астындагылар өстенә чыкмаска тиеш...

Шуны аңлагач, Идрисовка җиңелрәк булып китте. Һәм Мостафинның ихлас күңел белән сөйләшүе җанда утырган ачу юшкыннарын кырып төшергәндәй итте. Алар ызаннар белән бүгәләнеп беткән басу юлыннан бара-бара төрле нәрсәләр турында, ачылып, ниндидер тәм табып сөйләшәләр иде.

— Болар бигрәк үз җирләренә нык береккән халык инде, колхоз ничек төзелер монда?

— Крестьян гомергә кара акылга беткән нәрсә, аны тиз генә борып булмый.

— Латышлар сандал белән чүкеч арасында яшәгәннәр инде, Европа үзенә тарткан, Рәсәй үзенә каратырга тырышкан.

— Крестьянның башы борылса да, кара акылы борылырга ашыкмый. Үзенә яхшыны да тиз генә аңламый ул.

— Адәм баласы үзе белмәгән нәрсәгә дошман булыр дигәннәр.

— Бездә дә ярлы крестьян томаналыгы аркасында күпме акылын җуеп маташты?

— Яңалык өркетә инде. Үзебездә дә битниләр генә булып бетмәде?

— Яңалык башта куркыныч тоела, соңыннан әйбәт булса да...

— Әй, безнең эти дә шүрләде ул колхоздан,— дип, Идрисов елмаеп сөйли башлады.— Керми дә керми. Нәрсәдер көтә. Мин мәктәптә пионер вожатые идем, агитбригадага алдылар. Авыл саен концерт биреп, колхозга өндәп йөрибез. Мин декламация сөйләргә маһир идем. Шулай бер авылда манарасы киселгән мәчеттә тамаша күрсәтәбез. Бер пәрдәлек кенә. Аннары җыр, бию. Пьесаны әйбәт кенә ерып чыктык. Биюдән соң мин колхозга өнди торган шигырь сөйлим. Шул чак залдан кемдер кычкырды: «Син үзең дә колхоз түгел, кулак сандугачы, сайрама! Колхоз әйбәт булса, үзең кер әнә!»— ди. Ишетмәмешкә салышып, һаман сөйлим. Тагы кычкырды бу. Кайсыдыр ачы итеп сызгырды. Шау-шу купты. Берсе мич артыннан ямьсез сүзләр белән сүгенә. Җитәкче пәрдәне төшерергә мәҗбүр булды. Икенче көнне ул минем колхоз түгел икәнемне белеп, агитбригададан куды. Әтигә шундый ачуым килеп кайттым. Кеше күзенә күренергә оялам. Шәһәргә сызарга уйлыйм. Әмма русчам начар. Күршедә рус боярында эшләп үскән Нуретдин абзый бар иде, шуларда көне-төне ятып, русча өйрәнәм. Эшен эшләштерәм, этидән яшереп инде. Җәй җитте. Эти минем эшне сизде бит. Бер көнне бик каты ачуланырга кереште. Каршы дәшкән идем, яңакка чалт берне! Бар ачуымны эчемә төеп, мич башына менеп яттым. Әтидән үч аласы килеп, төне буе йокламадым. Кызган башта тәвәккәллек тиз туды. Китәргә булдым. Ничек? Акча кирәк бит. Эти иртәгә тырмага барырга дип, атны тышаулаган иде. Караңгылыяктылы вакытта шыпырт кына тордым да атны тотып йөгәнләдем. Әйдә, сары бия! Келәүле станциясе кырык чакрым. Беткән баш беткән. Станция базарында атны сатып җибәрдем. Тик акча кулга кергәч кенә айнып киткән кебек булдым. Нишләдем мин тиле, дим. Үчем таралды, аек уй килде. Әтине түгел, сары бияне кызгандым. Аннары әтине дә җәлләдем. Нишләр ул мескен? Тик чигенер җай калмаган иде инде. Шул китүдән кайтмадым...

— Атсыз калгач, әтиең дә тиз кергәндер колхозга, ә?— диде Мостафин көлеп.

— Шул. Бер атна да узмаган, атны караклар типте дип гариза илтеп биргән.— Идрисов үзенең сүзләрен Мостафин да ихлас кызыкка алганын, елмаюыннан күреп, тагы дәртләнеп китте. Күңелендәге юшкыннар эреп төшкәндәй булды.

— Үз атын үзе урлар дип кемнең уена килсен, ә?

— Инде-инде!— диде Идрисов, тәмам кәефе күтәрелеп.— Яшь чак, башсыз чак инде.

— Юк, гаярь чак диген. Сугышта да бит күбрәк яшьләр тәвәккәл.

Идрисов ым какты да, алар тынып бара башладылар. Идрисовның башына Мостафин турында әйбәт уйлар килде. Ул аның бәлане бер аңа гына өеп ташламавына, начальниклардан курыкмавына сокланды. Юкса, начальник алдында калтырап төшеп, ялгызыңны чоңгылга этүчеләрне дә күргәне булды. Аннары Мостафинның үзен акыллы итеп күрсәтергә тырышмавы да аңа ышанычны арттыра иде.

Мостафин шактый гына уйланып барды, әмма йөзендә Идрисов биргән сораулардан читенсенү ише нәрсә сизелмәде.

— Сугышта баштан укмы?— дип сорады ул кинәт кенә.

Идрисов фин сугышында яралануын, шуңа күрә госпитальдә озак кына ятып, фронтка бары кырык икенче елның башында гына эләгүен, аннары тагын ике мәртәбә яраланып, дәвалануын әйтеп бирде. Шуннан соң гына Мостафин сүзне әлеге четерекле мәсьәләгә китереп, болай диде:

— Алгы сызыкка килгәндә кеше үзенең куркакмы, түгелме икәнен белми әле. Үзен батыр дип уйлый, шулай сөйләшә дә. Үлем белән күзгә-күз килгәндә, эш төрлечәрәк килеп чыга.

— Кискен ситуациядә үзеңне ничек тотасыңны алдан белеп булмый шул,— диде Идрисов та килешеп.

— Шуңа күрә рухи чыныгу кирәк.

— Кешене нәрсә рухи чыныктыра соң?

— Уку, аңлы булу, идея иманганлыгы...

— Укыган кеше рухи яктан көчлерәк буладыр анысы...

— Әйе, үзен-үзе ныграк белә, шуңа башкаларны да күбрәк аңлый, хәлне тизрәк төшенә. Инанган иманына ныграк таяна ул.

— Әһә, чынлап та,— дип Идрисов бу фикерне аңлавына һәм аның үз уйларына туры килүенә шатланды.

— Шуңа күрә кешенең инанган нәрсәсе тормышчан, реаль җирлекле булырга тиеш.

— Менә нәкъ шулай, анда каршылыклар булмаска тиеш,— диде Идрисов тагы шатланып.

— Әйе, гамәли каршылыклар булмасын!

— Ул яктан бездә очы-очка ялганмаган нәрсәләр булгалады.

— Тач шул нәрсә башта каушап калуларга, фаҗигаләргә китерде дә.

— Анда кайчак хыянәтче хәленә төшүеңне үзең дә сизми кала идең.

— Кискен моментта салкын канлы булып кала алу — сугышта иң зур бәхет.

— Нәкъ. Уенда да салкын канлы кеше күбрәк ота.

— Ул вакытлар искә төшсә, хәзер дә аркалар чымырдап китә. Шул мәхшәрдә ничек бәлагә юлыгылмаган дип, шаккатып уйлыйсың...

— Хәзер ул яктан бөтенләй башка күренеш бит: бар төштә ныклы тәртип, корал-ярак көчле һәм күп...

— Шулай да башны ныграк эшләтәсе нәрсәләр шактый әле,— диде Мостафин хәстәрле төс белән.— Ныклап уйланылмый башланган һөҗүм — башланганчы ук җиңелә дигән кагыйдәне онытырга ярамый.

— Башланганчы ук җиңелә диген, ә?— дип Идрисов нигәдер тамак төбе белән кеткелдәп алды.— Баксаң шулай бит, шайтан алгыры!

Уйланып, сөйләми генә бара башладылар.

— Һи-и, ул чакларда ниләр генә булмады,— диде Мостафин сүзне ялгап.— Миңа бервакыт бик сәер кеше белән очрашырга туры килде. Кырык икенче елга чыккач шулай Калининнан ары һөҗүмгә хәзерләнәбез. Бик суык вакытлар. Мин штаб тирәсендә эшли идем. Алгы сызыкта торучы бер артиллерист үз кулына аткан. Уч төбенә калын гына телем ипи куйган да — шарт! Әмма врачлар белгәннәр. Хөкем иттеләр. Миңа аны тылга, тиешле урынга алып барып тапшырырга куштылар. Әмма салып алган, әй, сүгенә, каргана бу. Мин тылга китәм, ә син тәмугта каласың, ди. Себердә инде башка бомба ташламыйлар, ә сезне чебен урынына кырачаклар, фәлән-фәсмәтән. Әйдә, безнең таш башларга шунсыз акыл керми, ди-ди мине тәмам чиккә җиткерде. Халык нужасына сөенүен әйт син мөртәтнең...

— Шулай да акыл мәсьәләсендә дөрес сукалаган ул,— диде Идрисов уйчан, салмак рәвештә.— Нужа күрми, акыл керми ата балаларына диләр бит...

Идрисовның бу сүзләрен яклавын яки өнәмәвен Мостафин ым белән дә, йөз сызыклары белән дә белгертмәде.

— Каян шундый хәлләр килеп чыкты икән? Башка сыймый,— диде Идрисов, элекке уңышсызлыклар өчен уфтанып.

— Эшлеклелек җитмәгән, карар чыгарылган да эшләгән эш итеп күрелгән. Сер түгел, кызыл сүз эшне алыштыра иде кайчак...

— Эшлеклелек каты куелгач, хәзер әнә ничек әйбәтләнде.

— Хәзер дә кешенең эшкә түгел, сүзенә әһәмият итеlә әле. Башны эшләтү кирәк, акыл...

— Баш эше авыр шул. Бервакыт алла шайтанны эш эшләтеп җиңмәкче булган. Ләкин шайтан нинди генә эш бирсәң дә ялт иттереп эшләп куя икән. Ахырда алла моңа баш белән уйлап эшли торган эш биргән. Шунда гына шайтан җиңелгән, ди...— Идрисов кеткелдәп көлгән кебегрәк итеп куйды, Мостафин да аңа кушылып, елмайды, кәефе килгәндәй булды. Бу вакытта алар бер юл чатына килеп җиткәннәр иде. Мостафин туктады, үзенең дүртенче батареяга барганлыгын әйтте. Папирос алып кабыздылар да икесе ике якка киттеләр.

Бу Латышев аркасында үзенең чак кына штрафбатка эләкми калуын һәм командирының аңа хәерхаһ булуын уйлап, Идрисов эчтән генә сөенәсөенә атлады.

Латышевның югалуы бөтен эшне тизләтте. Батареяга замполит бирделәр дип, Асоев шалтыратты. Бәхетең, бик эшлекле кеше, диләр, капитан Тафтиловны, диде. Сөенечле хәбәр бу, дип Идрисов аңа рәхмәт әйтте, ә күңелендә капитан дәрәҗәсе әллә нинди шик тә уятты. Минем урынга җибәрмиләр микән? Башта көчләп диярлек аңа таккан бу урынны хәзер югалтасы килми иде.

Аның ерак бер складка запчастьлар белешергә барасы бар иде, иртүк шунда китте. Анда эше уңмады, шуңа күңеле кителеп, тәмам эт булып арып, батареяга төнлә генә кайтып керде. Кухняда аңа җиткерделәр: замполит килде, диделәр, ниндидер сагайган, әзрәк шүрләгән дә төс белән. Ул кухняда булган, төшке аш ашаган. Шул арада да кимчелекләрне күреп, шактый кискен сүзләр әйткән. Бәйләнчек нәрсә икән, дип нәтиҗә чыгарганнар мондагылар.

Пушкалар кухнядан әллә ни ерак түгел иде, кырдан әзрәк баргач, Идрисов кызыл почмак өчен әзерләнгән зур блиндажга керде. Керүгә аңа каршы түгәрәк тулы йөзле, аска таба киңчә яңаклы, кечерәк борынлы капитан сукыр лампалы өстәл артыннан күтәрелде. Ул нәрсәдер язып утыра, йөзе җитди, кашлары җыерылган иде. Күрешкәндә дә аның йөзендәге рәсмилек бетмәде. «Батарея хакында начар фикер әйтеп җибәргәннәр инде моңа»,— дип уйлады Идрисов. Ул ничектер аңа гаепле кешегә караган шикелле карый иде. Шуңа күрә күрешкәндә әйтелә торган «Кайдан, ничек?»— дигән сораулар да авыздан чыкмады. Тафтиловның кыяфәте бик эшлекле, гүя ул элек тә биредә еш булган һәм монда бөтен нәрсәләр аңа ачык билгеле. Ул батареяга иртүк килгән һәм бөтен төшне бер кат тикшереп чыгарга, күп кенә җитешсезлекләрне күрергә өлгергән икән.

— Безобразие, комбат,— дип, тотынды ул.— Батареяда тиешле тәртип юк. Карабиннары чистартылмаган, шинель түгел, эшче фуфайкасы киеп йөриләр... Хәтта каеш та бумаганнар...— Замполит шулай тезде дә тезде. Идрисов бераз аптырап калды, чөнки танышмас борын шулай канәгатьсезлек белән битенә бәргәнне очратканы юк иде. Тыловик икән бу, дип, Тафтилов сөйләүләреннән үзенә нәтиҗә дә чыгарды. Чөнки замполит карабиннарга әһәмият иткән, ә фронтовик исә пушка янында траншеялар казылмавына беренче булып әһәмият итәр иде. Тупчылар өчен ул иң кирәкле саклану чарасы. Аннары фуфайка киеп йөрү монда гадәткә кергән, чөнки ул җылы да, эш эшләгәндә уңайлы да. Моны тыловикка ничек итеп аңлатасың?

— Политзанятиеләрне оныткансыз,— диде Тафтилов, моңа аерым басым ясап. Бөтен җитешсезлекләр дә политзанятиеләр булмаудан килеп чыккан шикелле иде.

— Юк, лекторлар атна саен килеп торды,— диде Идрисов, ниһаять исен җыеп. Замполит, мөгаен, Латышев мәсьәләсен ишеткәндер, шуңа күрә политзанятиеләргә аеруча зур игътибар итәргә уйлыйдыр.

— Занятиене практика белән тыгыз бәйләп үткәрергә кирәк, юкса ул сүз генә булып кала,— дип Тафтилов зур фикер әйткән төсле кашларын җыерды. Идрисов аның битендә эре-эре сипкелләр булуын күреп алды, ә кул аркасында ул сипкелләр касмак кебек тагы да ныграк беленеп тора иде.

— Без нәкъ шулай эшлибез хәзер. Бәрелеш вакытында килеп чыккан кискен ситуацияләрне җентеклибез, шунда үзеңне ничек тотарга кирәклекне өйрәтәбез...

— Ничек алай?— диде Тафтилов аңламыйча һәм Идрисовка, шыттыра ахры бу дигән кебек карады.— Политик инанган кеше бернинди хәлдә дә куркып калмый. Инануга басым ясарга кирәк!

— Инану бик мөһим нәрсә, кешенең ныклыгы шуңардан тора, әмма ул гына җитми...— дип, Идрисов теге немец контратакасы вакытында булган хәлне сөйләп алды.— Бер бик активист сержант бар иде, пушкада төзәүче. Һәр җыелышта ялкынлы речь тотмый калмый. Болай уй-фикере белән чын патриот инде. Әмма немец танкылары пушкага якынайган бер арада югалып, куркып кала, шулай итеп расчетын, үзен дә харап итте...

— Ну, бу бер очрак кына.

— Монда күп нәрсә очрактан тора, шундый очраклар булмасын өчен, сугышчыны курыкмаска өйрәтәбез.

— Сәер, сәер, бер дә ишеткәнем юк иде. Юк, бу ерунда! Монда әллә куркаклар җыелганмы?

— Юк, ләкин барысы да госпитальдән килгәннәр. Анда шактый иркәләнеп, үзләре турында күбрәк уйларга гадәтләнгәннәр.

— Ул гадәтләрне ничек кырып төшерәсез инде?— диде Тафтилов кинаяле төрттермә белән. Ул Идрисов сүзләрен чынга алмый иде, ахры.

— Нинди кискен хәлләр килеп чыгасын пушка янында күрсәтеп, төшендерәбез. Иң мөһиме — югалып калмау, хәлне дөрес бәяләп, дөрес хәрәкәт итү...

— Юк, әллә нәрсә бу, аңламыйм,— дип, Тафтилов иякләренә таянды.— Политик аңы нык кеше курыкмаска тиеш. Шул җитмиме?

— Анысы шулай аның, дөрес әйтәсез...

— Просто курыкмаска и бетте!

— Уй белән шулай уйлана ул, әмма гамәлдә бөтәнчәрәк килеп чыга. Ә курыкмаска кеше әкренләп өйрәнә, әкренләп...

— Сәер, сәер!— диде Тафтилов күпме сөйләсәң дә барыбер барып җитми миңа дигән шикелле тавыш белән. Идрисов исә бу хәлне ничек аңлатып бирергә белмәде, моны кеше үзе кичермәсә чынлап та аңламас шул дип уйлады. Үзе ул курыкмаска әз-әзләп өйрәнгән иде, дөресрәге, курыкмаска күнеккән иде. Мәсәлән, ул башта тирә-юньдә снарядлар төшеп шартлаганда, шулардан блиндаж селкенеп торганда йоклый алмый иде, хәзер исә уйлап та бирми, блиндаж тирбәлүе бишек тирбәлүе кебек кенә, изрәп йоклап китә. Тагы бик күп шундый вак нәрсәләрне күрсәтергә мөмкин.

Икенче көнне Тафтилов сугышчыларны кызган табага бастыргандай итте. Һәрберсенең теге яки бу ягын ошатмыйча каты-каты сүзләр әйтте. Мылтыкларына, сырган фуфайка киюләренә бәйләнде. Ләкин һич ярамаган бер нәрсә, үзен алардан өстен итеп куйганлыгы сизелеп тора иде. Солдатлар аның кычкыруын тыңлап, киеренке йөз белән буйларына сеңдереп тордылар. Идрисов та замполитның бу кырыслыгына артык әһәмият итмәде, ярар, әйдә, кычкырынсын, туктар әле бер, дигән кебек иде аның төсе.

Аннары Тафтилов комбатның занятие үткәрүен күзәтте. Бер пушканың ике ягына озын траншеялар казып куелган. Дүрт йөз метр алда такта танк, аны озын бау белән тартып хәрәкәткә китераләр. Бөтен сугышчылар катнашында пушка өчен кискен хәл тудырылып, расчеттагыларның эше

күзәтелә... Тафтилов чыраен сытып күзәтте, сытыклыгы һич бетмәде. Болар аңа ничектер мәгънәсез уен булып күренә иде шикелле. Монда мылтыкның һич кирәге чыкмый, пушка белән эш итәргә өйрәнү, кеше кискен моментта нинди ялгышлар җибәрүе мөмкин,— бар шөгыль шул иде.

Тафтилов көн дә җыелыш җыя башлады. Монда да шул батареядагы җитешсезлекләр хакында сүз куерта, кайбер бәйсезрәк йөргән сугышчыларны тәнкыйтьләп ала. Ләкин артык вакчылланып чаманы югалта иде. Ул Маламишкинны ике-өч мәртәбә телгә алды.

— Мылтыкны чиста йөртмәү — дошман тегерменөнә су кою ул!— дигәч Маламишкин урыныннан чәчрәп торды, күзләре зур булып ачылган, керфекләре энәләр кебек тырпайган иде.

— Минме су коям, минме?!— дип кычкырып җибәрде ул күкрәгенә йодрыгы белән суга-суга һәм замполитка бик ачы-ачы сүзләр әйтеп ташлады.

— Молчать!— диде Тафтилов муен тамырларын кызартып. Ләкин Маламишкин үзенекен әйтеп бетермичә туктамады. Аннары Тафтилов иң тәртипле, бөтен батареяга үрнәк кеше, төзүче Кардәшевка да тел тигерде. Противогазны алып ташлаган да шул сумкага прицел приборы салып йөртә дип чәнчеп алды. Тагы вак кына нәрсәләрне дә әйтте. Мәсәлән, Кардәшевның хатыны укытучы булып, ул хатларын гел шигырь белән язып җибәрә иде. Кардәшев шул шигырьләрне төрки сугышчыларга кычкырып укыштыра иде. Замполитка шул нәрсә ошамаган икән.

— Әй, бәйләнмәгез сәнә!— дип ни сабыр Кардәшев тә йөзен читкә борды.

— Молчать! Мин ничек Ватанны сөяргә өйрәтермен,— дип кычкырды Тафтилов. Тагын Зәйнуллинның офицер ремене белән йөрүенә бәйләнде. Аның кесәсендә пистолет йөртүен уставны боза торган партизанлык дип атады. Мирхас каршы бер сүз дә эндәшмәде, замполит сүзләрен ишетмәгән кыяфәт белән утырды. Шушы күренеш үзе генә дә замполитның сугышчылар каршында авторитеты төшкәнлеген күрсәтә иде. Ләкин Тафтилов бу хакыйкатьне искәрми, аңа хәзер бу хакта әйтсәң дә аңламас кебек иде.

Сугышчылар чыгып, блиндажда үзләре генә калгач, ул Идрисовка ташланды.

— Демократ булып кыланып, сугышчылар алдында ялган авторитет казангансың!— диде һәм шул темага әллә күпме фәлсәфә сатты. Идрисов мондый кызу куыра торган кешеләрне очратканы бар иде, тел кайтарудан тыелды. Бу бик намуслы кешедер, дип уйлады эчтән. Алар шулай бераз вакчылланып тотыналар эшкә, бөтен нәрсәне берьюлы әйбәтлиселәре килә, аннары гына эзгә төшәләр. Чөнки бар нәрсәне дә тиз генә төзәтеп булмый, сабырлык кирәк. Моның әле алгы сызыктагы сугышчылар белән эшләү тәҗрибәсе юктыр.

Ләкин беркөнне Тафтилов сугышчылар алдында Идрисовка тагы кычкырынды. Монысы инде артык иде. Кухняда ашап утырганда Идрисов иплап кенә сүз башлады.

— Николай Петрович, сез миңа сугышчылар янында замечание ясамагыз, минә шулай икәүдән-икәү калгач, үземә генә әйтегез,— диде.

— Сез командир түгел, чүпрәк,— дип Тафтилов, кызарып, ашый торган кашыгын өстәлгә ыргытып торып китте һәм йөренергә тотынды.

— Ни өчен чүпрәк дисез инде?

— Сугышчыларның шөрепләрен бушайтып бетергәнсез, тугарылып йөриләр! Безобразие!

— Үзләренең эшләрен яхшы беләләр, тагы ни кирәк?

— Каршы дәшәләр, шулар булдымы сугышчы?

— Соң аларның җанына тимәскә кирәк.

— Ә панибратлык тагы да зарарлы.

— Кайда күрдегез сез аны? Юк ул!

— Бөтен мөгамәләгездә шул. Таләпчәнлек юк!

— Николай Петрович, сез бер нәрсәне абайлап житкермисез бугай. Юк-бар нәрсә белән үлем астында йөргән кешенең җанына тукыну әйбәт түгел. Аңа яки миңа ул үлем менә шушы сәгатьтә үк килер бәлки? Юк өчен аны кимсетсәм нәрсә булыр иде? Дөньядан рәнҗеп китәр, шул мәл дә бар бит әле. Таләпчәнлек кирәк, билгеле. Ә кеше үзенә кешечә караганны бәяли, ул аңа намус белән түли...

— Бу сезнең ялгышыгыз, комбат!— диде Тафтилов, кулын кинаяле селтәп. Бер кизәнү белән ихлас күңелдән әйтелгән сүзләрен сызды да ташлады. Идрисовның йөзенә кимсенү төсмерләре чыкты, битенә алсулык йөгерде.

Әкрен генә атлап блиндажына кайтканда, нәрсәдә икән минем ялгышым, дип, эче пошып уйланды. Бу кешенең җаен ничек табарга. Юк, ул алама кеше булмаска тиеш. Артык числыклы бугай ул? Аның белән эшләп булмас микәнни? Ул килгәнче сугышчылар үзләрен тыныч-салмак кына тоталар иде, хәзер бер-берсенә кычкырыналар, зәһәрләнеп сүгенәләр. Нинди дуслар Маламишкин белән Гыйльманов бүген нәрсәгәдер эләгешеп алдылар. Тизрәк һөҗүм башлансын иде, ул инде барча килешмәс-бәхәсләрне бик тиз хәл итә дә куя...

Тагы берничә көн шулай киеренкелек белән үтте. Идрисов өчен бу бик авыр иде. Менә Тафтилов аның блиндажына күчеп тора башлады, чөнки монда телефон бар иде. Икесе бергә яшәсәләр дә сүзләр берекми, фикерләр капма-каршы. Ни турында гына сөйләшә башламасыннар, фикерләрнең туры килмәве тагы да ныграк күренә бара. Берничә сүздән Идрисов тыелып, тынып кала иде. Ул үз сүзен өскә чыгарырга, кешене сүзләр белән җиңәргә тырышмый. Тафтилов исә үз фикеренең өстенлеген расларга җан фәрман килә, кешене сүз белән аста калдырырга омтыла иде кебек.

...Идрисов башына нидер бәрелүгә уянып китте. Төн урталары булгандыр. Блиндаж шыгыр-шыгыр килеп шул чаклы нык чайкалып китә, шартлаулар бик якын иде. Немецның төнге мессерлары тагы очып килеп үз эшләренә тотынганнар. Түшәм агачларының урта матчадан башлары ычкынып җимерелеп төшкәне ишетелә. Ут сүнгән, караңгы. Идрисов сикереп торды да ишеккә атылды, ләкин бер-ике адым атлауга нәрсәгәдер абынып, җиргә барып төште. Кармашып, ишеккә таба үрмәләргә итте, әмма колак төбендә генә куркынган тавыш ишетте.

— Комбат, комбат, нәрсә бу? Каян бу?!— диде калтыранган тавыш. Бу Тафтилов иде. Ул да идәндә икән. Әллә яраланганмы, сулышы бик еш һәм гыжылдап чыга иде. Идрисов бик тиз үзен кулга алып, шырпы сызды һәм мөкәләгән Тафтиловны күрде. Төсе-өне качкан, авызы-борыны канга баткан. Бер бүрәнә башы төшкән икән моңа, дип, Идрисов аңа ярдәм итәргә ашыкты. Тагы шырпы сызып, лампаны эзләп тапты һәм аңа ут элдерде. Тафтилов алдына тезләнеп, аны иңеннән кочты, нияте күтәреп торгызырга иде. Ни хикмәттер, Тафтиловның бөтен гәүдәсе бизгәк тоткан кебек калтырый иде. Үзе бер сүзне аңлаешлы итеп әйтә алмый, авыз эче тулы кан.

— Ни булды, Николай Петрович?— дип, Идрисов һаман аны иңеннән алып күтәрмәкче була, теге исә санын тота алмый, тагы бөгелеп идәнгә куллары белән таяна. Бизгәгеме, чиреме кузгалган, ахрысы, моның дигән фикергә килде Идрисов һәм тизрәк санбатка озатырга кирәк дип уйлады. Ул арада бар җир кинәт тынып калган иде, мессерлар киткәннәр. Шул чак тыштан:

— Бик эссе булмадымы? Башыгызга капмадымы?— дип Зәйнуллин тавышы ишетелде. Унган сержант ул-бу була калса дип ярдәмгә килгән иде.

— Замполит яраланды, давай мотоцикл!— дип кычкырды Идрисов, Зәйнуллиның шулай бик кирәк чакта килүенә эчтән сөенеп.

Бераздан алар һаман бөтен гәүдәсе калтырына торган, төсе бите кәгазьдәй агарган, авыз эче тулы кан булганга бер сүз әйтә алмаган Тафтиловны мотоцикл бишегенә чыгарып утырттылар. Мирхас аны шунда ук алып та китте.

Самолетлар һөҗүменнән батарея әллә ни зыян күрмәгән иде. Тик кайберәүләрнең колаклары бик нык тонган, шуңа күрә башларын як-якка селкеп алгалыйлар, учны колакка куеп, сыңар аякта сикергәлиләр. Су кереп чыккан малайлар кебек. Идрисов бомба чокырларын караганда Тафтиловны уйлады. Чирле кеше икән, бәлки батареяга бүтән кайтмас та. Аның бичара кыяфәте күз алдына килде дә, аны кешеләрчә җәлләп куйды. Тыштан тырпулы булса да, эчтән усал ниятле түгел иде. Аңа ияләнә дә башлаган идем инде, таләпчән булуын да күпмедер дәрәҗәдә хаклы дип уйлый идем... Тукта, ни өчен Тафтиловның кырыс хәрәкәтләрен аклаган шикелле итә әле ул? Аның яңадан батареяга кайтмавы һәм аңардан да корырак кеше килүе ихтималы булуданмы? Бәлки бу да үкенүгә якын уйларга төшерәдер аны. Ләкин иң дөресе — ул Тафтиловның йомшак якларын күрде, бигрәк тә бомбага тотканда. Хәзер ул аңардан һич тә курыкмый иде, үзен аның белән тиң итеп сизде.

Әмма дүрт-биш көннән соң Тафтилов тупырдап кайтып керде. Кыяфәтендә нindidер шатлык, күтәренкелек иде. Тәртип ярата торган кеше буларак, хушлашырга килгән, дип уйлады Идрисов. Аның бу фаразын ныгыткандай, Тафтилов өстәлгә печенье, кызыл балык консервасы чыгарып тезде. Идрисов тиз генә разведчиклары янына барып, Мирхастан яссы котелок белән чәй пешертеп алып килде. Затлы ризык белән каты чәй бердән кәефләрен күтәреп җибәрде.

— Мин анда күп уйладым һәм, комбат, сине аңлый башладым,— диде Тафтилов, җитди төстә. Аңарда хәзер элеккеге рәсмилекнең эзе дә юк иде.

— Мин дә шулай,— дип, Идрисов та ачылып елмайды.— Кай төшең яраланган иде соң? Ыгы-зыгыда белеп тә булмады.

— Юк, яраланмады, телне тешләгәнмен дә шул канады.

— Сине бизгәк тотты бугай, нинди чакта әләктереп ала диген?

— Бизгәк түгел,— дип Тафтилов күзләрен төшерде, кинәт күңелсезләнде.— Мин бик каты курыктым, комбат. Сиңа гына әйтәм. Ай-ай, курыктым, каушаудан үз-үземне белештермәдем. Яман да нәрсә икән ул курку! Үземне кулга алырга кирәклеген аңлыйм да, әмма эчтән нәрсәдер калтырата гына бит! Көн буе оятымнан нишләргә белмәдем, кеше күзенә карарга уңайсыз иде. Гүя алар минем куркак икәнемне күрәләрдер шикелле...

— Кайгырмагыз,— диде Идрисов дусларча,— үтә ул, үтә. Рас шулай аңлыйсың икән, димәк, бетте... Үземнән беләм.

— Синдә дә шундый булдымы?— дип Тафтилов кинәт яктырды. Аңа үзенең кимчелеге бүтәннәрдә дә булуы ышаныч бирәчәк,— күңеленә шул кирәк иде.

— Булмаган кая!— диде Идрисов, гәрчә аның андый курку бизгәге белән калтыранган чагы бернинди очракта да булганы юк иде. Бәлки киләчәктә булыр, кем белә сугыш хәлен?

Алар озак сөйләшеп утырдылар. Тафтилов китәргә кайтмаган икән. Идрисов моңа чын күңелдән сөенде.

— Дөнья ике килми, бергә эшлик әле.

Тафтилов һаман уйланып әкрен генә тәмәке көйрәтте. Шулай кинәт ачылып, үзенең эчендәге әйтеп ташлаганга үкенә дә шикелле иде. Идрисов аңа бүтән сүз кушарга кыймады. Йоклар алдыннан часовойларны барлап керергә чыкты. Ул, Тафтиловның эчкерсез кеше икәнен әлек тә чамалавын һәм шул гөманы бүген тагы расланауын уйлап, нindidер дәрт белән атлады.

Шул хәлдән башлап замполит уйчанрак, басынкырак була барды. Идрисовның ничек курыкмаска өйрәтүләренә йөз чытып карамый иде инде. Сугышчыга чын кешеләрчә булырга тырыша иде. Шулай итеп, ул алар белән уртак тел табуга да иреште. Батареядагы мөнәсәбәтләр әкренләп тигезләнә, ипләнә төште. Нервылы обстановка бетә башлады.

## 3

Теге иртәдә чәй эчеп утырганда нәрсәдер булды. Зиттаның аксыл битләреннән, күз сирпүләреннән тоташ нур бөркелеп торды. Ул нурлар Мостафинга төбәлгән кебек иде. Әллә шуңа җавап итеп инде Мостафин чыраеннан да нур бөркелде. Юк, бу аңлы рәвештә эшләнми, ә ике йөрәк бер-берсенең кылын тартып караганда шулай килеп чыга. Егет белән кыз сөйләшәләр, ә шушы вакытта күңелләре, ихтыярларыннан рөхсәтсез генә, бер-берсенә нур сигналлары тапшыра бугай... Мостафин белән Зитта да шулай булдылар, ахрысы. Юкса менә өч-дүрт көннән бирле инде кыз аның уйларын бимазалый. Башында ниндидер томанлы яктылык, йөрәге сулыгып-сулыгып тибә, авырткан да кебек иде. Әмма ниндидер рәхәт авырту бу. Зиһене кызның һәр ымын, хәрәкәтен теркәп барган икән, ялгызы калды исә, шуны кинолента кебек кире әйләндерә башлый. Нигә шулай күз сирпеде ул? Ник шундый ым какты? Мәгънәле итеп карап алды?..Күз карашы, кул хәрәкәтләреннән торган кроссворд чишәмени?

Мостафин мондый хисләргә һич тә әзер түгел иде, шуңа күрә шактый нык пошаманга калды. Бу бер дә көтелмәгән нәрсә аңа аяк чалу, ниндидер тозак кебек тә тоелды. Икенче минутта үзен мәлҗерәп калуда гаепләде. Моның бик мәгънәсез эш икәненә үзен ышандыргандай итте. Барысын күңеленнән себереп ташлап, эшкә, мәшәкатькә күмелде. Бүтән очрашмаска, белмәскә, шуның белән бетте-китте, дип үзен кат-кат тынычландырды һәм фатирына кунарга да кайтмас булды. Ләкин бар ыгы-зыгыны хөкемдар рәвештә бер якка каерып ташлап, кызның матур йөзе аның күз алдына килеп баса иде. Ул бер-ике көн, алгы сызыкны күзәтергә барган булып, Идрисов блиндажында кунып карады. Ләкин Зиттаның күңелдәге шәүләсе анда да ияреп барган иде. Караңгы блиндажда ничектер агарып, өй иясе кебек булып басып тора... Әллә ничек бу шәүлә аны әзәрлекләгән шикелле. Нишләргә? Мостафинга бит хатын-кыз белән якын бәйләнешләргә керергә ярамый! Ярамый. Шуның өстенә аның ерак өмет белән күңелендә йөрткән кызы да бар иде. Әйе, Рифа Хәбирова дигән санинструктор иде ул. Дөрес, алар әйбәт танышлар гына иде шикелле, шул чикне узарга туры килмәде. Туктале, шулай гына иде микән? Искә төшер әле, моның җан өзгеч тарихы бар. Мостафин үзен кыз каршында чиксез бурычлы итеп тоя иде. Ул шундый бурыч, аны болай гына җилкәдән төшереп булырлык түгел. Менә ни өчен Рифа аның хәтеренә килә дә кимсетелгән намус шелтәсе кебек йөрәген телгәләп ала...

...Ул чагында әле пушкаларга атлар җигелә, ә Мостафин батарея командиры иде. Шулай бик сазламык җирдә оборонада торалар. Беркөнне яңа өстәмә килде, арада бер кыз да бар иде. Аны санинструктор итеп җибәргәннәр. Бик юаш, яклаучысыз күренә. Шунлыктан Мостафин Хәбировага төнен санбатка кайтып кызлар янында кунып йөрергә рөхсәт бирде.

Ләкин шөбһәсез генә булган бер иртәдә кинәт кыямәт купты. Батарея пушкаларыннан бер чакрым алда урнашкан укчыларга искәрмәстән немец танклары һөҗүм иткән һәм алар каршы тора алмыйча чигенгәннәр. Мостафин үз пушкалары янында күзләре-башлары тонган, «Танклар килә!»— дип кычкыручы укчыларны күреп, югалып калды. Паниканы бик тиз туктатырга кирәк иде, Мостафин пистолетын алып бик каты команда бирде, һавага атты. Ләкин аның тырышлыгын якынга гына төшеп шартлаган снарядлар юкка чыгара иде. Сугышчыларның каушавы тагы да көчәйде. «Әнә дүртенче батареядагылар артка элдерәләр!»— дип кычкыралар Мостафин тупчылары. Куаклар артыннан танклар килгән тавышлар колакка керә. «Чигенмәскә!»— дип кычкыра Мостафин. Әмма аның сүзе коточкыч буталышка күмелеп югала. Ул штабка шалтыратырга, дип блиндажга керде, ләкин элемтә өзелгән иде. Чыкса ни күрсен, солдатлары пушкаларны атларга эләктереп, чигенеп баралар... Бу хәтәр ташкын кебек иде, моны туктата алмый инде ул. Мостафин чигенмәскә кирәген аңлый, нишләргә дә белми, сугышчылары артыннан йөгерә. Алларына чыгарга, туктатырга!

Туктатырга! Менә ничек ул паника, бер минутта бар кешене ташкын эченә эләккән йомычкага әйләндерә... Тыеп кара син аны!

Сазлык аша чыгасы бар иде, анда баткаклык өстенә агач тезеп эшләнгән бер генә юл. Атлар, пушкалар шуңа кереп тулды. Тупчылары артыннан куып житте дә расчет командирына пистолет белән янап боерык бирде: сазлыкны чыгу белән пушкаларны позициягә урнаштырырга, танкларны каршылар өчен хәзерләнергә! Тупчылар үзләре дә инде исләренә килгәннәр, гаепләрен аңлаганнар иде, чыгу белән пушкаларны куак артына яшерә башладылар. Бәхеткә, анда шактый куе таллык иде. Сугышчылар каушауларын җиңеп, гаепләрен тоеп, уттай эшләделәр. Танклар күренми әле, аткан снарядлары гына сазлыкка гөп итеп килеп төшә, кайсы ярылмый да кала. Мостафин бинокль белән карап торды. Менә сазлыкның теге ягына тәбәнәк маңгайлы кара «бегемот»лар туплана башлады. Алар туктап бу якка бик каты ут ачтылар. Ара ерак түгел, чакрым ярым булыр, снарядлар баш очыннан коточкыч тавыш белән җанны алырдай булып сызгырып үтә. Кайсы алда, кайсы арттарак ярыла. Позициягә дә бер-ике снаряд туры төште. Дүрт ат һәм биш сугышчы яраланды. Кешеләр тыныч, әмма яраланган атларның газапланып уфылдавына, ыңгырашуына чыдап булмый, йөрәккә тия. Аларны башларына пистолет терәп, тизрәк атып бетерделәр. Немецларның атуы да тынган сыман булды...

Ул да түгел, тезмә юлның теге башында танктан бер немец чыкты да болайга таба килә башлады. Аяклары белән тезмәне сытардай итеп катыкаты басып карый, бер урында сикереп тә ала, ныклыгын тикшерә. Шулай итенде дә кире китеп, танкка чумды. Танклар хәрәкәткә килде, тезмә юлга әкрен-әкрен үрмәлиләр: берәү, икәү, өчәү, дүртәү... Ара якыная, куркыныч артканнан-арта, кыза иде. Шул минутта түзүләр җанга иң авыры. Мостафин бер минутта тирләп, манма су булды. Расчет командирлары әле берсе, әле икенчесе килеп, түзәлмичә, тизрәк атыйк дип тыкырдаталар. Мостафинның үз хәйләсе бар, танклар тезмә юлга кереп бетсеннәр, ди ул. Башта әнә иң арттан килүчесенә атарга, шуны җимерергә кирәк. Шулай итсәң боларына чигенергә юл калмаячак...

Мостафин лафет янына тезләнде, прицелга ябышты: танк бик ачык күренә иде. Ул пушканың бар холкын исәпкә алып төзәде, танк бераз кырынрак торып килә, бу исә бик мач кына инде. Менә ул кулын өскә күтәреп кинәт төшерде, пушка артка чигенеп сикереп куйды, снаряд танк кырыенда ук шартлады. Моңардан кала тагы алты пушка танкларга ата башлады. Мостафин бары иң азактагы танкны гына белде. Минут та үтмәгәндер, бер снаряд, аннан тагы... Танк кинәт бер якка янтайды түгелме соң? Шунда ук бер як тәгәрмәч чылбыры танк астыннан кабык кебек кубарылып чыкканын күреп алды. Биноклен бүтән танкларга юнәлтте. Уртадагы бер танктан сыек кына күксел төтен күтәрелә иде. Иң башта килә торган танк та, тезмә юлдан читкә тайпылып, арты белән яртылаш сазга чумып бара. Мостафинның эченә җылы керде: мин аларны шушы тозакка эләктерер өчен чигендем, дип, акланырга була хәзер... Эх, молодец җиденче расчет, дүртенче танкны да яндырды. Немец танкистлары бая ук танкларын ташлап тезмә юлдан кире йөгергәннәр иде... Ләкин шул мәл немецлар тылдагы пушкаларыннан бик нык атарга тотындылар. Каршы як куак-чаукалар арасына яңа танклары килеп яшеренгән микән әллә? Прицелны шунда күчерергә кирәк, дип уйлады Мостафин. Шул уен расчет командирларына әйтү өчен лафет яныннан кузгалды һәм кинәт башына утын агачы белән арттан китереп суктылармыни, әллә кая атылып барып төште. Егерме-утыз метрда, снаряд шартлаган тавыш аңында чагылып узды, кайсыдыр уфылдады, «Мине яралады!» — дип кычкырды. Кемдер Мостафинның башын күтәреп торды да җиргә кире куйды: «Комбат үлгән!» — дип ямьсез тавыш белән акырды. Тагы кемдер килеп, аның кулын тотып карады, күкрәгенә учын куеп торды һәм ул да: «Үлгән!?» — дип китеп барды.

Мостафинга бу авазлар бик ерактан, җир астыннан килгән сыман, зәгыйфь кенә булып ишетелә иде... Ләкин ул, санын кыймылдату түгел, күзен дә ача алмый, уфылдый да алмый, гүя аны ниндидер тар чокырга тыгызлап салганнар сыман иде... Ул һаман каядыр еракка китеп барган кебек, дөньядан китү дә шулай була микән әллә? Юкка гына аны мәңгелеккә китү дип атамаганнардыр инде! Менә ул хәзер бик-бик ерак юл китте шикелле, каядыр бара да бара, барысы да аңардан мең чакрым ераклыкта калдылар. Ул япа-ялгызы ниндидер сусыз, тереклек булмаган кара чүл уртасында. Кире кайтып булмый торган җир шушы икән инде... Ә нишләп миңа авыр түгел соң? Нәрсәгә булса да тотынып туктарга иде, туктарга, юкса иптәшләрдән аерылу шәп булмаячак... Һаман һавадан очып бара ул...

Күпме вакыттан соңдыр, күкрәк турында тимер салкынлыгы тоеп, Мостафин аңына килде. Куенында ниндидер кул актарына, капшана иде. Йөзекле кул иде, шул тиеп тәнен пешереп алгандай итә. Тынлыктан һәм караңгылыктан файдаланып, немец разведчиклары бирегә чыккан иде, шулар мәетләрне капшап талап йөрделәр. Бу бик тиз арада булып алды, безнең тылдан килүче яңа подразделение тавышын ишетеп, алар күз ачып йомганчы кире элдерделәр.

Муен арты бик каты кисеп авыртудан Мостафин тагы аңына килде. Аны култык астыннан тотып, каядыр өстерәп баралар шикелле иде. Аң караңгылыгында тычкан уты хәтле генә чаткы пәйда булды. Колагына ниндидер тавышлар да керде. Аның гәүдәсен бер солдат белән санинструктор Хәбирова килеп тапкан иде. Рифа Мостафинның таушалган, балчыкка буялып беткән чыраена карап торды, ләкин үлүенә һич ышанмады. Ә гәүдә җансыз иде. Тик моны һаман аңы кабул итә алмый гына. Ул аның суынган битләрен ике учына алып сыпыргалап торды, беләзегеннән пульсын эзләп маташты. Боздай салкын куллар чиркандыргыч түгел, әллә ничек кенә якын һәм кадерле иде. Рифа бу әчке ягымлы кешене беренче күрүдә үк ошатты. Элегрәк фронтка килгән һәм бирендәге хәлләрне белергә өлгергән кызлар да аның Мостафин батареясына туры килүен бәхеткә санаганнар иде.

— Шушында гына күмик,— диде солдат. Рифа сискәнеп китте һәм гәүдә янынннан торды.

— Юк, тылга алып чыгабыз,— дип Рифа каршы төште. Солдат кечкенә саплы көрәген никтер җиргә сугып алды.

— Син нәрсә?! Анда чаклы күтәреп илтергә?..

— Юк, әйдә, күтәреп кара але.

— Соң кайда да шул ук җир ич инде, монда ни, анда ни?

— Ну, давай!

— Мәгънәсен күрмим, иптәш кече лейтенант?!

— Шундый приказ, комсоставны тылга алып чыгарга, ишеттеңме?

Солдат, авыз эченнән мыгырдана-мыгырдана, Мостафинны үз аркасына иләп озак маташты, аны селкетеп, гәүдәсен төрлечә тарткалап бетерде. Аларның сөйләшкәнен су астыннан ишеткән кебек кенә ишетеп яткан Мостафин шул селкетүдән тагын аңын җуйды. Солдат гәүдә авырлыгыннан чатан-чатан атлап алга таба китте. Әледән-але аркасыннан шуыша башлаган гәүдәне селкетеп рәтли, үлгән мәет белән эш иткәндәй, пырдымсыз кылана иде. Рифа мәетнең берәр төше авырта торгандыр дип җәлли һәм солдатка елардай булып ялвара, гәүдәне иплэбрәк алып барырга куша, ул да түгел, үзе дә күтәрешеп бара иде.

Шактый җир киткәч, гәүдәне җиргә иплэп кенә куйдылар.

— Шушында гына күмик,— диде солдат, тирләрен пилоткасы белән сөртеп. Ул кечкенә таучыкны күрсәтте. Бик әйбәт урын иде. Солдат чирәмгә тезләнеп, кечкенә көрәге белән кәзне дүрткелләп чокый башлады.

— Юк, санбат янына алып кайтыйк,— диде Рифа һәм ачулы карашы белән солдатны җирдән торгызды. Теге исә, мәгънәсез кешегә, эшең

төшмәсен дигәндәй, кулын өметсез селтәп, гәүдәне аркасына күтәрде дә тиз-тиз атлап китте. Санбат янында әзер каберләр бар иде, гәүдәне бер чокыр кырыена куйдылар. Рифа йөгерә-йөгерә кислород мендәре алып чыкты, тәҗрибәле врач килде. Ул гәүдәне карарга, тыңларга тотынды. Рифа гәүдәнең борынына кислород өрдереп маташты. Кинәт врачның күзләре очкынланды.

— Йөрәге тибә ич!— дип кычкырып куйды. Рифа шатлыгыннан нишләргә белмәде, елап җибәрүдән чак тыелып торды. Солдат, аптырап, ике кулын бот буена суккалады.

Мостафин госпитальдә озак ятты. Аңга килгәч, солдат аңа санинструктор кызның зирәклеге аркасында гына җиргә күмелми калуын сөйләде. Мостафин исә аларның сөйләшкән тавышларын ишетеп ятуын ышанмас дип аңа әйтеп тормады. Ул озак вакыт сөйләшә алмый интекте. Муен тамырындагы ярадан диделәр. Беркөнне аның янына тупчы полк командиры Кимбр үзе килеп чыкты. Ул кырыс һәм гадел холыклы, частьта абруйлы кеше иде.

— Чигенгән өчен сине трибуналга бирмәкче булдылар,— диде һәм озак кына дәшми торды. Мостафин бу хакта ишеткән иде инде, шуңа күрә паузаны бозмады.

— Биш танкны җимерткән, моның өчен ул герой булырга лаек, дип, тегеләрнең бугазларына ябыштым. Шуннан тындылар шикелле. Ләкин синең госпитальдән чыгуыңны көтүчеләр дә бар бугай...

— Шуңа ук барып җиттемени?!— Мостафин кимсенгән тавыш белән аптырау белдерде.

— Кеше бәласеннән җылынучылар бар әле. Ә генерал торды да әйтте: «Акыллы комбат икән, ул позициядә мин дә нәкъ шулай эшләр идем»,— диде. Шуннан беришләре шып булдылар.

— Рәхмәт инде, рәхмәт,— дип Мостафин күңелләләнеп китте.

— Борчылма, тиешлесен алырбыз,— диде Кимбр һәм аның күксел яңакларында елмаю чаткылары беленде. Аннары ул папиросын кабызды, сине талчыктырдым бугай инде, дип китәргә ашыкты.

Кимбр үзенекен итә торган нык фикерле, абруйлы командир иде. Сафка кайту белән Мостафинга майор дәрәҗәсе биреп, дивизион башлыгы итеп куйдырды. Бу эштә Кимбрның йола торган гадел кулы йөргәнлегенә шикләнмәскә мөмкин иде. Аңарда үзенә бер төрле аңлы яхшылык бар, кешене бары эшенә карап кына бәяли ул.

Юк, барыбер Рифага булган рәхмәт хисләре күңелендә көчле дулкын сыман кузгала. Ул кызның аны хәтәр үлем тырнагыннан ничек алып калуын әнисенә дә язмый булдыра алмады. Һаман шуңа гаҗәпләнә: солдат аны шушында күмик, дип ике мәртәбә җилкәсеннән җиргә төшерде, кыз исә: юк, юк, диде. Ә бит күмеп куюлары да бик ихтимал иде. Ул берни дә эшли алмый иде. Шул исенә төшсә, аркасына кайнар елдырым йөгерә аның. Рифаны соңгы күрүендә:

— Мин сезне мәңге онытмам,— дигән иде. Аның сүзләреннән кызның битләре кызарып китте.

— Юк, юк, алай әйтмәгез,— дип куйды, андый антлар барыбер онытыла бит, дигән чырай белән аңа күз сирпеп елмайды.

— Әллә ышанмыйсызмы?

— Ышаныргамы, юкмы, белмим...— Кызның тавышы моңсу булды.

— Менә аякка гына басыйм, без әле сезнең белән...— диде Мостафин, күп мәгънәгә урын калдырып, һәм шуңа сүзен әйтеп бетермәде. Егет кеше авызыннан мондый сүзләр чыкканда кызлар зирәк һәм еракка төбәп аңлаучан булалар. Рифага да бу сүзләр тәэсир итте, аның күзләренең чаткылары җетеләнде, ике күкрәк уртасындагы портупея каешы ыграк дерелдәп тора башлады.

Мостафин ниндидер сүз уңаеннан:

— Безнең әни: самавырның шатлыгы — күмер, кешенең шатлыгы — гомер,— дип әйтә торган иде,— диде. Шуннан Рифа аның әнисе хакында

сорашып китте. Мостафинга сөйләшү авырга төшсә дә сер бирмәде, кызның сорауларына, тотлыгып-тотлыгып, җавап кайтарып барды. Аның ешеш тотлыгуыннан кыз үзе дә эшне тиз сизенеп алды һәм тагы килергә вәгъдә итеп китеп барды.

Рифа килеп киткәннән соң Мостафин эченә шатлык оялаган кебек йөрде. Эченнән күп нәрсәләр турында уйлады, тормыш, киләчәк хакындагы татлы фикерләргә бирелде. Рифаның аңа әйбәт каравына, аны әз булса да ошатуына ул шикләнми иде. Сөйләшкәндә аларның туган җирләре бер тирәдәрәк булуы беленде һәм бу факт үзеннән-үзе аларны якынайта иде. Мостафин аны үз канаты астына алырга дигән ныклы карарны күңеленә төйнәп куйды. Ул үзенең бу ниятен ни генә булса да тормышка ашырган булыр иде, ләкин сугыш менә шундый изге ниятләрне җимерергә ярата шул. Берничә көннән Рифалар санбатының төнге бомбежкага тотылуын һәм кызның яраланып тылга озатылуын килеп әйттеләр. Ярасы артык авыр булмавын белгәч, ул бик сөенде. Төзәлгәч үз частена кайтачагына ул бик ышана иде. Шуңа күрә аны күңеленнән бер дә чыгармады, ышанып, йөрәгендә бер кешене йөртү ничектер рәхәт тә иде. Ул сине бүтән эретә торган чит карашлардан аралап тора кебек. Ниндидер әхлак сакчысы сыман. Шундый сакчың булса әйбәт икән. Ярату сакчысы... Берәрсе күңеленә очкынын төшерә башласа да шуны калкан итеп куясың...

Менә шул калкан да кулдан бәреп төшерелде шикелле хәзер. Нәрсә инде бу, Рифага хыянәтме? Үзе юктан файдалануны? Икенче уй килеп аваз сала: берниндн хыянәт юк, сез сүз бирешмәгән, бер-берегезгә өмет беркетмәгән. Син үзеңне аңа бурычлы итеп тоясың, бары шул гына. Бурычыңны бүтән төсле түләрсең соң, ни булган ул чаклы, дип бөтенләй тугарып ташлый...

Җыелыштан соң Мостафин военторгка сугылды һәм ни өчен икәнен анык кына исәпләмәстән эчемлек, консервы ише нәрсәләр алды. Кирәге чыгар, дип үзенең бу эшен аклады ул. Тиздән күченәсе, шуңа күрә хуҗаларны бер сыйлап китәсе булыр. Ләкин эчтән танарга оялган хәйләсе бар икән: Зиттаны күрәсе килү...

Бүлмәсенә кайтып керү белән бөтен тәне бик нык авырайганын сизде ул. Һәм каешын чишеп пистолетын кесәсенә салды да урын өстенә ауды. Эт булып арыган, күз кабаклары таш баскандай йомылдылар. Әмма аңарда әллә нинди җәнлек сизгерлеге уяу иде: Зиттаның өйдәме, түгелме икәнен белергә итә. Аның аяк тавышын әллә кайдан таный иде ул. Нишләптер бик тын, Зитта әбисе белән Елгавага киткәннәр, ахры. Карчыкның төп яшәве шунда диделәр... Ә йокы яман нәрсә, тыгызланып, мамыктай аны сара да сара...

Иртән ул бик ачык зиһен белән торды. Зиттаны күреп булмас, ахры, дигән үкенүле уй килде аңа. Әмма күңел почмагының кай төшедер: «Зитта!»— дип кычкыра сыман иде. Гүя ул икенче, аңа теләктәш кеше тавышы иде. Юк инде, анда чаклы эзләп бармам, диде ул теге тавышка җавап кайтарган кебек...

Баскычтан сикерекли-сикерекли төште дә капкага таба юнәлде. Ләкин өйгә терәлеп үскән бакчада чыжылдаган тавыш ишетеп, шунда карады. Зитта озын гына таяк белән биек алмагач ботакларына суккалап алма коеп йөри иде. Мостафин йөрәгенең кинәт дөп-дөп тибә башлавын ишетте һәм туктап калды, аннары аяклары аны үзеннән сорап та тормыйча бакчага алып керде. Зитта зәңгәрсу юка пальтодан, яланбаш, коңгырт чәчләрен баш артына түгәрәкләп төйнәгән. Мостафинны күргәч, кызның йөзендә ут кабынган кебек булды. Битләре яктырып китте. Майор да, елмая-елмая, таякны кызның кулыннан алып, булыша башлады. Алмалар коелган саен Зитта тыенкы гына көлә-көлә җыя, аның көлүе ничектер җиз кыңгырауның ягымлы чыңын хәтерләтә иде. Кәрзин кырыенда ак куллары житез хәрәкәтләнә, ак күгәрченнәр канат җилпеп торалармыни?! Ә эре аксыл алмалар, таяк сугуыннан һавада озын ак эз салып, җиргә коелдылар. Мостафин шундый

эш чыкканга сөенә-сөенә тырышты. Ләкин агачлар биек иде, ябалдаштагы алмаларга буе җитмәде.

— Ярар, алары фәрештәләргә калсын,— диде Зитта, тагы чыңлы итеп көлеп. Аның аксыл алма кебек битләре тагы да нурланган иде.

— Фәрештәләрне яратмыйм мин,— дип, Мостафин һаман алмагач ботакларына таягы белән кизәнде.

— Нишләп алай?— Зиттаның чыраена нык кызыксыну чыкты. Әллә ул «фәрештә» дигән сүзгә үзен дә кертеп уйлый иде микән? Мостафин аңымоны сизмәде, һаман да шаярган тавыш белән:

— Алар ышанычсыз булалар,— дип куйды. Таягын бер агачка сөяде. Зитта аңа бик үз иткән төс белән кәттә генә бер алма бирде, Мостафин шуны, кулъяулыгы белән сөрткәләп, тыйнак кына кабып алды.

— Әһә, аңлыйм, алар сезгә хыянәт иткәннәр?— Зитта сүзне майорның кылын тартып карау җаена борган кебек иде. Аның күзләрендә беләсе килү очкыны тибрәнде.

— Юк, болай әйтәм, дөнья фәрештәләр өчен җайланмаган, дим.

— Теләмәсәләр дә гөнаһка батарга мәҗбүрләр, әйеме?

— Гамәл кешедән көчлерәк инде.

— Шуның өчен тугры булып кала алмыйлар?

— Анысы һәр кешенең нindилегенә бәйләнгән, минемчә.

— Шулай да сезне кемдер алдаган, мөгаен?— дип Зитта Мостафинга сыный карап елмайды. Юк, бу яшь кызлар чытлыклануы түгел, яшьлеге иртә узган хатын-кызның тылсымлы каравы иде. Мостафин шуны сизде һәм аның күңеленә нидәндер канәгатьлек хисләре тулды. Дулкынлануы да кими төште, йөрәк тибүе тигезләнә башлаган кебек булды.

— Ә сезне бер дә алдаганнары юкмы?— Кыюлана биреп, сорауга сорау белән җавап кайтарды ул.

— Чын алдану акыл бирә. Бер дә алданмыйча гына яшәп тә булмый.— Зиттаның йөзен нур чаткылары күмде. Мостафинның да чырае үзенә бер төрле яктылык бөрки иде.

— Шуңа сез хәзер акыл белән генә эш итәсез инде, әйеме?

— Ничек әйтергә?— диде Зитта, матур күзләрен уйнаткалап елмаяелмая.— Шулай да элеккегедәй кечкенә нәрсәгә дә зур өмет багламыйм шикелле.

— Ачы тәҗрибә... Монда тормыш катлаулы булгандыр инде?

— Әле руслар, әле немецлар, сугыш...— диде Зитта һәм йөзендәге нурлары сүнде, сүзен әйтеп бетермәсә дә билгеле иде. Мостафин аның хәлен бик нык аңлаган кыяфәт белән ияген какты. Кыяфәтенә кызны җәлләгән төс чыкты. Тик Зиттаның үзен җәлләтәсе килми иде, ничектер горурлыгына тия кебек.

— Бер-беренә капма-каршы көчләр, ә арада упкын. Кешеләр кайсына карарга белмиләр.

— Упкынга тәгәрәүчеләр дә булгандыр?

— Булмыйммы соң? Әле хәзер дә...

— Ишетелгәли. Кеше миендә кара таплар күп шул әле.

— Әйе, кайчак берәр ахмаклык эшлисең дә үз-үзеңә шаккатып куясың.

— Үз-үзеңне танымыйсың, бу мин микәнни соң, дип, таң каласың? Шулаймы?— дип Мостафин елмайды, Зитта да күтәрелгән пальто якасын түшендә бер кулы белән тоткан килеш аңа күз сирпеп алды. Фикерләре туры килүгә ул да сөенгән кебек иде.

— Немецлар әшәке кыланганнардыр инде?— диде Мостафин һаман Зиттаны кызганган тавыш белән, Зитта артлы эскәмиягә барып утырды.

— Әйе,— дип җавап бирде ул.

— Сездә беренче карауда ук ышаныч уята торган чаткы бар.

— Чынмы? Миңа һичбер кеше ул хакта әйткәне булмады. Кызык!

— Аннары сезнең өстән сугыш та үтмәгән сыман, кул тимәгәндәй саклангансыз димме?

— Сугыш миңа әшәке тамгасын салмаганмы? Юк, минем барысы да эчтә.— Зитта пальто чабуы белән йомыры тезләрен япкалады, бер аягын алгарак сузып, нигәдер кыска куныч̧лы йомшак күн итегенә карап торды. Йөзе моңсу җитдиләнеп китте. Мостафин эскәмиянең теге башыннан якынрак күчеп утырды. Хәзер алар арасында аксыл алмалар тулы кәрзин генә.

— Эчтә саклаган әйбер энҗегә әйләнә, ди,— Мостафин көлемсерәгән тавыш белән әйтте. Зитта аның сүзләрен ишетмәгән кебек булды, бая сүз иярә сүз җае өчен генә сөйләгәндәй, хәзер үз алдына карап уйланып калды.

— Ә сез миңа ышана алыр идегезме?— диде ул, Мостафинга таба күзләре белән елмаеп карап.

— Әйттем бит, мөмкин дип. Ә сез — миңа!— дип ул Зиттага өметләнеп карады.

— Белмим шул.

— Ышаныч бары ике яклы гына була. Бер як ышанмаса, икенче якта да ышаныч бетә,— диде Мостафин көләргә әзер тавыш белән. Зитта эчтән елмайган килеш ниндидер бәйсез битараф кыяфәт белән утыра. «Белмим шул» дию дә гаять өметле яңгырады һәм Мостафинның йөрәген рәхәт чәнчү белән чәнчеп алды. Кызның нурланган йөзе үзенә тарта, котырта торган искитмәүчәнлеге, күңелендәге шөбһәләрен таратты да ташлады. Алай гына да түгел, ул аны үчекләде, мин - минлеген кузгатты. Егет ул кызда ниндидер ихласлык күрде. Шуның өстенә Зитта белән сөйләшүе җанга май яккан кебек иде, ул сүзләрне культуралы итеп аңлый, җаваплары да аның укыган булуын күрсәтеп тора. Ә үзендә укымышлы булып кылану юк.

— Сезгә миңа ышану авыр инде,— диде Мостафин һәм Зиттаның кәрзин кырыенда торган кулын тотты. Кул йомшак, ничектер оядагы кош баласы кебек кайнар иде.

— Без тыныч вакыттагы кебек сөйләшәбез, чын,— дип Зитта башын алга иеп көлгән итте, ләкин кулын тартып алмады. Шул вакыт өйдән «Зитта!» дип дәшкән аваз ишетелде. Әбинең тавышы шактый зәһәр, сискәндерә торган иде. Зитта бер дә исе китмәгән кебек кенә кузгалды. Гомумән, ул бернигә дә исе китми торган характерлы бугай. Мостафин исә кинәт каушап калгандай булды. Аның Зиттага әйтәсе сүзләре бик күп иде бит! Ахмак, ничек шулай баядан бирле корыны бушка әйләндереп утырды! Вакыт үткәне бер дә тоелмады шул.

Зитта пальтосын төзәткәләп, кәрзин сабына тотынды, Мостафин һаман зиһенен җыя иде әле. Ул торып басты да әйтте:

— Бүген кич сезнең вакытыгыз булмасмы? Бергә утырыр идек?—һәм каушагандай аска төбәлде. Кыз аның маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен күреп, дулкынланганын сизде. Күптән инде каршында ир-ат халкының тәкәллефле булуын тойганы юк иде. Аның хөкемен көтеп торганны очратканы булмады. Хәл-әхвәле белән берничек тә санашмыйлар иде. Ризалыгын да сорап мәшәкатьләнмиләр, стенага китереп терәргә генә торалар... Ә бу майор аның хөкемен көтеп тора, шуны үзенә бәхет саный булыр...

— Әби бик каты...— дип, Зитта ничектер өметле итеп сиздереп куйды. Мостафин аңа өмет тулы күзләр белән карады.

— Кичтән күк болытлы булса, әби белән абый подвалга төшеп яталар, беләсез, андый төнне немец бомбага тота,— дип, пышылдап сөйләнде Зитта.— Ә мин курыкмыйм, аска төшмим, аңлашыламы?

Мостафин, елмаеп, ияк какты, әйе, аңлашыла. Кәрзинне тотып, аның артыннан атлады. Бакча капкасын чыккач, Зитта күзләре белән аңа калырга кушты һәм үзе кәрзинне алды да баскычтан тиз-тиз менеп китте.

Зитта белән сөйләшкәч, Мостафин күңеленә ниндидер күтәренкелек һәм рәхәт моң утырып калды. Шуның белән эчтән кинәнә-кинәнә капкага таба атлады. Ул киңәшмәгә барырга тиеш, ә җанында көтелмәгән тойгылар давылы купты. Тойгылар һич искәрмәгән фикерләрне әллә каян казып чыгардылар. Ул үзе турында, фани дөнья хакында уйлана башла-

ды. Менә бу яфраклар бит, дип уйлады ул, үз вазифаларын башкарганнар да үләргә әзерләнгәннәр. Һәм бу бик табигый. Ә мин һәм меңләгән минем ишеләр төп вазифаларына тотынып та карамыйча җир астына керергә мәҗбүрләр. Юк, бу хакыйкатькә һич сыймый торган нәрсә. Әнә, агачларның да орлыклары кала, аларның да туганнары була. Ә бездән җиргә ни кала инде? Соңыннан сөйләрләр: алар ватанны яраталар иде, диярләр. Сүзләр, сүзләр...?! Алар безнең эчтә янган тойгыларны, дулаган фикерләрне дөньяга белгертә алмаслар. Күңелдә дөрләгән бөек ниятләрне бары безне дәвам итүче тере буын гына җиткерә алыр. Амбразура утына күкрәк куйган, курку белмәс, батыр, чиксез намуслы кешеләрнең дәвамы, нәселе калмаячак. Беркөн комбат Бакиров һәлак булды. Искиткеч математик, күренеп торган талант иде. Кеше буларак та миннән бер башка өстен, саф вөҗданлы егет. Бары егерме өч яшьтә... Сугыш беткәч аның урынына кем килер? Табигать бушлыкны тутырып кына тора. Нәрсә белән, кем белән тутырыр соң? Чүп-чар, эленке-салынкы кешеләр беләнме? Эш өчен, кирәк өчен теләсә нинди тәвәккәллеккә карусыз бара торган егетләрне алыштыра алырлык әмәл табармы табигать? Талантлы, әйбәт кешеләр урынын үзләрен тигәнәк кебек сарган ваклыклардан арына алмаучы һәм бөтен эшкә шул ваклыклары күзлегеннән генә караучы адәмчекләр биләсә? Менә фаҗига шул чакта килеп чыгачак әле! Соң бит кешеләрнең тормыш-көнкүреше, бәхете урындагы иптәшнең акылына, зиһененә, тәрбиясенә бәйләнгән. Аларның талантыннан, намуслылыгыннан тора...

«Туктале, нишләп миңа мондый уйлар килә икән?» — дип үз-үзенә хисап биргән кебек итте Мостафин тыл штабына җитәрәк. Әмма икенче минутта уйлары тагы Зиттага барып тоташты. Кем ул, нинди кеше? Нәрсә уйлый икән ул минем турыда? Әллә исенә дә кертеп карамыймы? Минем кебекләрне күргәне бардыр инде аның? Әллә юкмы? Хәер, минем ни эшем бар анда...

...Мостафин тәмам борчуга батты. Бу Зитта әллә нишләтте аны. «Нәрсә соң бу, әллә ычкына башладым инде?» — дип үз-үзенә сорау куя ул. Ник шул чаклы башны җуям әле? Яратуны шатлык кебек була дигәнне ишеткәнем бар иде, ә мин тирән кайгы белән йөрим. Кая әле минем салкын акылым, гүя җан шул кайгыга сусап торган. Башны зәңгәр уйларда йөздерә. Күңелне салмакландырып, хәсрәтле, үзе турындагы фикерләргә тупланган мондый вакытсыз бимазаны кичергәне юк иде әле...

Зитта? Фәрештәме, әллә фәрештә сурәтендәге гыйфритме? Юк, юк, тьфу, тьфу, әйттем исә кайттым, ничек Зитта турында шундый уй башка килергә мөмкин? Мин артык йончылганмын, шуңа гына күңелгә жыен чүп-чар уй килеп тула... Ләкин шунысы бар, Зитта немецларны бик яманламый. Оккупантлар тарафыннан җәбер-каза күрмәгәннәр. Ә шулай да Митова шәһәрен безнең самолетларны, союзникларны бомбага тоткан чакта әнисе һәлак булган. Кибеткә икмәккә дип киткән җирдән кайтмаган. Унлап кеше таш кибет хәрабәләре астында күмелеп калган, күпме казып маташсалар да таба алмаганнар... Ә әтисен ул бөтенләй диярлек хәтерләми икән, әллә кайчан аерылып китеп, кайсыдыр портта диңгезчелеккә ялланган, бүтән хәбәре килмәгән...

Зитта үзен бик ышанган кыяфәттә тота, әллә минем шулай аңа мөкиббән китүемне сизенгәнме? Мин аңа шаярып: сез хәзинә тулы савыт кебек омсындыргыч дигәч, ул: хәзинәле чүлмәк җирдә күмелгән була шул, дип көлде.— Ә сез җир өстендә,— дидем мин. Ә ул:— Әмма сез хәзинә эзләүче кебек түгел, алар елгыр һәм комагай булалар. Хәзинә савытын тизрәк ватарга гына торалар,— диде дә тагы кеткелдәде...

...Бер-ике көн соңрак, кичке ашны ашап утырганда, нәрсәдәдер сүз чыгып, Зиттаның абыйсы кабынып китте. Дәшми йөргән кеше бер ачу-

лана башласа, аны тиз генә туктата алмыйсың. Зарланды, карганды да Зиттага тотынды.

— Син майорны үз эшләреңә бутама,— диде, кашыгын өстәлгә шапылдатып куеп.

— Нәрсә син, абый?— дип, Зитта ачу сүндерә торган нурлы елмаюы белән аңа карады.

— Мин барысын да беләм...— Аның тавышы ышаныч казана торган тыныч тонга күчте.— Ташла, урмандагылар белән бәйләнмә. Үзеңне дә, безне дә харап итәсең килмәсә...

— Берни дә юк, абый, нәрсәдән шулай әйтәсең?— Зиттага чиксез оят булып китте, ул ничек тә эчендәген яшерергә тырышып, гаепсез төскә керде, аптыраган кыяфәт белән җилкәләрен җыерып куйды. Әмма абыйсы һаман үзенекен тукыды.

—Әгәр айзсорглар белән бәйләнештә булсаң, тизрәк өз, белдеңме? Майор белән булган уеныңны туктат, ут белән шаярма, белдеңме?

— Мин бернәрсә белмим,— дип Зитта, хәтәр ачуланып, урыныннан торды һәм, үпкәләп, ашамыйча чыгып китте. Аның хәзер бар көче шушы үпкәләүдә чагылды, чөнки бер гөнаһсыз төс белән икейөзләнеп утырырга түземе җитмәде. Ә гаебе барлыгын ул үзе дә аңлап бетерми әле. Аннары абыйсының шәхси эшләргә тыгылуы тәмам мин-минлегенә тиде. Үз икмәген ашатам дип, үзенең кубызына биетмәкче була. Балки мин дә үз икмәгемне эшләп алырга телим дер...

Зитта үз бүлмәсенә чыгып, тәрәзә төбенә утырды. Үз эшләренең абыйсына билгеле булуы аны бик нык рәнҗеткән иде. Гүя бер-бер начар эш өстендә тотылган кебек эченә әрнү тулды. Шунда ук күз алдына Балта килеп басты. Аңа абый кушмый дип әйтеп булмый бит инде. Әнә Луиза дигән кыз язылганда ук акыллы була белгән: хатын-кыз эше оя кору, бала табу, дигән дә оештыручыларның авызларын япкан. Айзсорглар исемлегенә аны кертмәгәннәр...

Әмма ул, үзенең күңел тирәненә колак салып, анда майор белән очрашканнан соң туган ниндидер яңалык шикелле бер тойгыны ачык барлады. Ул тойгы нигәдер борчый аны, рәхәт тынычсызлап тора... Менә шундый хәл: таякның бер башында Балта, икенче башында — майор... Зиһене аек сизә — майор аңа якынрак...

## 4

Мирхас бер дә тик торуны белмәс, күндәм егет иде. Нинди генә халдә булса да шул гадәтен куа. Аның тиктормас табигате үзенә кайчак зыян да итеп куйгалый. Бервакыт шулай кырда немец листовкасы тапкан иде, штабка илтеп бирде. Шуннан аңа кырын карый башлаулары сизде ул, дивизия разведкасы «телгә» барганда аны алмадылар. Тиктормаган башта бәла бар, дигән борынгылар. Шул сүз исенә төшеп, үзенең кимчелегенә эчтән сызып йөрде, әмма гадәтен барыбер ташлый алмады. Шул эшлекле булуын белгәнгә, Идрисов аны Зангирдан теләсә нинди әмәл белән телефон чыбыгы алып кайтырга җибәрде. Зангир чиңга бик мөкиббән нәрсә, болай гына аңардан әйбер алып булмый, шуңа күрә Мирхас аның янына бераз кызмачага салынып барып керде. Авызына кыйбатлы папирос капты.

— Смерш начальнигы белән утырдык әле,— дигән булды.— Коры спирты күп икән, суда эретеп эчтек.

Зангирның күзләре «ничек?» дип шаккатып карадылар. Мирхас кесәсеннән бик матур тартма чыгарып, шуннан, ике зур-зур ак садәфтәй тугәрәкне Зангирга сузды.

— Смерш белән син дусмыни?— диде Зангир, шыпырт тавышка күчеп. Мирхас ике урта бармагын бергә китереп куйды: — Әшнә!— дип ым

какты. Ун минуттан бер яңа, бер иске катушка кабель Мирхас кулында иде. Смершны Мирхасның күргәне дә юк, әмма Зангир ише кешегә кай яктан ничек якын килергә белә ул.

Батареяга кайтса — шау-шу: Латышев табылган, дөресрәге, аның үле гәүдәсен табып алып кайтканнар. Моннан өч чакрымнар булыр бер урман кишәрлегендә минага шартлаган икән бичара. Ни өчен анда барган, беркем белә алмый. Әҗәле тарткандыр, ди кайсы. Мирхас җирдәге гәүдәгә төбәлде. Күкрәк турында шинеле, күлмәкләре теткәләнеп умырылган. Ә-ә, «бака мина»га эләккән икән, дип уйлады Мирхас. Немецның әз генә кагылуга өскә сикерә торган минасын шулай атыйлар иде.

Сугышчыларның күзе Идрисовта. Аның чыраенда ниндидер чынлык өскә чыкканда була торган яктылык һәм сугышчының үлеме өчен әрнү көрәше сизелә. Латышевның югалуы аны ачы сәгатьләр белән күп агуллады. Аны таптырып Идрисовның җанына төштеләр, аңа шик тактылар, сиңа ышанычыбызны югалттык, диделәр. Бу бик авыр булды. Менә ул табылды, дөреслек тантана иткән шикелле...

Идрисов аның куеныннан алынган кәгазьләрне бик җентекләп, сак кына ике учына җыйды. Аннары планшетына салыр алдыннан кызылармеец кенәгәсен аерып икенче кулына тотты да кычкырып укып җибәрде:

— Латышев Николай Федорович, туган җире Чкалов шәһәре, милләте рус. Сугышка хәтле башлангыч мәктәптә укытучы булган...

— Ә бит, аны теге якка сызган дип, чабата кайтарып йөрделәр,— диде Кардәшев ниндидер әрнү белән. Ул һәрчак сүзен курыкмыйча, туры әйтә иде.

— Бәлки ул диверсант эзләп шунда баргандыр,— дип, Мирхас та Латышевны җәлләп өстәде.

— Солдат язмышы инде, ташка үлчим.— Моны әле күптән түгел килгән Гыйльманов әйтте. Аның җил каклаган озынча битенә, тоташкан куе кашларына, язмыштан узмыш юк инде, дигән искитмәүле сызыклар чыккан иде. Идрисов эндәшмәде. Бераз таптанып торды, аннары мәетне әлегә җирләми торырга кушып, урман артындагы шәһәрчек янына таба моңсу гына атлап китте. Аның особый отделга барганлыгын тупчылар сизенәләр иде.

Ул арада машиналар белән батареяга снарядлар китерделәр. Расчет командирлары, һәрберсе үз тупчыларын дәшеп алып, эшкә керештеләр. Маламишкин якташ дип Гыйльмановны үз расчетына алган иде. Чынлап та килешеп киттеләр. Гыйльманов Әлмәттән икән, ә Маламишкин Тәтеш тирәсеннән бугай. Казанда да байтак булган булса кирәк. Ничектер немец турында сүз чыккач, сөйләп алды.

— Казанда элек немецлар күп яшәгән,— диде. Гыйльманов ышанмыйча аңа карап куйды.

— Әйе, әнә хәзерге Менжинский клубы элек немецларның чиркәүләре иде. Аларча кирхе дип атала. Чиркәүнең ишегенә: «Кирхе, киндер, кохе»,— дип язылган иде. Янәсе, хатын-кызларның төп эше гыйбадәт кылу, бала табу һәм кухняда аш пешерү.

— Немецлар хатыннарны эшләтмиләр микән әллә?

— Булыр да, немец бик үткен халык.

— Ни өчен икән?

— Бәлки эшләп йончылган хатыннардан яхшы балалар тумыйдыр?

— Чыннан да, карале, һе...

— Бөтен нәрсә шул немец хәсисләрдән таралган.

— Денсез немецлар! Ничек алар безнең якларга килеп чыкканар, ә?

— Революциягә чаклы ук инде. Алар бездә күп булган, ә Пишмаш[1] төзелгәч, шунда эшләгәннәр.

Алар самовар төсле сары җиз, озынча снарядларны җилкәләренә салып

[1] Пишмаш — язу машиналары эшләп чыгара торган завод

баралар. Бу тирәләрдә бомба чокырлары күп булганга, машиналар килә алмыйча пушкалардан ерактa туктаганнар иде.

— Мин абыйларда бер ел торып, мәктәптә укыдым. Ул чакта Казанда русларга да татар теле укыталар иде,— дип куйды Маламишкин.

— Кит әле,— дип ышанмады Гыйльманов.

Снарядларны җилкәдән төшереп, пушка янындагы әрҗәгә куйдылар да ял итәргә утырдылар. Маламишкин куеныннан трофей блокнот һәм каләм чыгарды. Бер биткә гарәп хәрефләре сызгалап та бирде. Гыйльманов искечә белә иде. Маламишкин гарәп хәрефләре белән: «Мин сине яратам»,— дип язган иде, Гыйльмановның күзләре шар булып маңгаена менде, нәрсә әйтергә белмәде. Маламишкинның шуңа кәефе килде.

— Безне Мөштәри дигән бик чая кеше укытты,— дип көлә-көлә дәвам итте ул.— Беләсең, бер сүзгә бер төртке куйсаң, әшәке сүзгә әйләнә. Безгә ул аны юри начар сүз итеп язып куя иде, шайтан...

— Бездә Казан ягын ач як кына, диләр иде,— дип куйды Гыйльманов.

— Юк, Казан бик бай иде. Базарда берәр потлы осетрлар саталар, ә алманың иге-чиге юк иде. Әстрханнан карбыз, кавын китерәләр...

Маламишкин тәмәке кабызды. Ниндидер кызык исенә төшкәндәй, йөзендә нур балкып китте.

— Татарлар кызык халык,— диде.— Хәтердә, абыйлар белән янәшә бүлмәдә Әсгать исемле чибәр генә егет үзе кебек яшь, чибәр хатын белән яши иде. Әсгатьне эшеннән командировкага җибәргәннәр. Икмәк компаниесе чоры булган. Менә шунда авылның бер укытучы кызы яраткан бит егетне. Нишләтәсең, йөрәккә приказ биреп булмый. Әсгать үзе дә җавапсыз калмаган, күрәсең. Казанга кайткач, кыздан хат килеп төшкән һәм хатыны кулына эләккән. Менә китте скандал. Хатын ирен үз янына яткырмый икән. Ахырда икесе бергә Сөембикә мәчетенә барганнар һәм егет шунда тәүбә иткән. Тәүбәдән соң дуслашып киттеләр...

— Сөембикә манарасы тәүбә урыны алайса?..

— Татарлар үткәнгә бик бирелгән халык бит ул...

Кич белән ике әшнә блиндаж учагында Гыйльманов табып кайткан бәрәңгене ике котелокта пешерделәр. Сөйләнә-сөйләнә учак янында утыру солдатның иң бәхетле минуты ул.

— Әле хәтердән санап утырам, биш-алты тапкыр үлемнән калганмын икән мин,— диде Гыйльманов.— Кешегә ялган, миңа чын дигәндәй...

— Әҗәлең җитмәгән, шул. Бәлки изге эшләрең саклагандыр?— Маламишкинның тавышында шаяру юк иде, шуңа Гыйльманов аңа карап алды. Әллә дингә ышана торган кеше инде, дип уйлады. Теге чакта аны казып чыгаргач, качырып кына уң кулы белән җилкәләренә һәм маңгаена төрткәләп алганын күргәннәр, имеш.

Икенче көнне иртән замполит Тафтилов политзанятие уздырасы икән. Ул солдатлар алдында абруй казаныр өчен әңгәмәләрне еш ясый башлады. Тупчылар кызыл почмак блиндажы тирәсенә җыелалар. Алданрак килеп өлгергәннәр шундагы бүрәнә өстенә утырганнар да телләнәләр.

— Әйдә, кемнәрнең фикере кәкре, замполит хәзер үк турайтып бирә.

— Кара фикерең булса, аны да агарта.

— Ак булмаса, теге дөнья ишегеннән үткәрмиләр, ди.

— Әнә Мөслимовның фикере кара, шуны агартсын.

— Акны салып бирсен, шунда ук агарыр, ә?— дип көлде таза гына гәүдәле, озынча бите борчак-борчак бетчәле Мөслимов. Ул бераз саранрак булганга, аңа һаман суктырып үртәргә яраталар иде.

— Замполит иманыңны яңартырга чакыра — дип кычкырды кайсыдыр урманга кереп баручыга.

— Минеке болай да нык,— диде теге. Тупчылар шыпырт кына көлешеп алдылар.

Аларны ишетмәгәндәй, Кардәшев эчтән нурланган йөз белән утыра иде. Тагы өеннән хат алган булса кирәк. Үзе янына утырган берничә сугышчыга бик кадерле нәрсә кебек итеп сөйли.

— Бервакыт улым Илдарга уенчык ат алып кайтып бирдем. Әй, сөенде бу. Шуннан гел аерылмый. Икенче көнне атны коендырырга дип инешкә алып төшеп киткән. Суга кертеп бастырган да ышкый-ышкый чистарта икән бу. Юа торгач, атның муены нечкәргән, башы да өзелгән. Сырты да сынып чыккан. Бер мәл атның тимер чыбык скелеты гына калган. «Атым үлде, атым үлде?!»— дип елый-елый кайтып керде бу. Ат акбурдан гына катырып эшләнгән булган: суда җебегән дә беткән... Әй, заманнар...

Ул күзен бер ноктага төбәп тынды. Уйлары белән өенә, хатыны, балалары янына кайтып киткән иде. Аның биек маңгайлы, җил ашап каклаган йөзендә моңсулык шәүләләре йөгерешә. Хатыны, балаларын күз алдына китереп, аерылу ачысының ничек йөрәген телгәләвен кичерә һәм эчендәге тетрәүләрен сиздермәскә тырыша сыман иде.

— Шәкүрә апаның шигырен укы әле, Кардәш абый,— дип куйды Мирхас, аны кайгысыннан араларга теләгәндәй. Кардәшев сискәнде, елмайгандай итте, кабат мондагы хәленә кайтып төште.

Кесәсеннән хатларны алып укый башлады.

— Моңсу җирләрен калдырма, шулары йөрәккә әйбәтрәк,— диделәр. Шигырьләре күңелгә уй сала торганрак иде.

Сандугачлар сайрый-сайрый әйтә:
Нишләп болай аерылдыгыз, дип.
Икегез бер канат идегез лә,
Тик давылда каерылдыгыз, дип.
Кавышулар насыйп булыр микән?—
Сиреньдәге коштан сорадым.
Ләкин кошым җавап кайтармады...
Мин яхшыга шуны юрадым...

Әйтерсең лә, шигырьдәге кайгы эчкә җыелган сагышны үзенә ияртеп алып чыга да, каядыр илтеп очыра, күңелләр бердәй бушап, җиңеләеп китә кебек иде. Кемдер әрнүле итеп:

— Их-х!— диде һәм тирән итеп уфылдады.

— Безне өйдә көтәләр инде, көтәләр...

— Син бик саран бит, сине кем көтсен?

— Сиңа саран булсам, хатын-кызга юмарт мин.— Мөслимов мыек астыннан гына елмаеп куйды.

* * *

Кулына газеталар тотып Тафтилов килеп җитте. Иң элек сугышчыларның хәл-әхвәлен сораштыргалады, аннары газетадан соңгы хәбәрләр укырга тотынды. Замполитның кәефе әйбәт иде, йөзендә һәркемгә хәерхаһлык яктысы нурланып тора. Өченче Белоруссия фронты бик алга китеп, Көнчыгыш Пруссиягә килеп җиткән икән. Бүтән фронтлар да нык алга баралар. Менә кая таба китте эшләр. Хәбәрләр сугышчыларны бик нык куандырды, алар хаклы горурланып сөйләнделәр. Тафтилов Мәскәү митрополитының чит илдәге христиан өммәтендәгеләргә мөрәҗәгатен дә укыды. Россия рухание барча христианнарны кан коюга каршы күтәрелергә чакыра иде. Бу хәбәрне тыңлаган сугышчылар бераз гаҗәпсенеп калдылар. Аларда күп төрле уйлар кузгалган иде.

— Ничек моны басып чыгарганнар?— дип шаккатты кайберсе. Башларын як-якка селкеп, ни әйтергә белми тордылар. Тафтилов ни әйтер дип аңа карадылар. Ә ул дәшми.

— Союзникларга ярар өчендер инде,— диде арада зиһенле саналган Каракүз дигән сәер фамилияле, каратут йөзле сержант. (Егетләр аны «каракүз», дип кенә йөртәләр иде.) Ул үзе бай Кубань ягыннан иде булса кирәк. Аңа бик еш посылка килә торган иде. Алмадыр, грушадыр, тагы шундый ашамлыклар. Посылканы алуга Каракүз аны расчеттагыларга өләшә дә бетерә иде, шуңа күрә бик яраталар үзен... Аның сүзенә каршы килеп тә, шулайдыр шул дип, раслап та әйтүче булмады, дин башлыгының партия газетасында чыгыш ясавын һаман миләрендә әйләндерәләр иде. Каракүз үз фикерен дәвам иткәндәй өстәде:

— Сугышны бетерергә файдасы тисә, алланың үзе белән союзник булырсың...

— Әйтмәсәң дә,— диде Кардәшев бер дә бу эшкә исе китмичә. Ул һәртөрле диннең кешеләр уйлап чыгарган тәртип-низам кагыйдәләре җыелмасы икәнен белә иде.

— Бәлки немецларны күздә тоткандыр митрополит?— дип көлемсерәп әйтте Тафтилов. Аны сугышчыларның ничек фикер йөртүләре кызыксындыра иде.

— Нигә, немецларда да дин бар микәнни?!— дип гаҗәпсенде Мөслимов бу мөмкин түгел дигән төс белән.

— Алар да христианнар,— диде Милашкин, үзенең бу өлкәдә төшеп калганнардан түгеллеген белгертеп.

— Немецны дин белән йомшартырсың, бар. Шайтанга иман кертергә маташкан кебек,— дип, Гыйльманов тамак төбе белән көлеп куйды.

Сугышчылар да гөрелдәп көлеп җибәрделәр. Милашкинның сер бирәсе килмәгәндәй авызы ерылды, күзләре җитди иде. Ул һаман да ышанмаган кыяфәт белән башын күтәрде... Милашкин әкрен генә урыныннан торды һәм, аякларын көчкә-көчкә атлап, үз пушкасы янына таба юнәлде. Гүя башы авыр уйлардан түбән иелгән иде. Каракүз дә кузгалды. Ә Гыйльмановның йөзендә нәрсәдер әйтергә теләү нуры кабынды. Аның замполит каршында зирәк кеше булып күренәсе килә иде. Әмма ни генә сөйләсә дә, сүз җае туры китереп, кызын мактап алмыйча түзә алмый иде.

— Минем кызым укыган кеше, гел әйтә иде: коръәнне аңлап укыган кеше диннән яза, дип. Ягъни дәһригә әйләнә, имеш...— диде ул, Тафтиловка таба төбәлеп.

— Имеш түгел, чыннан да шулай,— дип, Кардәшев каршы килмәслек тавыш белән әйтеп куйды.— Аңлаган кеше коръәннең бик күп каршылыкларын күрә дә аңардан биза.

— Әйе, бернинди могҗиза юк икәнен белә ул анда,— диде Тафтилов абруйлы төс белән.

— Могҗиза булмагач, кеше аңа ышанмый башлый. Бар кәмите шул,— дип Кардәшев кеткелдәп көлгән сыман итте. Аның тавышында ниндидер ишарә бар иде. Ул шыпырт кына тыңлап утырган юлдашларга карап алды.

— Менә ни өчен пәйгамбәрләр үзләрен могҗизага төргәннәр!— диде Тафтилов.— Бу яктан Мөхәммәт барысын да уздырган шикелле.

— Үзе генә түгел, куштаннары шулай тылсымга төргән аны.

— Анысы да хак...— Ул нидер озын итеп, аңлатып сөйләргә җыенган иде, ләкин аны телефонга дәшеп алдылар. Замполит киткәч, бүтәннәр дә үз урыннарына таралдылар.

Көн кичкә авышып әкрен генә сүнеп бара. Күкне соргылт авыр болытлар каплаган. Көзнең салкынча сулышы шактый нык сизелә инде. Нәрсәдер моңсу, нәрсәдер бик җәл булып тоела иде. Тафтилов эшләрен бетереп килеп, тагы бүрәнәләр өстенә тәмәке тартырга утырды. Һаман диннәр турында уйлана иде. Күпме халыкларны шул дин бер-берсенә каршы сугыштырган. Икенче диндә булган өчен генә үзе кебек кешене дошман күргән, аны үтерергә барган. Кешенең эшләп туплаган байлыклары шушы сугышларга тотылып беткән. Моннан да мәгънәсезрәк исраф булуы мөмкинме? Нинди ахмак расход! Кеше миендә караңгылык күп әле, әх, егетләр!

Шуңа күрәдер инде акыллылар әйткән: кеше гомере буе караңгыдан яктыга бара дип. Дөнья да шулай караңгылыктан яктылыкка таба хәрәкәт итә...

...Идрисов исә һаман Латышев турында уйлап бара иде. Әй мин сиңа ышандым, туган, ышандым. Йөз кеше сиңа ышанмаганда да мин ышанычымны җуймадым, ялгышасың, дип, намусыма тукындылар, чукып, канатып бетерделәр, мин һаман сиңа ышанам, дидем. Әй бит мин сине юньләп белми дә идем. Юк, бу минем акыллы булуымнан яки зирәклегемнән түгел, мин ничектер синең дөрес кеше булуыңны тойганмын ахрысы. Аннары сиңа ышанмаска кушылгач, миндә тискәрелек уянды, әйе, минем аларга карышып булса да, сиңа ышанасым килде. Синең серле югалуың әнә нәрсәләр китереп чыгарды... Йөз кеше ышанмыйча синнән йөз чөергәндә, бер адәм сиңа ышанса, шул да әйбәт икән. Шул берәү коткара, тормыш тагы үз эзенә төшә икән... Йөз кешене бер кеше җиңә икән...

Их, Фәимәне күреп, шуларның барысын да аңа сөйлисе иде. Ничек мин ышанмаучылар ягына авышмый калдым? Шул турыда.

Особый отдел бер латыш утарына урнашкан иде. Керү белән ниндидер хатын-кыз көлгән авазлар ишетелеп калды. Идрисов моннан унбиш көн элек, үзенә бик каты ябырылган лейтенантны эзләп тапты. Ул Идрисовны танымады, Латышев табылды, дип, өстәлгә кәгазьләрен китереп салгач кына исенә төшерде.

— Кайда үзе, кайда?— диде кабалана-кабалана, өстәл тартмасын ачып, ниндидер катыргы алды. Матур йөзендә кызыксыну дәрте кабынды. Әмма Идрисов эшнең асылын әйткәч, кинәт чыраендагы ут сүнгәндәй булды. Аның тыңлыйсы да килми кебек иде. Идрисов һаман сөйләде, үзенең хаклы булып чыгуын төшендерәсе килде. Бу бит минем гамәли хәлемә дә сукты, диде. Лейтенантның кашлары җыерылды, ул бары көчәнеп, тырышып кына тыңлый иде.

— Миңа кара тап ягылды.— Шуны әйткәч, Идрисов лейтенантка күз салды һәм шунда аның устав калыбыннан бер миллиметр да читкә чыга алмый торган кеше икәнен сизгәндәй булды.

— Нигә, бик дөрес! Сез чиста гына йөрмәкче буласызмы?— Юк!— Лейтенантның ачуы кабарганлыгы тавышыннан беленде.

Бары тышка чыккач кына Идрисов үзенең ялгыш сүз ычкындырганын аңлап алды. Чынлап та, Латышев үлеме каршында нинди тап хакында сөйләргә мөмкин! Өлешеңә тигән көмешең...

Эш пешмәде, дип уйлады ул һәм шундый чакта аның үҗәтлеге чыга иде. Бу юлы да шулай булды. Шул үҗәтлек полкның кадрлар начальнигына сугылып чыгарга этәрде аны... Идрисовны һаман комбат итеп расламыйча йөртәләр иде. Мостафин бер очраганда мин стенаны тишә алмыйм, үзең барып кара әле дигән иде. Нишлисең, Идрисов барды. Бер генә түгел, ике дә, өч тә барды. Кадрлар начальнигы — елмаеп кына тора торган лейтенант — һаман өметләндереп кайтарып җибәрә. Тагы баргач, шулай ук майлы елмаеп, менә теге бүлек белән килештерелмәгән, менә тагы тегесе җайланмаган, дип сәбәп табып, шулар белән киртә кора. Мостафин да бу бюрократлыктан гаҗиз иде, әмма кискен сөйләшеп мөнәсәбәтне бозасы килми бугай. Күп нәрсәне мөнәсәбәт хәл итә шул... Иң җанга тигәне, командирлыкка тулы хокуклы булмагач, батареяга тиешле кирәк-яракны, запчастьне бүтәннәр авыздан тартып алалар иде. Бу хәл Идрисовның бик каты ачуын китерә башлады. Мостафин каршында да оят иде.

Нинди ачкыч табарга бу бюрократ Такрановка? (Кадрлар буенча начальникның фамилиясе шулай иде) — дип уфтанды Идрисов. Мостафин сүзен дә санга сукмагач, нәрсә инде? Командир итеп куясылары килмидер, мөгаен, шуңа сузып йөртәләр, үзләренә җайлырак кеше эзли торганнардыр?... Бер көнне кичкә таба Идрисов штабка барган иде. Такранов урынында юк. Әнә, күрше йортта гына аның квартиры, шундадыр диделәр. Идрисов керергәме дип икеләнеп торды да тәвәккәлләде.




*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме*

Такранов квартирасыннан чыгып килә иде. Үзе бик кәефле. Йөзе кызарган, Идрисовка да шатланып кул бирде. Мәсьәлә уңай хәл ителгән икән дип уйлады Идрисов.

— Син теге эш буенчадыр инде, ә?— дип, Такранов үзе башлады.

— Мостафин безнең белән киңәшми эшләде, понимаешь, шуннан матавык туды. Бездән генә тормый бит...

— Аңлыйм,— диде Идрисов, эшнең хәл ителмәвенә пошынып.

— Әтиең мулла идеме әллә?— дип пышылдады Такранов яшерен сер бүлешкән кебек.

Идрисов моңа каршы ни әйтергә белмәде, авыл мулласы сырхаулаганда, я буш булмаган чакта, кайбер дини мәҗлесләрдә коръәнне аның әтисеннән укыталар иде. Мәкаме әйбәт булганы, коръәнне яхшы белгәнлеге өчен генә. Моны әйтеп торыргамы икән?

— Юк,— диде Идрисов ныклы тавыш белән. Бу мине сыный икән, дигән уй килеп, сагаеп калды.

— Менә мин ни өчен үсә алмадым!— дип кызу-кызу сөйли башлады Такранов. Алар, ишегалдыннан чыгып, каршыдагы урман ягына бара торган ниндидер сукмактан атладылар.— Мин беспризорныйдан гарнизон башы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән кеше, ни өчен бүтән үрли алмадым? Чөнки аракы дигән бер иблис бар дөньяда, шуны беләсеңме? Шул иблис харап итте мине. Бер йомшак ягың булдымы, син инде житәкче роленә ярамыйсың. Ә синең шундый берәр йомшак ягың юкмы?

— Бар,— диде Идрисов ихластан. Эчтән ул: мине барыбер комбат итеп куймыйлар икән инде, дигән нәтиҗәгә килде дә, кул селтәп, барын да ачыктан сиптерергә булды.

— Нинди? Сине дә шул иблис чабуыңнан тартып түбән төшерәме?

— Юк! Мин кешене жәллим...

— Ә-ә, ансы да начар шул! Кешенең бер кимчелеге кискен моментта аңа хыянәт итә. Шундый хәл булды: бер рота командиры немецлар чигенеп барган чакта төнлә алга разведка җибәрә. Бер юка гына урманның теге ягында немецлар бармы, юкмы? Ике разведчик һәм элемтәче кабельне суза-суза китәләр. Өчесе дә яшьләр, тәҗрибәсез сугышчылар. Бераздан тегеләр монда немец юк дип шалтырата. Комрот сугышчылары белән шунда барып урнаша. Окоп, траншеялар корыштырып, тәмам хәлдән таеп, таң алдыннан йоклап китәләр. Яктырганда боларга арттан да, алдан да ата башлыйлар. Нәрсә бу? Бөтен тирә-юньдә немецлар икән. Болар чигенмәкче булып урманга шуышалар. Ләкин монда да немецлар пулеметтан аталар. Рота кырылып бетә диярлек. Комрот яралана, аны бик үнган, үткен разведчигы дошман авызыннан алып чыга.

Аннары комрот эше трибуналда каралды. Ни өчен шундый хәл килеп туды дип сорыйлар аңардан. Ник сукырларча фриц «кочагына» килеп кердең? Разведчиклар белмәгәннәр, тәҗрибәсезләр иде, дип акланып маташты ул. Нигә тәҗрибәле ике разведчигыңны җибәрмәдең? Мин аларны жәлләдем, чөнки алар укыган, бик акыллы кешеләр иде, ди. Ике кешене жәлләгәнсең, ә ничә кешене һәлак иткәнсең,— дип күзен дә ачырмыйлар комротның... Шулай кискен обстановкада кешене кызгансаң, эшең дә юкка чыга, кешеләрең дә, үзең дә...

Такранов сөйләгән саен кызмачалана бара иде. Бу ачылып китүгә дә аны шул иблис этәрде бугай. Бераз баргач, Такранов туктады, йөзендә: шунда кал, дигән эчке ым сизелде. Идрисовтан тизрәк арынасы килеп, аңа ныклы вәгъдәләр бирде.

Аерылып бераз киткәч, Идрисов артына борылып карады һәм Такрановның туп-туры эвакогоспиталь урнашкан җиргә баруын күрде. Чынлап та теге иблис йөртә икән моны дип, эчтән генә уйлап елмайды... Үзе әйбәт кеше ахры бу Такранов, ләкин йомшак ягы бар икән шул. Кемдә генә юк инде ул йомшак як. Шул йомшак ягы белән көрәшә-көрәшә яши инде адәм баласы...

Инде мәсьәлә хәл ителгәндер, дип ышанып, Идрисов шактый вакыт Такранов янына килә алмады. Латышевның югалуы, башка мәшәкатьләр...

Бүген кереп барысын да белешергә кирәк инде. Латышев та табылды, бүген гел аңа бәхет ишеге ачылып кына тора әле. Комбат итеп расласалар, тагы бер бәхет ишеге ачылган була...

Ләкин штабта Такранов өстәле артында бүтән бер өлкән лейтенант утыра иде. Идрисовның аптыраулы карашын күреп ул:

— Такрановны күчерделәр,— диде. Идрисов үзен кулга алып өлгерде һәм, исен җыеп, үзенең ни өчен килгәнен әйтте. Теге сейфтан папкаларны бер-бер артлы алып карап, моның кәгазьләрен тапты.

— Юк әле, расланмаган,— диде.— Мин иртәгә дивизия штабына барам, бу күптән сузылган эшне шунда хәл итәрмен...

Моның үз сүзендә тора торган кеше икәне күренеп тора иде.

### 5

...Әй, безнең әни тынгысыз да кеше инде, дип гаҗәпләнеп уйлап куйды Мостафин аның хатын укыгач. Туган Кандызым дип үлә иде инде. Бигрәк тә безнең бакчада үскән бәрәңгене сагына иде ул. Их, тәмле иде дә соң ул галан бәрәңге! Тышы бераз сыек алсу төстә, ә эче ап-ак мамык кебек ярмаланып тора. Аннары әни үзенә генә тотар өчен тагы шәмәхә бәрәңге үстерә, шуны ашасам, баш сызлавым бетә, дип әйтә иде. Ул шәмәхә бәрәңгенең тәмлелеген һич тә әйтеп бетерә торган түгел инде. Магнитогорскиның Березовка бистәсендәге кысан баракта шул бәрәңгене юксынып күз-яшь коя иде.

Әмма җанына кан саудырган нәрсә тагы шул иде: әти үләр алдыннан гына бетереп кергән алты почмаклы өй. Әти-әни ул йортның һәр бүрәнәсенә бик күп тир түккәннәр. Хәзер шул өйдә активист булып йөргән Шалтай Варисы тора иде. Әни шуның хурлыгыннан нишләргә белмәде. Юньле адәм булса тагы бер хәл әле, юк бит, яшьрәк чагында кәҗә урлап тотылган һәм кыйналган адәм. Авылда бер ертлач, сугыш башлангач, авыл советы председателе булып алган. Анда да үз начарлыгын итми калмаган, сугышка үзе урынына әллә ничә кешене җибәргән. Ләкин замана үзгәрде, моның әшәкелеге бик тиз ачыла. Хәрби закон буенча авылдан егерме дүрт сәгать эчендә туры фронтка озаталар Шалтайны. Ә хатыны ике баласы белән атасы нигезенә кайтып киткән... Өй бушап калган. Әнигә барысын җиткереп кенә торалар икән... Ниһаять, әнинең күгенә дә кояш чыккан. Бер малае майор, икенчесе — лейтенант, икесе дә алгы сызыкта. Моның белән һәрбер ана горурлана ала хәзер. Безнең әни үз көне килгәнлеген аңлап алган, үзенекен иткән. Хәрби мәктәптә җыештыручы гына булса да, башы эшләгән. Аңа мәктәп начальнигы Разумовский булышкандыр, мөгаен. Аның кебек әйбәт кешене Мостафинның күпме йөреп очратканы юк әле. Була бит шундый әүлия кешеләр! Белә, синең аңа бер файдаң да тимәячәк, ә үзе сиңа гел игелек итә!

Калининга гозерне миннән дә яздыра алыр иде, юк, безнең әни үткен, аңлы. Кулдан бер киткән нәрсәне кире кайтару четерекле мәсьәлә. Улларымның абруена хилафлык булмасын, кеше арасында йөзләренә кызыллык килмәсен дигән, гозерне Разумовскийдан яздырган. Җитмәсә, шул сөенеч шаукымы беләндер инде, Рифаның рәсемен сорап язган...

Кинәт бу минутта, ул кызны бер читкә этәреп ташлагандай, Мостафинның күз алдына тагы Зитта килеп басты... Нәрсә кирәк миңа аңардан? Ник күңелем һаман аңа гына омтыла? Нинди сихер кебек бу? Нидән шулай килеп чыкты соң? Тагы сәер хис: әйтерсең лә, минем аңа түлисе бурычым бар! Минем Зиттага бернинди дә бирәчәгем-алачагым юк, алайса нигә ул җанымны йодәтә?

Юк, Зиттаны бүтән күрмәскә, очрашмаска! Барысына да нокта куярга. Әгәр очрашырга туры килсә, салкын гына булырга, сөйләшмәскә, нинди

борчуга баткан чырай күрсәтергә, шуннан үзе аңлар. Миңа тиздән биредән китәсе, күз алдында тормагач, үзеннән-үзе онытылыр, йөрәктән өзелеп төшәр... Бу тиле хисләр бетәр...

Шулай итәм, бүгеннән башка безне «тоташтыра» торган күперләрне яндырам. Зитта ягына чыгышлы булмасын. Вәссәлам. Әллә шушы эш минем көчемнән килмиме? Килә!

Эченнән шулай план корган булып, Мостафин өенә кайтып бара. Үзе эт кебек арыган, яңак сөякләре калыккан, ияге саргылт төк белән капланган. Ике көн, ике төн ул гел аяк өстендә булды. Башта киңәшмәләр, аннары тикшерүчеләр белән мие тугланып бетте. Күзен йокы баса. Менә әле дә йоклый-йоклый бара ул. Күзе ихтыярсыз йомылган кебек атлый, ләкин аягы берәр нәрсәгә килеп сөртенү белән күзе тагы ачылып китә. Юл кырыенда утырган баганалар йоклый сыман тоела аңа, нинди рәхәт аларга! Йокыдан да рәхәт берни юктыр. Әнә Зитталарның капкалары, козырегын күзенә каплаган да, нинди татлы йокыга талган...

Әйе, барысын бер селтәнүдә өзәргә, дип өй ишегенә килеп җиткәч, тагы үзенең тәүбәсен кабатлады ул. Өй бикле иде, димәк, хуҗа чыккан. Ул кесәсеннән үз ачкычын алды.

Ул ятагына ничек ауганын да сизмәде. Бары бөтен тәне май кебек эрегәнен, нindидер рәхәтлеккә чума барганын гына шәйләде. Миендәге фикерләр дә, ләмгә эләккән балык сыман, әз генә талпындылар да тындылар. Барысын да йокы үзенең баллы кочагы белән тынычландырды...

Шундый рәхәт йокыда изрәп күпме яткандыр, бераздан нindидер бер эчке борчудан сискәнеп уянды. Гадәтенчә, уяну белән сикереп торып утырды. Көн якты иде әле. Башы сафланган, тәне җиңел булып калган иде, шуның рәхәтен тоеп, кулларын як-якка хәрәкәтләндереп алды. Коридорда ишетелгән аяк тавышлары аны өстәл кырыенда яткан кобуралы каешына үрелергә мәҗбүр итте.

Аңа шакыдылар, ул әйе дигәнче, ишек ачылды, Зитта күренде. Аның ике кулында ике йомры ак чәйнек иде. Мостафин аны-моны аңлап өлгергәнче гаҗәп хәл тойды: лампочка кабынган кебек бүлмә эче яктырып китте. Зитта үзе дә тоташ нур кебек якты иде. Ачык маңгай, юеш чия төсле иреннәре, яшерен очкын белән ялтыраган күзләре һәм килешле кашлары нindидер яктылык белән өртелгән. Мостафинның үз-үзенә биргән тәүбәләре шул нурлардан эреде дә юкка чыкты. Ул елмаеп, кыз каршына атылды.

— Кофе белән сыйлыйм әле үзегезне,— диде Зитта, чәйнекләрен куеп.

— Ай, рәхмәт, яугыры!— Мостафин шатланды һәм шуңардан кыюланып китеп кочагын җәеп килде дә кызны биленнән кочып алды. Кыз да ничектер кочактан ычкынырга итеп тайчынмады. Ул кызның сыгылма билен һәм тәненең ефәктәй шома икәнлеген тойды, бармаклары аша миенә кайнар елдырым йөгереп менде. Шул мәл үзенең тәүбә итүләре нинди ахмаклык булганын аңлагандай булды. Кызны иплəп кенә өстәл янына утыртты, үзе тәпи баскан көе, өстәлгә япкан газетны алып куйды. Стаканнарга кофе бүлә-бүлә Зиттаны күзәтте: аның бу эшендә берәр яшерен мәгънә ятмыймы? Юк шикелле, Зитта һәр хәрәкәте белән ихлас, юмарт күренә, шулай да нәрсәдер бар төсле: ул үзе өчен нindидер карарга килгән дә, шуның хуплануын Мостафинның яратулы кыяфәтендә күреп елмая, юк кына нәрсәдән дә көлеп ала иде. Көлгәндә ак кофтасы аша тыгыз, төртеп торган күкрәкләре, җил селкеткән алмагачтагы алмалардай, дерелдәп куялар, Мостафинны чиксез бер рәхәт дулкынына күмәләр иде. Шул дулкын ихтыярында ул нишләргә белми...

— Әллә биредән китәсезме?— дип елмаеп карады Зитта, Мостафин кофе бүлеп аның янына утыргач.

— Юк, нигә алай әйтәсез?— Мостафин ялган тотылудан шикләнеп күзен читкә алды.

— Ничектер китәрсез төсле.

— Бик күрәзәче буласыгыз килә, ахры?

— Хатын-кызда нииндидер алдан сизү бар. Теге, җәнлекләрдә бәлане алдан шәйләү була бит әле, шуның кебек. Диңгездә медузалар давыл алдыннан ярдан эчкәрәк йөзеп керәләр, юкса дулкын аларны яр ташларына бәреп үтерер иде.

— Хатын-кызда да шундый саклану бар, дисез инде! Кызык, белмәгән идем.

— Әйт әле, ничә кызның йөрәген яулап алдың?— дип көлә-көлә кыюланды Зитта. Ул хәзер үзен шактый иркен тота иде. Майорның әйбәт кеше икәнен белде һәм күңелендә якты өметләр дә туды. Бу нииндидер ышанычлырак өмет, шулай сизә. Өметсез өметләргә ябышып та яшәлде. Шушы өметкә тотынса, ул аны бер ярга илтеп чыгарыр төсле.

— Андый чослыгым юк, Зитта. Гаскәриләргә ул бәхет тәтеми.

— Син, Даут, аучы түгелдерсең дә, тик кайбер хатын-кызлар аучылыкка бик осталар!

— Яулап алдың, янәсе?— дип көлә-көлә әйтте Мостафин.— Әйе, кайберәүләр яуларга тырышып карадылар тылда, госпитальдә чакларда, ләкин йөрәгемне ала алмадылар...

Зитта көлде, ул үзен борчыган сорауларга уңай җавап алган шикелле иде. Йөзе тагы да ныграк нурланды. Аның шукланасы килә, кайчак Мостафинның беләгеннән тартып куя иде.

Зитта:

— Мин бер кешене яратырга телим, дигән Кыз. Мин дә синең белән бергә, дигән Ахмаклык.

Кыз тагы шыркылдады, Мостафин шаяруга шаяру белән ничек җавап кайтарырга белмәде, шуңа көлде дә көлде. Әмма зиһене әйбәт эшли иде, кызның кайнар кулын катырак кысып, уенның җаена шунда ук төшенеп алды.

Даут:

— Мин бер кызны дус итәргә ниятлим, дигән Егет. Мин дә синең белән бергә, дигән Бурыч.

Зитта:

— Йөрәгемне бер егеткә ачар идем, дигән Кыз. Мин дә синең белән бергә, дигән Тугрылык.

Даут:

— Бер кызга бик ышанасым килә, дигән Егет. Мин дә синең белән бергә, дигән Бала.

Зитта:

— Минем бер егеткә бик охшыйсым килә, дигән Кыз. Мин дә синең белән бергә, дигән Шөбһә.

Даут:

— Мин ул кызны яратам бугай, дигән Егет. Мин дә синең белән бергә, дигән Хыянәт.

— Яратуның юлдашы Хыянәт? Юк, ул юлдашны үзебез белән алмыйбыз!— Зитта башын аскарак иеп көлә иде, Мостафин аны ике куллап кочаклап алды. Зитта әз генә калтырап киткәндәй булды, үзе дә талпынгандай итеп ак беләкләре белән Мостафинның муенын урады. Егет үбешә белми иде, Зитта үзе башлап уттай кайнар иреннәрен аның иреннәренә ябыштырды.

Алар диванга авып төштеләр. Егет кызның ак муенынннан үпте, уйларының кинәт туктап калганын сизде. Зитта аны моңарчы аңа билгесез булган дөньяга алып киткән иде.

Иң элек бу фани, гаугалы дөньяга Зитта кайтты. Мостафин да күзләрен ачты.

— Кем син Зитта, кем син?— дип кабатлады башын күтәрмичә. Үзенең дәрте ташыганнан-ташый баруын сизде.

— Синең трофееңмин, Даут,— диде Зитта, аның чәчләрен бармаклары белән аралап.— Атып алган торнаң мин синең.

— Зитта, син нигә: мин синең хатының булдым, дип әйтмисең?— диде аны кочагына алып. Мостафин кайбер кызларның шундый сүз белән егетләрен үзләренеке итмәкче булуларын ишеткәне бар иде.

— Син нинди беркатлы кеше!— Зитта көлде.

— Юк, мин чынлап?

— Шундый иске нәрсә көткән идеңме?

— Минем өчен яңа бит ул.

— Юк, мин алай үземне сиңа тагарга теләмим,— диде Зитта бер кулы белән күкрәкләрен япкалап.

— Нилектән?

— Беләсеңме, менә юаш кына мәхлук бер этне бәйләп куй, ул шунда ук бик каты усаллана.

— Мин усалланып, җепне өзәр дип уйлыйсыңмы,— Мостафин шыркылдап көлеп куйды. Гаҗәп тә инде бу Зитта, һәрнәрсәнең үз бизмәне:— юк, кешене бәйләргә яратмыйм. Ул усалланса,— үзем дә усалланырмын, дип куркам.

— Син усал була алмыйсыңдыр?

— Сөйләшкәндә барыбыз да әүлияләр.

— Бәла килсә чын «кешегә» әйләнәбез, ә?

— Әйе, әрсезгә әвереләбез...

Алар үзалларына уйланып, тынып калдылар.

— Кайчан китәсез?— Хәрби серме?— диде Зитта.

— Юк. Белмим.

— Әй, гамәл фәрештәсе.

— Юк, без тәмуг фәрештәләре!— Мостафинга бу атама бик ошый иде һәм ул көлеп куйды.

— Синең эчеңдә гамәл белән намус тартыша инде?

— Белмәдең, Зитта. Алай уйлавың ялгыш!

— Тартыша.

— Син бик акыллы, Зитта. Ләкин хатын-кызга артык акыллы булырга ярамый бугай.

— Ни өчен?— дип Зитта Мостафинга яратып һәм кызыксынып карады.

— Акыллылык бәласенә төшүең ихтимал...

Зитта шыркылдап көлеп җибәрде һәм озын керфекләре рәхәтлек, наз тулы күзләре белән тагы Мостафинга текәлде. Аны үзенә таба тарткан шикелле булды, алар тагы бер-берсенең кочагына атылдылар.

## 6

Приказ... Ничектер бик кинәт булды бу. Мостафин, алгы сызыкка күчәсен алдан сизенеп йөрсә дә, бу хәтле ашыгыч китеп барылыр дип уйламаган иде. Яңа позициягә барырга ике сәгать вакыт куйдылар. Шул ара эчендә ул яңа урыннан шалтыратырга тиеш иде.

Машиналарга төялеп юлга чыктылар. Дөм караңгы, дегет кебек төн. Карлы-бозлы яңгыр ява иде. Машина тәрәзәсенә, борчак сипкән тавыш чыгарып, китереп-китереп бәрә. Яңгыр астына чыксаң, бераздан боз сөңгесенә әйләнәсең.

Вакыт шул чаклы тыгыз булды, Мостафин Зитта белән саубуллашып та чыга алмады. Шуның өчен хәзер бик нык эче пошып бара иде. Шайтан алгыры, качып киткән кебек килеп чыкты, дип эчтән генә үкенә, җанын нәрсәдер уеп-уеп алган кебек итә. Кабат күрә алырмы ул аны, юкмы? Әз генә арада Зитта аңа бар нәрсәдән дә якын булып китте. Моңарчы ул приказ белән генә йөрергә өйрәнгән иде, шуңа күрә Зиттага булган тойгылары аны куркыта да иде. Элек аңарда бер генә «мин» иде. Һәм ул кылган эшләрнең барысын да хаклы эш дип, эчтән раслап бара торган иде. Зиттаны ярата башлагач, аңарда икенче «мин» барлыкка килде. Беренче

«мин» Зитта белән булган мөнәсәбәтләрне хупламый, хәтта начарга саный. Көнелендәге эчке тартыш, эчке газап әнә шуңардан килеп туа иде. Зитта булмаганда ул: юк, аның янына бүтән бармыйм, бүлмәгә керсә дә салкын гына булам, шуннан үзе аңлар, нәтиҗә ясар, дип үз-үзенә кат-кат тукый, антлар бирә. Әмма кыз ишектә күренүгә бөтен антлары су белән юып алгандай юкка чыга, батыр булып маташулары әллә кая китә дә бетә. Ул тагы нурланып елмая, аны яратуы бөтен кыяфәтендә кычкырып тора башлый...

Ниһаять, алгы сызыкка барып җиттеләр. Бозлы янгыр һаман сибәли иде әле. Мостафин тупчы батареяларга позицияләр күрсәтеп йөрде. Караңгыда һәм янгырда бу бик авыр эш иде. Төнлә сайлаган позиция көн яктысында башкачарак булып чыга. Моны исәпкә алырга кирәк булды. Шул хакта комбатларны бик нык кисәтте, әз генә яктыра башлау белән җитәрлек яшерелмәгән пушкаларны ышыграк урынга күчерергә кушты.

Тәмам манма су булып кайтып керде. Плащ-палаткасын комбат дүртенче батареяга биргән иде. Ул күп эшләргә яратучы уңган комбат. Үзе бик юка тәнле, кәгазьдәй ак какча йөзле: әй, риясыз да кеше инде. Бик чыланган иде. Мостафин аны уңган, эчкерсез булганга җәлләде һәм, плащ-палаткасын аңа биреп, бүтән батареяларга китте.

Ярый әле, Асоев блиндаж табып куйган. Фрицтан калган нәрсә бугай... Уртада ара, ике якта сәкеләр. Асоев һәрчак үзе белән йөртә торган чуен мичне куеп, ягып та җибәргән иде. Ләкин Зангир юклык сизелә. Ул булса чәй дә кайнаткан булыр иде. Асоев та ничектер моңсу йөри хәзер. Зангирны юксына булыр. Алар бер-берсенә шундый нык бәйләнгәннәр, якын туганнар да алай булмас, чын. Ул аның өчен югарыдагы начальниклардан ун көнлек отпуска юллап озак йөрде. Тәки үзенекен итмичә калмады. Тылга кайтып китте. Үзенә кайта микән, Асоевка микән — Мостафин белмәде һәм белергә дә теләмәде. Чөнки Асоев боларның барысын да аңардан яшерә, белгертергә теләми иде. Бергә эшли торган кеше гамәлен синнән яшерә икән, димәк, ул сиңа ышанмыйчарак карый дигән сүз. Мостафин Асоевның уңган кеше булуын күреп һәм белеп, аңа тигез, тыныч карый, шәхси эшләренә тыгылмый, вакчылланмый иде. Асоев үзе дә комдивның киң күңелле булуын белеп, үзен иркен тота. Шулай да ниндидер ара бар. Бер-береңне өнәмәү түгел бу, ә бары горурлык саклау шикелле нәрсә иде.

Мостафин шинелен алыштырып мич буендагы сәкегә ятты, ләкин җылына да, йоклый да алмады. Суык тәмам эченә төшкән иде. Ул, торып, блиндаждан чыкты, яктырып беткән икән инде. Блиндаж урман буенда гына икән. Монысы әйбәт. Әмма бөтен җир өсте шома боз белән капланган, суытып та җибәргән иде. Манма юешләнгән солдат бу суыкта нишли инде, дип борчылып уйлады ул. Менә кемгә кыен фронтта. Бар авырлык солдат җилкәсендә шул. Бүген иртән бирсәң иде үзләренә йөзәр грамм, юк бит, бары һөҗүм көнне генә тиешле.

Ул элемтә сузучы солдатларны күзәтеп торды, җылынырга итеп, кызукызу йөренде. Аннары блиндажга керде. Тимер мич өстендә чәй кайнап чыккан иде. Асоев белән чәй эчә-эчә ашыгыч эшлисе эшләр турында сөйләшә башладылар. Ишектә плащ-палатка кыштырдады, һәм алар каршына таныш кеше килеп басты. Бу укчы подразделение командиры капитан Мамак иде. Аны көтәләр иде, шуңа гаҗәпләнмәделәр, ул бирегә ике-өч көн алдан килгән. Тыенкы-салкын гына кул кысыштылар. Икесенең дә йөзендә бу очрашудан канәгатьсезлек, читләшү төсмерләре беленеп калды. Нидән бу? Теге вакыттагы уңышсыз һөҗүм операциясен тикшерүдән соң, бер-берсенә кул биреп, дусларча аерылышканнар иде. Барысын да эчкә яшергән булганнар икән. Соңыннан һәрберсе үзалдына уйланган һәм үзен гаепсез, иптәшен гаепле итеп калдырган шикелле.

— Тагы бергә...— диде Мостафин, чәен эчеп бетереп, тыныч кына һәм Мамакның ризасыз, йомык йөзенә карап алды.— Нәрсә болай бик чытык?

— Теге вакытта бар гаепне миңа өеп калдырдылар,— диде Мамак эчкә яшерелгән ачу белән.

— Ә-ә, шуның өченмени? Онытмадыңмыни? Бәлане тигез бүлештек шикелле. Шелтә чәпәделәр. Юк, онытырга өйрәнергә кирәк. Кайрыга төренергә...

— Нахак онытылмый ул...

— Нинди нахак?— дип Мостафин әсәрләнеп һәм сагаеп Мамакка карады.

— Төп гаеп тупчыларда иде, ә мине...— диде Мамак әрнешкән тавыш белән. Бу чынлап рәнҗегән икән, дип уйлады Мостафин. Мондый кәеф белән хәзер тагы бергә эшли башлау читен булачак иде, шуның өчен барын да ачыктан-ачык сөйләшеп, мәсьәләнең төбенә тоз коярга кирәк. Ул кашларын түбән каратып уйланып торды. Юк, тавыш күтәрү бары кире нәтиҗә генә бирәчәк. Әйбәтләп аңлатырга, егетнең кимсетелгән күңелен дөреслек белән йомшартырга... Нәкъ шул моментта Асоев чыгып китте, әйбәт булды.

— Ну бит эш болай иде,— диде ул, гади бер нәрсәне әйткән кебек тигез генә...— Беләсең, беренче траншеяны алгач, немец бик каты каршылык күрсәтергә тотынды. Ә шушы очрак өчен без синең белән бер җай әзерләгән идек: траншеяның сул ягындагы тирән чокырга төшәргә һәм фрицның тылына чыгарга. Бары биш йөз метр ара. Дөресме?— Мостафин Мамакка карады. Теге мәҗбүри генә ияк каккандай итте.— Ләкин син моңардан файдалана алмадың. Мин сине гаепләмим. Һөҗүм ул мәкерле нәрсә. Ну, әгәр шушы мөмкинлекне тикшерүдә ачып салсам башың китә иде! Моны инде бик яхшы аңлыйсың булыр?..— Мостафин нинди дер газизләнү белән тезләренә суккалап алды да урыныннан торды. Мамакның дәһшәт тулы чыраенда йомшару сызыклары беленгәләде.

— Нигә әйтмәдең соң?— диде ул, горурлыгы өчен генә, чөнки аның Мостафин дәлилләренә каршы куярлык бер нәрсәсе дә юк иде.

— Ни өченме?— дип, Мостафин бер мәл дәшми торды.— Чөнки эшне берничек тә төзәтеп булмый иде. Ә иң мөһиме, син куркак түгел, ә үзеңне аямый торган риясыз кеше!

— Ярый, бетте, бетте,— дип, әз генә сизелерлек көлеп куйды Мамак. Аның украинлыларда гына була торган матур йөзенә ягымлылык һәм якынлык чалымнары чыкты.

— Инде эшкә тотыныйк,— диде Мостафин өстәлгә картаны җәеп.

Карта өстендә обстановканы өйрәнә башладылар. Мамакның зур лупасы да ярап куйды, алгы позицияне зурайтып күрү алданудан нык саклый торган нәрсә. Әле күзәтү мәгълүматлары юк дәрәҗәсендә, Мамак укчылары моннан өч көн элек кенә оборонага килеп урын алганнар. Шулай да бу тирәдә дошманның көче күп икәне билгеле. Аннары биредәге утрау-утрау урыннар һөҗүм белән алга бару өчен бик комачау итәләр. Дошман шуларда яшеренеп, беткәнен дә белмичә каршылык күрсәтә...

Мамак туры кеше иде, бераздан ниндидер сүздән тагы баягы мәсьәләгә кайтып:

— Шулай да эчтә ниндидер ачу төене бар,— дип әйтеп куйды. Мостафин аңа карап торды да, елмайды.

— Егет кеше кем — ачуын эчкә йота белгән кеше! — диде.

— Ачу йоту — дөя йоту, дигәннәр шул.

— Егет буласың килсә, дөя түгел, тауны да йотарсың аны!

— Ә йотып булмаса?

— Алайса син бер тиенгә дә тормый торган пүчтәк кеше!— дигәч, теге тагы көлемсерәп уйланды. Элеккеге житдилеге юк иде инде.

— Димәк, барысын онытгык, җиргә күмдек?

— Әйе, онытмау картайта гына!— Мамак көлеп җибәрде, аның эре аксыл көрәк тешләре күренде, күз кырыенда канәгатьлек җыерчыклары тезелде.

— Дөньяда иң төшемле нәрсә — түземлелек!— дип, тагы көлде ул. Мостафин чакрым-картаның икенче ягын күзәтә башлады. Ләкин шул чакта тыштан ачы гына өзеп кычкырган бер тавыш ишетелде.

— Туганнар, коткарыгыз!

Тавыш тагы һәм тагы колакларын ярып кергәч, командирлар блиндаждан чыктылар. Аларның күз алдында менә шундый күренеш иде: арырак сирәк урманлык, шул кара кәүсәле агачлар арасында иңенә яшел элемтә аппараты аскан бер солдат басып тора. Һәм әледән-әле әллә нинди күкләшелле тавыш белән кычкыра. Аның тавышы урманда катлы-катлы булып яңгырый иде.

Мостафин эшнең нәрсәдә икәнен уйлый-уйлый аңа таба кызу гына атлап китте. Бу тирәләр немецтан яңа гына алынган иде. Миналардан әрчергә өлгермәгәннәр икән.

— Миналар, иптәш майор, якын килмәгез!— дип кычкырды элемтәче. Солдат үзе ничектер миналанган җиргә зарарланмыйча кергән дә, хәзер генә куркынычны абайлап, кузгалырга да базмый тора. Чигенергә дә, алга атларга да әмәл юк икән. Ул юка бозга ялгыш килеп кереп, бата башлаган кеше кыяфәтендә иде.

— Син кайдан?— дип Мостафин, аяк астында миналарның тимерчыбык «мыекларын» күреп алып, туктады.

— Идрисов батареясыннан, иптәш майор. Менә элемтә суза идем, күрмичә килеп кергәнмен. Бая миннән артта миналар шартлады, чыбыгым «мыекка» эләккән булган. Шуннан күземне ачыбрак карасам...

— Ничек шартламыйча кердең соң?

— Үзем дә аптырыйм, иптәш майор.

Үтеп-сүтеп йөрүче солдатлар туктап, карап тора башладылар. «Мина»-лар кармагына эләккән элемтәченең йөзе кәгазь кебек агарган, күзләре ярдәм сорап очкынланалар иде. Ул арада каяндыр Мирхас килеп чыкты һәм, эшнең нәрсәдә икәнен аңлап, тегеңә сүз кушты.

— Мөслимов, атаң башы, күзең чыккан идемени?— диде бер дә ачуланмаган тавыш белән. Үзе ничектер коткару әмәле эзләп ары таба китте. Урманны урабрак узып, Мөслимовның теге ягына чыкмакчы иде ул.

— Килмә, килмә, анда адым саен,— дип кычкырды Мөслимов. Мирхас аның сүзенә әһәмият итмичә, аяк астына бик дикъкать белән төбәлеп, барды да барды.

— Кергән эзеңә басып чык,— диде Мостафин.

— Юк, иптәш майор, булдыра алмыйм.

Теге яктан Мирхас Мөслимовка озын колга суза башлады: шуның белән атынып сикер, янәсе. Мөслимов шырыйлап кычкырып җибәрде.

— Үтерәсең, чукынчык!

Карап торучылар көләргә тотындылар.

— Тычканга үлем, мәчегә көлке,— дип куйды кайсыдыр.

— Васыятьләреңне безгә генә кычкыр, әниеңә хат язарбыз.

— Иманыңны әйттеңме әле?

— Колһуалласын укыса да җиткән.

— Юк, колһуалла белән оҗмахка кереп булмый.

— Һәй, болай да аның савaплары җитәрлек.

Шау-шу китте.

— Бар, саперны алып кил! — диде Мостафин бер сугышчыга боерык биреп һәм блиндажына таба юнәлде. Шул чак төркемнән яшел шинельле бер сержант аерылды. Соры илтер кырыйлы, ал постау түбәле кубанка кигән иде ул. Мөслимовка нәрсәдер ымлады һәм, елмаеп, аның янына бара башлады.

— Сержант, туганнар кабере ясама!— диде кайсыдыр. Әмма теге бик ышанычлы адымнар белән атлый иде. Бераз баргач ул иплəп кенә җиргә тезләнде, уң җиңен сызганып, күтәреп куйды. Төркемдәгеләр, тынып, ни булыр, дип көтәләр, күзләре сержантта.

— Әй, үлем белән шаярма,— дип аваз салды берсе.— Башың ике түгелдер!

Сержант исә утырган килеш ашлы тәлинкә өстенә иелеп ашарга иткән кыяфәт белән, бер кулын хәрәкәтләндерә. Бармаклары кызу-кызу килеп нәрсәнедер боралар иде. Барысы да, ниһаять, күрделәр: ул миналарның капсульләрен борып ала иде. Әнә бер минаның чакмасын борып алган да инде. Башыннан кубанкасын сыпырып алып җиргә куйды да чакманы шунда урнаштырды. Аның һәр хәрәкәте бик төгәл һәм алдан исәпләнгән кебек иде. Уң кулының бармаклары җирне әз генә актарган итә дә капсульнең башын табып, борырга тотына. Үзләре гармун телләре өстендә биегән кебек җитезләр. Ә сержантның йөзендә канәгатьлек нуры күбәйгәннән-күбәя. Ашый торган ашы тәмле булганда кешенең чыраена нәкъ шундый яктылык чыга.

Мирхас каршы яктан сержантны тын да алмый күзәтте. Курыкмавына сокланып бетә алмады. Аның иң яраткан хыялы әнә шундый курыкмый торган кеше булу иде. Караган саен сержантның кай җиредер аңа бик таныш кебек тоелып китте. Тегеннән үк урап, аның янына килгәндә, зиһенен бер нәрсә бораулады: кайда күргәнем бар минем бу кешене? Мин яралангач алып чыккан солдатмы әллә? Фамилиясе Конев иде. Мәшһүр командующий белән адаш булганга хәтердә калган. Туктале, чырае ничектер үтә таныш шикелле... Мирхас карап торучылар янына килеп туктаганда сержант, капсульләр тулы бүреген алга тотып, мина кырыннан болай атлый иде. Әйтерсең, нindидер кош күкәйләрен агач башындагы оядан алып, бүрегенә тутырган да, малайларча сөенеп шуны күрсәтергә килә.

— Чисти тәмуг фәрештәсе икәнсең, молодец!— диде кайсыдыр, чын күңелдән сокланып.

— Мөслимов, тәмуг фәрештәсенә бер ярты куй!

— Минне куяр идем, уф! — дип, өтәләнә-өтәләнә сөйләнде Мөслимов сержант артыннан атлаганда.— Мәңге онытмам, сержант, рәхмәт!

— Әниеңне онытма! — Сержант бераз горурланып елмайды. Бүреген алгарак суды. Анда юан сигаралар шикелле каракучкылланып капсульләр ята иде.

— Бәхетең, бозланып катмаган үләнле җир...— диде сержант, иелеп бүрегендәге капсульләрне иплән кенә бушатты. Бүреген учына бергәләп алды да киеп куйды.— Тимер стакан формасында ясалган мина шартлаганда өскә бәрә... Кырыенда ятып исән калырга мөмкин...

— Сез сапермы әллә?

— Юк, аерым батальоннан...

— Нигә үлем авызына керәсез болай? Курыкмауның әллә берәр догасын беләсезме?— диде кайсыдыр чынлап торып.

Сержант аңа карап канәгать төстә елмайды гына.

— Сугыш өйрәтә, өйрәнмәсәң, кыйрата,— дип кеткелдәде ул. Сержанттан тагын нидер көткән кебек, сугышчылар аңа төбәлгәннәр иде.

— Бармаклар елгырлыгы гына!— Сержант кулын селтәде дә китә башлады. Мирхас бик кызыксынулы елмайган йөз белән аның каршына чыгып басты:

— Сез Хәбиров абый түгелме соң?

Сержант, туктап, Мирхаска башын борды.

— И-и, Дәвешнең Ярулла малае мәллә син? — дип карап алды.

— Әйе. Мин сезне чак-чак таныдым, ай-ай...

— Син дә бу баш тегермәненә килеп эләктеңмени?

— Тегермән әллә ничә ташлы, башларны уба гына!

— Суыра, суыра...— диде Хәбиров һәм нindидер уңайсызлык тоеп тынды. Чөнки Мирхасның гаҗәпсенгән, кызыксыну белән кабынган күзләре аны җентекли иде. Ул аның кай төшендер танып җиткерә алмый кебек иде. Элеккеге укытучысы һәм мәктәп директоры. Ничектер бик үз, бик якын. Шунлыктан аның әлеге миналарны әрчегәндәге батырлыгы кирәк бул-

маган башсызлык сыман тоелды. Курыкмавына исе китеп сокланды, нәрсәгәдер аны жәлләп, көенде дә. Укытучына ниндидер туганлык саклана икән. Аннары тагы шунысы да бар иде. Бер заман Дәвештә Хәбировлар Мирхаслар күршесендә яшәделәр, аларның коесыннан су алалар иде. Мирхас аның кызы Рифаны беренче тапкыр суга дип кергәндә күрде. Ак кофта, кара тар итәк, икегә үреп күкрәгенә салган саргылт толымнар. Шул толымнар белән саташып газапланды Мирхас. Өмет юклыгын аңласа да, яшерен генә пыскып янды ул... Сугыш башлангач, Хәбировлар район үзәге шәһәргә күчеп киттеләр. Шулай да аларның хәл-әхвәлләре Мирхаска килеп ишетелә торды. Хәбиров бик һавалы кеше, каршы әйткән сүзне күтәрми торган горур, үзе үңган, һәр эшне булдыра. Андый кеше турында артында күп сүз йөри. Мирхас колагына кергәне шул: Хәбиров беренче айларда ук сугышка үзе теләп киткән. Әмма фронтта, ниндидер бәлагә дучар булып, бәхетсезлеккә юлыккан... Рифаның сугышка китүенә, имеш, шул хурлык сәбәп булган, ди...

Бу уйлар Мирхасның башында яшен тизлеге белән чагылып узды. Әнә бит Хәбиров абый исән-сау икән, аңа берни дә булмаган. Баш иярга, куштанланырга яратмаучы кеше хакында телләр бик рәхимсез сөйлиләр шул...

Ул арада старшина тупчыларны снаряд бушатырга куа башлады. Тегендә өч студебеккер килеп тукталган иде. Мирхас старшинага ым какты, тege кулы белән селтәп рөхсәт бирде. Хәбиров белән тизрәк сөйләшәсе килә иде. Шуңа күрә аны үзләренең блиндажына алып керде.

— Әкияттәге җәһәннәмдә очрашу сыман бу,— дип куйды Хәбиров, аның йөзендә һаман аптырау иде, ул блиндаж миче каршына утырды.

— Ай-ай, үлем белән шаярасыз димме...— Мирхас теге миналарга ишарә ясады. Хәбиров, аның тавышында ниндидер команда тоны сизеп, Мирхаска карады, икесе дә сержантлар иде. Мирхас исә капчыгында актарынганда, әгәр бәлагә эләкмәгән булса, Хәбиров хәзер иң киме капитан дәрәҗәсендә булыр иде, дип уйлап алды. Әйе, ул түбән тәгәрәгән...

— Кешене коткарырга кирәк бит. Куркудан дер-дер калтырый теге солдат.

— Саперлар килгән булырлар иде.

— Җаен белгәч, берниди куркынычы юк аның.

— Ә кулың ялгыш тиеп китсә, беттең бит!

— Әйе, бу эштә ювелир төгәллек кирәк. Элек баянда уйнау ярдәм итә...

Хәбиров сүзне икенчегә борып өчен генә Мирхасның хәл-әхвәлен сораштыра башлады. Теге исә сагайды, сүз очы укытучысының бәхетсезлегенә барып чыга күрмәсен, дип, «әйе», «юк» белән шудырып үтте.

Җир сәкегә плащ-палатка җәйгәч, Мирхас укытучысына күз төшерде. Ул аңардан элек бик курка иде, дәресләрен күңелдән ятлап килә иде. Хәзер дә шулай кырыс микән? Тик нәрсә белән сыйларга үзен?.. Ул блиндаж миченең утлы күмеренә куйган берничә котелокның берсен алды да шуңа бер уч чәй тондырды, өстен япты. Аннары ипи, шпик чыгарды, юеш шикәр кисәкләре куйды.

— Әх, теге юк,— дип, Мирхас тамак астына чиертеп, шүрләп, укытучысына карады. Хәбиров чак кына елмайды, әйе, алар хәзер тигез, сугыш язмышларны үзенчә бутады һәм шактый тигезләде.

— Ну што син, иптәшләрдән яхшы түгел. Ә чәй мена какрас!— диде ул, кружкасын авызына китереп, һәм берни капмый эчә башлады. Кружка кырые тешенә бәрелеп шык-шык килеп торды. Ул бая бик киеренке хәл кичергән булган, нервылары нык тартылган. Хәзер шул изә торган авырлыктан тизрәк арынырга, тынычланырга ашыга иде...

Эчкәч ул, әх, шәп дип тамак кырды, йөзенә җылылык чаткылары чыкты. Күз агы ялтырап китте.

— Бик нык үзгәргәнсез, Хәбиров абый,— дип куйды аңа карап туймаган Мирхас.

— Син эчтән генә, нинди авторитетлы кеше иде бу, ничек шушы хәлгә калган, дип уйлыйсыңдыр! Йә, йә, яшермә, башыңда шул уй тора.—

Хәбиров тәмәке төрде. Мирхас кинәт бите кызаруын сизде, маңгаена тир бәрде. Хәбиров кабызды да сүзен дәвам итте:

— Беләсең бит, мактанып әйтүем түгел, авылны дер калтыратып тота идем. Юк, күпләргә яхшылык та эшләдем. Әмма кара фикерле кешеләрне аямадым... Ә сугышта иң чынын аңладым: мин үземә бирелгән власть белән генә көчле булганмын икән... Әйе, мин пүчтәк булганмын, тик кечкенә генә власть мине адәм рәтендә йөрткән...

Мирхас аның сүзләренең мәгънәсен аңламый иде, шул халәте бөтен йөзенә чыкты. Хәбиров аңа карап алды да:

— Аңларсың әле бер!— дип, нигәдер кулын селтәп куйды.— Аннары төтенен йота-йота тәмәкесен суырды, Мирхаска төбәлеп елмайгандай итте.

— Кызганыч, бу каһәрле җиргә эләккәнсең икән.

— Безне шушында озаттылар.

— Хәзер безнекеләр Германия җирендә. Андагылар, ну, бер яшәп кала инде. Европаны күрү үзе ни тора!

— Сугыш кайда да бердер инде,— дип көрсенде Мирхас.

Хәбиров уйланып торды да әйтте:

— Әйе, сугыш күп нәрсәләрне үз урынына куйды. Күпме күкрәк сугып, мактанып йөрдек. Мактану — ялганның бер формасы икән.

— Нишләптер ул хакта уйлаганым юк.

— Сине уйга төшермәгәннәр әле.

Шул вакыт җиргә бик авыр нәрсә белән китереп суккан кебек блиндаж селкенде, нindидер тонык авазлар килде. Һәм шунда ук, колакны ярырдай булып, якында гына снарядлар шартлаганы ишетелде. Немец, машина тавышын билгеләп алып, шуңа ут яудыра иде.

Сүз бүленде, Хәбиров тагы да моңсуланып калды. Мирхас аның ике яңак калкымы нык чыгып торганын күрде, шуннан ул бик күп газап кичергән бугай бу дигән фикер чыгарды. Чыннан да Хәбиров бик ябыккан иде. Тик Мирхас аңардан тагы ни турындадыр ишетәсе килә, әмма бәйләнчек булудан курка. Шулай да кыюланды:

— Сез соң кайсы частьта, Хәбиров абый?— Мирхас уйга калган укытучысын уяткандай итте.

— Мин аерым батальонда...— Хәбировның йөзе чытылды, бу хакта сүз озайтасы килмәгәнлеге сизелә иде. Мирхасның зиһене яшен тизлеге белән эшләп алды: ул штрафной ротада икән бит, дип эсселесуыклы булып китте һәм аңа тагы да җәлләп карап торды. Хәбиров тагы хуш исле мүк тәмәкене юан итеп төрде, шуны кабыза-кабыза әйтте:

— Тиздән сугыш бетәр төсле...— Аның тавышында исән калып булмас инде, дигән үкенү төсмере ишетелде.

— Хәзер немец та яраланган ерткыч кебек, тагы да әшәкеләнде,— диде Мирхас. Шуңа мисал китергәндәй, безнең бер лейтенантны ничек газаплап үтерүләрен сөйләп бирде. Аның Хәбировны үзе янында озаграк тотасы килә иде.

— Син яшь әле, саграк йөре...

— Бездән булмый ул, без андый сорт түгел, беләсез...

— Түгел шул. Эх!— дип Хәбиров тирән көрсенде.— Әнә, безнең Рифа да сугышта бит...

— Ничек? Аны да алганнармыни?— Мирхас өчен бу хәбәр яңа булмаса да йөзенә гаҗәпләнү чалымы чыгарды.

— Үзе теләп... Яшьлек җилбәзәклеге инде. Шушы унынчы армия госпиталендә хезмәт иткән. Яраланган. Ярасы кай төштә икәнен язмады...

— Хат алышып торасызмыни? Әйбәт...

— Нәрсәсе әйбәт? Тазардым, тагы элекке урыныма кайтам, дип язган иде, бер ай инде менә бүтән хәбәре юк.

— Карале, ә?— Мирхас хәзер чынлап торып гаҗәпләнде һәм ни әйтергә белми тотлыгып калды. Чын сөйлиме бу, дигән кебек Хәбировка текәлеп торды да, эчемдәге уйларымны белә күрмәсен тагы дип шүрлә-

гәндәй, карашын читкә алды. Башы әйләнеп киткән кебек булды. Ничек инде, Рифа шушы тирәдә генә йөрсен, имеш...

Хәбиров, тәмәке төпчеген эчке бер ачыну белән читкә ыргытты да кузгалды. Аның йөзендә ниндидер канәгатьсезлек күренә. Әллә Мирхасның шат чырае бирәр нәрсә сиздердеме? Ул коры гына саубуллашып чыгып китте. Артык горур кешеләр шулай үзләренең хурлыгына шаһит кешене өнәмиләр инде...

Мирхас җир сәкегә барып ятты. Шунда ук каты чәй белән куәтләнгән уйлары ташый башлады... Бу очрашуны әйт әле... Менә нинди хәлләр! Кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас, билләһи. Рифа безнең армия госпитальләрендә генә булган, имеш... Әх, адресын сорарга йөрәк җитмәде, нәләт... Юк, ярый әле, шундый ахмаклык эшләмәгәнмен... Рифа мине күптән онытгандыр, бер исенә дә төшермәгәндер. Ул укыган кыз, үз дәрәҗәсендәгеләрне генә иш итәдер. Кызлар үзләреннән түбән баскычтагыларга карамыйлар. Бу — закон. Ә мин бары ат көтүчесе, ләкин күңелемдә гел аны йөрттем. Күпме бозлы окоп төпләрендә бөрешеп ятканда үз-үземне аның шәүләсе белән җылыттым...

Исләрең китәрлек бит... Ул кызны Мирхас үзләренең ишегалдындагы коедан су алып торганда күргән иде бугай. Әйе, барысы да бүгенге күк күз алдында... Көянтәсендәге тулы чиләкләр авырлыгыннан үкчәле туфли кигән аякларын тиз-тиз хәрәкәтләндереп чыгып китте Рифа... Аннары Мирхас эштән кайткан араларда кызның күзенә чалынып өчен юри кое янында чуала торган булды. Бер-ике тапкыр кыска-кыска гына сөйләшкәләп тә алдылар. Ләкин сүз ялганмады.

Аннары октябрь бәйрәме булды. Күптән урнашкан тәртип буенча, һәр бригаданың олыларына һәм яшьләренә аерым-аерым зур итеп аш әзерләделәр. Рифалар шушы бригада төбәгендә торганга күрә, Мирхаслар белән бер табынга ашка чакырылды. Кермәс дип уйлаганнар иде, юк, яшьләр җыелып беткәндәрәк, бик шат кыяфәттә ишектән йөзеп кенә килеп керде ул. Рифа килгәч егетләрнең җорлануы тагы да көчәйде. Барысы да аның дикъкатен яуларга, аны көлдерергә тырыша иде. Шук сүзләр белән атыша-атыша, кызларны көлдерә-көлдерә башта аш ашадылар, норма эчемлек салынган стаканнар да бушады. Шуның кайнарлыгы белән егетләр тагы да берсеннән-берсе уздырып телләнделәр. Бәлеш килеп, аны ялт иттергәнне сизми дә калдылар бугай. Өстәлләрне җыймыйча гына бер кырыйга күчереп, кызлар уен башладылар. Иң элек кара-каршы сүз әйтеш китте. Мирхас берсендә җавап таба алмыйча «штраф» түләде — бию көенә уртага тыпырдап керде. Бу уен туйдыргач, «кулъяулык ташлауга» тотындылар. Ул уен болай: сизмәстән генә бер кызның кулъяулыгын алып идәнгә ташлыйлар. Тезелешеп утырган кызлар көлә-көлә егетләрнең исемнәрен бер-бер артлы атыйлар. Кулъяулык иясе кыз үзенә охшаган егетнең исеме чыккач, кулъяулыгын идәннән алырга тиеш. Шуннан соң егет белән кызны караңгы өйалдына чыгарып җибәрәләр. Алар анда серләрен уртаклашалар... Менә бервакыт Рифаның кулъяулыгы идәнгә очты. Кызлар шырык-шырык, иһи-миһи килеп, егетләрнең исемнәрен кычкыралар. Риза, Талип, Нәгыйм, Гарифҗан, Галим... Юк, Рифа урыныннан да кымшанмый, елмайган кое, битенә сибелгән чәчләрен әле бер, әле икенче кулы белән сыпырып тик тора. Әмма күзләрендә шаян очкыннар чаткысы уйный. Бөтен исемнәр әйтеп беткәч, кайсыдыр исенә төшереп, Мирхас,— дип кеткелдәп куйды. Рифа ялт кына урыныннан торды да кулъяулыгын барып алды. Кайсыдыр кыз ишетелерлек итеп көрсенде. Тәгәләрне этәлитөрткәли өйалдына чыгардылар. Мирхас бик нык оялды, ярый әле аякка ботинка кигән идем, дигән уй башыннан сызылып узды. Чабаталы кое директор кызы янына ничек чыгар идең... Әкълимә апасына рәхмәт, ул Харьковка вербовка белән китеп, шуннан салган иде.

Өйалды караңгы иде, Рифа, куркынып, Мирхасның беләгенә тотынды. Һәм, гаҗәп, шунда Мирхасның бөтен тәне мамык тутырылгандай йомша-

ды, буыннары көчкә тотты, маңгаеннан тир акты. Кымшанырга да базмады. Рифа үзен иркенрәк сизеп, сүз башлады, нәрсә турында булса да сөйләшергә кирәктер бит инде.

— Сезнең коегыз бик әйбәт икән,— дип әйтеп куйды.

— Әйе.

— Суы тәмле, шулай да каты, сабынны чыгармый.

— Ә сез моңарчы кайда тордыгыз?— диде Мирхас, көчкә исенә килеп.

— Кыдаш поселкасында. Минем анда шәһәргә мәктәпкә йөри торган атым бар иде. Мин атланып йөрергә яратам.

— Чынлапмы? Ничек?— диде Мирхас, бик нык гаҗәпләнеп.

— Әллә шапырта дип уйлыйсыңмы?

— Юк, мин дә бит тайлар көтәм.

— Тайлар? Ә миңа бер акыллы таеңны биреп тор әле, атланып чабар идем.

— Егылмассыңмы соң? Безнең тайлар усал...

Аларның сүзләрен бүлеп, эчтән ишек шакыдылар һәм шаян сүзләр ишетелде:

— Ах, маймычлар, кочакланышып туймыйсызмыни?

— Җитәр, капкан саен калҗа булмый...

— Шәһәрдә укыган кызлар шулай инде...— дип төрттерүчеләр дә бар иде.

Рифа ишеккә борылды һәм шул чак аның тыгыз күкрәге Мирхас беләгенә тиеп китте. Мирхасның кинәт колагы тонгандай булды, ул үзен ниндидер бер дулкынга эләккән сыман итеп сизде. Бусаганы ничек атлаганын тоймады, өйдә егетләр нәрсәләр сөйләнгәнен шактый вакыт ишетми утырды.

Уен дәвам итте, тагы кайсыдыр кыз белән егетне өйалдына озаттылар.

— Калтыранганчы кочаклашмагыз, пәрәмәчләр!

— Әйдә, кинәнсеннәр. Кызларны коча-коча яравайлаштыралар.

— Чит кортлар төшмәсен өчен!— дип егетләр берсен-берсе уздырып шукланалар.

Тегеләр керүгә Рифаның кулъяулыгы тагы идәнгә барып төште. Мирхасның йөрәге киле сабыдай дөп-дөп тибә башлады, күзләре күрмәс булды. Кызлар егетләрнең исемнәрен тезәләр. Бер кыз «Мирхас» дип кычкырды, ләкин Рифа урыныннан да кузгалмады. Нәрсә бу? Мирхас исенә килеп күзен ачканда, Рифа Риза белән чыгып бара иде. Мирхас йөзе кызарганын тоеп, сер бирмәс өчен юктан гына кычкырып көлгән итте, телдәрләнгән булды, бүтән кызлар янына барып утырып шаярган итте. Ә үзенең эченә кайнар агым булып ут ачысы акты.

Рифаның чәче-башы тузып керде, әмма йөзендә көләчлек тагы да ныграк балкый иде. Риза аны кочарга, кулын озайтырга уйлагандыр, ә Рифа аңа ирек бирмәгәндер, шуңа чәчләре тузып беткәндер, дип уйлап Мирхас үзен тынычландырмакчы булды. Ләкин икенче уенда да Рифа Ризаны «сайлады». Монысында Рифаның кофтасы бөгәрләнмәгән, чәче тузмаган көе керде. Сөйләшеп кенә торганнардыр, мөгаен, дип Мирхас үз-үзен эчтән юатты. Ул Рифага бөтенләй игътибар итмәгән кебек утырды, бүтән кызлар белән чыркылдашты. Инде өченче тапкыр Рифа Ризаны «алгач», Мирхасның эченә ут капкандай булды, ләкин ул түзде.

— Барыгыз оҗмахка тизрәк,— дип тегеләрне чыгарганны ишетмәде. Үз хәрәкәтләрен үзе абайламады, кызларның кытыгын китереп чеметкәләде.

Төн уртасында гына таралыштылар. Рифа гел Риза янында, аның сүзләренә генә авыз ера. Тышта Әптерәш гармунын тартып җибәрде, төнге караңгылыкны моңлы тавыш ярды. Авылның иң түбән, инеш ташыганда су буа торган җирен Пекин дип йөртәләр иде. Шунда кемнәрдәдер аулак өй диделәр. Әптерәш шул якка каерды. Риза Рифаны култыгыннан алган, җибәрми, аулак өйгә барыйк, ди. Рифа көлә, көлгәч, димәк, күнә инде. Әптерәш гармунын уйный-уйный алдан китте, бүтәннәр аңа иярде. Шунда ук Ризаның калын тавышы гармунга кушылды: «Кулымдагы йөзе-

гемнең исемнәре Идерис. Ятлар куеныннан алып яр сөюләр интерес...» Бу Ризаның, масаеп, Мирхаска төрттерүе иде. Мирхас бик нык гарьләнде, аларга иярмәде. Риза белән сугышырмын тагы дип шикләнде. Риза таза, Мирхасның аңа көче җитми иде, шуңа күрә ул эчтән генә янды, түзде. Гармун һәм аңа кушылып җырлаган Риза тавышы Ибләминнәр тыкрыгына кергәч тә озак ишетелеп торды: «Кулымдагы йөзегемнең исемен Рәҗәп итәрмен. Үзем алмам, ятка бирмәм, шундый гаҗәп итәрмен...»

Шунда Мирхасның бөтен дөньяга ачуы килде. Бер урында гына тәпиләнеп яши белмәгән әтисен һәм шулай ук җилбәзәк әнисен шелтәләде, аның бу бәхетсезлегенә гүя алар гаепле иде. Аннары Мирхаска аек фикерләр килә башлады, ул үзенең Рифага тиң түгеллеген уйлады һәм эчендә янган утны әкрен-әкрен сүрелдерде. Үзенең нинди ахмак булуына аптырый калды: юньгә кияргә бер пинжәге дә юк бит, ичмаса, нинди кызга үрелә! Моннан да башсызрак эш булуы мөмкинме?.. Мирхас кыш буе шулай хисләренең башына суга-суга яшәде. Рифаны кабат очратырга туры килмәде аңа, ул шәһәрдә укуда иде.

Ә җәй аларны тагы очраштырды. Мирхас өйләренә атка атланып кына кайтып йөри иде. Бер көндезге аштан китеп барганда таныш аваз аны туктатты:

— Мирхас, күрше булып күрешмичә узып барасың түгелме?— дигән тавышка борылып караса, Рифа басып тора. Матур, гаепле елмайган, күзләре тылсымлы чаткылана. Ул тагы да тулыланган, гүзәлләнгән.

— Исәнме, Рифа?— дип, Мирхас тезгенен тартты. Авызы үзеннән-үзе ерылып китте. Шулай да эчтә төкселегә бар иде.

— Минем дә ат өстендә чабасым килә,— диде Рифа, иреннәрен бик иркә бала кебек бөрештереп. Мирхас аны аңлый алмыйча аптырап калды. Теге чагында да шулай дип шаярткан иде, тагы чытлыклана дип уйлады.

— Нигә шаккаттың?— дип куйды Рифа, Мирхасның гаҗәпләнгән чыраен күреп.

— Шаяртасыңмы, чын әйтәсеңме?

— Фу, нишләп шаяртыйм инде?

— Кызлар атка атлана алмыйлардыр бит.

— Фу, син миңа бер таеңны биреп тора аласыңмы, юкмы?— диде Рифа ачулана башлап.

— И-и пажалысты, берне түгел, икене.

— Ә сиңа ышанырга буламы?— Рифаның тавышы йомшады. Дустанә чалымнар белән тулды.

— Була торгандыр...

— Минем атка атланып йөргәнне беркем күрергә дә, белергә дә тиеш түгел. Син шуны эшли алырсыңмы, ә?

Мирхас әйтәсе сүзенең бәясен күтәрергә теләгәндәй уйланып калды, аннары:

— Тырышып карармын,— дип, Рифага туры төбәлде. Миендә уйлар йөгереште: чынлап та кызык кына килеп чыга түгелме соң? Ат өстендә ничек йөри алыр ул?

— Кайчан?— Рифаның йөзе нурланып китте, күзләре ниндидер омтылу белән очкынландылар. Ахрысы, бу чытлыклану, иркәләнү генә түгел, ниндидер бер теләк иде. Узындырып үстерелгән тискәре кыздай, Рифа үз дигәненнән чигенмәс кебек карап тора. Мирхас атының ялын сыпыра-сыпыра уйланды.

— Үзем әйтермен,— диде аннары елмаеп.

— Мин сиңа ышанам!— диде Рифа шатланып кулларын чәбәкләп куйды һәм ымсындыргыч итеп борылды да урыс капканың кече ишегеннән кереп югалды.

Мирхасның сүнгән өметләре тагы гөлт итеп кабынды. Риза белән бернәрсәләре дә юк микәнни? Риза үзенә карата алмаган, күрәсең... Ничек шул

чаклы җилкенер иде?.. Мирхас үзен тыя алмады, аның күңеле яшерен газапланырга, төрле шикләрдән бәргәләнеп яшәргә, алданырга әзер хисләр белән тулды.

Ул Рифаның теләген үтәргә ашыкты, әмма әллә шуңа күрә инде җай чыкмый иде. Җитмәсә кыз үзе дә күренми, алар коесына суга керми башлады. Нәрсәдән бу шулай икән? Көтте-көтте дә, өметен өзде микән? Мач төшәргә торганда гына юкка чык, имеш. Аның белән эшләүче егет Гыйлмеяр шушы көннәрдә күрше Тайсуганга сабан туена апаларына барырга җыена иде. Шул хакта кызны искәртеп куясы бар, ә ул юк. Әнисе бик һавалы нәрсә, кызын Гайфуллаларның урам коесына йөртәдер. Рифаның минем белән сөйләшеп торуын ошатмагандыр... Тагы шул хәл китереп кыса: бүген тайлар белән урманга кардыга күчәбез, аннары гел кайтып йөреп булмаячак. Иртәгә Рифаны һичшиксез күрергә кирәк, шунсыз бөтен эш җимерелә, мин ялганчы булып калам...

Өйләдән соң Гыйлмеяр бер малай белән тайларны кардыга алып китте. Мирхас чабыш аты Очкынны сабантуена яхшырак тәрбияләү өчен дип, төп сарайда калды. Ул Очкын белән чабышка чыгарга хыяллана иде. Инде елдан артык әзерли ул атны. Әмма калуның төп сәбәбе Рифа. Ничек күрергә аны? Берәр йомыш табып өйләренә керергәме? Юк, әнисе очлы күз, кызы белән бер сүз алышырга да бирмәс.

Мирхас аранга кереп Очкынның ялыннан, бәрхет борыныннан сөеп торды, ә башында һаман бер уй — ничек Рифаны күрергә? Әмәл табылмый гына. Юк, табылырга тиеш, шулай сизә ул. Аннары буш калган утарга чыкты, утлыктагы тоз кантарларына карап узды, боларны кардыга алып барырга, дип уйлап куйды. Юк, башы каткан, бер әмәл эшләп чыгара алмый... Тагы сарайга керде, эчтәге борчу кыра, тынгы бирми иде. Инде кич булды, көтү кайтты, тирә-як адашкан сарык тавышлары белән тулды. Соңгы минутта гына зиһене кыймылдый башлады. Солыларыннан зур гына бер дорба алды, тиз генә утарга чыгып, шуңа утлыктан ат башы кадәр ике тоз кантары салды. Актык чыдамлыгын җигеп, караңгы төшкәнне, кеше аягы тынганны көтеп утырды. Вакыт җиткәч, атына атланды да ике пот чамасы дорбаны ияре мөгезенә күтәреп куйды. Ындыр артыннан иплән кенә үзләре тыкрыгыннан урамга төште. Тынлык, шылт иткән аваз да юк, караңгы. Атын кызулата төшеп, Гайфулла коесына килеп туктады. Коеның өсте ачык иде: атны бура кырыена тарттырды һәм ике пот тозны кое эченә — гөмберт...

Авыл караңгыдан ук уяна. Кояш чыкканда инде Гайфулла коесының суы әллә нишләгән, бик харап әче, эчәрлек түгел, дигән хәбәр бөтен төбәккә таралып өлгергән иде. Соңрак кузгала торган Рифа, шуны ишетеп булса кирәк, туп-туры Мирхаслар коесына килеп керде. Мирхас атына атланып кайткан гына иде, кызны күргәч, тоз турында уйлап, эчтән генә елмайды.

— Булды,— диде ул, Рифа янына аты белән килеп. Кыз аңышмыйчарак матур итеп кашларын җыерды, аңлагач, йөзе чәчәк аткандай нурга күмелде.

— Әнә, Туры юл тавы башындагы урманны күрәсеңме,— дип аңлатты Мирхас.— Иртәгә сәгать унберләрдә мин сине шунда көтәрмен. Без хәзер кардыда. Сөйләштек...

Кыз сөенечле елмаеп баш какты, Мирхас атын кырт кына борып, ишегалдыннан чыгып китте.

Барысы да алдан уйланганча барды. Мирхас иртүк Гыйлмеярны иң яхшы тайга атландырып кунакка җибәрде. Тайларны урманның иң шәп үләнле аланында ашатты. Көн кыздыра башлагач, Гөлле чишмәсе буена киртәләрдән корыштырган туплауга төшереп япты. Тайлар тыныч, тик өер айгыры Байкал гына борсалана, утарга сыймаган шикелле әрлебирле килә. Мирхас белә,Очкынны тегендә калдырганга нервылана Байкал— Очкынны бик ярата ул, теге аңа әллә ничә тапкыр типсә дә, ярата. Бербер хәл эшләп ташламаса инде, Байкалдан теләсә ни көтәргә мөмкин. Әмма көн эссе, тамаклары тук, кызу сүрелгәнче ятачаклар малкайлар.

Мирхас, урман алдына килгәндә, Рифа аны көтеп үләннәр эчендә утыра иде. Мирхасны ерактан ук күреп алып, шатланып торып басты да, үзенә дип алып килгән атның муенына ябышты, иркәләргә, сыйпарга тотынды. Конфетлар каптырып карады. Ат андый баллы нәрсәләр ашап өйрәнмәгән, конфетларны авызында бераз әвәләде дә кире чыгарды. Мирхас атны бер төп янына китерде, шунда басып Рифага ат өстенә менү уңайлырак булыр. Ул үзе дә аңа булышу өчен атыннан төште, моңа ничек булышырга, кай төшеннән тотарга диебрәк тора башлады. Тик Рифа үз янына якын җибәрмәде, үзем, үзем, дип кычкырып кына торды. Ул иярнең алгы мөгезенә тотынып, аягын өзәнгегә кертте дә бик җитез һәм оста атланды. Мирхас шаккатудан авызын ачып карап торды, шулай да Рифаның киң итәк астыннан тезенә салынып торган ак чалбар кигән булуы күзләренә чалынды. Ул өзәңге каешларын кыскартып, аякларына тигезләде, аннары чәчләрен рәтләде. Тезгенне оста җайдакларча сул кулына тотты. Алар урман кырыендагы юлдан янәшә киттеләр. Кызның йөзе шатлык белән нурланган, зәңгәр косынкасы муенына төшкән, иңендәге толымнары ат юргалаган уңайга җилдән тибрәнеп сибеләләр...

— Әйдә, чабабыз,— диде чиксез кәефе күтәрелгән Рифа. Мирхас һаман аңа шаккатып торды.

— Егылмассыңмы соң?— дип, Мирхас чак әйтергә генә өлгерде, Рифа: «Һоп!»— дип кычкырып җибәрде һәм атлар, сүз берләшкән кебек, алып та киттеләр. Карасана Рифаның ат өстендә баруын, алга, ат ялына таба бөгелеп куйган, күзләре үткен җанлекнекедәй елтырыйлар. Куллары канатлар кебек җилпенә. Бер чакрымнар әлдереп баргач, Рифа тезгенен тартты, атлар әкренәйделәр. Кызның сулышы кысылган иде, дулкынланудан сүзләрен өзек-өзек әйтеп, Мирхаска дәште:

— Уф, үләм, шундый рәхәт, шундый рәхәт!— Үзенең күкрәкләре тетри, чәчләре йөзенә сибелә, бер кулы белән ул аларны сыпыра, бөтен кыяфәтендә бәхет иде.

Бераз баргач, кире борылып, үргә таба чабып киттеләр. Рифа ат өстендә йөзгән кебек кенә бара. Кара, ничек, аңа болай җайдакланырга өйрәнгән бу?— дип, Мирхас аптыраганнан аптырый, әмма үзенә дә кыз янында бик рәхәт. Тау башына җиткәч, тезгеннәрне тарттылар, атлар адымга күчте.

— Уф, үләм, шундый рәхәт,— ди Рифа тынына буыла-буыла.— Сиңа да рәхәтме, Мирхас?

— Һи, рәхәтме дип, күбрәк чапсаң, эчкә кату төшә, шул...

— И-и көне буе чабар идем...

Шулай шактый вакыт рәхәт чигеп йөрделәр. Рифа шатлыктан нишләргә белмәде, ике бите дә алма кебек кызарып чыкты, иреннәре тагы да алсуланды. Көн сүрелүен чамалап, Мирхас тайлар янына барырга кирәклеген кызга сиздерде. Рифа көйсезләнмәде, шунда ук күнде, атны учы белән иркәли-сөя-сөя иярдән ялт кына җиргә сикереп төште.

— Рифа белән атта йөрдек дип егетләргә мактанырсың әле?— диде кыз чәчләрен рәтли-рәтли. Мирхас тагы шаккатып калды, ул эчтән бу хакта дусты Әсәткә сөйләрмен дип кымырҗып тора иде.

— Юк, мин — сандык,— диде ул, дикъкатен атына юнәлтеп, аның ялын учы белән сыпыргалады.

— Алайса, тагы кайчан?— диде Рифа үзенең көләч һәм балаларча үтенүле, кире кагарга мөмкин түгел йөзен Мирхаска төбәп. Егет башта аның нәрсә хакында сораганын аңлап бетермәде, әмма кызның йөзенә күз салу белән барысын да төшенде: тагы кайчан мине рәхәт чиктерәсең, ди икән.

— Җай чыккач, үзем...— дип елмайды Мирхас. Рифа, бик канәгать булып, зәңгәр яулыгын изи-изи кыланчыкланды, рәхмәте һәм саубуллашуы шул иде. Аннары борылды да түбәнгә таба йөгереп китте.

Мирхас утарга бик тиз чабып кайтты, әмма ни күрә ул? Киртә эчендә бер тай да юк иде. Ничек болай булды икән бу? Әллә пошый-мазар килеп

чыгып аларны куркытканмы? Мирхас, атыннан төшеп, утарны әйләнеп йөрде. Әйе, бер тәбәнәк арата бар иде, шуннан сикереп чыкканнар. Тик бу бары шул Байкал эше генә, башлап ул сикергән. Очкынны тегендә калдырган өчен миннән үч алуы бу аның. Сизенгән идем бит, нәләт, ник тышаулап калдырмадым икән?

Эчтән үкенеп, үзен тирги-тирги Мирхас бер таен тышаулап үләнгә җибәрде, икенчесенә атланып, тегеләрнең эзе белән китте. Тик эз генә урман эченнән баргач та эз югалды. Шулай да Мохсин тарлавыгына чаклы чаптырып барды, Мәсәгот яланыннан Кәшер имәнлегенә төште. Ул арада кич тә булып килә икән, аты да өшәнгән иде. Аның авызлыгын алып, тезгенен ияр мөгезенә электерде дә бик шәп кәрешкәлеккә ашарга җибәрде. Үзе җиргә сузылып ятып тыңлана башлады. Ике тай муенында кыңгыраулар бар, алар аваз салырга тиеш. Җиргә колакны куйсаң, тояк баскан авазларын да шәйләргә була.

Юк, берни дә ишетелми. Байкал, имансыз, көтүне кышкы утарга алып кайтып киткәндер. Очкынның шунда икәнен белә ул.

*Дәвамы киләсе санда*

# КЫЗЫЛ КОШЛАР ҖЫРЧЫСЫ



Күренекле татар совет шагыйре, Бөек Ватан сугышы ветераны, 1939 елдан СССР Язучылар союзында торучы, 1945 елдан КПСС члены Әхмәт Исхакка 80 яшь тула.

Әхмәт Габдулла улы Исхаков 1905 елның 1 маенда Казанда хезмәткәр гаиләсендә туган. Кечкенәдән әдәбият һәм мәдәниятка мәхәббәт белән үскән Әхмәт ага — революциягә кадәр үк күп язучыларны күреп тә, укып та белгән, хәтта Тукайны да күрү бәхетенә ирешкән әдип.

1919—1922 елларда Татар педагогия техникумында укыганда ул әдәбият белән чын-чынлап кызыксына башлый, 1923 елда исә «Кызыл шарык яшьләре» газетасында аның «Кызыл кошлар» исемле беренче шигыре басылып чыга. Ә 1928 елда яшь шагыйрьнең «Таш урамнар җыры» исемле беренче китабы дөнья күрә — ул •бу вакытта Мәскәүдә «Эшче» газетасында әдәби сотрудник була. 1928—1939 елларда Ә. Исхак «Чаян» журналы һәм «Кызыл Татарстан» газетасы редакцияләрендә эшли, ә 1939—1942 елларда СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге вәкиле була.

1942—1945 елларда шагыйрь фронтта, Совет Армиясе сафларында: ул башта взвод командиры, аннары «Ватан чакыра» исемле дивизия газетасында әдәби хезмәткәр. Бу елларда аның совет сугышчыларының фашизмга каршы көрәштә зур батырлыгын сурәтләгән күп шигырьләре, «Герой танкист Петр Новиков турында җыр» исемле поэмасы басылып чыга.

1963—1968 елларда — Ә. Исхак сатирик «Чаян» журналының баш редакторы...

Алтмыш елга якын иҗат дәверендә шагыйрьнең кырыкка якын китабы татар, рус һәм башкорт телләрендә дөнья күрде, алар арасында бу бай иҗатны тулырак чагылдыручы «Сайланма әсәрләр» (1965), «Мин җаваплы» (1967), «Шигырьләр, поэмалар» (1975, «Шигырь китапханәсе») китаплары бар. Шагыйрьнең иҗаты күпкырлы: ул — лирик, публицистик шигырьләр, поэмалар, балалар өчен китаплар, җырлар һәм сатирик әсәрләр — пародияләр, эпиграммалар һ. б. авторы. Укучы аны бигрәк тә «Карәхмәт» буларак, татар совет шигъриендә аерым урын алып торган мәсәлләре аша яхшы белә. Күренекле шагыйрьнең тәрҗемә өлкәсендәге хезмәтләре дә зур: ул Пушкин, Лермонтов, Некрасов, Гейне, Махтүм Колый, Җамбул, Нәван, Маяковский һәм башка күп шагыйрьләрнең татарча матур яңгырашына иреште, әдип бигрәк тә Көнчыгыш шагыйрьләрен яратып тәрҗемә итә.

Ул шулай ук оста либреттист та. Аның тәнкыйть мәкаләләре, Г. Тукайның шигъри осталыгына һәм М. Җәлилгә багышланган китаплары да укучыга яхшы билгеле. Шагыйрьнең әдәбият өлкәсендәге күренекле хезмәтләре хөкүмәтебезнең орден һәм медальләре белән билгеләп үтелде.

Әхмәт Исхакны юбилее белән кайнар котлап, укучыларыбызга шагыйрьнең төрле елларда язган шигырьләрен тәкъдим итәбез.

# Әхмәт Исхак

## Кызыл кошлар

Кызыл кошлар булып
Күккә очыйк без!..
Очыйк күккә,
Кояш,
Айны кочыйк без!
Очарбыз!
Мең кояшлар артына да без җитәрбез!
Очып,
Бар дөньясын хәйран итәрбез!
Очарбыз да,
Явыз җаннар оясына
Олуг дәһшәт белән выжлап төшәрбез.
Бөтен явыз,
Ләгыйньнәр дөньясын вәйран итәрбез.
Очарбыз күккә!
Монда ник
Канаты сынган аккоштай ятарга?
Без — Кызыл көч!
Без — Кызыл кош!
Нигә җирдә ятып, тиргә батарга!..
Канат селкеп очабыз, әйдәгез,
Айлар,
Кояшлар артына бергә!
Менәбез сызгырып күккә,
Очабыз ыжгырып күктә
Азатлык җырлары берлә!
Кызыл кошлар,
Кызыл көчләр булып күккә очыйк без!
Очыйк күккә,
Кояш,
Айны кочыйк без!

1923

## Нишлим икән?

Чәчәкләргә тиңли шагыйрь сезне,
Шомыртларга — кара күзегезне,
Чылтырап аккан чишмә тавышына —
Сезнең әйткән һәрбер сүзегезне.
Әллә шагыйрь түгел микән соң мин? —
Чәчәкләргә сине тиңләштермим.
Карап торам — күзең нәкъ күз төсле,
Сүзләрең дә бик гади сүз төсле.
Ала алмыйм ләкин күзләремне,
Туя алмыйм тыңлап сүзләреңне.

Әйтче миңа, дустым, нишлим икән?
Башкалардан шулай син ким микән?
Әллә сине чәчәкләргә түгел,
Чәчәкләрне сиңа тиңлим микән?

1938

Сугышларда сакласаң син туган илең,
Табан үбеп каршы алыр туган җирең.
Илең ташлап, яшәр булсаң чит-ят җирдә,
Исмәс сиңа туган илдән салкын җил дә.

1941.

## Батыр егет кем булыр?

Батыр егет кем булыр?—
Илгә туры ул булыр,
Кол булганчы дошманга,
Яки үзе кол булыр,
Я дошманны кол итеп,
Кайтыр юлы гөл булыр,—
Батыр егет шул булыр!

1945

## Яратам мин

Яратам мин яшен яшьнәп, күк күкрәвен,
Күкри башлый шунда гүя үз күкрәгем.
Яратам мин, көтмәгәндә чыгып давыл,
Наратларның чайкалышып шыгырдавын.
Яратам мин, күкрәк куеп шул давылга,
Бертуктаусыз һаман алга ыргылырга.

Давыллана башлый шунда барлык хисем,
Шул давыллы чорда чөнки туып-үстем,
Шул давыллы чорны кичтем!

1950.

## Ялагай белән Бюрократ

Чыкмасмы, дип, бирәр файдалы эш,
Пешереп бик зур бәлеш,
Чакырып үзенә кунакка,

Язу җибәрде Ялагай бер Бюрократка.
Ә Бюрократ
Күз дә салмыйча аның хатына,
Берәр гаризадыр дип уйлап,
Тыгып куйды сукно астына.
Ялагай аны бик озак көтте.
Бер көн дә үтте,
Ике көн дә үтте,
Ул арада бәлеш тә катып бетте.

Бу мәсәлдән моральне
Эзләп тә торма хәтта:
Нинди мораль булсын ди тагы
Ялагай белән Бюрократта?

1954.

## Борынгы Көнчыгышка ияреп

Чыкты кайдан бу бәла: иркәм нигә янда түгел?
Ул нигә монда түгел, я мин нигә анда түгел?
Аерылуның һәр көне җанга сала мең-мең яра,
Булсын иде ул яра тәндә, ләкин җанда түгел!
Түз, диләр, бер айга тик! Әйтү генә ансат моны:
Бик ерак бит айның ахыры, ул бүген таңда түгел!
Аңламассыз сез Карәхмәтнең хәлен, итмим гаеп.
Аңлаталмый ул да шул: чөнки үзе анда түгел!

1963.

## Сөйләмәгез!

Сөйләмәгез тузга язмаганны,
Тавык көләр сүзне, иптәшләр:
Картлар-фәлән, картлар-төгән, диеп,
Сөя белә, диеп, тик яшьләр.

Ә чынлыкта, хокук алар өчен,
Сөя белдем, диеп сөйләргә,
Ким дигәндә, утыз-кырык еллап
Кирәк берне янып сөяргә!

1969.

## Җыр һәм йөрәк

— Җыр чыкмас инде,— димәгез,
Карап сез карт җырчыга.
Ә тыңлагыз:
Тәннән түгел,
Йөрәктән бит җыр чыга!

1972.

**Мәҗит Рафиков**

# БЕРАЗ ГЫНА ҮЗЕМ ТУРЫНДА



Үзем Казанда, күңел Күгәрчендә: «Авылның бер күрешсәң сөйләшеп туймас картлары саулар микән? Урта мәктәпнең яңа бинасын салып бетерәләр микән? Быел кемнәрнең балалары кайда, нинди уку йортларына керделәр икән?..»

Безнең Күгәрчен — Башкортстанда. Җидеболак дигән йөгерек инеше, таулары-сыртлары бар. Басу-кырлары — калкулык та үзәнлек. Урманы-җәйләве элек-электән ерак, юллары ташлы таулык; авылның коелары тирән. Уңмаган-пешмәгәннәр мондый җирдә авыл булып яши алмаслар иде. Гаиләләр борын-борыннан ишле булган. Туган җанлы, өмәдәш халык. Эшнең авырыннан, «кара»сыннан курыкмас, авыр чакта сабыр, чыдам, кыен чакта — үҗәт, тоткан эшен булдырмыйча туктамас халык. Үзе ачык, юмарт күңелле, җырлы-моңлы: «Галиябану»ларны сәхнәдә шаулатып уйныйлар, авыл артистлары Башкортстанны иңләп йөриләр, олимпиадалардан призсыз кайтмыйлар.

Безнең авыл картлары белә: дөньяда могҗизалар юк. Булса да, чишмәсе бер генә — эш сөю, тырышлык, осталык.

Кайда гына юк хәзер безнең авылдашлар! Мәскәүдә, Ленинградта, Донбасста, Сахалинда, Себердә. Кайтып төшсәләр, күрәсең; күбесе коммунистик хезмәт ударниклары.

Мин дә — шушы авыл баласы. Унбер белән барганда бер иптәш малай белән икәүләп Олы тау аръягындагы Үрге Сазга чыгып киткән идек. Биштәрләргә әниләр пешергән ипиләрне салып, ботинкаларны бәйләвечләреннән бармакка элеп алып, ялан тәпи. Адаша-адаша. Русча укырга. 3 нче класска. Белмәгән-күрмәгән кешеләр арасына. Әле ярый, әрсезлек җиткән! Сагындыра, дип, елап кайтып кермәгәнмен, укып киткәнмен. Әле ни кадәр яңа дуслар табылган, ил тануым никадәр киңәйгән! Рус теле үз телем булып киткән. Бәхетле юлга чыкканмын.

Унҗидем тулды, Оренбургта фельдшерлар мәктәбен тәмамлап, Шарлык районы Сарманай авылына эшкә килдем. Миннән бер яшькә зуррак Ваня Обухов, Сәнгать Мөхәтдисов, Гоша Соколовлар военфельдшерлар булып фронтка киттеләр. Фашистларның Сталинградка җиткән чагы иде бу. Сарманайда хәтерләүчеләр бардыр, җиңел сөяк, җиңел куллы фельдшер булып чыктым булса кирәк. Эшләрем уңган саен күңел үсә иде. «Духтыр килгән»,— диешкәннәре истә. Хәзер унсигезгә чыкканнарга карыйм да көләм: «Духтыр, имеш!»

Кырык икенең сентябрендә Оренбургтан гаҗәп бер хат алдым. Машинкада басылган язуны беренче мәртәбә күрүем иде. Мине яңадан Оренбургка, мединститутның 1 нче курсына чакыру кәгазе иде бу: «В числе пяти отличников, окончивших Фельдшерско-акушерскую школу, Вы без приемных экзаменов зачисляетесь на 1 курс...»

Була иде, әлбәттә. Чакыру кәгазеңне күрсәт, эшеңне тапшыр, фанер чемоданыңны ал да бар, врачлыкка укый бир! Фронтта военврачларның да бик кирәк чагы...

Минем дәрт бүтәнда иде: «Безгә үлем юк, без җиңәргә тиеш. Уку җиңеп кайткач та качмас!» Малай чакта иптәшләр «Буденный» да «Ворошилов»лар булып «сугышлы» уй-

наганда, мин гел «Николай Щорс» булып «кылыч» болгап чаба идем. Бергә уйнап, бергә укып үскән малайлар утка кергәндә, култыкка китап кыстырып, лекцияләргә йөреп ят, имеш. Хыянәт!

Кырык икенең кара көзендә Сарманайдагы яшьтәшләрем Миркадәм Шәрипов, Ягъфәр Гәрәев, Әлмөхәммәт Дилмөхәммәтовлар — барыбыз бергә комсомолга кердек. Военкоматтан мине военфельдшер итеп фронтка җибәрүләрен көтә идем.

Сарманайда күзгә күренеп торган үлем тырнагыннан коткарып алып калган бер кешем, бүген дә исән — ул Бату Рәшитов исемле зәп-зәңгәр күзле бер ир була. 12-13 яшьлек малай, чана тартып, урманга, чыбык-чабыкка барган җиреннән тезләрентерсәкләрен көчләп тә яздыра алмас булып, бөгәрләнеп туңган иде ул. Өйдән-өйгә кереп, балаларга прививка ясап йөри идем, Батуны урманнан кайтышлый беренче өйгә үк кертеп сәкегә салганнар... Авызын ачтырып, кайнар чәй сала-сала, тәнендә кызыллык күренгәнче, спирт белән уа-уа, ясалма сулыш ясый-ясый... Фронтта ятып калган әтисенең бердәнбер баласы булган ул. Бүген үзенең армиядә хезмәт итеп кайткан улы, ике кызы бар. Тол әнисе белән бергә яшиләр. Үзе — терлекче, хатыны — сыер савучы. Шулар өчен генә булса да укуга китеп бармавым дөрес булган.

Ут сызыгында бик җитез, бик уңган военфельдшер булмакчы идем — дәрт шулай иде, военкомат исә мине Хәрби пехота училищесына җибәрде. «Максим» пулеметын күзең йомып сүт, күзең йомып җый, прицелны дөресли бел, бер пуляң да әрәм китмәсен — фронтта шулай булачак... Пулеметчылар взводы командирлары булып чыгачакбыз...

Училищены тәмамлап өлгермәдек — Степной фронтка! Күрәсең, Курск дугасы гарасатыннан соң фронтны капларга, дошманны, үкчәсенә баса-баса куарга яңа көчләр бик кирәк булган.

Пулемет. Ут кына ач — бөтен миналар, снарядлар, пулялар сине генә эзләп килә... Северный Донецны чыгып утка кердек. Гел алга да алга! Ул көзге яңгырлы җилләр, ул кара төннәр, ул төн саен диярлек 20-30 ар километрлык «форсированный бросок»лар ул пычрак аяк асты, күперсез сулар, ул өстәге сыксаң бераәр чиләк суы чыгарлык шинельләр, ул ашык-пошык казыган окобыңа тула килгән яңгыр суы, шул суга ятып салкын гашеткага басуларың, ул шартлаулар, дөп-дөп итеп өскә төшкән юеш балчык кисәкләре, ярчыклар, ул караңгы төшү белән баш очыннан сызгырып очкан алсу «трассирующий» пулялар...

Донецтан башлап, Славянск, Барвенково, Лозовая калаларын азат итә-итә, Днепрга кадәр диярлек алга узып, бер генә тапкыр да җылы өйдә өс-башны киптереп йоклаганны хәтерләмим. Безгә генә очрамады микән ул мичле, тәрәзәле-түшәмле йортлар?..

Гаҗәп, пулеметчик чакта өркетте дә, какты-сукты, күтәреп тә бәрде, әмма тәнгә тимер тимәде. Комбат, фельдшер икәнемне белеп, ротага санинструктор итеп куйгач кына бер үк көнне ике тапкыр — мә сиңа! Беренчесе — иртән, атака вакытында, икенчесе — көн уртасында. Кыр госпиталендә беренче җәрәхәт истән үк чыккан, чөнки икенчесе бик каты сызлый иде. Врачлар яралану документы тутырганда, мин ул беренче яраны әйтергә дә онытканмын. Шулай итеп, сугышның «пропискасыз» бер ярчыгы минем тәндә әле дә йөри — сөякне ватмаган, җанны алмаган — йөз ел йөри бирсен!

Унтугызым тулмаган, госпитальдән кайтып кердем. Фельдшер булып эшләдем. Көзен, соңлабрак, Уфага барып, пединститутка кердем, башкорт филологиясе бүлегенә. Икенче курста исемле стипендиат идем. Күңел Казан университетына тартты. Уфада әле дә әйбәт дусларым бар.

Минемчә, бу дөньяның иң кызыклы, иң изге, Ил өчен иң файдалы үсеш юлы — ул тирән профессиональ белем алу юлы, сәләтләр-талантларның ачылу, үсү юлы, фәнебез, техникабыз, сәнгатебезнең тизлек белән алга бару юлыдыр. Бу җәһәттән безнең яшьләр горурланырлык дәрәҗәдә бәхетлеләр. Мөмкинлекләре — чикләнмәгән! Без, фронтовиклар, яшьләребезнең азат илебездә рәхәтләнеп белем алу, Илгә хезмәт итүдә иң яхшы талантлары тулысынча ачылып китү мөмкинлекләре өчен сугышып йөрүебез белән горурлана алабыз. Тик яшьләребезнең кайберләре бу бөек бәхетне аңлап, кадерен белеп бетермиләр әле.

Укыту-тәрбия, профессиональ белем бирү мәсьәләсендә Партия ил күләмендә гамәлгә кертә башлаган мәктәп реформасы гаять зур әһәмияткә ия. Яшьләргә дөрес тәрбия бирү — мәңге телдән төшмәс тема, бу хакта уйлану, фикер уртаклашулар мәгаен, беркайчан да туктамас.

Мин эшчеләр микрорайонында яшим. Бер елны еш кына шундый хәлне күрә идем: бер йортның подъезд баскычында унынчыны тәмамлаган өч-дүрт егет көн саен диярлек сәгатьләр буе кәрт суга. Бер кичне исерек тавышлары, җикеренүләре дә ишетелде. Аяныч күренеш... Ирексездән уйланасың: хәрам акча, җиңел табыш юлына кереп китмәсләрме болар? Прогулчылар, брак бирүчеләр булмаслармы? (Дөрес, бу егетләр хәзер армия сафларында, әйбәт чыныгу, дөрес тәрбия алып кайтырлар, тормышның

төрле якларына күзләре ачылыр, дип уйлыйсы килә.) Әмма бүгенге дөньяның бөтен илгә танылган тәзүчеләре, инженерлары, конструкторлары, Арбузовлары, Сәгъдиевләры, Королевлары, Пророков, Шолоховлары була торып, ничек инде дәртле-гайрәтле яшьлекнең алтыннан кадерле сәгатьләрен заяга үткәрмәк кирәк?

Без, фронтовиклар, вузларга зур кыенлыклар аша килеп, кыенлыкларны җыйа-җыйа укыдык. Ә шулай да, әйтик, инде әдәбиятны яратканбыз икән, имтихан тапшырганда Тукай, Такташ, Пушкин, Маяковскийлардан гына түгел, Гете, Байроннар, Петрарка, хәтта Гомерның үзеннән дә яттан әллә никадәр мисаллар китереп җаваплар бирә белә идек. Бу — стипендия өчен генә түгел иде, әлбәттә. Яшьлектә алган белем зәвыкъны, рухыңны формалаштыра, гомерлек рухи байлыгың булып кала, һәр эшеңдә үзеңә югары таләпләр куярга өйрәтә. Ник соң бүгенге яшьләребез арасында үзе сайлаган профессиясендә «тирән чумучы»лар сирәк? Ник кайберләре иң югары ләззәтне фәнни эзләнүләрдән, иҗади ачышлар дөньясыннан түгел, бәлки әйбер, мода якларыннан эзлиләр?

Өлеге егетләрнең кәрт сугып вакыт үткәрүендә, бәлки, кайсыдыр бер мәктәп тә гаепсез үк булмагандыр? Профессиональ кызыксынуларына дәрт-куәт өстәп җибәрә алмагандыр? Кәрт уены — кызыграк!

Минем гомерем буе рәхмәт укыган кешеләремнең берсе — нәкъ укытучы кеше. Үрге Саз башлангыч рус мәктәбе укытучысы Тарас Иванович Мотин. Ике бүлмәле мәктәпнең мөдире дә үзе, дүрт классның укытучысы да берүзе иде ул. Бер кышны беренче белән өченче классларны укытса, икенче кышны — икенче белән дүртенчеләрне укыта иде.

Ни өчен соң шушы көнгә кадәр рәхмәт саклыйм мин аңа? Мин белер-белмәс телем белән җавап биргәндә, ул миңа эчкерсез бер теләктәшлек белән елмаеп, зәңгәр күзләрен нурландырып, шундый дәртләндергеч бер ышаныч белән карый иде ки, хәтта мин үземне оядагы бер кош баласыдай, менә хәзер, менә хәзер укытучы ачкан иксез-чиксез белем дөньясына очып чыгып китәрмен дә, бетмәс-төкәнмәс куанычлы яңалыклар белермен кебек хис итә идем. Билгеле, ул һәр малай, һәр кызчыкка шулай карый иде.

Аның өчен дәреснең мәгънәсе — минем «өчле»гәме, «дүртле»гәме белүемдә түгел иде, әлбәттә. Аның өчен дәреснең мәгънәсе — мине үзе укыткан фән белән кызыксындырып, аз гына белүем белән дә күңелне үсендереп, укырга, белергә дәрт өстәп, хәтта канатландырып җибәрүендә иде. Шуңа күрә аның биргән белеме дә балдан татлы иде.

Безнең Тарас Иванович моннан 42 ел элек, Бөек Ватан сугышында, авнадесантчы булып батырларча һәлак булган. Ул безнең күңелләрдә дөньядагы бөтен нәрсәгә, бөтен хәлләргә кайнар кызыксынучан караш, максатка омтылыш тәрбияләгән, хезмәт-иҗат дәртебезгә илһам канатлары куя белгән. Ул кызыксынучанлык, ул омтылыш, ул иҗат дәрте, илһам минем күңелдә әле дә сүрелмәгән...

Үзем хәзер Тукайның сайланма прозасын рус теленә тәрҗемә итәм. Бик яратып эшлим. Олы эш дип, изге эш дип эшлим.

## Уральск каласына

Уральск каласына
Сәлам юллап каламын:
Асрау Апуш Тукай булып
Үсеп киткән кала ул.

Шәкерт җырлавын ишеткән
Самавырлары газиз.
Питер ялкынын җиткергән
Кайнар җилләре газиз.

Пушкин сүзе, Горький рухы,
Хөррият лачыннары,
«Әлгасрел-җәдит» вә «Уклар»
Вә «Фикер» яшеннәре...—

Тукай илһамын уяткан
Ялкыннар җанга якын.
Тукай узган урамының
Тузан бөртеге алтын...

Уральск каласына
Сәлам юллап каламын. —
Асрау Апуш Тукай булып
Үсеп киткән кала ул.

## Йолдызлар

Җирләр иңлим:
Сталинград,
Днепр буе,
Эльба яры...
Кызыл йолдыз кабызган да
Йоклый минем кордашларым.

Моңнар тула күңелемә.
Офык иңләп күккә карыйм...
Җем-җем итеп нурын чәчкән —
Яудашларым, кордашларым.

## Обелиск каршында

Кызлар кулы тотып өлгермәстән
Алдык кулга сугыш коралын.—
Бергә үскән малайларның исемен
Обелисктан укып торамын.

Ялгыз яшәп пенсиягә чыга
Ил төзешкән бөек сылулар... —
Кавышалмаган егетләре белән
Ил аларны бергә олылар.

## Шаяң көчек

Юл буенда болын тулы эре-эре ак чәчәкләр.
Шул чәчәкләр арасында күренмәсә
тик бересе —
иң кечесе,
әле үсеп җитмәгәне,
ачылып китмәгәне,—
Бу җирләрнең мул ямена
нәрсәдер җитмәс иде.

И чыелдый, и очына аяз күктә карлыгачлар!
Авазлары арасында ишетелмәсә
иң тоныгы,
иң төссезе,
иң нечкәсе,
иң кыскасы,—
Бу көннең якты моңына
нәрсәдер җитмәс иде.
Чыр-чу килеп туп куыша, гол бәрешә бала-чага.
Шул наяннар арасында
атыла-бәрелә чабышмаса
әлсерәп бер шаян көчек,—
Бөтен Җир шарының бәхете
һич тулы булмас иде.

## Аккош күле

Куе урман,
Тыныч зәңгәр күлләр...
Кеше килгән,
Юллар, йортлар салган.
Аккошлар юк —
Тик исемнәреннән
Үзәк өзгеч татлы бер моң калган.
Кайда оя тибә икән алар,
Бәбкә чыгаралар кай җирләрдә?..

Сыйса алар безнең күңелләргә,
Сыймас идемени бу күлләргә!

## Өй белән Ил

Туган авылга кайтам кунакка.
Кайтам җан атып, кайтам ерактан.

Илгә ни алып чыктым соң өйдән?
Өйгә ни алып кайтам соң Илдән?

Ниләр өстәрмен Ил бәхетенә?
Ниләр өстәрмен өй бәхетенә?

## И шигырем...

И шигырем, барчы, Күгәрченгә кайт,
Чал башларга, ак йөзләргә сәлам әйт,
Ата-баба нигезләрен уйлап уз,
Бер көчекнең маңгаеннан сыйпап уз!

## Легенда

Суы бар җир күрсәткән ул юлда.
— Алдакчы!— дип үтереп киткәннәр.
Еллар узгач, шул урынга юлыгып,
Кое казып, суын эчкәннәр.

## Яшәү

Бу дөньяда яшәү уен түгел,
Тик көтмибез күктән әзерне.
Яшәү — бөек максатлары белән,
Җиңүләре белән кадерле.

## Минем иман

Минем иман — асылташтан асыл.—
Мәкерле җан битен капласын!—
Ленин исеме, Ватан исеме белән
Балкый минем яшәү максатым.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

## Газиз Кашапов

# ЯЗМЫШЫҢА ЫШАН

РОМАН

2



Берләшмәнең Кама буендагы причалына Фазыл Айбулатов ике төрле уй белән килде.

Беренчедән, Көмеш Аландагы төзүчеләр сынатмадылар — билгеләнгән вакытка мәктәп бинасын ялт иттереп житкерделәр. Көмеш Аланда, яңа гына кешеләр туплана башлаган бер чорда, бу инде чынлап та җиңү иде.

Икенчедән, Вергилий Никифорович аны Көмеш Аланга бер дә юкка гына чакырмый, әлбәттә. Анда ниндидер житди сөйләшү булачак һәм, мөгаен, Калатауны саклау-сакламау мәсьәләсе шунда хәл ителер дә. Дөрес, әлегә Дикопольцевның уйларын белмәгән Айбулатовка бу хакта тегеләй дә болай дип юрарга гына кала иде. Аларның сүз кузгатып сөйләшер, бәхәсләшер мәсьәләләре, кем әйтмешли, буа буарлык.

Айбулатов шоферын кайтарып җибәрде дә дамба бетонына баскан килеш борынгы елга өстенә, аның теге ягында каралып торган нарат урманнарына карап, арлы-бирле йөрергә кереште.

Елгадан искән салкынча җил аның ярыйсы гына сирәгәйгән, тоташ бәскә күмелгән чәчләрен туздырып уйнап-уйнап ала, соргылт кашлары агачтан-агачка сикерешкән тиен койрыгы сыман сикереп-сикереп куя, маңгаенда елганың тыныч төшендә уйнашкан су кәҗәләре төсле җыерылыр-җыерылмас тора, йөзендә әллә елмаю, әллә уйлану билгеләре чагылып-чагылып китә иде.

Көн кояшлы, җылы, тирә-якка баржалардан бушатып өелгән чуерташ, яңа гына китерелгән кызгылт-сары ком, тагын бик күп төрле төзелеш материаллары исе таралган. Күк йөзе үзенең куе ачык зәңгәрлеге белән шундый якын булып тоела ки, ирексездән шатланасы, кемнәрнедер шатландырасы килә.

Менә ничә ел инде Айбулатов шушы иксез-чиксез кебек күренгән корылмаларга, туган якларга килгән байлыкның зурлыгына, кеше хыялы житмәслек эшләрне чынга ашырырлык көч-куәтнең олылыгына, колачларның киңлегенә карый да күңелендә иркенлек, канәгатьләнү хисләре тоя, эшләгән саен эшлисе килә, яңадан-яңа корылмалар торгызасы, аларны берсеннән-берсен матуррак итәсе килә иде.

---

[1] Ахыры. Башы 3 нче санда.

Әнә шуңа күрә дә Фазыл Артышевич яңа төзелештә еш булырга, атнага бер-ике тапкыр барып әйләнергә тырыша. Төзелеш мәйданында йөри, монтажчылар һәм биналарның эчке ягын бизәүче хатын-кызларның эшләвен күзәтә, киңәшләрен бирә. Һәм еш кына кайберәүләрнең битарафлыгына, эшкә «миннән киткәнче...» дип каравына ачуы куба, кызып китүен сизмичә дә кала. Беркөнне дә шулай, кызып китеп, мәктәп бинасында идәнгә линолеум җәюче останы ярыйсы гына әрләп ташлады.

«Бу бит торак йорт түгел, идән кыл тигез булмаса да ярар»,— дип, күз дә йоммыйча карап тора бит, юньсез... Бу, бәлки, йортлар төзү комбинаты, берничә дистә мең кеше эшли торган коллективның җитәкчесенә килешеп үк бетми торган вакчыллык дияр кайберәүләр, әмма Айбулатов өчен бер дә вак-төяк түгел бу. Ул күрмәсә, башкаларның да карашы тупаслана, «җитәкче аны-моны әйтмәде, ярар әле» дигән ялгыш фикер тудыра башлый. Айбулатов яшь җитәкче, озакламый үзе бер төзү-монтаж идарәсен җитәкләргә тиешле Сәфәровны да әнә шуңа күрә вак-төяк нәрсәләрне дә күрергә, «ярар әле» дип калдырмаска өйрәтергә тырыша. Шушындый кызу утта чыныктырмасаң, кайда, нинди шартларда чыныктырырга соң аларны, безгә алмашка килүче яңа буын җитәкчеләрне?

— Фазыл Артышевич... — дигән тавышны ишетеп ярты адымда туктап калды Айбулатов. Башын күтәреп карады һәм машина тәрәзәсеннән башын чыгарган Вергилий Никифоровични күрде.

«Әле генә юк иде бит, кай арада килеп җиткән соң бу?» — дип уйлап алды Айбулатов йокысыннан яңа гына уянып, ләкин аңардан арынып җитмәгән кеше сыман күзләрен тутырып караган килеш.

Вергилий Никифорович:

— Йөрәгең алындымы әллә, таптата бу дип уйладыңмы? Шундый арысланны без генә таптый алабызмы соң инде? — диде ярым шаярып, ярым чынлык белән сүзләренә ниндидер яшерен төсмер салып.

Айбулатов шундук көрсенеп куйды, аннары елмая төшебрәк уйлап алды: «Бабакай» шаярган булып кына миңа Кама буе төзелеш берләшмәсенә тиңләшердәй Баш идарә җитәкчесе булырга тәкъдим ясауларын белгәнен сиздерә. Чынлап та, нигә инде бу хакта Вергилий Никифорович белән киңәшмәскә иде? Ә хәзер ничектер уңайсызрак килеп чыга: янәсе, Айбулатов «Бабакай»дан ул тәкъдимне яшергән...

— Арысланны таптатырдай машинаның хуҗасы нинди бит аның, Вергилий Никифорович, хуҗасы нинди... — диде Айбулат Шәкүрович һич көтмәгәндә теленә килгән җөмләгә шулай ук астыртын фикер салып. — Теләсә читлеккә яба да яхшы йозак белән бикләп куя, ашатса — ашата, ашатмаса — юк, дигәндәй...

Ул арада Вергилий Никифорович шоферына нәрсәдер әйтте дә, ишекне ачып җибәрде, җиргә төшеп басты, машина салмак кына кузгалды да, тулы әлмәк ясап, килгән ягына таба борылып китте.

— Ярый, ярый, усалланма, Айбулатов, тешләшергә генә торасың. Кайчан шулай өлкәннәргә каршы сөйләшүеңнән туктарсың да, кайчан үҗәтлегеңне ташларсың икән? — диде Дикопольцев килешүчән, гадәттәгечә үз дәрәҗәсен яхшы белгән кешеләргә хас тавышын үзгәртмичә, Фазылның җилкәсенә кулын куеп.

Аның кулы тимер шикелле авыр һәм нык иде.

— Усалланырсың сезнең алда, Вергилий Никифорович...

Айбулатов сүзен әйтеп бетермичә туктап калды, бераз дәшмичә торды, әмма Дикопольцев аңа озын-озак торырга ирек бирмичә катерга таба әйдәп алып төшә башлады.

— Менә сиңа мә! Җитәкчеләргә каршы сөйләп үз дигәнен үз итәргә осталыгы белән даны чыккан Айбулатов нәрсә дигән була. Ә кем Мәскәү хәтле Мәскәүгә барып, коллегия хәтле коллегия алдында «хуҗаны» сыртына салды, шәһәр салу урынын үзенчә хәл итте? Кем иде соң ул дим? Кем иде?

Айбулатов озын баскычтан катерга таба төшә төшешкә хәйләкәрлек чаткылары чагылган күзләрен күтәреп дәрья өстенә карады. Анда көтмәгәндә юлны бүлеп калыккан плотинаны кичәргә чират көтеп торучы өч-дүрт кораб — сәяхәтчеләр белән тулы теплоход һәм эреле-ваклы баржалар хәрәкәтсезлектән интегә иде. Якындагы теплоходның барлык палубалары да ярым шәрә тәнле кешеләр белән тулы, биек мачтага беркетелгән ак груша-көчәйткечтән салмак кына моңсу музыка агыла.

«Бар бит бу дөньяда ваемсыз кешеләр,— дип уйлап алды Фазыл баскычтан төшеп барышлый. — Ничәмә-ничә көннәр буена салмак кына агалар да агалар, теләсәләр — палубада тән кыздырып яталар, теләмәсәләр — каюталарында... Эххх-ма!»

Чынлап та, елга буйлап сәфәр кылучыларга кызыгырлыгы бар иде аның. Менә өченче ел инде ул үзенә тиешле ял вакытын файдаланмый диярлек. Дөрес, ул өзек-өзек, күп дигәндә бер атналык ял алгалый, әмма ул көннәрне я яңа бер проект коруга, я нинди дә булса яңалык эзеннән баруга, шуны өйрәнүгә багышлый. Менә ничә ел инде мактап дусты, Балтик диңгезенең гарәбәле якларында хезмәт итүче генерал дусты үзенә чакырып ята, барып күрергә вакыт тими...

Пауза бераз озаккарак сузылды, ләкин, барыбер, дәшми калырга ярамый иде. Айбулатов берләшмә җитәкчесенең сыгылмалы баскыч буйлап катерга күтәрелгәнен көтеп алды, алга уздырды һәм аның артыннан атлады.

— Җылы сүзегезгә рәхмәт, Вергилий Никифорович. Мин бит, гөнаһ шомлыгына каршы, ике арадагы мөнәсәбәтләр үзгәрер дип уйлаган идем...

Дикопольцев тыңлап бетерде, Айбулатов тагын нәрсә әйтерме-әйтмәсме дип көтеп торды һәм аннары гына:

— Хөрмәтлем Фазыл Артышевич, онытырга уйлаганым да юк. Онытыламы соң инде андый... җиң... җиңелүләр... Бигрәк тә озак еллар буена үз фикереңнең дөреслегенә инанып яшәгән кеше онытмый андый хәлне,— диде, көрсенеп куйды һәм катер палубасының борын өлешенә ясалган эскәмиясенә утырды.

Дикопольцев сүлпән генә елмаеп куйды, аның күзләрендә моңарчы күренмәгән үкенү катыш моңсулык билгесе чагылып китте.

— Юк, Айбулатов... син мине бүлдермә, бүлдермичә генә тыңлап бетер әле, яме. Эш, беләсең килсә, бөтенләй син уйлаганча түгел...

Айбулатов нәрсәдер әйтмәкче иде, ләкин Дикопольцевның кисәтүле соравын искә төшереп бугай, аны-моны әйтмәс булды.

Дикопольцев өзелгән сүзне яңадан ялгап китәргә җыенган гына иде, ярдәмчесе Алексей Мирков алар янына чыкты.

— Вергилий Никифорович, бәләкәй генә тоткарлык: катерчылар гафу үтенәләр, тагын унбиш-егерме минуттан кузгалырбыз диләр,— диде ул һәм җыйнак кына табын әзерләп «шифалы су», чытырдап торган үтә күренмәле кәгазьгә төрелгән, пешкән тавык, бер шешә әрмән коньягы һәм уймак кадәрле генә ике рюмка куйды.

Дикопольцев ике рюмкага да коньяк салды. Айбулатов «коры закон»га буйсынып яшәүче кеше, әмма бу урында рюмканы тотып кына куярга яхшысынмады, тел өстенә җибәрде. Эчемлек аның тамагына кадалды һәм Айбулатовны ирексездән йөткергәләргә мәҗбүр итте. Дикопольцев моны беркадәр гаҗәпләнеебрәк карап торды, тик ләм-мим әйтмәде, баягы сүзен дәвам итте:

— Эш, Фазыл Артышевич, менә нәрсәдә... Мин тоташтан ике хата җибәрдем. Беренчесе — Көмеш Алан шәһәрен кайсы урынга сала башлау. Икенчесе — Калатау нигезендә карьер ачу. Мин моның шулай икәнлеген шактый озак танырга теләмәдем. Нәрсә булсын, тау — тау инде, килеш калыр дип җиңел генә уйладым. Шушы араларда бик озак карап йөрдем мин Калатауны... Аңа салынган җәрәхәтләрне...

Бу минутларда йөзендәге, иңк асларындагы җыерчыклар тагын да зурая төшкән, тирәнәйгән иде. Җитмешнең өске ягына чыгып та күзлек

дигән нәрсәне белмәгән, салкын чишмә янында утыручы пар лачынныкыдай үткер күзләрнең авыр кабаклары еш-еш йомылалар иде. Атакайның характерын яхшы белгән Айбулатов аның мондый нәтиҗәгә нинди уйланулар аша килүен чамалады гына түгел, аермачык итеп күз алдына китерде.

— Син миңа, Айбулатов, менә нәрсәгә җавап бир,— дип дәвам итте Дикопольцев. — Калатауның карьерга таба ишелүен ничегрәк туктатырга?

Айбулатов моңа, билгеле, бик шат иде.

— Вергилий Никифорович, уйлашырга кирәк бу хакта. Миндә кайбер тәкъдимнәр булырга тора. Кайбер нәрсәләрен исәплән кенә карыйсы бар.

— Минемчә, Фазыл Артышевич, безне автогигант корылышында коткарган алым — субайлар кагып эшләү бирелә дә файдалы булыр төсле... Синең Кавказ ягындагы курортларда, мәсәлән, Кисловодскида булганың бар бугай, әйеме?

Сүзнең кинәт курорт хәлләренә борылуы Айбулатовны гаҗәпләндерде, әмма Дикопольцевның буш сүз сөйләп торучылардан түгеллеген белгән Айбулатов сагая төште, аның да күзләрендә хәйләкәр чаткылар чагылып алды.

— Мине курортка җибәрергә җыенмыйсыздыр бит, Вергилий Никифорович? Мин рәхәтләнеп риза булыр идем...

— Синең рәхәтләнеп риза булуыңа шигем зур. Син беләсеңме-юкмы икән, ләкин безнең төзүчеләр арасында бер мәзәк йөри. Имеш, йорт төзүчеләргә: «Бер путевкага комбинаттагы барлык кеше ял итә аламы?» — дип сорау биргәннәр. Килгән җаваплар арасында: «Бу бик мөмкин, ләкин моның өчен шушы путевка белән Айбулатов китәргә тиеш»,— дигәне дә булган...

Атакай да, Айбулатов та бүгенге сәфәргә җыенганнан бирле беренче тапкыр рәхәтләнеп көлештеләр.

Катер акрын гына кузгала башлаган иде инде, шул вакыт яр буенда Дикопольцев машинасы сузып-сузып кычкыртып җибәрде. Ул да түгел, шофер үзе күренде һәм, машина ишеген ябарга онытып, аска таба йөгерде.

Башта Айбулатов, аннары Дикопольцев аягүрә бастылар. «Нәрсә булган моңа?» — дип карап тора башладылар.

Тизлек тупларга өлгермәгән катер яңадан үз урынына чигенеп туктады. Шофер исә баскыч куйганны да көтмичә катер палубасына сикерде.

— Вергилий Никифорович,— диде ул еш-еш сулап. — Сезне Мирас Гайнанович бик ашыгыч кирәк дип эзләтә иде. Сезнең Калатауга китәргә җыенуыгызны белгәч, көтәргә кушты, житди сүз бар, мин дә алар белән барырмын дип әйтеп әйтте...

— Тагын нәрсә дип әйтеп әйтте? — диде Дикопольцев, шоферының тик торганда диярлек кабалануыннан көлеп. — Син кайчан тыныч кына сөйләшергә өйрәнәсең инде, Ренат? Озакламый институтыңны бетереп, үзең житәкче булып эшли башларга җыенасың, ә үзең малай-шалай шикелле юктан да кабалана башлыйсың... Ярый, рәхмәт. Көтәрбез, әлбәттә, бар, кайт. — Һәм шундук, Айбулатов ягына таба борылып, баягы фикерен дәвам итте. — Я, Фазыл Артышевич, курорт турында нindирәк фикергә килдең? Син инде бәлки күңелең белән анда йөрисеңдер? Кызганычка каршы, хөрмәтлем, якын араларда сиңа ул якларга барып чыгарга туры килмәс. Мин синнән Кисловодск курортындагы Космонавтлар юлы — терренкур дип аталган сукмаклардан йөргәнең бармы, дип сорамакчы идем...

— Бар, Вергилий Никифорович,— диде Айбулатов сүзнең төбенә төшә алмыйча.

— Йөргәнең булса, күргәнсеңдер, долонит тауларның текә упкынярыкларын ничек ныгытканнарын... Минемчә, безгә дә шундый алымны кулланырга, урыны-урыны белән Калатау тәненә субайлар сугарга, алар өстенә тау астында аунап ята торган ташларны җайлап тезеп куярга,

борылмалы-борылмалы сукмаклар салырга һәм шул сукмаклар арасына, кара туфрак өстәп, агачлар, гап-гади наратлар утыртырга...

Фазыл Артышевич булачак шәһәр кешеләренең Калатау битендәге борылмалы сукмак буйлап йөрүләрен, яшьләрнең төрле ярышларга әзерләнүен, ә инде ветераннарның аларга карап шатлана-шатлана саф һава сулап рәхәтләнүләрен күз алдыннан үткәрде. Димәк, Көмеш Аланда яшәүчеләргә ерак юллар үтеп Кавказ тауларына кадәр барып торасы да булмый. Айбулатов аңлады: Атакай барысын да алдан уйлап, аңа хәйләле тозак корып куйган иде. Ул әлеге тәкъдиме белән бер атуда кимендә ике куянны бәрде дә екты... Белә, белә Дикопольцев кемнең күңелен ничек кузгатырга икәнлеген. Югыйсә, Калатауны Алмазов төзүчеләре актарып салды, нәкъ менә алар күп көч һәм тырышлык куймыйча гына причал дамбаларына ташлы җир алды. Ләкин Атакай бу эшне Алмазовтан, коры күтәренкелек бәрабәренә генә эшләтеп булмасын да чамалый иде бугай. Әйе, монысы — Айбулатов эше, чөнки аңа үзенең туган җирен матуррак итәргә, Алмазов кебекләр бозганны да төзәтергә туры килә...

Айбулатов тагын баягыча кычкырып көлеп җибәрде, беравыктан елмаеп кына торган Дикопольцев та аның көлүенә кушылды.

## 3

Гөлфирә больницадан чыкканда, әбиләр чуагының иң матур, иң җылы һәм якты гәрәбә көне иде. Соргылт төстәге яшь чыпчыклар, көзнең соңгы көннәре икәнлекне сизгән кебек, ишегалдындагы тузанга чумып уйнаша, чыркылдаша, пырхылдап югарыга таба чөелгән булалар да яңадан шушы ук тузан өеменә килеп төшәләр.

Кичә төштән соң бригада кызлары килгәндә аның чыгасы билгеле түгел иде әле, бүген иртәнге обход вакытында Гөлфирәнең ялварулы, больницада озак ятудан сагышланып калган күз карашын күргәч, доктор түзә алмады:

— Ярый, алайса, Гөлфирә, син инде хәзер безнең ярдәмнән башка да терелеп бетәрсең. Мин синең Көмеш Аланга кайтуыңа каршы түгел, әмма эшкә чыкканчы, табигый ки, сиңа байтак вакыт ял итәргә кирәк булачак,— диде.

Больницадан чыгу ыгы-зыгысы белән ике-өч сәгать сизелмичә дә үтеп китте. Ниһаять, Гөлфирә, әнисе шикелле үк, кадерле җанга әверелгән Санук апа һәм шәфкать туташы ярдәмендә ишегалдындагы эскәмиягә чыгып утырды.

Көзге көннең җылы кояшыннанмы, аллә больницадан чыгу шатлыгыннанмы — Гөлфирәнең башы әйләнеп китте һәм ул, утырган җиреннән егылып төшмәскә тырышып, куллары белән як-ягын капшап, таяныр урын эзли башлады. Санук апа аның хәрәкәтләрен күреп тора икән, тиз арада янәшәсенә килеп утырды.

— Менә бетте... Менә син дә, Гөлфирә җаным, дөнья яктысына чыктың. Югыйсә бит ул больница һавасы килеп терәлгән вакытта гына шифалы. Бераз җан керә башладымы — аннан китүең хәерлерәк. Борчылма... борчылма берүк, озак ятканнан соң шулай булу бик гадәти инде ул, Гөлфирә җаным,— дип, үзенең ышанычлы тавышы белән тынычландырырга кереште.

— Әй, Санук апа, киң күңелле дә кеше инде син үзең, синнән башка бу бинада ниләр генә эшләгән булыр идем соң мин? — диде Гөлфирә утырган урынының ныклыгына ышангач, Санук апасына таба борылып. — Рәхмәтләр генә яусын инде сиңа, Санук апа... Бу йортта эшләүче барлык кешеләрнең дә күңелендә шәфкать тулы, аларга да рәхмәт...

Саф һавада бераз сулу алгач, Санук апа белән шәфкать туташы машина кайгырту мәшәкатенә керештеләр, Гөлфирә ишегалды уртасын-

дагы эскәмиядә ялгызы гына утырып калды, беравыктан башын күтәребрәк караса — исләре китте. Аның каршысында үзенең бөтен киңлеге, Кама дәрьясы ягына таба сөзәгәя барган текә биеклеге, шул биеклек өстендәге урманнарының яшеллеге һәм урыны-урыны белән алтынсу төскә керә башлаган Ширәмәт тавы сузылып ята иде.

Шушы гүзәллек, мәгъруранә биеклек һәм олылыкка гаҗәпләнеп карап торган Гөлфирәнең күңелен, искәрмәстән эчке бер калтырану, әллә нинди курку хисләре биләп алды. Ул үзен искиткеч иркенлек кочагында ялгыз итеп тойды. Аның, акылын җуйган карт лачын шикелле, ялгызлыктан җәһәннәм кочагына атылып очасы, алдын-артын карамыйча китеп югаласы килә башлады.

— Әллә соң... әллә соң тагын берәр җиргә, күз күрмәгән-колак ишетмәгән якларга, БАМ төзелешенең кеше аяк басмаган тайгасына китеп олагыргамы?.. — диде Гөлфирә үз-үзенә пышылдап кына, яшь тулган керфекләрен күтәреп.

Чынлап та, бу минутларда ул кешеләр арасында яшәп тә искиткеч ялгызлык ачысын йөрәге аша кичерә иде. Бу минутларда, әйтерсең, аның өчен янып-көеп йөргән, кыен минутларда янәшәсендә булып аның гомерен даулашкан врачлар, янына килеп йөргән хезмәттәшләре, кызы Таңсылу һәм, хәтта, күңеленә көннән-көн якынрак, кадерлерәк була барган Гаяр да юк, бөтенләй яшәмиләр иде. Бу минутларда, әйтерсең, аның бөтен әйләнә-тирәсен бары тик ялгызлык, ялгызлык һәм ялгызлык кына биләп алган...

Яргаланган иреннәрен тыгыз кыскан Гөлфирәнең аңы ачыкланып, күзләре дөнья яктылыгын күрә башлаганда аның каршысында кызыл хач рәсемнәре төшерелгән «рафик» басып тора иде. Ачык ишегеннән Санук апа төшеп килә.

— Әйдәле, Гөлфирә җаным, акрын гына, иплән кенә кереп утырыйк әле,— диде Санук апа Гөлфирәнең маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен күрмәгәнгә салышып. — Әйдәле, әйдә...

Бәләкәй җиңел автобус больница ишегалдыннан салмак кына кузгалып авылның тигезсез урамына чыкты да чайкала-чайкала барып олы урамның бетон юлына күтәрелде һәм Көмеш Алан ягына таба җилдерде.

Байтак кына баргач, аның күзләре каршыдагы үр башына төбәлделәр. Анда, әле кайчан гына Гөлфирәләрнең бердәнбер краны торган төштә, инде өч катлы ак бина, аның янәшәсендә генә тагын бишме-алтымы кран арлы-бирле боргаланып, очлы борыннарын күккә чөйгән килеш тимербетон плитәләрне күтәреп китерәләр дә җайлап кына кирәкле урыннарына төшерәләр иде.

«Төзелеш, безнең төзелеш яши, әнә ничек зурайган бит ул!»— дигән уй Гөлфирәнең күңелен җылытып, горурлык хисе уятып үтте. Гөлфирәнең ил һәм хәтта дөнья күләмендә дан яулаган яңа төзелешләрне күргәне бар, ләкин аларны Гөлфирә түгел, ә бүтәннәр башлап җибәргән иде. Ә менә монысын Гөлфирә иң беренче казыктан башлады. Бусы — аныкы, Гөлфирә төзелеше иде!

Санук апа да, янәшәдә утырган килеш, ләм-мим бер сүз әйтмичә, Гөлфирәне үз иркендә калдырып, яңа төзелешне күзәтеп килде.

Көмеш Аланга керәсе күпер янында сансыз-хисапсыз төрле машиналар — үзбушаткычлар, краннар, плитә ташыгычлар һәм тагын әллә ниндиләре тупланганнар да бу юлны бикләп торалар иде. Кайчандыр ат арбасына исәпләп салынган күпер, вак ташлар салып ныгытуга карамастан, куәтле БелАЗ үзбушаткычының авырлыгыннан сыгылып төшкән иде.

Көмеш Аланның хәзер инде терлек-туардан тынып калган ферма биналары яныннан узгач та яңа төзелеш үзенең бөтен корылмалары белән уч төбендәгедәй булып аермачык күренә башлады...

Җиңел автобус «с» хәрефе сыман тезеп куелган вагоннар уртасына кереп туктауга, аны төшке аштан соң ял итеп утыручы төзүчеләр, монтажчылар һәм штукатур-буяучы хатын-кызлар урап алды.

Автобусның киң ачылган ишегеннән кулларына култык таяклары тоткан Гөлфирә күренүгә, хатын-кызлар арасыннан Әнүрәнең:

— Егетләр, я инде егетләр, нәрсә карап торасыз, күтәреп алыгыз Гөлфирә апаны, тоже миңа рыцарьлар... — дигән шат тавышы ишетелде.

Гөлфирә:

— Үзем, үзем! — димәкче иде, ләкин кая ул, аның тавышын ишетмәделәр дә. Башта кулындагы таякларын тартып алдылар, аннары ул үзе дә көчле куллар ихтыярына эләкте.

— Исәнме, Гөлфирә апа,— диде аны бер яктан тотып баручы Зөлфәт Зәйнуллин. — Нишләп хәбәр итмәдегез, үзебез барып алган булыр идек...

— Болай да әйбәт булды, Зөлфәт... Сезне борчып торганчы... Больницаның өр-яңа автобусы селкетмичә дә китереп җиткерде... Ә сез...ә сез биредә җир җимертеп эшлисез икән...

— Кая инде ул, Гөлфирә апа! Чаллыярдагыча кызулыкка җитеп булмый әле. Тоткарлыклар чыгып кына тора...

Ишек ачылганнан бирле Гөлфирәнең күзләре Гаярны эзли иде, ләкин ул күренмәде. «Берәр җиргә киткәндер, ахрысы»,— дип уйлап куйды Гөлфирә.

Ул арада Гөлфирәне вагоны янына китереп җиткергәннәр иде инде, кояш ягындагы эскәмиягә утырттылар.

Гөлфирә үзе яши торган вагонга, үзе белән бергә эшләгән хатын-кызларга карады. Танышлар бар, ләкин яңа килүчеләр дә байтак иде. Аның турында, бригадир булгач, төрлесен ишеткәннәрдер, билгеле, әмма хәзер алар бер иптәшләренең терелеп кайтуына чын күңелдән шатланалар, шуңа йөзләрендә елмаю балкый иде.

«Мин бит, мин үземне япа-ялгызга санап,ниләр уйлап бетермәдем... Мин алардан аерылып, үземне-үзем караңгы һәм билгесезлек хөкем иткән упкынга ташлый яздым»,— дигән уй Гөлфирәнең күңелен тагын да күтәреп җибәрде.

Ул мөлаем гына, чын күңелдән елмаеп куйды...

## 4

— Йомыш-фәлән төшмәсә, үзең чакыртып алмасаң, сезне бер күрергә тилмереп үләрсең, дусларым. Автогигантны салган чакларда, кем әйтмешли, без алай түгел идек тә, без болай түгел идек, ә? — диде Мирас Гайнанович күперчекне сыгылдырып ярдан катерга кирә-керешкә үк. Аның кәефе, күренеп тора, әйбәт, күңелендә эчке бер күтәренке рух барлыгы сизелә. — Юк бит, үзләре белеп: «Иптәш секретарь, без АЭСка сәфәр кылырга җыенабыз, әйдәгез»,— дип чакыра белмиләр...

Дикопольцев белән Айбулатов аны күперчек янына ук килеп көтеп торалар иде.

Дикопольцев:

— Гаеплебез, Мирас Гайнанович, әйтәсе дә юк. Кыйнарга, шәһәр комитетына ешрак чакыртып әрләргә кирәк безне,— дип сөйләнә-сөйләнә, кулларын сузып каршы алды секретарьны.

— Миңа калса, сезне кыйнарга да, әрләргә дә кирәкми,— диде Мирас Гайнанович, җитәкчеләрнең икесе белән дә күрешеп. — Сез үзегезне үзегез бик әйбәт кыйный да, әрли дә беләсез. Үзтәнкыйть яши икән әле...

Җитез катер, моторын гүләтеп, урыныннан кузгалды да, салмак чайкала-чайкала, елганың көмеш өслеген ярып, эчкә таба кереп китте. Винт әйләнешеннән барлыкка килгән вак дулкыннар яр читендәге бетонга барып бәреләләр дә аерата бер елдамлык белән үзләрен кузгатып җибәргән катер артыннан ыргытылалар, ярдан ерагайган саен киңәяләр.

Борнашев кулында йомарлап килгән газетаны сузды.

— Менә, рәхим итеп, укыгыз, белегез үзегезнең нинди эшкуарлар, вәгъдәсезләр икәнлегегезне...

Айбулатов якынрак тора иде, газетаны сузылып алды да кайсы битен ачарга диебәк уйлап торды.

— Икенче битен ач та иң өстәге баганаларны укып кит,— диде Борнашев түземсезләнеп. — Макталган Алмазовыгыз бирә анда кирәгегезне. АЭС төзелешендәге темпларның чын йөгереш алмавы, йортлар кору, хәтта турыдан-туры үз идарәсе башкарырга тиешле дамба салу, чистарту корылмаларын торгызуда да, вакытлы-вакытсыз мәктәп өлгертүегезне дә гаепләр җай тапкан...

Ниһаять, эзләгән мәкаләне тапты Айбулатов. Булачак АЭСның шушы араларда гына килгән, табигый ки, әлегә эшләр торышы белән танышып та өлгермәгән директоры һәм Алмазовның хәбәрче белән әңгәмәсе иде ул. Фазыл Артышевич күз йөгертеп кенә укый башлаган иде, Дикопольцев аңа:

— Я, Айбулатов, кычкырып укы, без дә ишетик,— диде.

Айбулатов бер тын белән диярлек укып чыкты. Мондый кычкырып торган гаделсезлектән аның чигә җепселләре кыса башлады, күзләрендә нәфрәт очкыны кабынды.

Вергилий Никифорович аны бүлдермичә тыңлады, берничә тапкыр «так-так» дип куйды.

Борнашев исә Айбулатов укыган арада табын янына барды һәм пыяласы тирләп торган «Шифалы су»ның шешәсен ачты, тәмен белеп кенә, Дикопольцев белән Айбулатовны күзәтә-күзәтә эчәргә керешә.

— Менә сиңа мә! Авыртмаган башка тимер тарак бит бу! — диде мондый көтелмәгән сөмсезлектән исе китеп, әңгәмәнең кайбер урыннарын икенче мәртәбә карарга керешкән Айбулатов. — Соң бит, Вергилий Никифорович, карагыз әле, Мирас Гайнанович, эшләрнең тоткарлана төшүендә Алмазов идарәсенең гаепле икәнлеге көн кебек ачык, моннан биш-алты ай элек сафка кертелергә тиешле измә-бетон узелларының әлегәчә эшләмәве...

Дикопольцев кинәт борылды да катерчылар тәрәзәсе янына барып:

— Алексей... Мирков! — дип кычкырды. — Кая югалдың?

— Тыңлыйм сезне, Вергилий Никифорович. — Алексей ишектән чыгып, Дикопольцев каршына басты.

— Хәзер үк рацияне кабыз да Зәй белән сөйләш. Алмазовны җир читеннән булса да тапсыннар, ике сәгатьтән Көмеш Аланда булсын. Бетте.

Байтак кына сүзсез бардылар. Айбулатов елга ярындагы күренешләрне карап барган сыман итте. Ә Дикопольцев палуба идәнен бер кат «үлчәп» чыкты.

Мирас Гайнанович аларның икесен дә тынычландырырга теләп:

— Ярый, Вергилий Никифорович, ахыр чиге, Алмазовның үз гаебеннән качарга омтылуын, кайберәүләрнең гайрәтенә сугарга тырышуын аңлап була. Минемчә, ул иптәш көтмәгәндә ябырылган катлаулы мәшәкатьләрне, киеренкелекне өнәп бетерми бугай. Анда, мөгаен, автогигант сынавын үткән кешеләрнең берсен күчерү кирәктер... — диде.

Алексей табынны яңартып җибәрде.

— Әйдә, кил әле, кил монда, утыр, Никифорович (бөтен Чаллыярда бер Борнашев кына үзеннән егерме яшькә өлкән Дикопольцевка «син» дип эндәшә иде). Айбулатовка да «Утыр!» — дип ымлады. — Монда, дусларым, Алмазов — вак мәсьәлә. Беләсезме, АЭС хәтле АЭСтан да болайрак мәсьәлә кубарга тора бит әле...

«Тагын нинди хәбәр әйтер бу?» — дигән сыман Дикопольцев белән Айбулатов башта бер-берсенә карашып алдылар, аннары икесе берьюлы Борнашевка төбәлделәр.

Борнашев исә ашыкмады, «Шифалы су»дан авыз итте, кулъяулыгын чыгарып, күзен-битен сөртте, аннары гына башлап китте:

— Бүген иртә белән генә Мәскәүдән шалтыраттылар, Вергилий Никифорович. Бездән, дускайлар, автогигант тирәсендә трактор завод-

лары комплексын торгызу ихтималлыгын тиз арада өйрәнеп хәбәр итүне сорыйлар. Төзелеш индустриясенең көчле тәҗрибәсе үзенекен итә, күрәсең... Якын араларда бу мәсьәлә әзер тәкъдим буларак Үзәк Комитет Политбюросына кертелергә тиеш. — Борнашев, сүзеннән туктап, урыныннан торды, баярак Дикопольцев йөргән шикелле палуба мәйданчыгын урап килде. — Мин, дусларым, Карабуга һәм аның тирәләрендәге җирләрне өйрәнеп карарга вәгъдә иттем... Белсеннәр безнең халыкның эшкә сәләтле, теләсә нинди сынауларда да сынатмаслыгын, әйеме, Фазыл? Син ничек уйлыйсың, Вергилий Никифорович, хаклымы мин, юкмы?

Фазыл Айбулатовның зиһене кайчандыр үзе эшләгән, элек ничек тыныч бер агымга кушылып яшәсә, киләчәк гасырларда да шулай дәвам итәр шикелле тоелган Карабуганы, аның тирә-ягындагы йөзьяшәр нарат урманнарын, кайчандыр, борынгы бабайларның бабалары корган һәм хәзергәчә «Шайтан шәһәрчеге» дип аталган хәрабәләрне күз алдына китерде. Ул җирләрнең табигый тынлыгы, бөек рәссамга илһам биргән хозурлыкның озакламый автогигант төзелешендәге сыман шау-шуга күмеләчәген тоеп, ирексездән сыкранып куйды.

Вергилий Никифорович исә Борнашев җиткергән хәбәргә чиксез шатлануын яшереп тормады:

— Шә-ә-әп бит бу, Мирас Гайнанович, бик шәп бит бу! Димәк, Кама буендагы батырлык алдагы елларда да дәвам итәчәк. Безнең берләшмәнең эшләре тагын да шау-шу күтәрәчәк. Автогигант, нефть химиясенең иксез-чиксез корылмалары һәм, ниһаять, трактор заводлары комплексы! Искитәрлек бит бу! Сокланырлык пейзаж бит бу, Мирас Гайнанович! Бу яклар илебез экономикасының болай да мөһим божрасын тәшкил итә иде, хәзер исә отыры мөһим, аеруча ышанычлы чылбырына әвереләчәк. Шә-ә-әп! Браво, Фазыл, хуплыйм мин бу идеяне. Мирас хөрмәтлем, хуплыйм! Яшә, берләшмә, ныгыт илебезне... Болай булгач, АЭСның кору эшләренә дә игътибар икеләтә артачак, иптәшләр, менә күрерсез, әйтте Дикопольцев диярсез...

Әле генә әңгәмәнең үзәгенә әверелгән Карабуга ярлары бу вакытта артта калган иде инде.

Акчарлактай җитез, ак катер сул тармакка борылып керде һәм елга ярындагы агачлардан төс иңдереп куерган яшькелт дулкыннарын яра башлады.

5

Гөлфирәгә аш-су алырга дип, ашханәнең арт ишегеннән ялгыш икенче бүлмәгә килеп кергән Санук апа тораташ булып катты да калды: аның алдында фашист концлагерена ачлык-ялангачлык, кимсетү-җәбер, җан-үлем җәзаларын бергә-бергә кичергән, Каршылык төркеменә Вергин фамилиясе белән кереп киткән кеше тирләп-пешеп чәй эчеп утыра иде!

Сүзләре сүз иде, күрәсең, Санук апага игътибар итүче булмады. Дөрес, чәй эчеп утыручы аңа таба караш ташлады ташлавын, әмма ул караш кына кырык елга якын вакыт катламын күтәрерлек, хәтер сандыгының иң тирән тартмасына ябылган хатирәне күрерлек түгел иде.

Санук апаның бер генә мыскал шиге дә юк — бу, һичшиксез, ул иде!

Хөкем ителгәннәр арасыннан төнлә үлгән бер бичараның киемнәрен Каршылык төркеме кушуы буенча үз куллары белән салдырып, алмаштырып кидерткән, аннары тагын ике атна буена сулыш өреп диярлек яшәүгә кайтарган бу кешене танымыймы соң?

Тыйнаклыкның үзе булып яшәгән, больницада ятарга мәҗбүр булганнарны хезмәт вазифасы кушканга гына түгел, җанының бөтен җылысын биреп карарга, аларны терелтүгә үзеннән дә өлеш кертергә тырышкан Санук апага зур җитәкчеләр алдында кычкырып сүз әйтерлек кыюлык каян иңгәндер, әмма ул калтыравык, ләкин шул ук вакытта ярыйсы гына тәэсирле тавыш белән:

— Вергин! — диде.

Әңгәмә өзелеп калды... Санук апа авызыннан чыгып, бүлмә уртасында бомба шартлаган сыман яңгыраган сыңар сүз Вергилий Никифорович Дикопольцевны калтыранып куярга мәҗбүр итте. Аның баш миен маңгае турысыннан кыл урталай бүлеп, яшен кылычы ярып үтте. Күкрәк сөяге астыннан көчле бизгәк өянәге тоткандагы шикелле салкынлык бәрде, мускуллары тартышып-тартышып алды, кулындагы чәе кайнарлыгын бар дип тә белмәде.

— Вергин! — диде бу юлы ишетелер-ишетелмәс кенә Санук апа һәм өстәп куйды: — Өнемме бу, әллә төшемме??

Бу өн иде, ләкин кайчандыр өндә күрелгән коточкыч төш шикелле хәлләр онытылырлык түгел, еллар үткән саен һаман эзәрлекле иде...

...Авылдашлар телендә Санук дип аталган кыз — Александра Субаева туган бишеге Субайда тыныч, иркен һәм күңелле тормыш белән яшәп ята иде. Үз ишләреннән ул бары тик бер сыйфаты белән генә аерылып тора — үзен яраткан егетләрдән килгән папирос һәм трактор маеның исен, аларның басу буйлап кара буразналар калдырып йөрүен, ындыр табагына басып, молотилка әйләндереп эшләүләрен ярата иде. Унбер-унике яшеннән үк, чаялыгы йөзенә чыккан Санук МТС тракторлары янында мазутка буялып йөрүне барыннан да артыгракка санады. Әнисе әллә ничә мәртәбә орышып, тарткалап, хәтта аз-маз суккалап та карады. Тик кая ул! Курку белмәс, тынгысыз Санук, киресенчә, әнисе катырак орышкан саен, трактор тирәсен ныграк ярата барды. Тагын ике-өч ел үттеме-юкмы, Санук колхоз малларын карарга керешкән иптәш кызларына күз дә салмыйча, МТСка барып тракторчылар курсына язылды.

Авылдашлары да, әнисе дә:

— Шунда эшләүче берәр кара чутыр-тракторчыга кияүгә чыгар да тынычланыр, баласы булгач та тракторларын онытыр әле,— дип кыздан битәр үзләрен тынычландырырга теләп сөйләделәр.

Әмма... Кырыгынчы елның җәйге челләсендә Субай авылындагы укытучы Заһидә апа янына Көнбатыш чик буенда хезмәт итүче улы — командир егет Ирбулат кайтып төште. Төште һәм беренче кичтә үк ындыр табагында ашлык суктырып ятучы яшьләр янына килде.

Әй, Ирбулат! Кара чәчле, каратут йөзле, бер карауда теләсә нинди чая кызның да йөрәген яндырып алырдай кара күзле, җил шикелле җитез хәрәкәтле егет, кайтмаган-күренмәгән булсаң, ни иде соң?

Кырыгынчы елның урак өстендәге бер кичендә молотилка белән трактор шкивын тоташтырган киң каеш шартлап өзелде. Ул нәрсәне, ындыр табагына шундый эшләрне караштырырга дип чакырылган Ләксәй дәдәй озын-озак тотмыйча тегеп-тоташтырып та куйды. Ләкин шкивларга киертә башлагач, аның ярыйсы гына тыгызлануы мәгълүм булды. Берничә хатын-кыз тырышып-тырышып карасалар да, каешны элә алмадылар. Ә Ләксәй дәдәй, җегәре чамалы калганга күрә, ярдәм итә алмады.

Шулвакыт, көтмәгәндә күктән иңгән Хозыр Ильяс сыман, Санук янәшәсендә яшел кырпулы фуражка кигән, биленә җилкәсеннән алдырып каеш буган егет пәйда булды.

— Кая, туганнар, мине дә кертегез әле арагызга,— диде ул һәм каеш кидертергә азапланган хатын-кызлар башларын күтәреп караган арада трактор белән молотилка шкивларын тоташтырып та өлгерде. — Менә булды, кабыз, матурым, тракторыңны...

Телгә осталыгы белән танылган Ләксәй дәдәй дә «тәк-тәк-тәк»тән башканы әйтә алмады.

Ә Санукның йөрәге әллә нишләде, бәйгә чыгасы юрга шикелле бәргәләнергә кереште.

«Ул!» — дигән уй Санукның бөтен чаялыгын юкка чыгарды.

«Ул!» — дигән уй арыслан йөрәкле Ирбулатның да күңелен айкап ташлады.

«Кем бәхетенә үскән бу егет? — дигән уй икешәр бала белән егерме биш яшендә тол калган Әнфисә белән Мәрфукның бәгырьләренә үткер хәнҗәр кебек кадалды.

## 6

Шушы хәлләргә төгәл бер ай тулган яңгырлы кичтә Санук белән Ирбулат илнең көнбатыш чигеннән «теге» якка узып китәчәк поездан төштеләр.

Вокзал алды хәрбиләр белән тулы, аларның кайберләре үзара сөйләшеп йөриләр, ә кайберләре поездан төшеп калучыларның кәгазьләрен тикшерәләр, нәрсә турындадыр сорашалар иде.

Бер командир белән ике сугышчы (ул вакытта Санук аларның званиефәләннәрен бөтенләй белми иде әле) Ирбулатның каршысына ук килеп бастылар. Командир кеше Ирбулат янәшәсендәге Санукны яшькелт күзләре белән капшап-капшап чыкты. Ирбулатның хатыныдыр дигән уй аның башына килмәгән, күрәсең:

— Ә бу туташ-иптәш кем була? — диде, кызыксынудан битәр гаҗәпләнгән тавыш белән.

— Хатыным! — диде Ирбулат тантаналы төстә.

Теге командирның ни өчен гаҗәпләнгәне Ирбулат хезмәт итә торган төшкә барып җиткәч мәгълүм булды. Соңгы вакытларда бик күп командирлар үзләренең хатыннарын һәм балаларын, киресенчә, ил эченә табарак озатырга тырышалар икән. Ирбулатны бераз әрләп тә алдылар бугай, әмма русча бер авыз сүз белмәгән Санук аларның нәрсә сөйләгәннәрен аңламады, чамалады гына...

Ике-өч көннән барысы да рәтләнде, фатиры да табылды, тик торуны башына да китермәгән Санукка да эш чыкты. Командирлар ашханәсендә табак-савыт юа башлады ул.

Әгәр дә яңа гына бергә кушылган ике яшь йөрәк бер-берсеннән башка яшәүне күз алдына да китерми икән, җитмәсә аларның икесенә уртак куышлары да бар икән, алар өчен бер ел гомер нәрсә ул — нибары өч йөз алтмыш биш көн һәм йокысыз диярлек сөешеп-серләшеп узган шулкадәр үк төн генә бит.

Узды да китте бер елга якын гомер: ай күрде, кояш алды...

Саратан башы[1] җитте.

Таң алды тынлыгын ярып, башта беренче, икенче һәм өченче залп ишетелде. Аннары аерым залплар тоташ күкрәүгә әверелде. Йокылы-уяулы кешеләр нәрсә булганын чамаласа да, күңел төпләреннән чынчынлап ышанырга кыймыйча ишегалларына, урамнарга атылышып чыктылар.

Санук үз күзләренә үзе ышанмады, алар яши торган шәһәрчекнең иң зур корылмалары йомычка булып күккә оча, әйләнә-тирәне төтен һәм көек исе баскан иде.

Санук үзенең ничек, нигә һәм кая барганын хәтерләми. Аны елга ярына җитеп су өстендәге хәрәкәтне карап торган җиреннән кемнеңдер көчле куллары эләктереп алды да артка таба тартып китте.

— Ирбулат кайда?! Күрсәт, зинһар,— дип ялварды Санук старшина кулына тотынып барган килеш. — Минем аның янында буласым килә.

Бу як ярдан туктаусыз диярлек атып торуларына карамастан, фашистларның беренче төркемнәре елганы кичеп чыккан һәм чик сакчылары яткан траншеяларга таба автоматлардан тоташ ут яудырып һөҗүмгә килә башлаганнар иде инде.

Ирбулат бер генә мизгелгә күренде һәм Санукка елмайгандай итте.

---

[1] Саратан — кояш елының дүртенче ай исеме. 22 июнь — 21 июльга тик.

— Яралыларны бәйлә, застава аръягына таба чыгарыш, Санук,— диде һәм траншея төбенә авып төшкән пулеметчыны тотып алды, ипләп кенә җир идәнгә яткырды һәм үзе аның урынына басып фашистларга ут ачты.

Санук шунда ук пулеметчы өстенә иелде, ләкин коты алынып, кычкырып җибәрде: сугышчының теле авызыннан чыккан, тешләре аны тешләп өзгән диярлек, ә күзләре урынында канлы, каралып торган тишекләр генә иде...

Бер сәгатьме, әллә бер минут уздымы — анысын хәтерли алмады Санук. Янәшәсендәге Ирбулат кыска гына ыңгырашып аның өстенә ауды. Баягы күкрәү, атыш һәм кычкырыш тавышлары — барысы-барысы да тынып калды, дөнья тоташ караңгылыкка күмелде шикелле...

Санукны җилкәсеннән тотып өскә таба өстерәп чыгардылар.

— Фрау, а... красивая женщин,— диде берәве.

Кемнәрдер ихахайлап көлештеләр, ят телдә бер-берсенә кычкырыштылар.

Санук әллә нинди бер миңгерәүләнгән хәлдә фашистларга карады, ләкин ул аларның ыржайган йөзләрен күрмәде. Аның күзләре Ирбулатны, бүтән сугышчыларны эзли иде.

«Безнекеләр... безнекеләр кая китеп беткәннәр, нигә мине монда калдырганнар соң?» — дигән уй Санукның йөрәген чәнчеп-чәнчеп алды.

Санук икенче көнне таң алдыннан гына аңына килде. Аның битләренә, күзләренә, яргаланып беткән, кабарынкы иреннәренә салкынча, ләкин искиткеч тәмле булып тоелган яңгыр тамчылары тама иде. Ул аларны тел очы белән ялап-ялап алды. Тәне әллә бар, әллә юк — бары тик бертуктаусыз әрнегән ит кисәкләреннән гыйбарәт иде. Күрәсең, ул ыңгырашып куйгандыр, янәшәсендә генә:

— Аңыштыңмы, сеңелкәш? — диде берәү калтыравыграк, ләкин ярыйсы ук ышанычлы итеп.

Санук әлегә үзенең кайда һәм нинди хәлдә икәнлеген төшенеп житмәгән иде — дәшмәде.

Тирә-як караңгы иде әле. «Таң алды караңгылыгы бит бу»,— дип уйлап куйды Санук, басуда эшләгәндә, гадәттә шушы вакытта тракторы янына барганда түзә алмаслык булып йокы килә торган иде.

Санукның аңы кинәт яктырып китте. Ул зәңгәр күк йөзендә бер-бер артлы атылган йолдыз тизлеге белән үзе кичергән хәлләрне исенә төшерә башлады. Ирексездән терсәкләренә таянып күтәрелергә тырышып карады һәм тәнендәге күзгә күренмәс яралардан авыр ыңгырашып:

— Ә-ә-ә-ә-ни-и-и! — диде.

Шундук баягы тавыш тагын ишетелде:

— Аңыштыңмы, сеңелкәш, әйдә, әйдә, тырыша күр, тырыш...

Ләкин Санукның яткан җиреннән күтәрелә алмаганын күреп, ярым пышылдап кемгәдер әйтте:

— Менә бит, кабахәт нәрсәләр, хатын-кыз дип тормаганнар, нишләткәннәр... Мин аны бераз хәтерлим, ул бездән ерак түгел яши иде. Ире — чик сакчысы...

— Тссс, телеңне тый син,— диде икенче берәү.— Алар чик сакчыларын беренче чиратта кырып бетерергә тырышачак...

«Ни өчен телне тыярга? Ни өчен чик сакчыларын беренче булып кырырга?» — дигән беркатлы сорау Санукның уена килде, ләкин җавабы табылмады.

Өч тәүлеккә якын бер валчык икмәк күрмәгән, күбесе сугышның беренче сәгатьләрендәге коточкыч ябырылу вакытында ук яраланган, шартлаулардан миңгерәүләнгән кешеләр язмышларының көтмәгәндә болайга әйләнүеннән аптырашта иде. Һәрхәлдә, Санук һәм аның янәшәсендәгеләр шундыйрак хәл кичерделәр. Барысы да алай ук аптырашта булмаган, күрәсең, чөнки Санук аңына килгәннән соңгы беренче

төндә үк кемнәрдер әсир төшкән сугышчылар арасында кемнәрнедер эзләгәндәй арлы-бирле йөрде. Аннары төн урталары авышa башлагач тагын кемнәрдер капка төбендәге сакчыны чакырып китереп аңа ябырылды. Бер мизгел арасында фашистны сытып, аның кулындагы автоматны алып тышкы якка ташландылар. Әмма... алар күп булса егерме-утыз адым атларга өлгермәделәр, өсләренә тоташ яңгыр булып коела башлаган кургаштан тончыгып җиргә аудылар. Бик күпләр әнә шушы соңгы һөҗүмгә күтәрелгән урыннарында мәңгелек йокыга талдылар.

Соңыннан белде Санук: әгәр дә шулар арасында ятып калса, үн тапкыр яхшырак буласы икән...

Дүртенче көнгә китте дигәндә, аларны урыннарыннан торгыздылар да әле кайчан гына Ирбулаты белән килеп төшкән станциягә кудылар, эткәләп-төрткәләп, бурзайларыннан талатып, агач вагоннарга тутырдылар.

Таң алдыннан поезд кузгалып та китте... Тик ул Санук килгән якка, аның үзәкләрен өзеп төшләренә кереп йөдәткән туган якларына таба түгел, ә бөтенләй икенче якка — ят илләргә таба кузгалды...

## 7

Вергин!!!

Алты гына хәрефтән торган бу фамилия шәһәр торгызу кебек тыныч, игелекле эш белән мәшгуль булган, дөньясын онытып шуның мәшәкатьләренә чумган Вергилий Дикопольцевның да хәтерен, моннан еракларда калган, ләкин онытылмаган, барлык вак-төякләренә кадәр күңелнең тирән тамырларына сеңеп калган вакыйгалар дәрьясына алып китте.

Дошман явы туган иленә бәреп кергәч тә үзенә тиешле броньнан файдаланмыйча, кирәкле урыннарында әйткәләшә-әйткәләшә сугыш кырына ашкынган, аннары яу кырында туфракка күмелеп, мәңге-мәңгегә «хәбәрсез югалды» дигән мөһер артында калырга тиеш булган Вергилий чынлыкта әсирләр арасында аңына килде. Ул, яраларыннан арынып, үз хәлен аңлаган минуттан алып, язмышның шушы явыз шаяруы белән килешергә теләмәде. Аз-маз хәрәкәтләнә башлауга, хурлыклы һәм мәсхәрәле хәлдән — әсирлектән качу уйларына бирелде. Тумышыннан ук кешеләр белән аралашу серләренә төшенгән, алар белән уртак тел таба белгән Вергилий Дикопольцев табигать тарафыннан курку белмәсләр арасына кертелгән һәм үлем дигән нәрсәнең ач бәбәкләренә туры карап та калтыранмаган зирәк акыллы, тапкыр ир-егет иде.

Ул иреккә, бары тик иреккә, туган илен яклаучы кордашлары арасына омтылды.

Беренче тапкыр качуы бөтенләй уңышсыз булды аның. Икенче көнне үк тотып яптылар. Бүтән алай эшләмәслек итәргә тырышып, немец итекләре белән изделәр, бурзайлардан талаттылар.

Рухына аз гына да зыян килмәде.

Ул бары тик үҗәтләнә, үчләнә-нәфрәтләнә төште. Вергилий Дикопольцев дигән ир-егетнең йөрәгендә буйсыну дигәнне белми торганнар рухы тибә иде.

Тагын качу, тагын фашист вәхшиләре кулыннан җәзалану...

Дикопольцевны белгән яки аның соңгы аралардагы хәлләрен күргәннәрнең исе китә иде. Качу турында уйлаудан башканы белмәгән әсирнең болай да чыгам-чыгам дип торган җанын фашистлар ничек суырып алмагандыр? Шулай итеп, соңгы качудан соң тотып кайтаргач аны куллары-аяклары талганчы кыйнадылар, җәзаладылар да, «флюгпункт» дигән тамга салып, тагын кырысрак, тын алырга җай табылмаслык үлем лагерена кертеп җибәрделәр. Фашистларның уенча, җәзалау-мәсхәрәләүнең

әлегә мәгълүм булган барлык ысулларын үзендә татып та буйсынырга теләмәгән әсир моннан инде бары тик бер генә юл — крематорийморҗасы аша төтен булып кына чыгарга тиеш иде... Тиеш иде...

Үлем дигән нәрсә никадәр генә кансыз булмасын, әмма яшәү дигән иманына тап төшермәгән әсир Вергилий Дикопольцевны бу юлы да тиеш урынга алып китә алмады. Үлем лагерында да совет кешеләренә хас рухи бердәмлек, кыюларга булган ихтирамы фашистлар мөмкин түгел дигән чикне дә узды.

Каршылык төркемендәгеләргә фашист тоткынлыгына буйсынырга теләмәгән совет әсирен китерүләре шул ук көнне билгеле булды. Ул әсирне үлем тырнагыннан тартып алырга карар кылдылар.

Үлем лагерендагы лазаретның исеме генә исем, җисеме исә шифаханә булудан ерак, әмма Каршылык төркеменә тупланган әсирләрнең фашистларга төрле җәзалар уйлап чыгаруы өчен бик тә уңай иде. Лазаретта, фашистлар күзәтүе астында, төрле милләт вәкилләре — врачлар, шәфкать туташлары, санитарлар эшли, һәм алар, үзләренә үлем җәзасы янаудан курыкмыйча, бәлагә юлыккан әсирләрне ач бәбәк тырнагыннан йолып алу чарасын табалар иде.

Өзлексез җәзалаулардан хәрәкәтләнер хәле калмаган Вергилий Дикопольцевны крематорийга түгел, лагерь лазаретына кертеп салганнар һәм тагын җәзалау өчен аның бераз тернәкләнүен көтәләр иде бугай.

Дикопольцев, һушына килеп, туктаусыз кыйнаулардан яргаланган иреннәрен ялап, кутырлап беткән күз кабакларын ачты һәм эсэсовчылар урынына башына кызыл хач төшерелгән ак кыекча бәйләгән, түгәрәк йөзле яшь хатынны күреп гаҗәпләнеп калды.

— Әһ-һә, качкын егет, күзләрең ачылдымы, тагын юл эзлисеңме? — диде хатын, аның янына килеп. Дикопольцев русча сүзләрне ярыйсы ук ватып сындырган бу хатынны башта поляк яки чех кешеседер дип уйлаган иде, соңрак аның Идел буеннан, татар хатыны икәнлеген чамалады.

— Исемең ничек синең, үлем фәрештәсе? — диде ул хәленең кискенлегенә карамыйча шаяртырга тырышып. — Кем син?

— Исемем, бик кирәк булса — Санук минем,— дип җавап кайтарды әлеге хатын. — Ә менә син үзеңнең исемеңне, дөресрәге, фамилияңне беләсеңме икән, качкын егет?..

— Өч ел инде фашистлар минем исемемне, илемнең исемен оныттырырга тырышалар...

— Алайса, онытмадым дисең инде?

— Юк, онытмадым...

— Онытмасаң — бик яхшы, ләкин син хәзер аны онытырга, аңлыйсыңмы, онытырга тиешсең. Син — Вергин! Ишетсен колагың... Хәзер синең аркаңда «флюгпункт» тамгасы юк, киемеңдәге саның да, тәнеңә сукканы да бүтән... — диде ярым пышылдап «үлем фәрештәсе» дип аталган хатын. Янәшәсендә кеше юклыгына ышангач, тагын өстәп куйды: — Бәхетеңә каршы, элеккеге саннар турысын бурзайлар умырып алганнар, яңа сугылганнары Вергин фамилияле кешенеке булыр. Аз гына ныгый башлауга, без сине моннан блокка күчерербез...

— Кем соң ул — без? — диде кемнәрнеңдер кодрәте белән дөньяга яңадан туган Вергин-Дикопольцев. Шул ук мизгелдә үзенең урынсыз сорау биргәнен аңлады, ләкин бу түгәрәк битле, кара-көрән күзле хатын, әйтерсең, әллә кайчаннан таныш, һәм алар инде бер-берсен мең ел буена беләләр иде. Хатын «Вергин»ның соравына каршы кашларын гына сикертеп алды, «телеңне тый, күп белсәң, тиз картаерсың», дигәндәй, бармагын селкеп, янап куйды. Әмма Вергин тыелып калуны кирәк дип санамады бугай, кабат сорады.

«Үлем фәрештәсе» ничәмә-ничә тапкыр лагерьдан качарга батырчылык иткән бу егетнең ышанычлы икәнлеген, әлбәттә, белә иде, шуңадырмы, тагын бер тапкыр кашын сикертеп карады да әйтте:

— Без — Каршылык төркемендәгеләр.

Өч елга якын фашистлар әсирлегендә булган Вергин бу сүзләрнең тикмәгә генә әйтелмәгәнлеген, аны үлем тырнагыннан йолып алучыларның иртәме-соңмы үзләрен белгертәчәкләрен чамалый иде, билгеле...

Шул көннән соң кыйналуларга үзенә күрә бер төсле каршылык алымнарын булдырган яшь тән күзгә күренеп диярлек матурая башлады һәм тагын берничә көннән обход ясаучы әсир-врач аны блокка күчерергә боерды.

Дикопольцев-Вергин Каршылык төркемендәгеләргә кушылу гына түгел, аны житәкләүчеләр арасында да иң өлгергә әверелде, әсирләрнең сугышчан әзерлеген булдыру, листовкалар бастыру, аларны тарату кебек аерата саклык һәм зирәклек таләп иткән вазифаны башкарды. Күпме генә тырышмасын, күпме генә эзләмәсен — беренче күрүендә үзе «үлем фәрештәсе» дип атаган, чынлыкта аңа тормыш бүләк итүчеләрнең берсе булган хатынны эзләп таба алмады, азатлык килгәннән соң да аның кем икәнлеген белмичә калды...

— Санук! Ах, син, «үлем фәрештәсе»! — диде, кулындагы стаканын өстәлгә куя-куя, берләшмә житәкчесе Вергилий Никифорович Дикопольцев, гажәпләнүдән ишек төбендә сыны катып калган хатынга таба атлады. — Санук, кадерлем, сине очратасы көнем дә бар икән бит... бар икән...

Ул өстәл артыннан гәүдәсенең бөтен авырлыгы белән гаять җиңел чыкты, ике арадагы берничә адымны шулай ук җиңел генә атлап узды, аннары кырык елга якын күрмәгән, ләкин беркайчан да бу хатынның үзенә кылган изгелеген онытмаган килеш, яше инде житмешкә якынлашып килүче бу хатынны олы колачын җәеп кочагына алам дигәндә... моңарчы сынатмаган гәүдәне тотып кала алмыйча, үзе белән бергә Санук апаны да ияртеп, стена кырыена тезеп куелган урындыклар өстенә сыгылып төште.

Әлеге очрашуга исләре китеп торган Айбулатов, Сәфәров һәм Зөлфәт Зәйнуллин нәрсә булганын тиз генә төшенеп житкермәделәр. Ничә еллар янәшә яшәп тә, кайчандыр язмышлары кисешеп алган ике кешенең, илдәге иң эре төзелеш берләшмәсе житәкчесе һәм гап-гади авылның участок больницасында няня булып эшләүче татар хатынының шулай очрашуы исләрне китәрерлек иде.

Менә бит ул язмыш дигән нәрсәнең шаярулары! Менә бит ул кеше дигән олы затның тормышы! Бүлмәдәгеләрдән беренче булып Зәйнуллин эшнең нәрсәдә икәнлеген чамалап алды.

— Иптәшләр, иптәшләр,— диде ул,— монда... монда... — һәм кинәт тавышын күтәреп янәшәсендәге житәкчеләренә кычкырып җибәрде. — Нәрсә карап торасыз дим, нәрсә... Ах, сезне... Йөрәк бит бу... Врач, врач чакырырга кирәк,— диде һәм башкалардан узып үзе ике ишекне бәреп тышка атылып чыкты.

Бәхеткә каршы, Көмеш Аланның яңа ачылган медпунктында Ширәмәт больницасының терапевты авырулар кабул итә икән. Биш-алты минут үттеме-юкмы, Зәйнуллин аны, кулыннан житәкләп, ашханә бүлмәсенә алып та керде.

Чынлап та, тормыш дигән серле очраклылык бар, бар икән бит... Санук исемле гади бер татар хатынына гомерендә нибары ике тапкыр очраткан кешене ике тапкырында да үлем тырнагыннан тартып алырга язган булып чыкты. Ул шушы минутларда Вергилий Никифоровичның күлмәген аерып салган да, туктаргамы-туктамаскамы дип икеләнеп типкән яралы йөрәк тибешен туктатмас өчен бөтен осталыгын куеп массаж ясый иде.

Бәхеткә каршы, Ширәмәттән ашыгыч ярдәм машинасы килеп житкәнче, Дикопольцевның ашкын йөрәген туктатмыйча саклый алдылар.

## Сигезенче бүлек

### I

Йокысызлыктан интегеп яткан Гаяр үрелеп кенә баш очындагы торшерны кабызды һәм янәшәсендәге тумбочка өстендә яткан китапның

бөкләп калдырылган битен ачып укый башлады: «...Старик Парацельский святую правду изрек: ин нербус, вербис ет лапибус...»

Туктап калды, аннары әлеге сүзләрнең мәгънәсен эзләп, бит астындагы аңлатмага карады: «в травах, словах и камнях...» — диелгән иде анда.

Барыбер, бу сүзләрнең дә мәгънәсенә төшенеп җитмәде ул. «Нәрсәне аңлата соң бу сүзләр, нәрсәне?» — дип уйлап алды Сәфәров һәм, очына чыга алмагач, китапны яңадан урынына куйды. Кулларын баш астына салып, күзләрен йомып, берничә минут ятып торганнан соң, «ах, шайтан алгыры»,— дип сикереп торды. Идәнгә җәелгән линолеум салкын иде, шуңа күрә үкчәләренә басылтан башмакларын эзләп киде, тәрәзә каршысына килеп басты, үрелеп утны сүндерде.

Күк гөмбәзе астында чүмәлә башы сыман киселгән ай йөзә, ә җир өсте һәм вагон араларындагы мәйданчык яңа гына яуган беренче кар яктысына күмелгән сихри тылсым белән тулган иде.

Аның башына килгән беренче уй тагын төзелеш хәле иде. «Кар төшкән, кар төшкән, димәк, озакламый салкыннар башланыр, ә безнең котельный эшләми, вагоннарны кайдан туры килде шуннан табып алган «кәҗә»ләр һәм тагын әллә нәрсәләр белән җылытабыз. Бу, сизеп торам, бер дә яхшыга түгел»,— диде күңелендәге төзүче аңа ишетелер-ишетелмәс кенә.

«Синнән генә тормый лабаса котельный кору, син бит үзеңә тиешлесен эшләдең, бинаны торгызып куйдың, нигә кыбырсынасың әле син, иптәш Сәфәров?» — дип каршы төште битараф бер уй. «Шулаен шулай, ләкин бит әнә киләләр дә Сәфәров алай итми, Сәфәров болай итми дип, үзәккә үтәләр, әйтерсең, мондагы эшләрне җайга салу бер Сәфәровтан гына тора да әйтерсең, ул эшләргә бер аның гына көче җитә...»

Кичә тагын Айбулатов килеп «мунча» кертеп китте. Хәер, төзелештә андый гына хәлләр булгалый да булгалый, җитмәсә, бу араларда, эшләрнең дә ибе-ябе күренми.

Юк, Көмеш Аландагы төзелештә һәм анда эшләүчеләрдә Чаллыярдагы күтәренкелек, андагы рухи күтәренкелек юк иде әле...

Сәфәров, ялангач басып торудан тәнендә чирканчыклар чыга башлавын тоеп, караватының теге башындагы урындык аркасына ташланган халатын барып алды, яңадан тәрәзә янына килеп, аклыгы белән күзләрне чагылдырган кар өстенә карады.

Анда, яңа яуган кар өстендә, ай камыр изә иде.

Гаяр аңа игътибар итмәде, ләкин күңел күзе шушы табигый гүзәллекне күрә, аңа карап соклана-хозурлана иде.

«Дөрес,— дип дәвам итте ул бая өзелеп калган уенын җебен яңабаштан әләктереп,— дөрес, әгәр дә мәгәр без мондагы төзелештә Чаллыяр рухын булдыра алмасак, әгәр дә мәгәр без төзелештә яшәп тә мондагы эшләребез белән түгел, Чаллыярыбыз белән горурланып яшибез икән, безнең бәябез сукыр бер тиен булачак. Хәзер без инде автогиганттагы эшләр өчен түгел, мондагылар өчен җавап бирәбез. Дөрес әйтә Фазыл Артышевич, анда яшәп, тизрәк анда кайту турында күбрәк уйлап йөрсәк, мондагы эшләребез бармас, билгеле. Моңа чик куярга кирәк...»

Бусы бер. Әмма соңгы бер-ике айда Сәфәров күңелендә тагын бер уй, моңарчы барлыгын белгертмичәрәк йөргән уй кисәгенең коткы тарата башлавын сизә. Баштарак ул аңа, искитәрлек нәрсә түгел, вакыты җиткәч үзеннән-үзе хәл ителер, диебрәк караган иде. Алай булып чыкмады, уй кисәге салган коткы оеткысы әледән-әле әйләнеп килде дә Гаярның төрле уй-мәшәкатьләрдән шыгрым тулы миен бораууларга керешге. Үзе алай дип уйламаса да, бүгенге йокысызлык, һичшиксез, шушы оеткының камырны күпертә башлавыдыр, әлбәттә...

Сәфәровның, Айбулатов авызыннан бугай, ишеткәне бар: имеш, бер тиенлек шәм бөтен Мәскәүне яндырган, ди. Баштагы мәлне уйның да бер кисәге генә булып тоелган бу нәрсә, көнләп түгел, сәгатьнең һәр минуты саен Гаяр күңелен били бара.

Теге вакытта, рухи үзгәрешләр кичереп азапланган бер чакта, Нурлыбикә хыянәт итеп китеп баргач, авариягә юлыгып, больницада яткан Гөлфирә белән аңлаша башлаган көннәрдә Гаяр моннан күп еллар элек күңелендә яралган беренче мәхәббәт хисләренең кайнар килеш сакланганлыгын күрсә дә, ышанып бетмәгән иде әле. Алар бит Чаллыярда бергә эшләделәр, көн саен диярлек бер-берсен күреп йөрделәр. Әмма Гаяр каяндыр килеп чыгып, нәрсәсе беләндер үз йөрәген яулап алган Нурлыбикәгә хыянәт итү, Гөлфирә белән якынаю турында уйлап та карамады. Гөлфирәгә булган хисләре вакыт-вакыт баш күтәрергә чамаласалар да, тымызык күл суына тутык ләм утырган сыман, аларны еллар ләме басып ятар, картлар әйтмешли, бер узып киткән болытны куып тотып булмас, дип уйлый иде Гаяр.

Гөлфирәнең больницадан чыгып, Көмеш Аланга кайтуына да өч атналап вакыт узды бугай инде. Әмма Гаяр, төзелештәге мең дә бер төрле мәшәкатьләр белән булашып, әллә болар сәбәп кенәме, аның янына бер-ике тапкыр кереп чыгу һәм тагын бер-ике тапкыр вагон эргәсенә кояшта җылынырга чыгып утырган Гөлфирә белән күп булса биш-ун минут сөйләшеп торудан узмады.

Гаяр томанлы, үзенә дә аңлашылып бетмәгән уйларын ачыклый алмыйча, ниндидер сәер бер көчкә буйсынып йөрде. Күрәсең, һәр нәрсәнең үз сәгате булган кебек, бу очракта да борынгыларның: гомер түгелдер күпер, чыгып китәргә генә түгел, төрлесен уйлыйсың да төрлесен күрәсең, дигән сүзләренең никадәр сынауларда сыналган икәнлеген раслау булгандыр.

Чынлап та, яшьлегендәгечә ярата идеме соң Гаяр хыялында озак еллар кадерләп саклаган Гөлфирәне?

Хыялында... хыялында идеаль сурәт булып йөргән Гөлфирәне ярата, ничек кенә ярата иде Гаяр. Ләкин хыялда сакланган Гөлфирә — бер, ә чынбарлыктагысы үзгәрәк булуы да бик ихтимал бит...

Беренче сөйләшү-аңлашудан соң Гаяр яшьлек мәхәббәтенең сүрелмәгәнлегенә ышанган сыман иде. Ул үзен, югалып калган мәхәббәтен табу бәхетенә ирешкән сирәк кешегә санап, Гөлфирә белән күрешү, икәүдән-икәү генә калачак минутларны көтеп яшәде. Ул мәхәббәт аңа төзелештәге кыенлыкларны җиңелрәк кичәргә, элек үзе башкара алмастай эшләрне җиренә җиткереп башкарырга җилкендереп торды. Сәфәровның нинди күтәренкелек кичереп, нинди хыял канатларында йөзгәнен үзе генә түгел, башкалар, төзелештәгеләр, хәтта Айбулатов та күреп торды. Шуңа күрә ул кичәге «мунча»дан соң:

— Молодец, әйбәт кыз синең Карлыгачың, әти-әни янымда юк, дип бер дә боегып калмады, менә дигән иттереп укый. Быел көзне мәктәпкә очрашуга чакырганнар иде, алар классы булып чыкты. Йолдызбану апасы: «Болай барса, безнең Сәфәрова алтын медальне ала да ала»,— дип сөйләп китте. Таңсылу белән ике бертуган сеңел шикелле йөриләр,— дип өстәп тә куйды.

Шундук Сәфәровның дәшмичә көтеп утыруын яратып бетермичә бугай:

— Соң син бит, Гаяр, шәхси тормышыңны да җайга салырга тиешсең инде. Мөстәкыйль төзү-монтаж идарәсенең җитәкчесен раслаганда, минемчә, аның гаилә хәлләрен дә исәпкә алмыйча калмабыз. Син моңа ничегрәк карыйсың?

— Мин ничек карыйм ди, Фазыл Артышевич, уңай карыйм. Ләкин шәхси тормышны җайга салу миннән генә тормый бит ул. Сезгә соң примерный ир кирәкме, әллә төзүчеләр җитәкчесеме? — Гаярның сүзләрендә бераз ачыну, үпкә һәм канәгатьсезлек бар иде.

Айбулатов, гадәтенчә, күзләрен кысып, кашларын җыерыбрак дәвам итте:

— Беләсеңме, Гаяр, моннан шактый еллар элек мин апагыз Йолдызбану туташны алып кайттым. «Менә шушы минуттан син, Йолдызбану

туташ. Айбулатов дигән кешенең хатыны буласың инде. Шулай булгач, без болай сөйләшик — син миңа аз да түгел, күп тә түгел, төп-төгәл ун малай тап»,— дидем. Ул вакытта миңа егерме тугыз, ә аңа... нибары унтугыз яшь иде. Кешегә нинди дә булса бер шөгыль кирәк бит, югыйсә өйдә утыра-утыра ук кешенең миендәге шариклары урыннарын алмаша башларга мөмкин. Өстәвенә, мин көне-төне диярлек эштә, ә Йолдызбану декрет дигәннәренә чыгарга чамалап йөри.

Фазыл Артышевич ул чаклардагы халәтен искә төшереп булса кирәк, күзләрен йомып-йомып алды, көрсенеп куйды һәм башлаган сүзен дәвам итеп китте.

— Яңа кеше дөньяга килдеме, хатын-кыз заты сәгатьләп матурлана, чәчәк атарга керешә. Тормыш тагын үзенекен итә башлый. Шулай булып чыкты да. Йолдызбану апагыз өйдә утыра-утыра төрле уйлар уйлый башлаган — көнләшергә керешкән. Я тегенең белән күргәннәр, я мин моның белән фәлән җиргә барганмын. Җитмәсә, күршеләрнең дә менә дигәннәренә тап булдык, «аһ» дигәнче төймөне дөя итеп куя белә күрше хатыны. Ә инде анда киткәч, утыз теш арасыннан бер чыктымы, күр дә тор,утыз кешегә дә җитә ул.Аннары инде беләсең, көнләшү башлана, ә көнләшүнең төчесе аның, парин, теләсә нинди нәрсәне үтәли үтеп чыга да китә. Шулай, ул арада икенче малайны да «шалт» алды да кайтты Йолдызбану апагыз...

Гаяр янына монтажчылар бригадиры килеп басты. «Тагын ярым җимерек санузел китергәннәр. Нишләтергә?» дип сорады, аннары Айбулатов та ишетерлек итеп, фикерен әйтте:

— Үзләренә ярамаганны монда озаталар, без алардан йорт төзергә тиеш, күрәсең?!

Сәфәров кабул итмәскә, кире җибәрергә кушты.

Айбулатов әлеге сөйләшүгә илтифат итмәгәнгә салынды, тагын сүзен дәвам итте:

...— Йолдызбану апаңа, икенче малайның тууы гына кирәк булган икән, беркөнне бу миңа: «Туктыйсыңмы шул хатын-кызларга күзеңне ялтыратуларыңнан»,— дип куймасынмы! Юк, мин әйтәм, карчык, андый хәлләрнең булганы юк, дим. Кая ул? Очына апагыз, тагын нәрсәдер әйткән иде, түзем тезгенем ычкынды да китте. Йолдызбануның иңбашына үз кулым белән чәпелдәттем дә җибәрдем. Янәсе: чыбыкны вакытында бөгәм, хатынны көнләшмәслек итәм. Шул гына җитмичә торган икән. Мин анымоны уйлап өлгергәнче, хатыным ике малайны ике култык астына кыстырды да — син күр дә мин күр, юк булды. Ярый, мин әйтәм, мин ир кеше — горур булырга тиеш, бармыйча карыйм әле. Бер көн түздем, ике көн... бер атна булды, әмма күренми минем хатын да, тыпырдашып торган малайларым да... Нишләмәк кирәк, тегеләй иттем, болай иттем дә, үзем гаепле бит, төн уртасында тегеләргә барып та кердем. Хурланып үләрсең: «Кем кирәк сезгә, абый?» — дигән була тагы. Мин дә бик аптырап тормадым, чөнки бабайның минем якта икәнлеген беләм: килеп керүгә теге күз кысып алды, янәсе, корырак тот. Ике малайны аның үзе шикелле үк ике култыгыма алып кыстырдым да: «Кайтасы булсаң, чыгып утыр машинага, бүген кайтмасаң, иртәгә эзең дә булмасын»,— дип чыгып киттем ишегалдына. Апагызны әйтәм, өстенә кием кияргә онытып, эчке күлмәк-халаттан килеш атылып чыкты... Нәтиҗәсеме? Нәтиҗәсе көтелмәгәнрәк булып чыкты бу хәлнең, шуннан соң ул түгел, мин чыбык булып чыктым; тәки акрынлап бөгә башлады бит апагыз... «Мин сиңа хәзерге заманда ун малай табарга фәлән түгел»,— диде дә больниска китәргә җыена башлады. Көч-хәл белән, зинһарлап кына саклап калдым өченче малайны. Менә шундыйрак эшләр, дускай...

Айбулатов үзе сөйләгәндә Сәфәровның түземсезләнеп, бөтен хәрәкәте белән эшенең муеннан икәнлеген сиздерергә тырышып утырганын күрде, ләкин барыбер сөйләде, әйтәсе килгәнне әйтеп бетерде. Бетергәч тә бераз дәшмичә ак-кара шакмаклы кепкасын әйләндергәләп утырды да:

— Шулай, Гаяр, син — минем хәлдәге кеше түгел, яшь балаларың хатыныңның ышанычсыз итәгенә ябышып китмәде. Минемчә, аның тагын кайтып куенга керерлеге дә юк. Димәк, форсатың китсә дә, сырпатың китмәсен дисәң, үз җаеңны үзең кара... Минем бабай әйтмешли, аерылган куч я агачка, я җиргә, я умарта әйләнәләренә сарырга тиеш бит ул... Гөлфирәме анда, бүтән берәр күңеленә охшаганымы — ал да кайт һәм син — яшь кеше әле — хатыныңа кимендә ике-өч малай табарга куш. Балалы өйне базар дисәләр дә, баласызы — кабер дигәне дә бар бит әле,— диде, әңгәмәсенең беткәнлеген белгертеп, урыныннан торды. — Ә санузеллар өчен борчылма, бусы — соңгысы булыр, чарасын күрермен.

Әйе, һәр нәрсәнең бер чиге, үз вакыты була. Әйтик, озак вакытлар сыкранып яткан авыру кеше көннәрнең берендә, бүгенгедәй матур тәүге кар күбәләкләре сыман йокысыннан уянып китә һәм үзен ип-исән кеше итеп тоя, урыныннан торып тормыш кочагына ташлана.

Хәзер дә шулайрак килеп чыкты.

Вагон тәрәзәсеннән ак мамыкка төренгән мәйданга карап уйга батып торучы Гаяр кичәгенәк Фазыл Артышевич сөйләгәннәрне хәтереннән уздырырга өлгермәде, төзелештәге мәшәкатьләр каядыр арткарак чигенделәр, ул кайчаннан бирле хәл итә алмыйча йөргән нәрсәне — Гөлфирә белән мөнәсәбәтләренең дәвамын ап-ачык күрде.

— Яратам мин сине, Гөлфирә,— дип сөйләнә-сөйләнә, халатын салып, урын өстенә атты, ашыгып-кабаланып киенде һәм ишеккә ташланды.

Тагын бер мизгелдән ул инде төнлә яуган беренче кар өстенә яңа эз салып, ике вагон арасындагы бушлыкны кыл урталай ярып үтте дә Гөлфирә ишегенә шакый башлады.

## 2

Дикопольцев үз-үзен белә башлаганнан бирле беренче тапкыр иң тыныч, мәшәкатьсез көннәр кичерә, ни кылырга белмичә аптырап тик ята. Аның ярым ачык, ярым ябык күзләре генә элеккеге зирәклеген саклый һәм, шуңа күрә кергән-чыкканны барлап кирәген-кирәкмәсен күреп кала иде. Сирәгәйгән, аксылланып йомшарган чәчләре тигез рәтләргә сузылганнар, өстендәге ак күлмәге биредә ята башлаганнан соң кәгазь төсенә кергән йөзенә тагын да ныграк аклык иңдереп тора. Хәлсезләнгән зур-зур йодрыклары: «Бу нинди хәл соң әле, без нишләп болай тәгәрәшәбез?» — дигән шикелле ак җәймә өстендә ята, бары тик бармаклар гына әллә нигә бер тапкыр, ирексездән булса кирәк, сизелер-сизелмәс селкенгәләп куя. Кара зәңгәрсуланган иреннәре тыгыз кысылып калганнар иде.

Дөрес, хәзер инде озак еллар буена алны-ялны белмичә, искиткеч киеренкелек белән типкән йөрәк теге көнне Көмеш Аландагыча «тук... тый-ыйм, тук... тый-ыйм», дип теләр-теләмәс кенә түгел, ясалма җайланмалардан башка да мәһабәт гәүдәне яшәтерлек эшли. Ләкин үлем белән якага-яка килеп тарткалашканда алынган җәрәхәтле йөрәкнең сизгер мускуллары элеккегедәй көчле тибә алмый иде әле. Шундый тетрәнү кичерүенә карамастан, Вергилий Никифоровичның мие ярыйсы гына эшли, теге якта — тормыш эчендә калган нәрсәләрне уйлап анализлый, үзенә ни булганлыкны аңларга, киләчәкне күзалларга сәләтен югалтмыйча саклый иде. Бу — врачлар һәм шәфкать туташлары, хезмәттәшләре һәм якыннарының тыю-чикләүләренә бирешми торган бердәнбер мөмкинлек булганга, Вергилий Никифоровичның аңы шактый ук актив тормышны дәвам итә.

Узган атнада шундый сәгатьләр булды ки, төнге дежурда торучы тәҗрибәле врачның да легендар Бабакайның тибәр-типмәс йөрәген яшәү ритмына чыгарганчы маңгаена бөрчек-бөрчек тир бөртекләре чыкты, хәтта күңеленең кайсыдыр бер җирендә: «Бетте!» дигән хыянәтчел уй ярала башлады.

Шушы кискен минутларның берсендә:

— Син кабаланма, агай-эне, үз эшеңне эшлә... туктап ял итеп алмакчы буладыр ул,— диде Вергилий Никифорович йөрәгенә туктаусыз массаж ясаучы врачны сискәндереп. — Каушамагыз... аның бөтенләйгә туктар вакыты җитмәгән әле...

— Ә сез аны каян беләсез? — диде үзен кулга алып өлгергән, Дикопольцевның кискен минутта да ихтыяр көчен югалтмавына сокланган врач, шундый ук шаян тонга күчеп: — Хәзер үк туктагыз, Вергилий Никифорович, сөйләшүегездән. Монда сез түгел, мин берләшмә начальнигы, беләсегез килсә, мин...

Дикопольцев тагын нидер әйтмәкче иде, әмма авыртуның чираттагы дулкыны күкрәк астын чәнечте...

Чаллыярның нарат урманына сыенып утырган больницасы турына күзгә күкнең сирәк болытлары арасыннан ялгыз бер йолдыз үз артыннан якты эз калдырып атылып төште.

Димәк, картлар әйтмешли, кайдадыр еракта, җир шарының кайсыдыр материгында кемнеңдер гомере өзелде, йөрәге тибүдән туктады.

Бәхеткә каршы, бу Вергилий Дикопольцев йолдызы түгел иде әле.

Төннең калган сәгатьләрендә йөрәк кешене борчымады, яшәү өчен кирәкле көчне мыскаллап тупларга, үзенең яшерен сандыгына тутырырга кирәк иде.

Ул арада җирнең игелекле улы Вергилий Дикопольцев үзеннән соң яшәүчеләргә — егерме беренче гасыр кешеләренә дип төн йокылары һәм ару-талу, киеренкелек белән хисаплашмыйча, баштарак хыялында, аннары чынбарлыкта торгызышкан ак кала — Чаллыяр урамнарына быелгы кышның беренче хәбәрчесе булып төймә-төймә карлар яуды, ак юрган булып ябылды.

## 3

Көз белән кыш кушылган, күбәләк-күбәләк кар яуган минутларда шәһәр янындагы аэропортның бетон тасмасына турылап көмеш канатлы ТУ-154 лайнеры төшеп килә, аның белән бергә иркен һәм җылы салонның берсендә йомшак креслога сеңеп, биленә ышанычлы нык тасма тарткан, шуңа карамастан, ике куллап кресло тоткасына чытырдап ябышкан Нурлыбикә үзе ташлап киткән ак калага якынлаша иде.

Чынлап та, «Төкермә коега — суын эчәрсең»,— дип картлар бер дә юкка гына сөйләмәгән икән бит.

Җиңел, матур, бәхетле тормыш эзләп киткән Нурлыбикә дә әкияттәге комсыз карчык кебек ярык тагарак янында утырып калды түгелме соң?

Кызганычка каршы, бернәчә ай элек үзен фәрештәдән кимгә санамаган Нурлыбикә, бу юлы да борынгыдан калган хакыйкатьне аңлап түгел, бәлки торыр урыны, таяныр кешесе калмаганга гына «ире һәм кызы» янына байтак вакыт йөзеп йөргән бушлыгыннан төшеп килә иде.

Бушлык... Кеше күңелендәге бушлык гомернең кайсы минутларында, ничәнче адымында башлана да кайсы чиккә кадәр дәвам итә икән? Һәм нәрсә белән тәгәлләнә соң? Бәлки, аны төп-төгәл белүче, ачыклаучы кеше бардыр? Бәлки, аны беркайчан да ачыклап булмыйдыр? Бәлки, аны бары тик шуңа дучар булган кеше генә белә торгандыр? Җир йөзендәге кешеләр, милләтләр һәм илләр арасындагы бушлыкны, шушы бушлык китергән фаҗигаларны нинди үлчәүләргә салып үлчәп була һәм аны нинди киртәләр куеп туктатырга мөмкин соң?

Нурлыбикәнең «эзләп тапкан бәхетем» дип атаган Эдигы гап-гади бер алып-сатар булып, аны тиешле җиргә ябып куйганнан соң, аннары гадел хөкем әһелләре каршында утырганда үзе тап булган бушлыктан ничегрәк чыгу турында аз уйланмады ул. Тикшерү, аннары суд ярыйсы гына озакка сузылды. Ә Нурлыбикә Атнабаеваны шаһит буларак тоткарладылар.

Анардан Эдик язмышы өчен ни он суы, ни тоз суы өмет итәргә туры килмәде. Нурлыбикә тикшерү вакытында һәм бигрәк тә суд барган көннәрдә ишеткәннәр уйлана белгән кешегә нәтиҗә чыгарырлык иде. Дөрес, Эдикның ничәмә-ничә мең табыш ясавы, кемне, кайда һәм ничек алдавы Нурлыбикәнең исен әллә ни китәрмәде. Барыбер аның мүкләнгән йөрәгенә дә сугарлык нәрсәләр байтак булды.

Иң ачысы — суд залында, Нурлыбикә янәшәсендәге урыннарның җидесендә Эдикның төрле шәһәрләрдән килгән, һәркайсы үзен генә бердәнбер дип санаган җиде «хатыны» утыра иде... Һәм аның иң кызыгы — бәлки, кызганычыдыр — шунда иде ки, ул хатыннар барысы да җиңел генә бәхетле булырга теләгән булып чыкты.

Нурлыбикә утырышлар арасындагы бер тәнәфестә шуларның берсе — Уралдан килгәне, Лариса исемлесе белән танышты, хәтта әллә ни көндәшлек хисе тоймыйча, урамда күрешкән берәү кебек күреп сөйләшеп тә китте.

Никадәр уртаклык, никадәр бертөрлелек иде аларның моңарчы узган тормышында!

Нурлыбикә дә, Лариса да әйбәт кенә эшләп яши торган кешегә тормышка чыкканнар, икесе дә башта «яратып» яшәгән һәм тора-бара «яратмый» башлаганнар. Дөресрәге, тамаклары туеп, өсләре бөтенәйгән саен, бердәнбер балалары үсә барган саен, аларның мәшәкатьләре кимегән. Икесе дә «ирне карау» сылтавы белән эштән чыгып киткәннәр, Нурлыбикәне — тозүче, Ларисаны тегүчелек һөнәре кимсеткән. Ниһаять җиңел генә матур киенергә, «бәхетле» яшәргә уйлаганнар һәм шушы юлдан атлаганда икесе дә Эдикның тозагына килеп капканнар.

— Мин аның аны-моны таба белгәнен чамалый идем, ләкин шуның тиклем ата «эспикулат» (Лариса «спекулянт» сүзен шулай «дөрес» итеп әйтте) икәнлеген каян белим, Бикә җаным, каян белим? — дип чәбәләнде Лариса һәм, һич көтмәгәндә: - Менә хәзер ул эспикулаттан яралган малайны нишләтергә инде?.. — дип куйды.

Шунда гына Нурлыбикә үзенең ярыйсы гына җиңел котылуын, Эдикка ияреп чыгып китәр алдыннан гына таныш врач ярдәмендә өч көнгә больницага кереп чыгуын искә төшереп көлеп үк җибәрде.

Лариса аның көлүен ошатмады бугай.

— Нәрсә, авызыңны ерасың, Бикә җаным,— диде Нурлыбикәне гомер буе белгән кешесе кебек үз итеп. — Син үзең дә бит әле әнә кайларга кадәр тагылып киткәнсең. Кешедән көләрлегең юк, житмәсә, минеке ише инструкторлыктан башы чыкмаган ирне түгел, умырып-умырып акча алган данлыклы кешене тишек чабата кидереп калдыргансың...

Нурлыбикә бу юлы инде Ларисаның авызын томаларлык сүзләр әйтермен дигән иде, өлгерә алмый калды — тәнәфес беткәнлекне белдереп, кыңгырау шалтырарга кереште. Һәм алар, ике көндәш, суд залына кереп, җилкәне җилкәгә терәп янәшә утырдылар...

Куәтле лайнер салмак кына җиргә якынайды да бетон тасма өстеннән беравык йөгергәннән соң моторларын үкертеп алды һәм аэровокзал бинасының каршысына ук килеп, туктап калды.

Якынлашып килүче трап-баскычны түгәрәк тәрәзәдән карап торган Нурлыбикә ирексездән: «Чыгаргамы-юкмы? (Әйтерсең, салоныннан чыкмыйча калырга мөмкин?). Чыксам, туры кая барасы да кемгә керәсе?» — дип уйлап, борчылып алды. Әмма бу уй аны биләп өлгермәде, пассажирлар арасында ыгы-зыгы башланды, барысы берьюлы диярлек киштәләрдәге киемнәрен алып киенергә керештеләр. Нурлыбикә дә ирексездән ыгы-зыгыга кушылды.

Домодедово аэропортында томан булу сәбәпле, самолет алты сәгатькә кичегеп очкан иде, шуңа күрә бирегә төнге өчләр тирәсендә генә килеп төште. Чаллыяр белән ике арада йөрүче автобусларның ял вакыты булган-

га, шәһәргә кайтуы кыенлашты. Дөрес, мәйданда берничә такси һәм тагын биш-алты «Жигули» басып тора иде торуын, әмма Нурлыбикәнең аларга биш бәя түләп кайтасы килмәде. Аннары, аннары бит ул кемгә кайтып керәсен дә хәл итмәгән иде.

— Ярый, бик җайлы булып чыкты бит бу, ике ярым сәгатьне аэровокзалда гына уздырырмын, иртә-кичтән хәерлерәк, ди иде бит әнкәй,— диде, ниһаять, Нурлыбикә, сүзләрен теш арасыннан сыгып. Аннары чемоданын күтәп алды да, каршылаучылар арасында танышлар очрамасын тагы дигән уйдан шомлана төшеп, (соңгы елда беренче мәртәбә кеше күзенә күренергә оялуы иде бу) аэровокзалга кереп китәргә ашыкты. Анда кергәч тә киң баскычтан икенче катка менде, иң арттагы креслоларның берсенә барып, вокзал алды мәйданына таба карап утырды.

«Чынлап та, нәрсәгә дип кенә кайттым соң әле мин бу Чаллыяр дигән нәрсәгә? Нәрсә калган соң монда миңа? — дип башлады Нурлыбикә күңелендә хәзерге хәлне анализлаучы фикер. — Нәрсә генә тартып китерде соң мине бу җиргә? Нәрсә дип кайттым соң мин бер киткән җиргә? Хәзер монда миннән күләчәкләр генә. Юк инде, минем бу җирдә ничә ел бергә яшәгән ирем, кызым бар. Мине алар тартып кайтаргандыр. Мин алар янына... Я аллам, нәрсә дип болай бимазаланам соң әле мин? Кайтам да керәм үземнең квартирама. Мөгаен, Гаяр үзенең Көмеш Аланындадыр әле...»

Шул чагында гына Нурлыбикә киткәндә үзе белән алган квартира ачкычының Эдик дачасында онытылып калуын исенә төшерде, искәртмәстән сыкранып куйды. «Менә бит юләр, юләр дисәң дә юләр»,— дип битәрләде үзен-үзе һәм, кискен бер карарга килгән шикелле, утырган җиреннән сикереп торды, идәннән түшәмгәчә сузылган тәрәзә пыяласына борынын төртеп, мәйданга килеп туктаган «Жигули»га карап тора башлады.

Кайтырга, хәзер үк кайтырга да өйгә кереп утырырга. Ачкыч булмаса, ишекне ватып керергә һәм аннан чыкмаска! Алай гына түгел, ирем минем яныма кайтмый дип иртәгә үк Айбулатовка, ахыр чиге Дикопольцев янына керергә. Үземнең хокукларымны югалтмаска. Квартирамны Казангамы, я булмаса бүтән берәр калага алмаштырырга ахыр чиге. Кызымны да үземә карата алсаммы — алсаммы! Мин вакытлыча гына Башкортстандагы апаларга барып яшәдем, дияргә. Аларның мине урамга чыгарып ташларга хаклары юк, юк, юк! — дигән уйлар өермәсе миеннән үрмә җилдәй узып китәр-китмәс борын чемоданын эләктерде һәм йөгерә-йөгерә машина янына ашыкты.

Җилгер машинага кызулыктан ничек кереп утырганын һәм «Күпме алсагыз да алыгыз, тик мине Чаллыярга кайтарыгыз гына» дип әйткәнен соңыннан, ак каланың күккә ашкан стелласы күренгәч кенә исенә төшерде Нурлыбикә.

Ә җилдән җитез «Жигули», кемне алып кайтуына битараф булып, оча да оча гына иде.

Ул арада шәһәргә барып та керделәр. Нурлыбикә уң яктагы биек-биек йортларга карады һәм тиктомалдан йөрәгенең чәнчеп-чәнчеп алуын тойды. Шул ук мизгелдә аның күз алдыннан үзе һөнәргә өйрәнгән техник училищеның яңа бинасы, аннары үзләре салышкан биек-биек йортлар күренеп-күренеп калды.

«Әйе, әйе, хәзер бу машинаны туктатып, яисә борылып килеп артта калган биналарны яңабаштан карап чыгарга мөмкин... Ә кешенең узган гомерен, кылган эшләрен дә шулай яңадан әйләнеп килеп карап булса иде,— дип уйлап алды Нурлыбикә, баягы кискенлек, кыюлыкның каядыр китеп югала башлавын сиземләп. — Хәер, кеше гомер юлын хәтер йомгагыдай сүтеп карый ала. Тик аны кире кайтара гына алмый».

— Сезгә, апа кеше, кай төшкәрәк кирәк соң? — диде моңарчы бер сүз әйтмичә, утырган урынының биек аркасына башын терәгән шофер беркадәр Нурлыбикә ягына таба борылыбрак.

Нурлыбикәгә аның үз-үзен тотышы, бигрәк тә сөйләшүе ничектер таныш, бик таныш кебек иде. Ләкин ун елдан артык шунда яшәгәч, таныштыр да бәлкем, кем белсен, дип, шоферга игътибар итмәде ул.

— Син мине, матурым, әнә ул урамнан кертеп, кунакханәнең теге очында төшер инде, яме,— диде дә бәләкәй сумкасын ачып, соңгы акчаларын барларга кереште. — Күпме бирим соң сиңа, матурым?..

— Барлык акчаң шушы гына калган булса, Нурлыбикә апа, барыбер җитмәс түләргә, әзләп азапланма да. Мин сине бушлай гына кайтардым, тиз генә төш тә, мин китим инде, каршылыйсы кешем бар иде,— диде шофер ярыйсы гына тупас итеп.

Нурлыбикә аны бу юлы «Нурлыбикә апа» дип әйтә башлаганда ук таныды.

— Бәрәч, Зөлфәт... Син түгелме соң?..

— Мин инде, мин, Нурлыбикә апа, бик тиз танымый башлагансың син бергә-бергә эшләгән кешеләрне. Артык зур үсеп киткәнсең бугай...— Бераз дәшми торгач, тагын өстәп куйды: — Йомыш белән киләсеңме соң, Нурлыбикә апа, берәр кешене күрергәме әллә, дип әйтүем...

Нурлыбикә аның бу сүзләрендә ниндидер төртке ятуын чамалап алды, сиздермәскә тырышты, ләкин, Чаллыярга кайту максатын үзе дә белмәгәнгә, тиз генә җавап бирә алмады, сөрлегеп калды.

— Нәрсәкәй, Чаллыяр бер синең өчен генә түгелдер лә... — дигән булды. — Чаллыярга, Зөлфәт энекәш, бик беләсең килсә, килмим мин, ә үзем салышкан калага кайтам... Кай-та-м,— дип, соңгы сүзне сузып, иҗекләргә бүлә-бүлә әйтте. — Я, әйтсәң әйт тә туктат бу нәмәрсәкәеңне менә бу турыда...

— Миңа калса, Нурлыбикә апа җаным, синең бу турыдан йөри торган сукмагың өзелгән инде. Юкка гына киләсең син монда... Әйтте Зөлфәт диярсең менә...

Һәм ул, онытылып китеп машинасының тормозына басты. Яңа яуган кар өстен шомартып, моңа кадәр дә берничә машина узган булган, шуңадыр, мөгаен, «Жигули» бер янга шуып китеп, йөз сиксән градуска борылыш ясады, килгән ягына таба карап басты. Арттагы креслода утыручы Нурлыбикә кискен борылыштан бер якка таба ауды һәм башы белән тәрәзә пыяласына бәрелде. Калын пыяла, вакыты җиткән булган, күрәсең, чәлпәрәмә килеп, уалып китте. Ниһаять, машинаның бер урында басып торуын, әйләнеп капланмавын, үзләренең исән-имин икәнлеген аңлагач кына Нурлыбикә яңадан элеккеге хәленә кайтып утырды.

— Машина йөртергә хәлеңнән килмәгәч, кеше утыртып чыкмыйлар аны... Үтерә яздың бит кешене.

Сүнгән машинасын яңадан кабызырга дип ачкычны капшап әзләгән Зөлфәт аңа каршы: «Син кешемени соң, син...» — дип, бик әшәке итеп әйтмәкче булган иде, әмма вакытында тыелып өлгерде, дәшмәде. Нурлыбикәнең ишекне ачып төшкәнен, аннары үрелеп чемоданын алганын көтеп торды да машинасын урыныннан ук ямьсез уылдата-уылдата килгән якка китеп югалды.

Ак мамыкка охшаган кар бөртекләре җиргә төшәргә ашыкмыйча гына очалар, алар да, әйтерсең, Нурлыбикәнең ояты качкан йөзенә бәрелүдән, күз-керфекләренә кунудан куркалар иде.

Хәер, бу вакытта Нурлыбикә аларның ни уйлаганын белми, белсә дә әллә ни исе китеп, шуңа күрә берничә ай элек үзе ташлап, бар булган җиһазларын машинага төяп чыгып киткән йорттагы куышына, үзләре яшәгән квартирага таба атлый иде инде.

## 4

Көмеш Аланның канкойгыч сугышларда барлык хәбәрләрне дә беренче булып кычкыру хокукын яулап алган карт этәче йокысыннан уянып

канатларын кагып алды да, гадәттәгечә, гасырлар аша кичкәндә язмышның бик күп төрле сынауларын узган авыл өстенә «Кик-ррррри-күк! — дип, күкрәк киереп, таң хәбәре салды.

Аның артыннан ук таң алды эңгер-меңгерен калтыратып, күк биеклегендәге салкынлыкны ярып, өлгер самолет очып үтте.

Әлеге тавышлардан булса кирәк, йокысыннан вакытсыз иртә уянган Гөлфирә, ишек шакыганнарын чамалап, бүлмәсендә ут кабызып тормыйча гына тәрәзә янына килеп басты.

Тыштагы гаҗәеп аклык, күзләрне чагылдыргангадырмы, берәүне дә күрмәде ул. Ишекне кабат шакыдылар.

Гөлфирә ачып куелган бәләкәй форточкага табарак үрелеп:

— Кем бар анда? Нәрсә кирәк сезгә? — дип сорады.

Җавап урыңына тышкы яктан яңа яуган карның шыгырдаганы ишетелде. Гөлфирә пәрдәне томалый төште, ләкин сызык кына ачык калдырып күзәтүен дәвам итте. Вагон болдыры ягыннан башта кемнеңдер тамак кырганы ишетелде, аннары шәүләсе күренде, шуннан соң гына:

— Мин бу, Гөлфирә, мин — Гаяр! — дигәне аңлашылды.

Бөтен тәненең эчке калтыравын кичерә башлаган Гөлфирә каушап калды, кулында таяк барлыгын онытып, халатын алырга үрелде. Таяк шапылдап идәнгә төште. Өстәвенә әлегә кадәр тигез генә тибеп торган йөрәге дә күкрәк авызын ярып чыгардай булып «дөпе-дөпе» бәргәләнергә кереште.

— Гаяр! — дип пышылдады Гөлфирә. — Гаяр...

Җирдәге ике рәт кирпечкә утыртылган вагонның форточкасына якын ук килеп баскан Гаяр да ярты тавыш белән генә:

— Керт әле, Гөлфирә, сиңа сүзем, әйтер сүзем бар,— диде.

Гөлфирә ирексездән:

— Хәзер, хәзер, Гаяр... — дип, ишеккә таба килде.

Гаярның борынына бүлмәдәге җылы һавага кушылган сирень чәчәге исе килеп бәрелде кебек. Аннары гына Гаяр шушы таныш хуш исне чынбарлыкта булганга түгел, ә күңеленә сеңеп сакланганга күрә тоюын аңлады. Ул арада инде Гөлфирәгә кадәр булган соңгы адым ясалган иде. Аның көчле, нык куллары Гөлфирәне гаять җиңеллек белән күтәреп алдылар, салкын иреннәре пышылдап:

— Җитте, ур... урлыйм мин сине, Гөлфирә, саклан! — диде.

Бу сүзләрнең мәгънәсенә игътибар бирергә өлгермәгән Гөлфирә ишетелер-ишетелмәс әйтеп куйды:

— Урла соң... хәзер үкме?

— Әйе, хәзер үк, Гөлфирә, хәзер үк... — Һәм Гөлфирәне күтәргән килеш тар коридордан артка таба чигенеп, аркасын ишеккә терәде, төртеп җибәрде.

Гөлфирә әле аны шаяра дип уйлый иде, тыштагы яңа аклыктан күзләрен чытырдатып йомды. Көчле, ышанычлы кулларны тою шундый рәхәт, гаҗәеп бәхет иде.

Борынгы авыл читәненә тотынып диярлек салына башлаган яңа шәһәрдәге беренче йортның абзар куначасында утырган баш әтәч үзенең чиста, көр тавышы белән яңа туган бәхетне котлагандай: «Кикриииикүүүүүүк!» ләп салют биреп куйды.

Төзүчеләр шәһәрчегендәге вагоннарда бер-бер артлы утлар кабына башлады.

Гаяр Гөлфирәне үзенең караватына, җыелмаган урын өстенә алып кереп утыртты.

— Я, ни эшләвең инде бу, Гаяр? Күреп калсалар... Кеше нәрсә әйтер?

Тәнендәге эчке калтырауны тыя алмаган Гөлфирәнең тавышы калтырап-калтырап чыга иде.

— Соң бит үзең «урла» дидең, ризалык бирдең.

— Шашкан... Мин шаярдым гына лабаса...

— Икенче тапкыр ничек шаярырга белерсең.

— Хәзер үк бу юләр хатынны алган урыныңа кертеп куй,— диде Гөлфирә ике кулын картлар дога кылгандагы кебек күкрәк турысында тоткан килеш. — Югыйсә...

Югыйсә, нәрсә буласын Гөлфирә үзе дә белми иде.

— Юк инде, Гөлфирә иптәш... Хәзер син бу вагоннан бары тик Көмеш Аландагы беренче торак йорт төзелеп беткәч, Сәфәров исеменә бирелгән квартирага гына чыгасың... Син яшәгән вагонга бүген үк буяучы кызларны кертәбез.

— Иптәш Сәфәров, хатын-кыз урлаган өчен, беләсезме, кимендә ун елга ирегегездән мәхрүм ителәчәксез... Икенчедән — хезмәт вазифаларыгыздан явыз ният белән файдаланасыз, кул астыгыздагы кешене ирексезлисез...

— О, хөрмәтле хөкем иляре! Гөлфирә исемле бу хатынны урлаган өчен мине ун елга түгел, гомеремнең соңгы минутларына кадәр ирегемнән мәхрүм итүегезне үтенеп сорыйм,— диде Гаяр, караватта утырган Гөлфирә каршына идәнгә тезләнгән килеш ике кулын берьюлы түшәмгә таба сузып. — О, хөрмәтле хөкем ия... ия...ләре...

Күзләрен тутырып идәнгә тезләнгән Гаярга карап торган Гөлфирә түзмәде, утырган җиреннән үрелеп түшәмгә таба сузылган куллардан тотып алды, үзенә таба тартып китерде һәм уттай янган бит алмаларын эштә чыныгып кытыршыланган кушучына яшереп, сулкылдап-сулкылдап елый башлады.

Берничә минут Гаяр шушы хәлдә, шатланырга яки кайгырырга белмәгән кеше кебек хәрәкәтсез калып, Гөлфирәнең төнлә чәбәләнә төшкән чәчләренә төбәлеп карады. Аннары Гөлфирәнең яшькә чыланган иреннәрен, бит алмалары һәм күзләрен үбәргә кереште. Бу юлы аның зур ачылган күзләрендә курку, ләкин сөйгән кешесе белән бергә, гомерендә беренче тапкыр аның мәхәббәтен татырга ашкыну иде.

## 5

Баскычтан менеп килгән Нурлыбикәне, никадәр генә тыныч булырга тырышмасын, шомлы дулкынлану биләп алды. «Нәрсәгә болай дулкынланам соң әле мин,— дип уйлады ул,— үзем яшәгән квартира, анда үземнең йөрәк парәм — кызым Карлыгач йоклап ята торгандыр».

Шунда гына Нурлыбикә кызының инде монда булмавы, атасы янына китеп бару ихтималы турында исенә төшерде. Бәлки, алар квартирасында җиде ят кеше яшидер?

Бу соңгы уй аны менеп барган җиреннән баскыч уртасында килеш туктарга мәҗбүр итте. «Чынлап та, нәрсә эшләргә соң миңа хәзер, кыңгырауны шалтыратыргамы, юкмы? Ишекне ачып җибәрсәләр, нәрсә әйтергә? Җитмәсә, ни иртә, ни кич дигәндәй, ишек ачтыргач, рәхмәт әйтмәсләр?

Шул чагында Нурлыбикәнең хәтере почта тартмасында ниндидер кәгазьләр, күрәсең, кичә кич алынмыйча калган газеталардыр, барлыгын әйләндереп чыгарды. Бу, билгеле, суга батучының саламга ябышуы сыманрак иде, әмма үз атасы аңа юкка гына: «Елан аягын кискән нәмәрсә син»,— дип әйтми иде.

Нурлыбикә кулындагы чемоданын баскыч мәйданчыгына куйды да йөгерә-атлый аска — беренче каттагы тартмалар янына ашыкты. Тартма бикле булып чыкты, ләкин Нурлыбикәнең малайлар һәм ир-атларның ул тартманы ничек итеп ачканнарын күп тапкыр күргәне бар иде. Шуңа күрә ул югалып калмады. Калай тартма капкачын ике кулы белән астан өстән тотты да үзенә таба тартты. Калай капкач артык карышып тормыйча урта бер җиреннән тышкы якка таба бөгелә башлады, аннары «кыррррт» иткән тавыш белән ачылып китте. Нурлыбикә газеталарны карап

та тормады, анда квартира номерын гына язалар иде, газеталарны аралар-
га кереште.

Нурлыбикә эзләгән нәрсәсен тапты: Сәфәров исеменә «Огонек» приложениесен кереп алыгыз» дип язылган хәбәр бар иде. Шатлыгыннан үзенең хәзерге хәлен онытып җибәрә язды. Нурлыбикә чемоданы калган мәйданчыкка ничек менеп җиткәнен дә сизмичә калды. Кырыкмыш шикелле азгын язмышына бирелеп чыгып киткән, үзе яшәгән, үз ачкычы белән теләсә кай вакытта ачып керә торган, дерматин белән ташланган ишек алдына килеп баскач кына аңына килде. Ут борчасы кебек терелегенә карамастан, ишек янагындагы таныш төймәгә басарга кыймый торды. Ләкин, килбәте нинди — күләгәсе шундый, дигәндәй, кешесе нинди — максаты да шундый иде. Нурлыбикә башта кыяр-кыймас кына кыңгырау төймәсенә бармак очын гына тидереп алды. Бераз көтеп торды, теге якта тавыш-тын ишетелмәде, түгәрәк күздән яктылык күренмәде. Хәзер инде Нурлыбикәнең баягы куркуы беткән, чөнки эшнең яртысы эшләнгән иде, төймәгә тагын бер тапкыр басып алды. Ниһаять, теге яктан:

— Кем бар анда, хәзер киләм, хәзер инде,— дигән тавыш ишетелде.

Тавыш Карлыгачныкы түгел, ләкин ныгып җитмәгән кызларныкы. «Әллә чынлап та күчеп китteләрме икән?» — дип уйлап алды Нурлыбикә тагын бер мәртәбә. Һәм ирексездән, бер адым арткарак чигенеп, түгәрәк күз турыннан читкәрәк борылып басты. Ул арада түгәрәк күз караңгыланып калды һәм шул ук мизгелдә кемдер:

— Карлыгач... әниең кайткан бугай,— диде.

Нурлыбикә, үзен барыбер күреп торуларын белгәнгә, читтәрәк баскан җиреннән әлеге күзнең алдына ук чыгып басты.

— Мин бу — әниең, кызым, курыкма, ач!

Йозактагы ачкыч борылды, әмма ишек бөтенләй үк ачылып китмәде, песи йөгереп керерлек кенә ярык булып калды.

Кызлар үзара пышылдашып алган шикелле булдылар...

Эчке яктан шундый таныш һава агымы чыгып, Нурлыбикәнең борынына бәрелде. Ул Карлыгачны күрде, арттарак моңарчы бер тапкыр да күзенә чалынмаган ят кыз басып тора иде. Ләкин Нурлыбикә ул кызны да кайдадыр күргән шикелле булды, чөнки аңарда ниндидер таныш кешенең чалымнары бар иде. Шуннан соң гына Нурлыбикә күзләрен күтәреп кызына карады.

Ана һәм кыз бер-берсенә каршы басып торалар, ләкин алар арасында бусага бар һәм аны атлап узу, бу очракта ана кешегә, гаять кыен, катлаулы, әбиләр әйтмешли, сират күпере кичү белән бер иде.

Бәлки шуңадыр, нәрсәдер әйтергә дип авызын ача башлаган, бүтән вакытларда теле-телгә йокмаган Нурлыбикәнең күкрәген таныш булмаган бер көч кысып-кысып куйды, тамагына әстерхан чикләвегедәй каты төер укмашты.

Карлыгач исә, саф һәм тирән мәгънәле күзләрен йоммыйча, бусаганың тышкы ягындагы анасына карап, нәрсә әйтер бу дип, көтеп торды. Аның карашында Нурлыбикәне өтеп-өтеп алган чаткы, нәфрәт белән кызгану, шул ук вакытта очыну чаткылары тулы иде. Хәтта оят дигән нәрсәне күптән онытып, ул сыйфаттан башка яшәргә күнегеп алган Нурлыбикә дә аларны аермачык күрде... Күрде һәм үзенең инде беркайчан да, берничек тә шушы кызый тарафыннан гафу ителмәячәген упкынга охшаш тирәнлеге белән аңлады. Аның усаллыгы, шәфкатьсезлеге янәшәсендәге кырыслыгы берьюлы юкка чыккандай булды. Бу сәер, бик тә сәер халәтне Нурлыбикә моңарчы беркайчан да кичермәгән иде.

— Әйдә, ән-ни, күрергә килдеңме? Кер, алай булса...— диде Карлыгач һәм «рәхим ит» дигән сыман ике кулын ян-якка җәеп, тезләрен чүгә төште.

Нурлыбикә, кызына карап торса да, аның нәрсә әйтүен ишетеп бетермәде, дөресрәге кызының тавышын ишетте, ләкин әйткән сүзләренең

мәгънәсенә төшенеп җитмәде. Баягы каты төер тамагын тыгызлап авырттыра ук башлады, күзләренә ирексездән мөлдерәп яшь тулды. Карлыгач һәм аның артындагы кыз яшь пәрдәсе хасил иткән томан арасыннан бер күренеп, бер күренмәс булдылар. Әле кайчан гына «Кайтам да керәм!» — дигән катгый карар белән кайткан, шуннан башкача булырын уйлап та карамаган Нурлыбикә үз кызы белән ике арада беленер-беленмәс яткан бусаганы атлап керерлек көче юклыгын сизде. Кызы авызыннан чыккан сүзләргә салынган үпкә, рәнҗү катыш нәфрәт кыйпылчыклары яндырып-яндырып алганны тоя-тоя, ике баскычны бер итеп аска таба йөгерде, беренче катның ишегеп чемоданы белән бәреп ачты да урамга килеп чыкты.

Күзләре акны-караны аера алмас, чигәләрен тимер кыршау кыскан хәлдә ашыккан Нурлыбикә быел җир өстенә беренче тапкыр яуган, әле тузан заты кунып өлгермәгән ак карда чуар эзләр калдыра-калдыра каядыр бара, ләкин ул үз аякларының кая таба алып барганын тоймый иде.

Ирексездән тулып, хәзер инде ургылып ташкан күз яшьләре аның уттай янган бит алмалары буйлап түбәнгә тәгәриләр, хәзер инде чуер ташка охшаш салкынча төер сулыш алырга ирек бирмичә тын юлларын авырттырып ала иде.

Кайчандыр Нурлыбикә һәм аның кебек йөзләгән кыз-кыркынны кочагына алып җылыткан, күбесенә үзләренә тиң бәхеттән өлеш чыгарган шәһәрдәге ак йортларның бу юлы йөзе караңгыланган һәм ул да: «Бәхет ул, үскәнем, саклап тотсаң гына мең көнлек, сакламасаң — нибары бер көнлек»,— дип үртәшә сыман күренде.

Нурлыбикә күзләрен томалаган яшь томаны аша каршысындагы мәһабәт бакчага күтәрелеп карады. Томан таралган арада кунакханәнең мәрмәр плитәләр җәелгән киң һәм зур болдыры янында басып торуын чамалады. Шул ук мизгелдә аның болай да чәнчеп-чәнчеп авырткалаган йөрәгенә тагын да ныграк, хәзер инде үткер хәнҗәр кадалган шикелле булды. Аның хәтер йомгагы кинәт сүтелеп китте һәм шушы мәрмәр ташларга кадак-үкчәләрен тык-тык бәреп, иң беренче тапкыр Эдик янына кергән, мәхәббәт бизгәгенә бирелгән минутларын ялтыратып күрсәтте.

Кунакханәнең иркен вестибюлена килеп кергәндә, аның йөзеннән кан качкан, керфекләрендәге буяулар күз яшьләреннән изрәп битләренә сыланган, кыяфәте ярыйсы гына куркыныч төскә кергән иде, күрәсең.

— Ой, нәрсә булды сезгә, нәрсә булды? Кыяфәтегез... — диде кунакларны кабул итүче хатын, Нурлыбикә пыяла ишектән керешкә үк.

Нурлыбикә дәшмәде, ишек төбенә чемоданын куйды да, кытыршы стенага сөялде, бәләкәй сумкасыннан хушбуй исе аңкып торган кульяулыгын чыгарып, күзләрен сөртергә кереште.

Дежур хатын, Нурлыбикәнең хәлен бик дөрес чамалап булса кирәк, бүтән эндәшмәде, сорашып җанына тимәүне яхшырак дип тапты, керүче үзен беркадәр тәртипкә китергәч кенә, аның йөзенә игътибар белән карап торганнан соң, әйтеп куйды:

— Абау, Нурлыбикә апа, сез... син түгелме соң бу?

Нурлыбикә кульяулыгы белән маташуыннан кинәт туктап калды, күзләрен күтәреп карады.

— Әй-йе, мин... Ә син мине каян беләсең?

— Соң инде, Нурлыбикә апа, белмичә. Без бит бер бригадада эшләдек. Мин кияүгә чыккач та ирем белән Төмән ягына киткән идем. Әле менә ике ай элек кенә кайттык. Мин менә монда эшлим хәзер... Ә син, син соң, Нурлыбикә апа, нишләп болай? Кем әле, Гаяр абый белән ызгыштыгызмы әллә? Шушы вакытта чыгып киттеңме? Кабахәтләр алар-ирләр... авызларыннан кире чыга башлаганчы эчәләр дә аннары кайтып, хатыннарын бимазалый башлыйлар. Күр инде... Ну, Гаяр абый... андый түгел кебек иде бит ул. Менә сиңа, ишетмәсәң ишет...

Кунакханәнең уяу хуҗабикәсе сүзгә батыр хатын икән, шулай сөйләнә-сөйләнә, Нурлыбикәне түргәрәк, үзләре утыра торган пыяла бүлмәләр янына алып килде. Аннары теге якка кереп, грушасыман ялтыравык тимер тагылган ачкычны алды да, янәдән бу якка чыгып, тагын тезепме-тезәргә тотынды:

— Әйдә, Нурлыбикә апа җаным, үзеңне менә дигән бүлмәгә урнаштырам. Ял итәрсең, тынычланырсың. Анда синең җаныңа берәү дә тимәс. Кирәк булса, айнычач, табар әле. Эзләсен әле менә!

Аннары лифт ишеге янына килеп җиткәч:

— Ярый, Нурлыбикә апа, мин соңрак менеп алырмын синең кәгазьләреңне. Миңа монда шалтыратулары бар. Сигезенче катка мен дә уң якка борыл, яме,— дип, җылы сүзләр белән озатты.

Сигезенче каттагы бүлмә тәрәзәсеннән иртәнге шәһәр утлары, кар бөртекләре белән аралашып, аеруча матур, сихри бер күренеш хасил итә иде.

Ерактагы проспект, иртәнге тынлыкны ярып йөгерүче автобуслар, бер-бер артлы яктылык иңдереп уяна башлаган биек-биек йортлар — барысы-барысы да Нурлыбикәгә шундый якын, шундый таныш һәм... соңгы ике-өч елда беренче тапкыр шундый кадерле сыман иде. Кунакханә алдындагы бер катлы иске агач йортлар гына сигезенче кат биеклегеннән тагын да каралыбрак күренәләр.

Чүт кенә уңдарак, урамның теге ягында, төзелешләр башланыр алдыннан ашык-пошык салынган биш катлы соргылт йортлар аркылы-торкылы салынган кирпечләр шикелле тезелешкәннәр, түбәләрендәге күп санлы вак-вак антенналар әрәмәлегенә күмелгәннәр.

Нурлыбикә ирексездән элек үзе яшәгән, әле генә үзе дөньяга китергән кызы алдыннан җебеп чыгып киткән йортны эзләп тапты. Ул, берни булмагандай, ничек утырган булса, шул килеш утыра бирә, тәрәзәләрендәге утлар шулай ук бер-бер артлы кабыналар, кешеләрне иртәнге сменага озатырга җыеналар иде.

Үзен ярыйсы гына кулга алган, инде тынычлана башлаган Нурлыбикә күңелен тагын ниндидер сәер, шул ук вакытта гаять җылы сагыш били барганын сиземләде. Һәм кирәгеннән артык дулкынлана башламагаем дип, тәрәзә каршыннан китте.

Бүлмә уртасындагы кечкенә өстәлдә кызыл төстәге телефон аппараты Нурлыбикәне сискәндереп җибәрде. Ул, ашыгып барды да, аппаратның номеры язылган кәгазьгә күз салды. Анда таныш саннар сугылган иде... Нурлыбикә тагын йөрәгенә инәләр кадалганын тойды. Беренче тапкыр Эдик янына кереп, урланган мәхәббәтнең татлы бизгәген кичергән бүлмә иде ул.

Күрәсең, язмыш Нурлыбикәне эзәрлекләвен дәвам итә иде әле...

## 6

Алар якынлыкның зәңгәр диңгезеннән икесе берьюлы чынбарлыкның күгелҗем тынлыгына кайттылар.

Вагон эчендәге кечкенә бүлмәдә әллә нинди бер серлелек, тирәнлек һәм тантана хөкем сөрә иде.

Гаяр үзенең Кама дәрьясының җәйге җылы дулкыннарында чайкала-чайкала йөзеп баргандагы сыман хис итте. Аның күкрәге моңарчы тоелмаган, татып карамаган мәхәббәт кутәренкелеге белән мөлдерәмә тулган иде. Юк, ул хисләр ир уртасы җитеп килгән кешенең хатын-кызга, бары тик хатын-кызга гына була торган хисләреннән гаять аермалы, иң якын, иң кадерле һәм аңардан башка җир йөзендә бер генә минут та яшәп булмаслык дәрәҗәсенә җиткән кайнарлыкка тиң иде.

Гөлфирә, башын Гаяр күкрәгенә куйган килеш күзләрен йомып, көтмәгәндә ябырылган хисләрдән айнып җитә алмый, аның йөзендә ниндидер яшерен елмаюның сизелер-сизелмәс нурлары чагылып-чагылып китә,

ләкин ул дәшми, әле дә булса кайнар иреннәрен якынының күкрәгенә тидереп алудан канәгать иде.

Гаяр шулай ук сөйләшми, Гөлфирәнең чәчләреннән аңкыган сирень исләренә күмелеп, рәхәт барыберлегенә бирелгән килеш Көмеш Аланның уянганын тыңлап ята.

Ниһаять, Гөлфирә башын өскә табарак күтәрде һәм ишетелер-ишетелмәс кенә, ләкин һәрбер иҗеге ачык аңлашылырлык итеп әйтте:

— Га-яр, син мине ни өчен ничә еллар буе яраттың?

Гаяр дәшми.

— Әйт инде, Гаяр, ни өчен?..

— Белмим... кешене ни өчен яраталар соң?

— Яхшы, матур, ягымлы, эшчән булганы өчендер, бәлки?

— Алай гынамы икән?

— Ә син мине ни өчен яраттың мине? Юк, хәзер димим, теге чакта, мәктәптә укыганда... Кочак-кочак сирень чәчәкләре өзеп бирмәкче идең... Мин, юләр, синең яратканыңны белеп йөри идем, ләкин ни өчендер синнән очраган бер урында көлеп йөри идем. Хәзер менә, ничәмә-ничә еллар үткәннән соң беләм инде: кызлар алар, Гаяр, барысы да диярлек каты бәгырьле була һәм беркайчан да үсмер малайлар күңелен аңламыйлар.

— Һәм шуның өчен дә күп очракта ялгышалар, күз яшьләре түгәләр, язмышларын каргыйлар, ахыр чиге кешеләргә, бигрәк тә ир-ат халкына ышанычларын югалталар димәкче буласыңмы, Гөлфирә?

— Мин, Гаяр, синең эчкерсезлегеңне күрәдер идем... Ләкин син кызларны да аңларга тырышып кара. Алар, гадәттә, егетләрдән алдарак үсеп буй җиткәләр. Аларга үз ишләре кебек малай-шалай түгел, ишетсен колагың, е-гет-ләр күз кыса, сүз куша башлый. Мәктәптәге ишләренең күбесе сиңа бер сүз әйтергә куркып-калтыранып йөргән чагында әлеге егетләр матур-матур сүзләрне сибепме-сибә. Ә кыз күңеленә, Гаяр, күп кирәк дисеңмени? Дөньяда күпме кыз яралган һәм күпмесе генә аның тәҗрибәле егетләрнең татлы теленә ышанмаган дип уйлыйсың? Бик сирәк андыйлар... Өстәвенә бит әле сезнең, чибәр егет, армиягә китеп, өч ел хезмәт итәселәрегез бар иде. Сөлектәй сузылып, җыйнакланып утны-суны кичеп кайтканнары янында бөтерелеп йөргәндә, әле армиягә китәргә җыенып кына йөргән яшь егетне көтеп утырмассың бит инде. Ярый ла көтүләреңә каршы аннан кайткач, сиңа караса... Ә карамаса, яшьрәк, тагын да матуррак булып үсеп җиткәннәргә күзен ялтырата башласа?.. Монда, Гаяр, берьяклы гына уйларга ярамыйдыр, күрәсең. Ничек диган әле шагыйрь? —«Мәхәббәт — ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта»,— дигән түгелме?

Гаяр нәрсәдер каршы әйтмәкче булып, Гөлфирәне бүлдерергә әзерләнгән иде инде, өлгерә алмый калды, өзек-өзек итеп телефон шалтырый башлады.

«Алыргамы-юкмы? Алсам ни әйтергә?»— дигән уй белән Гаяр Гөлфирәнең баш астыннан кулын салмак кына тартып алды, караватчитенә торып утырды.

Телефон отыры үҗәтләнеп, ешайганнан-ешаебрак биергә керешге. Алмыйча ярамый иде, әлбәттә. Гаяр тумбочкадагы будильникка күз төшерде. Җиде тулып килә, димәк, көндәлек планерканы башлар вакыт җиткән иде.

— Әйе, тыңлыйм сезне, тыңлыйм,— диде Сәфәров, артык исе китмәгән тавыш белән.

Трубкада бер үк вакытта телефонистка һәм диспетчер вазифаларын башкаручы, әле кайчан гына «Эшкә ал!» — дип, Сәфәровның үзенә үткән, артыннан калмыйча йөргән Фәния тавышы ишетелде:

— Иптәш Сәфәров, сезне Чаллыяр сорый...

Ләкин Сәфәров аның сөйләп бетергәнен көтеп тормады.

— Кем әле бу? Фәния сеңелем, синме? — диде ул таң алдыннан кычкырган баш әтәч сыман башкаларның тавышын тыңларга теләмичә. — Син булмаса әйт, кем шалтыратса да әйт, яме: Сәфәров абый өйләнеп кайткан, миңа өч көн ял тиешле, дип әйтеп әйтә, диген...

Ул трубканы аппарат өстенә куеп, Гөлфирә янына барып утырырга өлгермәде, телефон баягыдан да ешрак итеп, бу юлы инде болындагы чикерткә шикелле «черт-черт» сайрарга кереште.

— Юк, яшь кәләш янында да тынычлык бирми болар,— диде ул, телефон трубкасын кабат ала-ала. — Я, тагын нәрсә кирәк, әйттем бит мин сиңа: мин өйләндем... нибары ике сәгать элек, понимаешь?

Телефонда Айбулатов үзе иде. Ул Сәфәровның сәер чыгышын тыңлап бетерде һәм:

— Син нәрсә, егетем, кичә кич артыграк җибәрдеңме, әллә бүген таң тишегеннән баш төзәтергә өлгердеңме? — диде ачулырак тавыш белән.

Гаяр бер мәлгә ни әйтергә дә белмичә торды. Ләкин аның бер тискәреләнсә гел кирегә тибә торган сәер сыйфаты бар иде, хәзер дә шул өскә чыккан мизгел туры килде бугай, ул үз тугызын тугызлап, кемнең кемлеген онyта төшеп, шулай ук тамак төбен киереп кычкырды:

— Әйе, кичә сез керткән «мунчадан» соң төн буена исерек йөрдем, Фазыл Артышевич, аннары менә төзәтергә исәп иттем. Тик, сез уйлаганча, башны түгел, әҗәмыш ялгышын төзәттем мин, Фазыл абый...

Инде Айбулатовның гаҗәпләнер чагы җитте бугай. Аның эш дәверендә мондый очрак беренче тапкыр очраганга күрәдерме, әллә бүтән бер-бер сәбәптәнме, төгәл әйтүе кыен, ул ярыйсы гына «нәрсә әйтергә?» дип уйлап торды. Ахыр чиге, башына бу очракка ятардай тапкыр сүз килмәгәч:

— Алаймы, парин? — диде. — Алай булса... алай булса, котлыйм мин сине һәм теләсәң өч көн түгел, туп-тулы бер атна вакыт бирәм мин сиңа. Яшь кәләшеңнең дә күңелен күрерсең, шул арада шәһәргә кайтып Нурлыбикәң белән дә арaңны өзәрсең. Бәхетеңә каршы, ул монда... Дөрес, кызың аны ишек төбеннән борып җибәргән...

Хәзер инде Сәфәровның нәрсә әйтергә белмичә аптырап торыр чагы иде.

— Нәрсә тынып калдың, Гаяр, яшь кәләшең ишетмәсен дисеңме әллә? Нурлыбикәңнең кемлеген беләсең, ул әллә кайларга ишеттерер, әллә кемнәргә барып җитәр әле өйләнеп ятуыңны белсә...

Ниһаять, Сәфәров та телгә килде.

— Ишетәм мин сезне, ишетәм, Фазыл Артышевич, ишетәм,— диде.

— Ишетсәң — бик яхшы. Башың белән уйла, тик бер киселгән икмәкнең кире ябышмаганлыгын бел!

Телефон трубкасында кыска-кыска «бии-ип, бии-ип»ләр ишетелеп тора башлады. Сәфәров аны колагыннан алып, тын калды, аннары... бөтен бүлмәне яңгыратып һәм Гөлфирәне сискәндереп, көлеп җибәрде...

## Тугызынчы бүлек

### I

Көн иртәдән үк боек, күк йөзен тоташтан актарылучы кабарынкы болытлар томалаган, җир куенында урыны-урыны белән соргылт томан сарыла, озак та үтми карлы яңгыр ява башлый һәм, ул да түгел, болыт араларындагы тәрәзәләрдән кояшның сүлпән нурлары күренгәләп ала иде.

«Волга»сының арткы урыннарына сеңеп утырган Марк Львович Алмазов, акка кара белән басылган әңгәмәсен исенә төшереп: «Шул кирәк сиңа, сөрхәнтәй!» — дип үз-үзен сүгеп алды.

Турысын әйткәндә, Марк Львович газетада басылган әлеге әңгәмәне күргәч: «Чебен дулап тәрәзә вата алмас әле,— дип, үз-үзен тынычландырды, борчылмаган булып күренде,— үтәр әле»,— диде. Үтмәде...

Башта Алмазовны ут чыккандай ашыктырып Дикопольцев Көмеш Аланга чакырып алды. Кем белсен, әгәр дә Вергилий Никифорович үзе генә булган булса, Марк Львович бу юлы да аның күңелендәге йомшаклыкны бер-бер җаен табып файдаланган, якланып калган булыр иде. Ләкин...

Ул Көмеш Аланга килеп җиткәндә Бабакай, Борнашев һәм Айбулатов өчәүләшеп Алмазовның бәгыренә ачыташ булып укмашкан измә-бетон узелларының хәрәкәтсез яткан корылмаларына карап басып торалар иде.

Марк Львович машинасыннан төшә-төшешкә үк Бабакай кулындагы үзе кузгатып та, үзенең башына суккан әңгәмә басылган газетаны күреп алды.

— Бу нәрсә, нәрсә дип атала, иптәш Алмазов? — диде Дикопольцев сул кулындагы газетаны измә-бетон узелларына таба селкеп.— Соңгы киңәшмәдә бирелгән вакыт узды түгелме соң, Алмазов? Нигә эшләми болар?

Төзелешкә яңа гына килгән студент-мазар түгел, Алмазов андый вакытларны күптән узып, бернichә төзү-монтаж идарәсен берләштергән мөстәкыйль идарә җитәкчесе булып ныгыган, төрле-төрле әрләү-кызулатуларны гына кичергәләгән кеше, артык каушап калмады.

— Узеллар эшкә әзер, Вергилий Никифорович, бары тик су булмау сәбәпле генә эшкә керешеп китә алмыйча тора алар...

Әйтсәң — сүз, төртсәң — күз дигәндәй, шул гына җитеп бетмәгән икән. Дикопольцевның гадәттәгедән тынычрак, басынкырак, ләкин шул ук вакытта ачуы соңгы чиккә җиткәнлеккә белдерә торган усаллык чыңлаган тавышы аны ярты сүздә бүлдерде:

— Вәгъдә биргән чакта син тау башында су юклыгын белә идеңмекюкмы, Алмазов? Узелларны базага якын була дип шушы урынга коруны кем тәкъдим итте? Аларны әнә тегендәрәк төшерергә, су буена коруны кем тыйды сиңа? Дөядәй урының булганчы, төймә кадәрле акылың булырга тиештер бит синең, Алмазов?

Алмазов ни әйтергә белмичә басып калды. «Айбулатов алдында бөтенләй адәм хуры итте бит»,— дигән әрнүле уй баш миеннән араланып чыкканчы, бәхеткә каршы, янәшәдәге Борнашев:

— Ярый, иптәшләр, биредә әрләшеп торудан он суы да, тоз суы да чыкмас. Хәзер инде бу ялгышны тизрәк төзәтергә, Айбулатов әйткәнчә, Камадан вакытлы су үткәргеч сузарга гына кала,— дип, сүзгә кушылды.— Ләкин биредәге тоткарлыклардан, иптәш Алмазов, сез сайлаган юл белән арынып булмаячак. Ил сүзе — диңгез дулкыны, ди безнең халык. Дөреслеккә туры килеп бетмәгән әңгәмәгезнең дулкыны да шуннан ким булмас, дип уйлыйм.

Марк Алмазов тормышында караңгы эз калдырган һәм сизелерлек салкын җил булып искән ул көннән соң атнадан артык вакыт үтте. Ниһаять, измә-бетон узелының берсе, әллә ни искитмәле өлгерлек белән булмаса да, эшкә керешә. Дөрес, йорт төзүчеләр Алмазовныкыларга таяк тыгырга дигәндә һәрвакыт әзер, бу юлы да ул измәне бер көнне генә алдылар да, вәссәлам, баш тарттылар. Әмма хәзер юл салучыларның эше сәгатьләп алга үрмәли. Аның каравы, көннәр бозылып китүгә котельныйны җиткерү Алмазовның бугазына басты. Вагоннар һәм анда яшәүчеләр саны көн саен арткаmakan-арта бара, ә җылы юк, димәк җылы су да юк... Кичә инде баш инженер урынбасары байтак кешенең суык тидереп эшкә чыкмавыннан, бигрәк тә хатын-кызлар арасында канәгатьсезлекнең зурлыгыннан зарланып алды...

— Соң, ничек болай булып чыкты соң әле бу? Нигә эшләр гел артка тәгәрәргә генә тора? — дип уйлап алды Марк Львович ачынып.— Барысы да шул АЭСның төп башкаручысы итеп билгеләнгәннән соң кирегә китте. Аны безнең идарәгә такмаган булсалар, электәгечә тыныч кына яшәгән булыр идек әле. Эш бетмәгән иде, планнарны да үтәп бара идек, әрләүбитәрләүләрдән дә читтә идек. Менә хәзер инде өлкә комитеты бюросында җавап бирергә туры килә. Ярый ла, шелтә-фәлән биреп кенә калдырсалар... Мәскәүгә китү түгел, мондагы урыныңнан ничек ычкынганыңны да сизмичә калуың бик ихтимал.

Җилгер «Волга», карлы-яңгырлы юлдан түбән табарак төшеп, Шомбыт елгасы күперенә керде. Шул ук вакытта каршы яктан зур тизлектә килүче КамАЗ күренде һәм, Марк Львович аны-моны уйлап өлгергәнче, машинаны баштанаяк пычрак суга коендырып узды. Шофер мыгырданып кына пыяла чистарткычларны эшкә кушты...

Алмазов маңгаена бәреп чыккан салкын тир тамчыларын сөртеп алды, күкрәгенә ярып өскә таба менеп баручы кайнар кургашсыман нәрсәне тамак төбенә авырттырып йотты, ни хикмәттер, шоферын битәрләп сыңар сүз дә әйтмәде. Беравык барганнан соң гына «Яхшыга түгел бу»,— дип юрады...

## 2

Еш кына теге яки бу коллективның тоткан урыны турында башкара торган эшләре һәм җитәкчесенә карап сөйлиләр, фикер йөртәләр. Кама буендагы автогигантны кем төзеде дип сорасаң, һич икеләнүсез: «Дикопольцев»,— дип җавап бирәчәкләр. Билгеле, шундый гигантны бер кеше, ул никадәр генә кодрәт иясе булмасын, башкарып чыга алмый. Моны йөзләр һәм меңнәр башкара. Ләкин бу очракта сүз ил белән телгә алып сөйләрлек эшне башлап йөрүче, оештыручы җитәкче турында бара.

Төзелештә катнашкан һәркем авыз тутырып шулай дип әйтәчәк. Бу — төзүчеләрнең генә түгел, барлык һөнәр ияләренең дә Дикопольцевка булган ихтирамы, аның сәләте һәм кешелеклелегенә бирелгән югары бәясе.

Мирас Гайнанович Борнашев Чаллыярда олы төзелеш башланганчы ук шәһәр комитетының беренче секретаре итеп сайланган иде һәм ул биредәге төзелешнең иң беренче ветераны, аның казанында иң беренче көненнән алып бүгенгесенә кадәр кайнаган кеше. Аның абруе зур, ләкин ул моңа карап Дикопольцевны ихтирам итүдән, аның язмышына, эшләгән эшләренә сокланудан тартынмый һәм моны, кирәк урында, сиздереп куя белә иде.

Дикопольцевның ул китеп озак та үтми бәхетсезлеккә очравы турында ул Мәскәүдә Үзәк Комитет тарафыннан уздырыла торган семинарга очар алдыннан ишетте. Башта ышанып та бетмәде. «Ничек инде,— дип уйлады ул,— бер сәгать элек кенә шундый нык йөргән кеше иң киеренке көннәр узгач та нинди дер инфаркт тарафыннан җиңелсен?» Ләкин Борнашевның андый хәлләрне күргәне, күрү генә түгел, андый хәлләрдән килгән югалтуларны кичергәләгәне бар, эшнең җитдилеген аңлый иде. Шуңа күрә дә Мәскәүгә җитеп, кунакханәгә керү белән тизрәк Чаллыярга шалтыратырга кереште.

Усал хәбәр дөрес иде, ләкин, Дикопольцевның хәле ул кадәр куркыныч түгел, диделәр. Шулай да Борнашев тынычланмады, шифаханәнең баш врачына шалтыратты.

— Урында оста ярдәм күрсәтелмәгән булса, Мирас Гайнанович, Ширәмәттән ашыгыч ярдәм килеп җиткәнче... Вергилий Никифорович...

Борнашев аңлады, баш врач калган сүзләрне авыз тутырып әйтә алмый иде. Хәер, андый сүзне ничек әйтәсең, тәнәфесләрнең берсендә аларның берләшмәсе буйсына торган министрлык җитәкчесе килеп:

— Сез, иптәш Борнашев, Атакайны нишләттегез? — дип сорагач, Борнашев үзе дә:

— Хәзер инде алай ук куркыныч түгел, терелер дип ышандыра врачлар,— дип җавап кайтарды. Көмеш Аландагы кискенлекләрне сөйләп тормады.

Министр, үзе дә җитмешнең өстендәге кеше, Атакайның хәлен юкка гына сорашмаган икән, икенче тәнәфескә чыккач, ул яңадан Борнашевны терсәгеннән тотып, читкәрәк чакырды.

— Мин менә, иптәш Борнашев, уйлап-уйлап утырдым да, шундыйрак фикергә килдем. Без Атакайның эш тәҗрибәсе зурлыкны, аның артыннан кешеләрнең утка-суга керергә әзерлеген һәм әле аның ил файдасына бай-

так эшләр башкарачагына шикләнмибез. Хәзерге заманда ин... ин... ин... шайтан алсын шуны, ерак йөрми безнең халыктан. Шуңа күрә, бәлки Атакайның үзенә артык сиздермичә генә, алмаш әзерли башларга кирәк булачак. Сезнең берләшмә, мәгълүм булганча, илдәге беренче дистәгә кертелгән эре оешмаларның берсе. Башкара торган һәм алда каралган эшләре гаять зур һәм җаваплы. Мәгълүм булганча, сезнең регионда тагын трактор заводлары комплексын кора башлау уйланыла. Димәк, бу очракта, шуйдый эре берләшмә хәзергечә үк зур киеренкелек, җаваплылык белән эшләргә тиеш. Кыскасы, сез мине аңлыйсыздыр, дип уйлыйм: Атакайга алмаш турында сездә нинди фикер бар?

Борнашев дәшмәде. Дөрес, бу хакта ул бөтенләй уйламады дисәк, хаклыкка туры килеп бетмәс иде. Уйлаштырды. Ләкин менә шулай көтмәгәндә генә ул сорауга җавап бирергә туры килер дип башына килмәгән иде.

— Изге урын буш тормас, иптәш министр,— дип ярым шаяру белән котылмакчы иде, әмма министр сүзен төгәлләп куюны кирәк тапты:

— Без, иптәш Борнашев, андый җаваплы урынга кеше таба алабыз. Әмма... сезнең белән эшләү дәверендә бер-беребезне шактый гына яхшы өйрәндек, төзелештәге байтак кешене — иң беренче чиратта төзүче-инженерларны күрдек-белдек, аларның теләсә нинди җаваплы эшләрне дә җиренә җиткереп башкара алуларына ышанабыз. Шуңа күрә бу мәсьәләдә сезнең белән киңәшү һәм сезнең шәхсән фикерне белү әһәмиятле... Минемчә, иптәш Борнашев, сезнең үзегездә Атакайны алыштырырлык кеше бар һәм аның үз кешегез булуы бигрәк тә яхшы,— диде. Борнашев чамалыймы, дигән сыман күзләрен кысыбрак карап торды һәм, ниһаять, әйтеп бетерде.— Безнең фикеребезчә, иптәш Борнашев, хәзер Чаллыярда эшләүчеләр арасында иң абруйлы, оештыру сәләтенә ия булган кеше — йортлар төзү комбинаты җитәкчесе Айбулатов... Сез бу хакта ничек уйлыйсыз?

Мирас Гайнанович та: «Министр шаяртмыймы?» — дигән сыман тиз генә аңа карап алды. Юк, министр шаяртырга ярата торган кеше булса да, бу юлы йөзендә андый билге күренми иде.

— Билгеле, Мирас Гайнанович,— дип дәвам итте министр,— безнең бу сөйләшүебез вакытлыча авырган кешене урыныннан алу турында бармый. Дикопольцев — колосс, андый җитәкчеләр, кызганычка каршы, еш очрамый. Әмма без — коммунистлар, вакыйгаларның йөзенә туры карый белергә бурычлыбыз. Тагын бер тапкыр, кызганычка каршы, дип әйтергә туры килә, әмма Вергилий Никифоровичның җитмешенең өске ягына чыгуын онытырга ярамый. Аны алыштырырлык җитәкчене әзерли башлау — аның кирәге бетте дигәнне аңлатмый әле ул...

Борнашев министрга җавап бирергә өлгерә алмый калды, утырышлар залына чакырып кыңгырау шалтырады.

Бүтән тәнәфесләрдә әлеге сүз яңадан кузгатылмады. Шулай да Борнашев бу хакта уйламыйча булдыра алмый иде инде. Ул, билгеле, Айбулатовны Атакай урынына иң лаеклы кешеләрнең берсе итеп күрә, ләкин Айбулатовның катгыйлыгы, беркадәр үзсүзлелеге һәм үзбелдеклелеге белән эш йөртергә яратуы аны министр фикере белән килешүдән сизелер-сизелмәс кенә тоткарлый иде... Хәер, кем әйтмешли, алыш-көрәшләрдә характерының шул сыйфатлары өчен кыйналып-кыйналып та үзгәрмәгән икән, димәк, ул үзенең шундый сыйфатларының ныклыгына ышана. Атакайны язмыш дигән нәрсә аз кыйнаганмы, аз сынаганмы? Ул да бит, нинди зур эшләр башкаруына карамастан, автогигантның икенче чиратын тапшыргач кына Герой исеменә лаек булды, ил күләмендә танылды, дәбаса.

Мирас Гайнанович якты һәм иркен палатага кергәндә сизелерлек сирәгәйгән ак чачларен артка тараган Вергилий Никифорович күзләрен йомып биек мендәр өстендә ята иде.

«Йоклый!»

Беренче секретарьны озата кергән баш врач:

— Утырыгыз,— дип куллары белән дә ишарә ясады һәм үзе йомшак, җиңел адымнар белән барып бармакларын Вергилий Никифоровичның беләгенә тидерде.

Атакай шул ук секундта күзләрен ачты. Башта ул бүлмә уртасында ак халатка төренеп утырган Борнашевны әллә танымады, әллә аның килүен көтмәгән идеме, карашын йөгертеп узды, башын врачка таба борды.

— Хәлегез ничегрәк соң, Вергилий Никифорович, борчылмадыгызмы? — диде баш врач йөрәк тибеше саен салмак кына ияген кага төшеп.

— Егетләрчә... дисәм, барыбер ышанмассыз инде сез, ләкин начар дип зарланып та булмый.

Вергилий Никифоровичның карашы шул чакта яңадан Борнашевка төбәлде. Ул ирексездән кутәрелә башлап:

— Күзләрем ялгышмыйдыр ич... — диде. — Мирас?..

Борнашев урыныннан торды да Дикопольцевның аяк очына килеп койканың аркасына тотынып басты.

— Әйе, Вергилий Никифорович, мин бу — Борнашев.

— Кайттыңмы башкаладан? Нинди яңалыклар бар соң анда?

— Кайтуын кайттым да бит әле, Вергилий Никифорович, ләкин без аерылганда болай булырга дип сөйләшмәгән идек...

— Шулай да бит, Мирас...

Баш врач Дикопольцевның хәлсезләнгән кулын акрын гына юрган өстенә салды. Мирас Гайнанович белән Вергилий Никифорович икесе берьюлы диярлек сүздән туктап аңа карадылар.

— Безнең фикеребезчә,— диде ул ике җитәкчегә дә елмаеп,— иң кыен көннәр артта калды инде. Озакламый терелеп һавага чыга башларбыз. Артык борчылырга урын юк шикелле...

Вергилий Никифорович тамагындагы төерне йотып җибәргәч, ишетелер-ишетелмәс кенә әйтеп куйды:

— Рәхмәт, туган, рәхмәт сезгә — ак халатлы фәрештәләргә.

Баш врач урыныннан кузгалды да бүлмәдәгеләргә:

— Озын-озак утырмагыз һәм дөнья хәлләрен хәл итәргә керешмәгез, зинһар өчен,— дип палата ишеген тавыш-тынсыз ябып чыгып китте?

Ул чыгып китүгә Вергилий Никифоровичның күзләрендә хәйләкәр чаткылар чагылып китте.

—Әйдә, тизрәк сөйлә, Мирас, яңалыкларыңны,— диде ул түземсезләнеп.

— Яңалыклар байтак, Вергилий Никифорович, кирәкләре дә бар, кирәкмәсләре дә дигәндәй... Безнең өчен иң зур яңалык шул, Вергилий Никифорович, «Атомэнергострой» идарәсендәге коммунистларны территориаль принцип буенча безгә түгел, Түбәньяр шәһәре комитетына беркетергә карар чыгардылар. Шулай булгач, безнең берләштерелгән партком булдыру турындагы тырышлыгыбыз чынга ашмый калды дигән сүз...

—Соң, туктале, Мирас, син соң анда нинди ситуация килеп чыкканлыгын яхшылап төшендердеңме? — Дикопольцев беренче секретарьны бүлдерде. — Атом электр станциясен, аның янындагы шәһәрне безнең ике подразделение кора, алар хәзер безнең шәһәр партия оешмасында исәптә тора... Югыйсә тагын нәрсә килеп чыга инде?

— Шулаен шулай, Вергилий Никифорович, төзелеш өчен без җавап бирәбез, тулысы белән эшләрне без башкарабыз, ләкин безнең кешеләрне политик һәм идеологик тәрбияләү Түбәньярларга тапшырылган булып чыга...

— Соң бу хәл дөресме, синеңчә, дөресме? — Вергилий Никифорович, дулкынлана башлап булса кирәк, урыныннан кутәрелергә кереште, ләкин шундук йөзен чытып яңадан урынына ятты. Хәле чамалырак иде әле аның. Мирас Гайнанович сүзеннән туктап, Дикопольцевка карады, аның яңадан урынына ятканын күреп кисәтүне кирәк тапмады, сүзен дәвам итте:

— Безнеңчә, бик үк дөрес түгел, Вергилий Никифорович, төзелештә ике хуҗа барлыкка килә һәм, гадәттә мондый очракта җаваплылык кими, берсе икенчесен төрле кимчелекләр өчен битәрли башлаячак... Хәер, хәзергә бу мәсьәлә хәл ителгән: берләштерелгән партком чынлап торып эшкә керешмәс борын таратыла...

— Аннары нәрсә була? Төзелештәге кешеләрнең рухи ныклыгы, идея-политик тәрбиясе өчен кем җавап бирә?

— Өлкә комитетында бу хакта сүз булды, хәзергә «Атомэнергострой»лылар Түбәньяргага исәпкә керә, йортлар кору комбинатыныкылар элеккегечә, бездә кала. Соңрак, АЭСта хәлиткеч эшләр башлангач, бу мәсьәләне яңадан күтәрергә туры килер, Вергилий Никифорович.

— Мдаааа... Чынлап та кәкрегә кыеграк килеп чыга икән шул... Ярый, күз күрер... Ләкин күршеләр бу юлы үзләре турында күбрәк кайгырта бугай...

Алар, сүз белән мавыгып, палатага шәфкать туташы кергәнне күрмичә дә калганнар икән, ул үзенең йомшак тавышы белән эндәшкәч кенә, икесе берьюлы аның ягына таба борылдылар.

— Вергилий Никифорович,— диде шәфкать туташы,— даруларны эчәр вакыт җитте. Менә, рәхим итегез әле... — һәм стаканга су салырга чыккан булып, Дикопольцевка аркасы белән борылды, Мирас Гайнановичка күз кысты, «калдырыгыз» диебрәк башын янга авыштырды.

Шәфкать туташы бәләкәй стаканнарын алып, эшен бетереп чыгып киткәч тә Борнашев:

— Ярый, Вергилий Никифорович, борчуым өчен гафу ит. Озын-озак ятарга чамалама бирелә, чөнки... Карабуга янында трактор заводлары кору турындагы сүз ярыйсы ук ныгыган өстә,— дип күзләрен түшәмгә таба күтәреп күрсәтте. Саубуллашырга керешмәкче иде дә, Дикопольцев аны туктатты.

— Син, Мирас, аларның сүзенә артык игътибар бирмә.

— Алар сүзенә карасаң, тегесе дә ярамый, бусы да... — Вергилий Никифоровичның сөйләшүендә, Борнашев беренче тапкыр игътибар итте, картларга хас сукрану сизелеп китте. — Менә мин монда, больница түшәгенә эләккәч тә уйлап-уйлап ятам әле, Мирас, уйларымның очына чыга алмыйм... Трактор заводлары безнең берләшмә өчен инде ул... Аны... аны...

— Вергилий Никифорович, уйлап баш ватып ятарга түгел, тизрәк терелергә, элеккеге уйлардан да арынып ял итәргә кирәк.

— Менә кереп ятарсың да уйламыйча карарсың, Мирас, кадерлем,— диде Атакай тагын картларча сукрана төшеп. — Син мине бүлдермичә генә тыңла әле, яме.

Борнашев «ярый»ны белгертеп башын кагып куйды. Дикопольцев әйтәсе сүзенең мөһимлегеннәнме, әллә Борнашевка караганда үзе әйтәчәк сүзләрнең гаять әһәмиятле булуыннанмы, туктап калды, күзләрен йомып, кулын күкрәгенә, йөрәге турына куеп торды, йөткереп тамагын чистартып алды, бер йотым гына су эчте, аннары гына сөйләп китте:

— Син беләсең, Мирас кадерлем, мин инде яшь кеше түгел. Турысын гына әйтсәк,— мин инде карт кеше, җитмешнең өске ягына чыккан кеше. Җир, ил һәм халкыбыз алдында мин үземә йөкләнгән бурычларны үтәдем шикелле. Әйеме? Туктале, тукта син, бүлдермичә генә тыңлыйм дидең бит... Әйе, үтәдем һәм мине дөньяга тудырган ата-анамның йөзенә кызыллык китермәдем. Шулай икән, алай-болай була калса, мин инде тыныч күңел белән. Дөрес, хәзер мин үзем дә сизәм, бу урыннан торырмын әле, ләкин, сезнең бер язучыгыз әйтмешли, картлык — кемгә шатлык соң ул? Бер булгач, икенче тапкыры да ерак йөрмәс аның...

Дикопольцев туктап калды, ул әллә дулкынланудан, әллә тагын йөрәгендәге яра сыкраганнанмы, еш-еш сулый башлады, тагын кулын күкрәгенә куеп торды. Борнашев аңа су бирде һәм:

— Ярый ла, Вергилий Никифорович, әллә ниләр сөйләшмик әле. Син әле бу бишьеллыкта гына түгел, икенчесендә дә эшләрсең. Бергә-бергә

яшәрбез. Без бит инде хәзер — автозаводныкылар, без бит инде рухи туганнар синең белән,— дип тынычландырырга тырышты.— Бетерик бу сүзне...

— Юк... Хәер, хәзер бетерәбез, Мирас кадерлем, бетерәбез... Син дөрес әйтәсең, без биредә рухи яктан да, кан ягыннан да туганлаштык. Татар халкының эшчән халык икәнлеген белә идем. Алар Вилюйдагы һәм бүтән барлык төзелешләрдә дә сынатмады, иң авыр эшләргә алыналар иде... Хәзер инде мин алар белән якыннан таныштым, культураларын, көнкүрешләрен күрдем. Әнә кияү дә сезнең кеше булыргарак тора... Анысы ярый... Чаллыяр ул, Мирас, безнең, минем төзелеш иде... Көмеш Алан һәм атом электр станциясен әйтәсе дә юк, Карабуга заводларын, сизеп торам, миннән башка төзерләр, ахрысы...

— Зинһар, туктатыйк әле бу сүзне, Вергилий Никифорович, туктатыйк... Ярый, алайса, мин китим инде, икенче тапкыр, синең күңелең тынычрак чакта сөйләшербез...

— Юк инде, Мирас, мин сиңа тагын шуның хәтле керешләр сөйләп утырырга җыенмыйм. Иң мөһиме шул — син каршы килмәсәң, Фазыл Айбулатовның берләшмә җитәкчесе урынына әзер икәнлегенә мин кул куям һәм сездән, иптәш Борнашев, шуны истә тотуыгызны үтенәм,— диде ул кинәт «сезгә» күчеп.— Иң лаеклы кандидат ул. Дөрес, аның характеры үзенчәлекле. Ләкин бит характерсыз кеше булганчы, булмаганы яхшырак, шулай бит... Мин... мине берәр урын табып берләшмә җитәкчесенең консультанты итсәгез... шушы төзелешләрдән аермасагыз...

Шул вакыт бүлмәгә баш врач һәм аның артыннан шәфкать туташы килеп керде. Баш врач ашыгып Дикопольцев яткан урынга атлады һәм килә-килешкә үк:

— Мирас Гайнанович, зинһар өчен чыгыгыз! Сез нәрсә, кеше рәтләп тернәкләнеп тә бетмәгән, аңларга тиешсез... — дип Борнашевны битәрләргә кереште, тиз генә барып Дикопольцевның беләгеннән тотты, йөрәк тибешен саный башлады.

— Әйе, әйе, зинһар гафу итегез, зинһар гафу итегез...— Борнашев урыныннан торып басты, Вергилий Никифоровичның сул кулыннан тотып: — Терел, тизрәк терел, Вергилий Никифорович, тизрәк терел,— ди-ди палатадан чыгып китте.

Тагын өч-дүрт минуттан ул үзенең «Волга»сында утыра иде инде. Ләкин аның уйлары Дикопольцев белән баягы сөйләшүне дәвам итә иде шикелле.

— Җир йөзендә яшәү, кем шулай дигән соң әле, үзе үк вафатыңа таба бару дигән сүз,— диде ул үзенә-үзе.— Һәр кеше яшәү дәвамында үзенең соңгы чиге — үлеменә таба бара... Ул үз шәхесен үзенең балалары, игелекле эшләре, ягъни килер буыннарның хәтерендә мәңгеләштерә. Җирдә яшәүне һәм үлемгә таба хәрәкәтне дәвам итүнең ике юлы барлыгы мәгълүм. Беренчесе — яну, икенчесе — пыску. Икенчесен сайлаган кеше гомере буена зәңгәр күк йөзенә корым җибәреп, аны пычратып йөри — монысы мещаннар, вак җанлылар өлеше. Ә Атакай-Бабакай кебек көчле рухлы, ашкын йөрәкле кешеләр юл башыннан ук януны сайлый һәм соңгы сулышына кадәр шуңа тугрылыклы була. Дөрес, януның да төрле юллары бардыр, бәлки... Берәү — яна һәм үзләре белән башкаларны да яндыра, хәтта... хәтта бөтен кешелекне яндырырга да әзер. Икенчеләр — бары тик кешеләр хакында уйлап яна, үзе янган җылыда башкаларны җылытырга, аларга юл күрсәтергә тырыша. Данко шикелле. Вергилий Дикопольцев янып яшәүчеләрнең шундыйларыннан...

## 3

Берүзенә «үҗәт», «киребеткән», «хәйләкәр татар» кушаматлары булган Айбулатов башы исән чыкмастай бәхәсләргә ташланып, урыны һәм архитектура матурлыгы өчен дау кузгатып, аннары Калатау итәгендә

рөхсәтсез сала башлаган яңа шәһәр — Көмеш Аландагы беренче биш йортның тапшыруга әзерлегән карап йөри иде.

Гаяр Сәфәров, парторг Зөлфәт Зәйнуллин, бригадирлар Варвара Колобова һәм Гөлфирә Шәйхетдинова (эшкә чыгуына өч көн) буяу, обой келәе, цемент исе аңкып торган, кайчан гына төзелеш чүп-чарына күмелеп күңелләрне кайтарырлык шыксызлыкка чумган, бүген инде кияүгә чыгасы кыз шикелле купшы киенгән бүлмәләргә керәләр, эшләнеп бетмәгән эшләрне берәмтекләп барлыйлар иде.

Иртәгә, Бөек Октябрь бәйрәменә багышланган тантаналы җыелыш алдыннан, бирегә дәүләт комиссиясе әгъзалары киләчәк.

Көмеш Аландагы беренче торак йортлар яңа хуҗаларны кабул итәргә әзер. Шуңа карамастан, Айбулатов кашларын җыерып, тавышын тагын тамак төбеннән чыгарырга тырышып, әле анда, әле монда гаеп таба, аларны «Кичекмәстән бетерергә!» боера.

Өченче йортның беренче подъездагы бүлмәләренә линолеум җәючеләргә ул аерата усалланды.

— Бу идәндә аяк белән генә түгел, күкрәк белән шуышып йөрүчеләр дә булыр, сез моны аңлыйсызмы? — диде ул Сәфәровка карап. — Шулай булгач, ни өчен монда Калатау тезмәләрен торгызыдыгыз? Ни өчен дим мин сезгә? Карап-карап торам да, иптәш Сәфәров, сез җыелышлар уздырырга, күбрәк сөйләргә күнегеп киткәнсез бугай. Эшнең җаен оныткансыз...

Сәфәров дәшмәде, бригадирлар исә идарәнең хәзергә вакытлы житәкчесенә төбәп әйтелгән һәр кимчелекнең үз гаепләре икәнлеген күреп, әлеге «таулы-чокырлы» идәнгә карап ни әйтергә белмичә торалар. Чөнки беләләр, каршы дәшү Айбулатовның ярыйсы гына күтәренке кәефенең эзен дә калдырмаячак.

Беренче каттагы өч бүлмәле квартираны караганда Айбулатов аерата тузынды. Чөнки кайсыдыр вөҗдансызы өстәге катта су кранын ачык калдырып линолеумны бөтенләй харап иткән. Обойны тиз алыштырдылар, идәнгә вакыт җитеп бетмәде.

— Кичекмәстән алыштырырга моны, а-лыш-ты-рыр-га! — диде Айбулатов бу юлы инде чыгырыннан чыга язып.

Сәфәров аның артыннан иярде, башкаларга «Калыгыз»,— дип кулын изәде.

Ак мамык сибелгәндәй аклыкка күмелгән тирә-юнь, берсеннән-берсе матуррак киенгән өр-яңа йортлар тәэсир иттеме, әллә бүтән берәр нәрсәме, һавага чыккач Айбулатовта баягы ачуының эзе дә калмады.

Яралып килгән киеренкелек таш өстеннән тәгәрәп төшкән дулкын сыман юкка чыкты. Сәфәров, урамдагы яктылыктан күзләрен яшерә-яшерә әйтергә ашыкты:

— Бүген үк алыштырырбыз, Фазыл Артышевич, борчылмагыз, үзебез өчен бит...

— Үзебез өчен... үзебез өчен дисең диюен, ә үзең, иптәш Сәфәров, Чаллыярдагы квартираңны тапшырырга ашыкмыйсың. Хәер, ике хатынлы кешегә шулай кирәктер, бәлки, кем белсен... — дип Сәфәровның авызын йомарга мәҗбүр итте Айбулатов. — Монысы янында торасың, тегесен дә онытмыйсың... ә?

— Соң, Фазыл Артышевич, сезгә мәгълүм ләбаса, мин түгел, мине ташлап чыгып киттеләр, өйдә идән юарлык чүпрәк кисәге дә калмады...

— Миңа бик яхшы мәгълүм дә бит, за-кон-лы хатынның җалу белән кергән, иптәшләр беләдерме-юкмы?

Сәфәров бирешергә уйламады.

Шул вакыт ишектә Гөлфирә күренде. Аның өстендә башкаларныкы кебек үк буяу һәм акбурга манчылып өлгермәгән киҗе-мамык куртка һәм шундый ук чалбар, яулыгы муеныннан урап бәйләнгән, ныгып җитмәгән аягына ярдәмгә кыска таяк тоткан иде. Ул бераз аксабрак атлый-атлый Айбулатов белән Сәфәров яныннан узып китмәкче булган иде, аңа:

— Син, Гөлфирә, күрмәмешкә салынма. Кил әле бире. Тукта... Тукта дим мин сиңа... Менә шулай... Больничныең беттеме соң әле синең? Врачлар эшкә чыгарга рөхсәт иттеме? — диде Айбулатов һәм җавап көтеп тормастан: — Бу эшегез... уйланылган булса, берегезгә берегез таяныч булырлык булсагыз...

Шул чакта Кама ягыннан җылы якларга соңга калыбрак китеп баручы киек казлар төркеме күренде. Алар бөтенләй көтмәгәндә:

— Кыйгак-кыйгак-кыйгак! — кычкырышып, аэродром тасмасына турылап килгән көмеш лайнер сыман түбәнәя башлап, шәһәр өстендә тулы бер әйләнеш ясадылар да берәм-берәм Калатау башындагы маяк янына төшә башладылар.

— Әнә, күрәсезме, киек казларны? — диде Фазыл Айбулатов туган якларыннан китеп барышлый соңгы тапкыр көч тупларга дип җиргә төшкән кошларга ымлап. — Сезнең бәхетегез дә соңга калып килгән бәхет. Кем әйтмешли, соң булса да уң булсын. Чын күңелдән котлыйм сезне, дусларым!

Гаяр белән Гөлфирә һәм баскычтан аллы-артлы чыккан Зөлфәт белән Варя Колобова беравыздан диярлек әйттеләр:

— Рәхмәт сезгә, Фазыл абый!

Айбулатов Калатау башына төшкән киек казлар ягына тагын бер тапкыр карап алды да күкрәген тутырып сулады һәм әйтте:

— Белегез һәм онытмаска тырышыгыз: бәхетегезне Калатауда, яңа Көмеш Аланда таптыгыз. Сез — беренчеләр! Сез, яңа шәһәрнең иң беренче йортларын салу белән бергә, анда яшәячәк гаиләләрне туплап, беректереп торучы өлге булырга тиешсез. Моңа исә үз язмышына нык ышанган кешеләр, аның өчен гомер буена көрәшүчеләр генә ирешә ала. Мин ышанам: Калатау нигезендә барлыкка килгән шәһәр дә, гаиләләр дә нык булыр. Озакламый борынгы тау күкрәгендә яшеренгән яшен ташы да ялтырап яшьнәр, яшәү кадерен белгән кешеләр акылына буйсынып, аллы-гөлле чаткыларын Көмеш Алан тәрәзәләре аша ерак-ерак офыкларга сибеп торыр...

Яңа гына сибәли башлаган кар төймәләре, бу сүзләрнең чынлыгын раслагандай, тирбәлә-тирбәлә җиргә таба төшәләр, әйтерсең, алар да яңа шәһәрнең яңа кешеләренә сыенып иркәләнәләр, бетмәс-төкәнмәс бәхет телиләр иде.

1982—1984 еллар.

*Дубулты — Брежнев — Переделкино.*

## *Роберт Әхмәтҗановка 50 яшь*



Танылган шагыйрь, 1965 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы Роберт Вәли улы Әхмәтҗанов 1935 елның 1 апрелендә Татарстанның Балык Бистәсе авылында туган. Урта мәктәп тәмамлагач, Казан педагогия институтының тарих-филология факультетында укый, аннары Астрахань өлкәсендә — Җәмәле мәктәбендә балалар укыта; «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре» газеталары редакцияләрендә әдәби сотрудник, М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында әдәби бүлек мөдире булып эшли.

Роберт Әхмәтҗановның беренче шигырь китабы — «Егерменче яз» 1958 елда басылып чыкты; хәзер ул — татарча һәм русча уннан артык китап («Кызыл усаклар» 1966, «Идел-йорт» 1972, «Хәтер елгасы» 1980 һ. б.) авторы. Шагыйрьнең «Таш елады», «Фидаи» кебек балладалары һәм «Йолдызстан», «Уйна, улым», «Таш аргамак», «Сонгми» поэмалары укучыга яхшы таныш, шулай ук аның очерклары, тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләре дә дөнья күрде.

Каләмдәшебезне редакция һәм журнал укучыларыбыз исеменнән 50 яше белән котлап, бу санда аның «Сәхипҗамал» дип исемләнгән яңа поэмасын урнаштырабыз.

# Роберт Әхмәтҗанов

# СӘХИПҖАМАЛ

*Күр, ничек иртә кояш чыкса,*
*җиһанда нур тула;*
*һәр күңелләр нурланадыр,*
*чыкса Гыйззәтуллина.*

Г. Тукай

### I

Казан өстендә болытлар,
гүләп тора ак диварлар;
Казан суы өсләрендә
оча көзге акчарлаклар,
тавышлары ташка үтә!

Петропавел чиркәвенең
чәукәләре кыш алдыннан
соңгы вираж ясый күктә...

«Юлларымда калыкканнар,
ничек өреп аударасы?» —
котыра җил. Очып бара
Сөембикә манарасы —
гомерләрдән гомерләргә,
очып бара Тарих аша!

Көзге күктә кәрван-кәрван
теткәләнгән болытлары...
Идел көзгесенә карый
көзге Казан, туган Казан...

Казан берни онытмады:
бер мизгелгә артка чигеп,
бүгенге көн үткәннәргә
урын бирә күз алдында.

...Вознесенский буйлатып
шаулый тояк тавышлары,
уза погонлы җайдаклар,
очкын чәчә дагалары...

Александр мәйданында
зеңләп куя өзәнгеләр.
Укшым-укшым кан шикелле
яфрак коя өрәңгеләр.

Рәшә кебек пәйда була
ютәлләгән кярханәләр,
сау эшчеләрне кайнаткан
иске сабын заводлары;

җил китерә Бакалтайдан
йөкчеләрнең авазларын...
Ай да, бизгәк тоткан кыздай,
карый моңсу чарлагыннан.

Агыла «көфер почмаклары»,
нотыклары, вәгазьләре...
Ишетелеп киткән сыман
үткәннәрнең «Яшәсен!» һәм
«Сау бул!» дигән авазлары.

Ишетелеп китә чаттан
бутышникның сыбызгысы,
җигүле ат борылып керә
Мәскәвески урамына,
шагыр-шогыр көпчәкләре...

Апуш чүккән арба төбе...
Ил түрендә куылып йөри
фида җаннар, нәфис җаннар...
Бер тәрәзәдән моң агыла:
«Кем белер кадереңне и...»
Сәхипҗамал!

II

Казан өстендә болытлар,
гүләп тора ак диварлар.
Казан суы өсләрендә
ерткаланган афишадай,
оча көзге акчарлаклар...

Утларын кабызды Казан,
бар кәченә яктырды ул,
кемне кәтә, кемне якты
тамашага чакырды ул?

Мәйдан тоташ сәхнә гүя,
рампа утлары кабынган...
Бер күләгә менеп килә,
килә Черек күл ягыннан,
тамак кыра, таяк тавышы;
үзе әле якынлаша,
күләгәсе, мәйдан тутырып,
узып китте мәйдан аша.

— Әй, чал карчык, син кем?— ди җил,
ә ул берни эндәшмәде,—
хәсрәт эчкән Тугзакмы син?..
Учма-учма чал чәчләре
тузгып чыккан, ап-ак шәле
сыйпап килә мәйдан ташын.
Каберлектән киләсеңме?
Әй бичара...

Таяк тавышы
тора мәйдан ташларында
бүгенгедәй.

Акрын гына, өрәк төсле,
атлаганы сизелми дә,
узып китте мәйдан буйлап
ак күләгә, озын шәүлә,
таягына таянган да...

Узды шәүлә, озын шәүлә,
ак диварларга елышып.
Аңа балкып карап калды
«Дворяннар җыелышы».

Узды уңга, узды сулга,
тыкрыктагы таш баскычтан
күтәрелде... Сөялде дә
язды һуштан.

Хәлсез бармак кәчкә-кәчкә
ак төймәгә баса алды.
Ачылып китте гүя дөнья,
гүя тулы гасыр үткән,
гүя мәйдан аша түгел,
гасыр аша килеп җиткән.
Ачылып китте якты ишек,
өйдәгеләр шаулаштылар,
аягына сарылдылар:
«Синме соң бу, Сәхипҗамал,
Сә-хип-җа-маал?!»
— Сәхипҗамал — Казанында!

## III

...Курче, нинди сәхнә Казан!
Декорацияләре дә
әзер килеш, тот та уйна,—
бөтен Россияләрендә
бер генә ул моңлы Казан,
бер генә ул нурлы кала.
Кемнәр уйный, кемнәр елый,
кем көрәшә гомере буйлый,
үз йолдызын үрелеп ала...

Кемнәр сүнә, кемнәр тунә,
кемнәр күнә тук язмышка.
Шундый итеп уйнады ул.
балкыды ул мең балкышка!
Мохтаҗмыни ул алкышка?

Алкышлады аны заман...
Бүгенгә ул Казанында
үзе кайный! Кайнатты ул
миллионнарны заманында!

Волжская! Идел кызы!
Көтә Ижау бүген аны...
Мутиннар вә Кариевлар,
дер селкетеп бу дөньяны,
уйнадылар үз-үзләрен
бөек заман каршысында.
Иленә гашыйк Җан-Таһирлар
Җан-Зөһрәләр — барысы да!

Сәйяр җаннар — юлда әле,
Юлда — «Сәйяр» арбасында,
бүген — «Сәйяр» арбасында,
иртәгә — «Нур» сәхнәсендә
үз-үзеңне табасың да
юл тотасың яңасына —
гомер буе сәйярлеккә!—
«әйдә, халыкка хезмәткә,
хезмәт эчендә йөзмәккә»,
яфрак эчендә йөзмәккә,
яфрак булыйк арасына,
керикләче дәвасына!

Курче, нинди сәхнә Казан!
Уйналадыр Яңа Заман.

## IV

Халык тарихында олы юлга —
зур сәфәргә чыга Театр.
Кан елатыр еллар алда синең,
юлың сикәлтәле, eрактыр!

Әмирханның киңәшләре истә:
милләт кызы, сәхнә — синең эш.
Куй, шауласын «кәфер почмаклары»,
ирләр уйный хатын-кызлар ролен,
бүгеннән соң менә син тиеш!
Киңәшләре истә Галиәсгарнең,
соклануы истә Тукайның...
Сәхипҗамал, шул сәхнәдән гайре
ни шатлыгың синең, ни кайгың?..
Сәфәр чыкты Театр... Зур сәнгатьнең
почмаклары алда, түрләре!
...Күкшелләнә ерак офыкларда
Академиянең үрләре.

V

— Сәхипҗамал, җиткән, күпме юдың
Апанайлар табак-савытын?
— Бәлки сине бай кияүгә димлик?
Иртә киден тормыш камытын.

Ыспай егет, кара мыек белән
чәчегезне бәйлик, үскәнем!..
Сәхипҗамал сизә иңнәрендә
зур очышка канат үскәнен...

Әрҗәсен бирмиләр,
кияүгә димлиләр,
бирмиләр киемен,
биклиләр йозакка.
— Җүнлерәк яшәрсең,
кияүгә бар, җүләр.

*— Ачыгыз ишекне,*
*һич кермәм тозакка!*

— А, ничек байыйлар калфакчы кызлар,
нинди бай кияүләр баш имиләр!
Синең сүзне көтә яучы-димче.
Карасана, син бит яшь димиләр...
Килгән егет, бар да олы купкан,
бирнәләрең синең, һай, кичекте,
Тора да кыз: «*Кияү — Театр түгел,*
*алыштырасым юк,*
*ач ишекне!*»

Ач ишекне, апа, кеше булсаң,
ач ишекне, көтә юллар алда:
ач ишекне, тормыш, киң дөньяга,—
ак канатлар үсте, тоям җанда!

— Калфак бирәм сиңа, энҗелесен...
— Кагылма син, толчок, тиң түгелсең!
Театрмы, әфиюн сатучымы —
ачыкланыр — алда Көн беленсен!

## VI

Җыеныгыз, көтә Мәдәният,
өч тиенгә тамак ялгасак та,
Син, Кудашев, сатма чалбарыңны,
бу вокзалдан алга бармасак та.

Җыелдылар «Сәйяр» әһелләре:
— Таралабыз, я хуш, Сәхипҗамал.
Спектакль кабул ителмәде,
акча бетте, рәт юк тамак ялгар.

Җыелдылар «Сәйяр» әһелләре:
Кариев та тирән уйга баткан...
Әлфиректан әлмисакка илткән
Сәнгать юлы төшә, һай, кыйбатка!

— Җыеныгыз, көтә мәдәният,
Локман, Ильяс, Кари, Гыйлаҗ, Барый...
— Сәхипҗамал туташ, сез — кыз бала,
ир-егетләр ич без, безгә — ярый...

Чалбар сатып түгел, ат сатып та
җитеп булмас иде вакытында
Олуг сәнгать дигән кыйблаларга,
бу җигелү авыр — хакы шунда!
Ничек сезне саклап калыйк икән
ач-ялангач итми, Волжская,
Зөләйха вә Фәхерниса туташ?
Юлга чыктык,
иш беребез җитми, Ильяс кая?

Берәм-берәм авыл, калаларда
сибелделәр, кушылдылар тагын.
Калмыйк әле, син биредә икән,
шул арбада, Сәхипҗамал җаным!
Бер арбада, без «Нур» арбасында
киләчәккә үтик әле тагын...

Кышын кышлап, юлда җәен җәйләп,
килеп чыктык Өфе, Чиләбегә...
Чиләбедә уразага эләктек,
туры килер озак чиләнергә.

Ни эшләмәк кирәк, «гөбернатыр»
рөхсәт бирер, бәлки, бераздан соң,
Ничәнче көн инде, ирексездән,
театр да тота «ураза»сын.

## VII

Менә... килеп җиттек. «Без — монда» дип,
яз афиша фәлән чатларга.
Ява яңгыр, арба тәгәрмәче
ыңгыраша ерак якларда...

Җаек, Өфе, Мәкәрҗәләр аша
бара ширкәт, җилдә тирбәлеп.
Бара Театр, кыен мәгърифәтнең
биштәрләрен иңгә күтәреп!

Бара Театр халык каршысына,—
кул чапмыйлар, дустым, елыйлар...
«Сәхипҗамал, кайда Кариев?» дип,
аягыннан егып сорыйлар...

«Без үзебез инде зур булдыкмы,—
без үзебез инде «Нур» булдык.
Нур төшәме бездән күңелләргә?
Нур булдыкмы, әллә... хур булдык?..»

— Сәхипҗамал, уйнап күрсәт әле
искитмәле итеп тормышын!
Ир-егетләр чәчелә төрле якка,
ник атыңны туры тотмыйсың!?

— Сәхипҗамал, кая китте Ильяс,
кая Мохтар, кая Тарханов?
— Олы юлда бар да, уртак юлда
Театр ул бетмәс таркалып!

...Бара Театр, чакырым баганалары
атылып кала озын юлларда.
Ярты юлын уза сәйяр булып,
әверелеп аннан нурларга.
Сәйяр була, күз яктысы була,
ил яктысы олы сәхнәдә.
И, талантлы тормыш-спектакль,
ия икән олы мәгънәгә!

Сәнгать бөек! Түбәләре — күктә.
«Арыдым» дип, тешең агартма.
Барып җит шушы хакка соңгы
калфагыңны салып ломбардка[1].

## VIII

Менә җәннәт! Сәхипҗамалкаем,
чакыралар сине табынга.
Ташла театрны, күч җәннәткә,
аша да эч ять-яшь чагыңда!
Табын сыйлы. Сылу сине сыйлый,
күркә кебек бугаз киереп,
иркәчләре килә, шампан кайный,
коч ярларны, яшә сөелеп!

Өстериләр аны сыйлы түргә:
менә тормыш, менә театр!
И, замана, килмәдем табыныңа,
тормыш — сәхнә, шуны күрә тор!

---

[1] ...олжская ширкәт калфагын да ломбардка салган булган. Артистканың истәлекләреннән.

— Фәкыйрьлектән сине йолып алам,
менә шампан, кайный ак күбек.
Син яшь кызсың, йөрмә дөньясында
гидайларны төяп ат кебек!

Назлар кирәк синдәй нәзкәй билгә,
йомшак түшәк, сеңел, түшикме?
Күтәрелә, тора ят коллардан
СӘХИПҖАМАЛ:
*— Ачыгыз ишекне!*
*Ачыгыз ишекне сез ак дөньяга,*
*Театрга, пәрдә, күтәрел!*
*Энҗе калфак дуслар башында дип,*
*Мәдәният таҗын йөртә бел!*
*Ачыгыз ишекне сез, мещан җаннар,*
*сезләрдән без сөяк көтмибез.*
*Ач булса да, горур безнең халык,*
*без тән белән сату итмибез!*
...Бара Театр, бара, төйи-төйи
юл уңае рухи байлыкларны.
Әкиятләр юл бирәләр!.. Әйдә,
гизеп кайтыйк Мәскәү, Җаекларны!

Узыйк әле алга, офтанмыйча,
юл яктыртып кыен чорлар аша.
Бу дөнья бит үзе бер театр,
халык рухы — үзе бер тамаша!

## IX. Сәхипҗамалның ак шәле

Кыйбла йолдыз каршысында,
Җил-җил тибрәтеп чукларын,
чакыра, әйди оныкларын
биек, якты офыкларга!

Сәхипҗамалның ак шәле
ерак еллар томанында,
Киек Казлар юлы сыман,
сузыла якты кыйблаларга...
Шул ак шәлне җилләр алды,
илтеп дәрьяларга салды,—
мәхәббәте дәрьясына!

Төнне яктырткан шул ак шәл,
балкып татар дөньясында,
иңбашында сылуларның
якты сагыш, якты моңдай,
йомшак наздай сузылып ята,
җил-җил килеп чакыра алга!

Татар хатынының хәле
кара шәлдәй сөйрәлгәндә
инкыйлабка илткән юлда,
Сәхипҗамалның ак шәле
мәгърифәткә алып чыга.
Караңгылык патшалыгын
үтәдән-үтә яктырта

якты образ — Катерина.
Сәхипҗамал-Катерина
ерак еллар томанында
тоныкланмас хәтер инде!

Сәхипҗамалның ак шәле
зур бирнә ул көрәш-туйда
Ил кызының батырына!
Сәхипҗамалның ак шәле!
Саубуллашып китеп бара
ерак-ерак офыкларга...
Сагыну кала оныкларга.
Сәхипҗамалның ак шәле,
пакь йолдыздай туташ шәле
ашып бара болытларга!..
Кемнәр уйнар Яңасында?..

## X

...Татар зиратында көз. Пәрәвез
керфекләргә сарыла. Барам шуннан —
эзләп соңгы йортын. Комач кызыл
карга миләшләре арасыннан.

Афишалар укып йөриммени,—
укып йөрим ташка язганнарны...
Кариевта булам. Ә бер чатта
килеп табам Ильяс Ашказарны...

Төп нигездән ерак китмәгәннәр —
күрше генә икән Тукай, Камал[1]...
Өянкеләр шавын тыңлап ята
гастрольләрдән кайткан Сәхипҗамал...

Гәүдәләре бирелә. Шәүләләре
тормыш сәхнәсендә, күк чатында.
Көз саргаеп тезен чүккән — ул да
сәҗдә кыла Татар зиратында!..

Зиярәт иттем мин дә күңелемнән,
фигылемнән мөмкин кадәресен...

Һәр калкучык йөрәк уртасында,
чирәменә чаклы кадерле соң!

## XI. Дога фасылы

Халык күзендәге карындыкны ачкан кебек,
Сәхнә пәрдәсен иң беренче күтәрүчегә
багышладым — кара мунчаларда, чыра кабызып,
театр сүрәләрен ятлаучыга,

[1] Ш. Камал.

аң орлыгын, яктылыкның нурын
күз карасы кебек саклаучыга;
Багышладым — сәхнә колларына,
өйдән-өйгә читек-калфак җыйган,
йөрәгенә кочак-кочак игелек сыйган
туташларга,
беренче театр улларына!

Багышладым — Галиәсгар җәнабләренә,
«Сәйяр» ширкәтенә, аннан «Нур»га.
Кариевлар шәрәфенә, Кудашевка,
зөбаныйлар җанны кыскан чорда
шәмнәр булып төнне яктыртучы
фида җаннар үткән кыен юлга!

Багышладым — беренче сукмакларда,
диндар әтиләрдән кача-поса.
рәеш киемен киеп, кысыла-кысыла,
залга кергән беренче тамашачыга.
Багышладым —
Бөек сәхнә хакына
читкә куеп тормыш нигъмәтләрен,
диндар күсәгенә каршы барган,
йөрәгенә йөз җәрәхәт алган,
чүпкә санап сарай зиннәтләрен
халык мәнфәгате өчен янган
фида җанлы сәхнә йолдызына —
милләтебез кызына —
Сәхипҗамал ядкаренә!
Багышладым олуг мәгърифәт юлында
гөлтләп янган гомерләргә.

Яшәсен һәм чәчәк атсын гомер бакый
Беренче Театр рухы күңелләрдә!

1984.

## Кави Латыйпов

# ЯШЬЛЕК РӘХМӘТЕ



Зөфәр эшләгән бригадада Ясәви күренгәләде, мотор детальләре тирәсендә маташты.

— Ни йомыш?— диде үсмер чакырылмаган кунакка.— Безнең бригадага күчәргә уйламыйсыңдыр бит?

— Үзем дә белмим... Бәлки, күчәрмен дә. Бездә акча эшләп булмый. Хәер, теләгән кеше акча таба ала.

— Ничек?

— Русча әйткәндә, син молодо-зелено... Менә акча,— диде Ясәви, мотор детален күрсәтеп.— Мин моны, мәсәлән, үзем дә сатып алыр идем, юк. Дефицит!

— Көймәң бармы соң?

— Бар иде, кем әйтмешли, комга терәлде.

— Ничек алай?

— Моторы ватылды. Бер деталь кирәк иде, пүчтәк инде... Кесәгә салам. Мин алмадым, син күрмәдең. Әбиеңә сәлам әйт!..

Берничә көннән соң Ясәви тагын Зөфәр янына килде.

— Я, план үтәлдеме?— диде ул.

— Үтәлә шикелле.

— Коллективныкымы, үзеңнекеме? Һәркемнең үз планы булырга тиеш.

— Ә минем андый планым бар, шәхси йөкләмә алдым.

— Сүз ул хакта бармый, син молодо-зелено шул әле...

— Әйтсәң, аңлаешлы итеп әйт.

— Алайса, тыңла. Шәхси байлык турында ишеткәнең бармы синең? Хәзер күпләр шул хакта кайгырта.

— Син дәме? Әйтәм, урланган детальләр белән көймә моторы җыймакчы буласың.

— Стенаның да колагы бар, кычкырмый гына сөйлә. Хәер, мин кешедән курыкмыйм. Мин кесәгә салган детальләр артык бит алар. Яратам мин техниканы... Кулларым алтын! Беләсең килсә, кайчандыр самолет моторы җыю цехында эшли идем мин. Китәргә куштылар... Минем белән бергә эшләүчеләр хәзер җаваплы постларда, ә бит мин алардан башлырак идем.

— Кулларың туры идеме соң?

— Ташла, һәркемнең бармагы үзенә кәкре.

— Шулай шәхси байлык җыясың, ә?

— Мин җыям, ә син теләсәң нишлә!.. Мин алмадым, син күрмәдең... Хуш, әбиеңә сәлам әйт!..

Берничә деталь кыстырды да китеп барды Ясәви.

«Әйтергәме, әйтмәскәме?— дип аптырады Зөфәр.— Каравылчы бар ич, ул шөгыльләнсен. Я молодо-зелено диярләр...»

Бригадаларга бүленгән цехта һәрбер эшче аерым, үзе генә мотор җыйды. Зөфәргә көнлек норманы үтәр өчен бер көймә моторы кирәк иде. Детальләр санап бирелмәде. Ясәви шул хуҗасызлыктан файдаланды. «Каравыл ни карый?»— дип борчылды үсмер.

Зөфәр эте белән паркта прогулкада йөри иде. Агачлар арасында берәү күренде: нәрсәдер күтәргән, ләкин төгәл әйтеп булмый, өсте капланган... Үсмер таныды — Ясәви иде бу. Ясәви узып китим дигәндә генә, Зөфәр:

— Тукта-а!— диде.

— Туктамасам, нишләрсең?

— Тукта, дим!

— Туктыйм алайса...

— Җилкәңә нәрсә салдың?

— Үз җилкәм, ни телим, шуны салам.

— Әйтәсеңме, юкмы?

— Молодо-зелено... Аннары, брат, синең белән сөйләшеп торырга вакыт тыгыз. Хуш-ш!..

— Милициягә баргач хушлашырсың, Ясәви.

— Син нәрсә, җүләрләндеңме әллә?

— Киресенчә, акыл керде.

Ясәви китә башлады.

— Этне җибәрәм!— диде үсмер, кисәтеп.— Әйдә, яхшы чакта милициягә...

Зөфәр этен бәйдә тоткан килеш Ясәви артыннан атлый бирде.

— Сулга-а!— диде үсмер.

Ясәви тыңларга мәҗбүр булды. Күпмедер ара җәяү баргач, Ясәви:

— Троллейбуска утырыйк,— диде.

— Тәпиләп тә барырсың, егет.

Тагын урам буйлап җәяү генә киттеләр. Милиция бүлегенә якынлашкач, Ясәви: «Бәлки, кирәкмәс»,— диде. Ләкин Зөфәрнең карары нык иде.

Дежурный янына кергәч, Зөфәр сөйләп бирде.

— Көймә моторын каян алдың?— диде милиционер Ясәвигә.

— Каян булсын, магазиннан, иптәш начальник.

— Кайсы магазиннан? Моторның паспорты бармы?

Сорый торгач, кем әйтмешли, фактлар белән стенага терәгәч, Ясәви дөресен әйтергә булды.

— Син жулик!— диде милиционер Ясәвигә.— Ә сиңа, егеткәй, рәхмәт.

— Человек меняет кожу,— диде Ясәви үсмер турында русчалап.

Механика мастерскоенда мотор өчен кирәкле бер деталь ясап маташканда, Зөфәр янына мастер Тумашыйлов килде.

— Сине, Мохтаров, кадрлар бүлегенә чакыралар. Җиденче бүлмәне беләсеңме? Белсәң, яхшы, шуннан шалтыраттылар.

Мастер хәйләкәр генә елмайды да китеп барды. Кулына микрометр тоткан килеш Зөфәр уйлана калды: «Җиденче бүлмә! Прогулчылар, хулиганлык эшләүчеләр, айныткычка эләгүчеләр, дебоширлар, хөкемгә тартылучылар, хезмәт дисциплинасын бозучылар — һәммәсе шушы бүлмә аша уза. Ә бит Зөфәрнең айныткычта булу түгел, җәмәгать тәртибен дә бозганы юк. Дисциплина, эш буенча үзен мактап кына телгә алалар. Шанлы җиденче бүлмәгә аның ни өчен керәге булды икән, ә?..

Зөфәр баш ватты, әмма җавап таба алмады. Цехта токарь, фрезерлау, шомарту станоклары эшли иде. Ләкин үсмер аларның гөрелтесен ишетмәде. Барысы да бетте, онытылды дигәндә генә, Тумашыйлов хәйләкәр генә елмаеп хәбәр итә. Ничәмә кеше, ничә күз карап торганда, бар тавышына кычкырып, стеналар ишетерлек итеп... Станоклар гөрелтесе бу хәбәрне цехтан цехка тарата шикелле. Алай гына да түгел, заводның тимер капкасыннан үтеп, хәбәр бөтен шәһәргә таралыр сыман... Эш киемен алыштырмыйча гына Зөфәр кадрлар бүлегенә килеп керде.

Инспектор чакырылган кунакка урын тәкъдим итте. Зөфәр теләртеләмәс урындыкның кырыена барып утырды. Һәм бүлмәдәгеләргә күз йөртте.

— Менә сиңа хат,— диде инспектор.— Заводка җибәрелсә дә, сиңа адресланган. Колониядән...

Өйгә кайткач, Зөфәр әлеге хат турында сүз кузгатты.

— Әби, сиңа бер сер әйтимме?— диде ул.

— Кызлар турындамы?

— Белмәдең... Мин Ясәвидән хат алдым.

— Булмас.

— Чыннан да шулай, әби. Ул миннән ярдәм сорый: завод коллективы мине порукага алсын, дип яза.

— Кешелеклелек хисләре уянды микәнни үзендә? Юк, завод теләсә ничек эшләсен, ә син нәрсәгә аның өчен борчыласың? Минем уемча, Ясәвинең кайтуына остазың Сөнгатулла да, мастер Тумашыйлов та каршы булачак.

Икенче көнне Зөфәр төрмәдә утыручы Ясәви турында остазына да әйтте.

— Үзең каптырттың, ә кайтарырга телисең,— диде Сөнгатулла абыйсы.— Аңламыйм мин сине, Зөфәр. Бу мәсьәләдә принципиаль булуың яхшы. Үкенмисеңдер ич?

— Үкенмим, әмма яхшылык эшлисе килә. Минемчә, кеше өчен көрәшергә кирәк. Үзең дә бит шулай өйрәттең.

— Анысы шулай. Ә бит Ясәви начар кеше, син моны үзең дә беләсең.

— Юк, ул хезмәт колониясендәге срогын үтәргә тиеш.

— Бу соңгы сүзегезме, остаз?

— Әйе, Зөфәр Мохтаров... Син мине гафу ит, кәеф шәптән түгел, иске яра ачылды, кан басымы да югары. Больницага керер идем, цехта, үзең беләсең, эш тагын катлауланды — план үтәлми!..

Зөфәр Ясәви турында цех начальнигы белән дә сөйләшеп карады. Ләкин юкка гына, ул катгый рәвештә каршы килде: «Җинаятьче өчен тагын җинаять эшлисем килми!»

Ясәвинең нинди җинаять эшләвен, аңа карата халыкның мөнәсәбәте нинди икәнлеген, ниһаять, Зөфәр аңлады һәм карандаш тотып җавап хаты язарга утырды: «Ясәви, синең өчен йөрәгем сыкрана. Шулай да үзеңне югалган кеше дип санамыйм, чөнки син миңа хат язарга батырчылык иткәнсең. Син — ут, ә мин — су түгел, кайчандыр көрешербез, аңлашырбыз. Ә хәзергә түз, срогың тулганчы түз, төзәлми кайтуыңа мин каршы. Мин синнән гафу үтенмим— ә син үтенергә тиеш: завод халкыннан, җәмгыятьтән, шул исәптән — миннән дә. Зөфәр Мохтаров...»

Ясәвигә язылган хатны кесәсенә салды да Зөфәр заводка китте — бу план дигәне соңгы вакытта бик тә гарьләндерде, үтәлми генә! Ә халык күпме тырышты, ял белми, төн дими армый-талмый эшләде. Тау кузгатырлык эш башкарылды, ә төп максатка ирешеп булмады. Электкеге иске техника белән мотор ремонтлау, эш күләме арту, хезмәт процесслары катлаулану — Зөфәр аңлавынча шул иде план үтәлмәүнең

сәбәпләре. Анынча халык такыр, шома юлдан барырга өйрәнгән, ә хәзер «буксовать» итә... Кем тартып чыгарыр? Кем алга сөйрәр?.. Эшчеләр үзләре, әлбәттә. Чөнки мондый мотор биредә генә ремонтлана, аны Зөфәрнең цехташлары башкара, задание аларга тапшырылган. Шулай да план үтәлмәүне производство сылтауларына гына кайтарып калдыру — дөрес үк булмас иде. Кайберәүләрнең уңыштан, кулларына акча күп керүдән башлары әйләнгән. Зөфәр моны сизә, күрә. Ремонтлау һәм реализацияләү планы өчен директор алдында баш-аягы белән җавап бирүче производство начальнигы, теләсә нинди бәһа белән план үтәлсен дип, капчыклап акча ташыган икән. Үзем тапкан мал түгел, әтинеке җәл түгел, дигән принцип белән эш итүче житәкче, казна акчасын эшчеләргә конфеттай өләшкән: өченче сменага калдыңмы — хезмәт хакына өстәмә биш сум, шимбә һәм якшәмбедә эшкә чыктыңмы — өстәмә ун сум! Айлык план үтәлешен өченче ункөнлек хәл иткәнлеген Зөфәр яхшы аңлый иде, чөнки беренче һәм икенче ункөнлектә эшкә аптыраган эшчеләр кулларын угалап йөрде, эшләрләр иде — детальләр юк. Тик егерме беренче көнне генә эшчеләр җиң сызганып эшкә керешәләр: ун көн рәттән мотор ремонтлыйлар, план үтиләр. Тәүлеккә ике-өч сәгать йоклап алалар, аягүрә тамак ялгыйлар. Инде унсигез яше тулган Зөфәр дә өченче ункөнлектә тоташ ике көн һәм төн эшләде, аннары өенә кайтып туйганчы йоклады. Икенче сменага эшкә барырга җыенганда, өйгә цех комсоргы Ләлә килеп керде: борчылу, һавалану йөзенә чыккан иде аның.

— Ни булды?— дип сорады Зөфәр.

— Сөнгатулла ага үлгән...

— Булмас, без аның белән әле кайчан гына җилләнеп эшләдек.

— Үлем рөхсәт сорамый икән шул, аныкы гел кинәт. Минем әти өстәл янында чәй эчеп утырганда вафат булды. Бәхил булыгыз дип тә әйтә алмады.

— Ә минем кадерле остазыма рәхмәт әйтәсем килгән иде.

— Соң инде.

Зөфәр остазы Сөнгатулланы җирләүдә катнашты: өченче дәрәҗә «Дан» ордены салынган нәни мендәрне тотып барды. Заводның тынлы оркестры матәм маршы уйнады.

Кызыл йолдызлы кабер янында бер егет басып тора, ул — Зөфәр. Бер кесәсендә Ясәвигә адресланган хат, икенчесендә остазы Сөнгатулла партия сафларына тәкъдим иткән рекомендация, анда мондый юллар бар: «Олы тормыш юлы телим мин шәкертемә, мин аңа коммунистларча ышанамын, ул коммунист исемен аклаячак...»

Зөфәр беренче остазы вафат булгач, күңелсезләнде. Илле тугыз яшьлек Сөнгатулла агай белән уртак тел тапкан иде ул. Зөфәр шуның өчен дә уңайсызланды: остазы исән чакта, аның кадерен белеп бетермәде кебек. «Кичер, гафу ит син мине, остаз. Бәхиллә син мине!.. Мин сине мәңге онытмам, гел горурланып сөйләрмен, яшьлегемдә генә түгел, картлыгымда да, чал чәчле булгач та. Матур исемең гел телемдә тибрәнер, якты истәлегең гел күңелемдә яшәр. Мәңгелек ут янында да син төшәрсең исемә, синең хакта уйлармын. Тезләнеп, җир-туфрагыңны үбеп ант итәм: ышанычыңны аклармын, хезмәт кешесе исемен дәвам итәрмен. Аңладым мин, горур яңгырый хезмәт кешесе исеме. Рәхмәт, остаз!.. Мин ятим үстем: әниемне беләм, әтиемне белмим. Син әти кебек кеше идең...»

Берничә көн кесәсендә йөрткәч, Зөфәр Ясәвигә дигән хатны почта ящигына илтеп салды.

## Ркаил Зәйдуллин

### Ана

Тәрәзәгә багып тып-тын гына,
Ул күз яшен юрый йолдызлардан.
Йокысыз төн. Төпсез күк йөзендә
Аның күзләредәй Ай кызарган.

Урамнарда өйсез җилләр йөри,
Өшеп куя ишек кашагасы.
Улын уйлый ана: нигә кайтмый,
Киеме бар микән, ашаргасы?

Бу изге сүз борынгыдан калган:
Туган нигезеңне онытмаска!—
Безме соң ул истә тоталмаган?..

Балаларга васыять, оныкларга!
Болытларга баккан әни тып-тын...
Ак каеннар кайный офыкларда.

### Гомеремнең гаҗәеп бер таңы

Аккош чаңраганы ишетелә.
Дөм-караңгы урман, учак төтене...
Гомеремнең гадәти бер төне.
Аккош чаңраганы ишетелә.

Гадәти бер төн бу. Менә тиздән
Яктылыкны алып килер җилләр.
Кошчык томшыгында чык тамчысы
Кояш белән кавышырга теләр.

Гамьнәремнең тәме иренемдә.
Тасвир итеп буламы соң аны!
— Сере нидә?— диеп сорау бирмә...

Ишетелә аккош чаңраганы.
Якты урман, учак төтене, тирмә.
Гомеремнең гаҗәеп бер таңы.

## Ә күкләрдә...

Җиребезгә әкрен генә иңә көн —
Сизәсезме күзгә кояш сеңгәнен?

Тамырымнан ага тынлык җай гына...
Изри бәгырь — хисләр кайта ярына.

Бәлки күңел шул халәтне сагынган?
Туа шигырь — ага сагыш җанымнан.

Шушы тынлык йөрәгемне сорады!
...Ә күкләрдә дулый йолдыз бураны.

## Күренеш

Дәү кеше, кеп-кечкенә әрем,
Алсу офык, зәңгәр күк гөмбәзе...

Дерелдәде әрем — исте җилләр,
Офыклар бер-берсенә йөгерделәр.
Һәм күк гөмбәзе егылды түбән,—
Әрем башын игән.

Өнме соң бу, төшме?

Зәңгәр офык, алсу күк гөмбәзе,
Зуп-зур әрем, кеп-кечкенә кеше.

Нигә шаккаткан соң?
Сәҗдәгә егылган кемгә?
Нинди сурәт
Әремгә эләгеп калган
Ул күк гөмбәзендә?

## Төнге әкият

Иделемнән бөркелә бер яктылык,
Аймы әллә төшкән аңа атылып?

Яктырып китте күк белән дөньялар,
Күңелеңә һәрбер нурын җыя бар...

...Җил йөгерде Идел-дәрья өстеннән,
Кемнәр килер тагын аның эзеннән?

Күмеп китмәкче дулкыннар шул айны,
Шашты алар, ә ай һаман елмайды.

Өзгәләмәкче булалар шәүләне!
...Аларгамы соң аңларга хәйләне?

Ай һаман шул, тынып калды җил генә.
...Идел-ярда сәҗдә кылам илемә.

## Бәхәс

Килеп керде тиз-тиз генә атлап,
исәнләште,
әйтте: «Йә, ни дисең?—
Искә төшердем дә яшәвемне,
килдем сиңа бәхәсләшер өчен».
Һәм тиз генә килеп утырды да,
китап киштәсенә
сәгатен салып куйды,
йөзен салып куйды һәм тотынды...
Онытылды вакыт.
Иң мөһиме — Вакыт онытылды.
Ә югыйсә һаман тәкърарлый бит.
Төн артыннан көн килә дим, һәрчак.
Каршы төшә: чыпчык дигән кош, ди,
бервакытта бөркет булмаячак.

...Һәм берзаман аңга килсәм: бер кеше юк,
иртәнге биш; кием утыра алда...
Шуның белән күпме гомер бәхәсләшәм, имеш.

Ә мин...
Ә мин тәмам чишенеп беткәнмен ич,
Калганмын бит шыр ялангач килеш.

●

*Агыла да болыт агыла*

*Х. Туфан*

Тәрәзәгә сарылдым мин —
Күңелем китте түгелеп:
Безгә ят түгел болытлар,
Болытлар безгә ят түгел...
Тәкърарлыймын: — Ни син, Кеше?—
Пәрәвездә минем сүзем
Чәбәләнде, чәбәләнде...
Ватылды идәнгә төшеп.
Борынгы, ирекле болыт
Дымлы иреннәре белән
Керфекләремә орынды —
Тәрәзә куйды сулыгып.
— Кеше икәнеңне, егет,
Онытма, онытма-а...—
Тәрәзә аша моңсу-моңсу
Пышылдадылар болытлар.

**Жан Миндубаев**

# ЮЛБАШЧЫ ЯШӘГӘН ГАИЛӘДӘ

Ульяновск шәһәренең үзәгендә «Йөзьеллык» исемле мәйдан бар. Билгеле ки, дөньяда әллә нинди бай тарихка ия урыннар күп, әмма «Йөзьеллык»— бөтенләй башка. Аның бинһая иркенлеге карашларны ерак-еракларга алып китә. Иделне, аның яр буйларын күрәсең. Чамасын белеп кенә искән дымлы җиле дә җанны иркәли сыман. «Йөзьеллык»! Шәһәр халкы бу мәйданга, дөнья пролетариатының даһи юлбашчысы Владимир Ильич Ленинның тууына йөз ел тулуны мәңгеләштерү ниятеннән чыгып, шундый исем биргән.

Мәйдан уртасында — Ленин Мемориалы. Мемориалның эченә үтсәң, гади генә бер йорт каршына килеп чыгасың. Стенасына: «Бу өйдә 1870 елның 10 (22) апрелендә Владимир Ильич Ульянов-Ленин туды» дип язылган. Олы юлның беренче адымы, димәк, нәкъ менә шунда ясалган.

Әгәр Ульяновскины апрель аенда килеп күрергә уйласагыз, шәһәрдәге бәйрәм рухын тоеп, сокланып туя алмас идегез. Язның бу шифалы ае, бигрәк тә Ильич туган көн гомуми тантанага әйләнә. Таң аттымы, әлеге тарихи мәйданга кешеләр агыла башлый: зур-зур предприятиеләрнең, мәктәпләрнең, башка учреждениеләрнең коллективлары, күрше шәһәр кешеләре, чит ил кунаклары... Кулларына чәчәк бәйләмнәре тотканнар. Ильичка! Аның һәйкәлен тагын да матурларга!

Яз төрлечә килә. 22 апрель дә гел кояшлы гына булмый. Яңгыр яварга, салкын җил исәргә, болытлар куерырга да бик мөмкин. Әмма шәһәрне биләгән шатлык хисен табигать хәле генә үзгәртерлек түгел. Шатлык, шатлык, шатлык! Аны син Ильич һәйкәле янында тантаналы рәвештә сакта торучы пионерлар йөзендә дә, шушы көнне сәхнәләрдән яңгыраган шигырьләрдә дә, эшчеләрнең хезмәт рапортларында да сизәсең. Җыр, музыканы әйткән дә юк. Үзәк мәйданга мең кешелек хор тезелә. Владимир Ильичның иң яраткан җырлары яңгырый. Кичке караңгылык төшә башласа, дөньяга шатлык китергән бер көнне озайтырга омтылгандай, шәһәр өстен гаҗәеп мул фейерверк яктырта. Дөньяга Ильичтай кыю көрәшче бүләк иткән борынгы кала серле нурларга күмелә.

Апрель аенда Ульяновскига көн саен меңләгән кунак килә. Даһи юлбашчы туган шәһәрне нәкъ шушы вакытта күрергә теләү нәтиҗәсе инде бу. Моны гадәти кызыксыну белән чагыштырырга ярамый. Кешеләрне тарихи чынбарлык, аны мөмкин кадәр дөресрәк күзалларга тырышу теләге мавыктыра. Ульяновскидагы Мемориал Ленин идеяләрен өйрәнүнең һәм пропагандалауның бер үзәгенә әйләнеп бара.

Бу комплекс 1970 елның апрелендә ачылды. Гаҗәп бер тантана булды ул. Әүвәлге көнне кичтән шәһәр күген кургашындай авыр болытлар басты. Җил. Салкын. Яз көне кебек тә түгел иде. Таң алдыннан исә барысы да үзгәрде дә куйды: кояш балкый, җилнең исе дә калмаган, күкнең зәңгәрлеге әле генә боздан арынган Иделне дә күгелҗемләткән кебек. Шәһәр үзе дә яшәреп, яңарып киткән сыман. Һавасы ук башка, сулыш алулары иркен, җанга рәхәт. Үзәккә якынайган саен, «Йөзьеллык» мәйданына җитәрәк, бу тойгы артканнан-арта бара. Иске Сембер каласына шундый да киң, матур мәйдан корып куйсыннар әле!

Бу изге урынның күркәмлеге әллә нинди зиннәтле бизәкләргә бәйле түгел, киресенчә, төзелешендәге җитдилек, тыйнаклык матур иткән аны. Чәчәк түтәлләре, хәтфә үлән, күк чыршылар... Ульяновлар гаиләсе яшәгән йорт янындагы каеннар шавыннан моң агыла. Дөньяга Володя Ульяновны тудырган йорт кешеләрне сәламли кебек. Килүчеләр исә арта бара. Монда ел саен миллион кеше булып китә. Миллион! Алар арасында кем генә юк: эшчеләр, колхозчылар, укучылар һәм укытучылар, хәрбиләр, пенсионерлар, студентлар, сәяхәтчеләр... Кайберәүләр «Йөзьеллык» мәйданына бөтенләй

башка шәһәргә узышлый, поездан поездга күчеп утырган арада гына булса да килергә ашыгалар.

Безнең илдә гыйбрәтле тарихы белән кешеләрне үзенә тартып торучы мәйданнар шактый: Кызыл Мәйдан, Революция мәйданы, Кышкы Сарай мәйданы, Марс кыры, Восстание мәйданы... Әмма аларның барысында да халык горур атлап йөрсен өчен кечкенә генә Сембер шәһәренең тын гына бер өендә Владимир Ильич туу кирәк булган. Һәм һич шик юк ки, еллар узган саен, барлык башка мәйданнарга иркенлек китергән бу мәйданның кадере арта барыр. Чөнки ул — Җирдә хөр яшәүнең беренче үрнәген күрсәткән бөек Ленинның тууына йөз ел тулуга багышланган мәйдан.

Монда һәрчак җанга рәхәт. Шулай да кичке сәгатьләрнең үзенә генә хас ләззәтләре бар. Чыршыларның куе ботакларына эңгер-меңгер оялаган. Гөл түтәлләреннән хуш ис бөркелә. Мемориал үзе дә бер мәл тагын да җитдиләнеп киткән кебек тоела башлый. Аның каршындагы көзгедәй бассейн суы шәфәкъ нурларыннан алланып ялтырый. Борынгы земский собрание бинасы (нәкъ шул йортта иң беренче тапкыр Сембердә совет власте игълан ителә) манарасының шәүләсе алсу бассейн яссылыгына гаҗәеп серлелек иңдергән. Элекке соры диварлы бина янында ап-ак мәрмәр Мемориалның маһабәт рәвештә калкып торуы тарихның нинди юлдан, кай тарафка атлавына ишарә сыман. Мәйдан гаҗәеп иркен, әмма бушлык юк монда. Мәйдан искиткеч матур, тик купшы түгел ул. Барысы да тирәннән уйланып һәм бик оста итеп башкарылган.

Ленин Мемориалында Сембер шәһәренең диорамасы бар. Рус дәүләтенең хәрби яктан бер таянычы төсендә 1648 елны салынган бу шәһәр, Владимир Ульянов гимназиядә укыган чакта, икешәр катлы вак-вак йортлардан, күп санлы чиркәүләрдән торган. Ильичның балачагы һәм үсмер еллары белән танышу әнә шулай Сембер тарихына сәяхәттән башлана. Фотографияләр, язулар, китаплар, замандашларының истәлекләре...

Йөз дә унбиш ел вакыт узган. Шәһәрдәге бу чор эчендә булган үзгәрешләрне исәпләп тә, хәтта күз алдына китереп тә бетерерлек түгел. Хәтта шул көенчә саклан-ган биналар яки башка әйберләр дә бүген инде башкача кабул ителәләр. Әйтик, Владимир Ульянов укыган гимназия бинасы яңартылганнан соң, аңа башлангыч класс балалары хуҗа. Ул андагы шатлыклы авазлар, ул укучыларның мәш килеп йөрүе,— гимназия белән ничек чагыштырасың?!

Шәһәр кешеләре Ульяновлар гаиләсенә кагылышлы һәр нәрсәне кадерләп саклыйлар, яңарталар, бу эшкә алынган рәссамнар мөмкин кадәр төгәл булырга тырышалар.

Элекке Мәскәү урамы хәзер Ленин исемен йөртә. Ул Идел буеннан башлана да аска таба, Зөя уйсулыгына сузыла. Монда йөзьяшәр агачлар да, кечкенә йортлар да, ишегаллары да үз хәлендә сакланып кала бирә. 58 нче йорт Ульяновларныкы. Бу — аларның үз гомерләрендә сатып алган бердәнбер өйләре. Гаилә 1878 елда әлеге йортка күченгән дә Сембердәге соңгы көненәчә шунда яшәгән. Моңарчы алар гел берсеннән икенчесенә күченеп, кеше карамагындагы йортларда торганнар. Дәүләт халык училищелары директоры вазифасын башкаручы Илья Николаевичны квартира белән тәэмин итү турында уйлап та карамаган. Аз-азлап акча җыйганнар. Мария Александровнаның сакчыллыгы аркасында гына гаилә йорт сатып алырлык мая туплаган.

Агач өй бу. Урам яктан бер генә катлы, эчтә, чарлаксыман өске өлеше дә бар. Куе үлән белән капланган ишегалды бик иркен. Койма буйларында агачлар, эт шомырты, хәтта карт өянке үсеп утыра.

Хуҗалык кирәк-яраклары өчен утын келәте, ат абзары, ике баз ясалган. Келәт белән ат абзары өстендә — печәнлек. Ишегалдында бүрәнәдән салган өч бүлмәле флигель; аннары җәен аш-су әзерләргә ярарлык тагын бер кечкенә бина бар. Шулар янына ук кое казылган, су тутырыр өчен, зур агач чан куелган.

Җиләк-җимеш агачларына бай, иркен бакча йортны аеруча күркәмләндереп тора. Монда алмагачлар, чия, кура җиләге, крыжовник үсә, сирень, сары акация чәчәк ата. Бер читтә ялгыз усак шаулап утыра, ә урта сукмакның ике ягына топольләр тезелгән, чәчәк түтәлләре сузылган. Чәчәкләр янында тимер түбәле беседка да бар. Бакча хуҗаларны, аеруча Мария Александровнаны, бик сөендерә, чөнки ул гаиләгә рәхәтләнеп ял итәргә дә, балаларны эшкә өйрәтергә дә, табигать матурлыгы белән хозурланырга да мөмкинлек тудыра.

Кыскасы, Ульяновларның инде шактый ишле булып өлгергән гаиләсенә бу өйдә яшәү бик рәхәт була. Моңарчы сигез кешелек гаилә кысынкылыкта яши. Яңа алынган йортта исә, ниһаять, һәр кешегә аерым бүлмә табыла, сабыйларга балалар почмагы ясала, няня да бик уңайлап урнаша. Гаиләнең бер җыела торган залы да, ашханәсе дә барлыкка килә.

Мария Александровна да үзен чын хуҗабикә итеп сизә башлый. Кайсы бүлмәгә кем урнашырга тиешлеген дә ул билгеләп чыга: балалар өске катка менәләр, Илья Нико-

лаевич өчен зал белән ашханә янәшәсендәге кабинет алына, бакчага карап торучы бик матур якта няня яши. Мария Александровна үзе Илья Николаевич кабинеты янындагы, карап торышка, иң җайсыз бүлмәне сайлый.

Ульяновларның элекке Мәскәү урамындагы тормышлары шул рәвешле башланып китә. Алар биредә тугыз елга якын гомер кичерәләр һәм бу чор гаилә тормышында бик мөһим урынны тота. Илья Николаевич нәкъ шул елларда үз хезмәтендә зур уңышларга ирешә. Саша белән Анна, гимназияләрдә бик яхшы укыганнары өчен, беренче медальләрен шушы өйгә алып кайтып керәләр. Бу йорт балаларның шатлыклы көлешүләреннән, ихлас бәхәсләреннән, җыр-музыкадан гөрләп тора. Еш кына Илья Николаевич янына хезмәттәшләре килә, алар халык мәгарифенә кагылышлы мәсьәләләр турында сөйләшәләр. Шушы өйдән гаиләнең ике баласы — Александр белән Анна — Петербургка укырга юл алалар. Алар каникулга кайткан көннәрдә өйдәгеләр яңа шатлык кичерәләр.

Әмма Мәскәү урамындагы бу йортның ишеген кара кайгы да шактый еш кага. Һич көтмәгәндә-уйламаганда гаилә башлыгы Илья Николаевич вафат була. Адәм балаларына моннан да зуррак хәсрәтнең килүе мөмкинме?! Бер генә ел уза — атасыз калган гаиләгә Петербургта укучы Александрның патшага һөҗүм вакытында кулга алыну хәбәре килә. Берничә атнадан Александрны үлем җәзасына хөкем итәләр.

Әнә ниләр кичерә бу йортта Ульяновлар гаиләсе. Монда узган тугыз ел аларның тормышында бик мөһим вакыйгаларга бай. Балаларның икәве шушында студент булып өлгерәләр, Владимир мәктәпнең югары классларында укый башлый, Ольга, Дмитрий, Мария үсмерлек чорына аяк басалар. Ә нинди булып үсеп җитәләр соң алар? Омтылышлары, максатлары кая юнәлгән? Туган йортта, ата-ана тәрбиясеннән нинди җим алганнар?

Ульяновлар йортына аяк басканда, мөгаен, һәркемне шуңа охшаш сораулар билидер. Дөрес, бу турыда без китаплардан укып та күп беләбез. Музейга әйләнгән әлеге өйгә килгәч исә ишетеп яки укып алган мәгълүматларга ул хакыйкатьне матди тестә тою хисе өстәлә. Киләсең. Керәсең. Үткәннең бөек чынбарлыгы белән очрашасың. Капкасының шыгырдап ачылуы, болдыр баскычының шомарып беткән култыксалары, тәрәзәдәге пәхтә пәрдәләр — барысы да безнең күңелләрдә инде күптән формалашкан олы образларны тулыландыралар, кешенең җирдә яшәү мәгънәсе турындагы фәлсәфи уйларыңны тирәнәйтәләр. Өйнең бер бүлмәсеннән икенчесенә кереп-чыгып йөрисең. Белгәннәреңә кечкенә-кечкенә яңа мәгълүматлар өстәлә бара, һәм әгәр син фикерләүгә, нәтиҗә ясауларга оста икәнсең, күз алдыңа гаҗәеп гаиләнең искиткеч кешеләре килеп баса. Меңнәргә, миллионнарга яшәү үрнәге булырдай тормыш гәүдәләнә башлый.

* * *

Өйгә кергәнче, капка төбендә бераз тукталып торыйк. Элекке Мәскәү урамына утыртылган топольләр йортны түбәсеннән үк каплап киткән. Алар гүя гап-гади йортны матуррак, купшырак итәргә тырышалар.

Җыйнак кына ишегалды, аннан — бакча. Белеп торасың: күптән инде монда берәү дә юк, тик ишегалдына килеп керү белән үк күңелне хуҗалары шушында гөрләп яшәп ятадыр, дигән серле тойгы дәртләндереп җибәрә. Озак та үтмәс, хуҗалар кайтып керер, өске катның баскычыннан балалар йөгерешеп төшәр, тирә-юньне аларның шат тавышы тутырыр сыман.

Беренче карашка, бу йортта да башкаларныкы кебек үк гадәти тормыш дәвам иткән: ата кеше һәр иртәдә эшкә ашыккан, балалар укырга таралганнар. Бәйрәмнәрдә, ял сәгатьләрендә өйне музыка тутырган, балалар чыр-чу килгәннәр, елашып та алгалаганнар. Әни кешенең акыллы, таләпчән сүзләре ишетелеп-ишетелеп торган. Бары да гади генә кебек. Әмма шул ук вакытта гаилә әле ул чакта ук кешеләрне үзенең кай яктандыр башкалардан аерылып торуы белән дә җәлеп иткән. Юк. Гади генә булмаган шул ул. Гадәти булмаган. Өйдәгеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәте, көн күрү алымы, тормыш агымы, алга куелган максат, рухи омтылышлар, — барысы да кабатланмас дәрәҗәдә камил, бөек.

Ульяновлар гаиләсенә тыйнаклык, материаль ихтыяҗларның минималь дәрәҗәдә азлыгы, купшылыкны бөтенләй ят күрү кебек сыйфатлар хас. Туган көннәрдә бер-берсенә бирелгән бүләкләргә генә игътибар итик: Саша әнисе өчен йомгаклар тартмасы, ипи турый торган бизәкле такта ясый, Анна Илья Николаевичның туган көненә шигырь чыгара. Бу детальләрнең һәммәсе Ульяновларның рухи дөньясын ачарга ярдәм итә.

Балалардагы бу тыйнаклык, ихтыяҗларны чикли белү чамасы тора-бара тагын да ныгый, тормышчан, инде зуррак мәсьәләләрне хәл итүдә дә чагыла башлый.

Илья Николаевич Петербургта укучы Александр белән Аннага ай саен кырыгар сум акча җибәрергә була. Саша әйтә: «Миңа утызы да җитә»,— ди. Тик әти кеше ба-

рыбер, үзе вәгъдә иткәнчә, кырыгар сум җибәреп тора. Җәйге каникулга кайткач, улы әй саен җыеп барган, үзенчә, артыкка санаган унар сумны кире биргәч, Илья Николаевич гаҗәпләнеп кала. Чынында, ул акча артык түгел бит инде. Әти-әнисенә, туганнарына карата ифрат кайгыртучан мөнәсәбәттә булмаса, студент егет ул ун сумны туздыру мөмкинлеген тапмас идемени!? Үзе турында гына борчылып яшәүне кабул итмәү, якыннары хакына үз кирәгеннән дә баш тарта алу, сафлык, намуслылык кануннарын олылау Ульяновлар гаиләсендәге һәр кеше өчен төп кагыйдәгә әйләнгән. Дәлил йөзеннән, Владимир Ильичка кагылышлы бер мисалга тукталырга да була. Уналты яшьлек Володя гимназиядә имтихан бирергә әзерләнүче чуваш егете Никифор Охотниковка борынгы телләр өйрәтә башлый. Бу елларда гаиләгә бик авыр кайгылар кичерергә туры килә: Саша кулга алына һәм үлем җәзасына хөкем ителә. Илья Николаевич вафат. Гаиләнең матди хәле шәптән түгел. Әмма Володя Никифордан бер тиен дә акча алмый. Ул чорда укытучы яллау гадәти күренеш була, һәм күп кенә гимназистлар, репетитор рәвешендә, үзләренә акча эшлиләр. Володя исә алдына бөтенләй башка максат куеп тырыша. Үзе өйрәткән фәннәрдән Никифорның имтиханны уңышлы тотуы Володя өчен әллә нинди байлыклардан да мәһимрәк.

Бу гаиләдә балаларның күп кенә күркәм сыйфатлары Мария Александровна Ульянованың дөрес тәрбиясе нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Өйдә няня булуга карамастан, әни кеше һәр баласын кечкенәдән үк хезмәткә өйрәтүне, җаваплылык тоярга тиешлеген алга сөрә. Йортның зур бакчасы бу өлкәдә зур таяныч була. Анда Ульяновларның барысы да эшли.

Мария Александровна теләге буенча, өйдә атнаның бер көнендә — француздча, бер көнендә немецчә генә сөйләшү тәртибе кертелә. Уенга охшаш бу гадәт чит телләрдә сөйләшергә күнегү өчен гаҗәеп отышлы булып чыга. Әти белән әни икесе дә кешене сүздә генә түгел, шәхси үрнәктә раслап ышандырырга кирәклеген тирәннән аңлыйлар. Һәм алар, балаларның кылган эшләрендә намуслылык, ярдәмчеллек, буш сүз белән мавыкмау, ныклык, максатка ирешмичә тынычланып калмау күреп, шатланалар.

Балалар төрле холыклы булып үсәләр. Александр аз сүзле, уйчан, үз-үзенә бик таләпчән, яшьтән үк җитдилеккә омтылучан. Анна исә шигъри җанлы, нечкә күңелле. Аңа музыка, әдәбият дөньясы якынрак. Владимир кешеләрне бик төгәл бәяли, күп укый, мең дә берне белә. Оля, Володяның иң тугрылыклы дусты, ә үзе Александрга охшарга тырыша, бик әйбәт укый. Митя белән Маняша бу чакта әле сабыйлыктан гына чыгып киләләр.

Илья Николаевич, талантлы педагог буларак, балалар тәрбиялләгәндә иң мөһиме үз-үзеңне ничек тотуга бәйле икәнен тирәннән аңлап эш итә. Ул ял сәгатьләрендә күп укый, шахмат уйный, музыка тыңлый. Аның күп вакыты эштә, юлларда үтә. Өйдә ул күргәннәре турында мавыктыргыч иттереп сөйли, балалары исә шул чакларда әтиләренең дөнья хәлләренә мөнәсәбәтен дә тоймый калмыйлар.

Илья Николаевич, бик җаваплы вазифалар алып барса да, гаиләсендәге эшләргә катнашырга да өлгерә, һәркемгә бик игътибарлы булырга тырыша. Балалар аңардан ниндирәк китаплар укырга кирәклеге турында сорашалар, әтиләре белән бергә төрле модельләр ясарга, экскурсияләргә йөрергә яраталар. Аннага ул грамматика үзләштерүдә ярдәм итә, Александр белән бергәләп грек телен өйрәнә. Володя да укый башлауга ук үз мәшәкатьләрен әти-әнисе белән уртаклаша. Гимназиядән кайтып керүгә, Володя әтисенә дәрестә ниләр булуын, укытучыга үзенең ничек җавап бирүен сөйли. Алган билгеләре бер үк төрле булгангадыр инде, кайбер көннәрдә Володя әтисенең кабинет ишеге төбеннән үткәндә кыска гына әйтеп куя:

— Грек теленнән — биш, немец теленнән — биш...

Шунысы бәхәссез: Ульяновлардагы әхлакый сыйфатларның чыганагы — иң беренче чиратта, туган йорт, газиз гаилә.

Ульяновларның дуслары әллә ни күп булмый, әмма ни бары — чын дуслар, ихлас күңеллеләр, эш белән мавыгучан кешеләр. Әңгәмәләр халык язмышы турында бара, Некрасов, Тютчев шигырьләрен укыйлар. Добролюбов, Чернышевский, Писарев, Белинский әсәрләре белән танышалар. Һәм, мөгаен, балалар шул чакта ук яшәп килүче иҗтимагый төзелешнең илдәге миллионлаган кешеләрне канәгатьләндермәвенә төшенә башлаганнардыр. Илья Николаевич бу фикерне үз хезмәте үрнәгендә, халык мәгарифе өлкәсендәге хәлләрдән чыгып расласа, балалары инде бу очкыннан ялкын урлаталар, профессиональ революционерларга әйләнәләр. Халык бәхете өчен көрәшчеләрнең юлы катлаулы. Күпме генә өйрәнсәң дә, аның барлык серләрен чишеп бетерү мөмкин түгел. Әмма юлның башы, һичшиксез — монда, гаиләдә, борынгы Сембер шәһәренең элекке Мәскәү урамындагы шушы йортта.

Музейда йөргәндә өйдәге йөзләгән китапларга игътибар итми мөмкин түгел. Алар арасында — Пушкин, Лермонтов, Кольцов, Никитин, Тютчев, Крылов, Толстой, Тургенев, Гоголь...

Әти кеше, әдәбиятның шактый четрекле дөньясында югалып калмасыннар өчен, балаларына һәрвакыт ярдәм итә, нинди китаплар укырга кирәклеген әйтә, әсәрләрнең кыйммәтенә төшендерә. Ул балаларының әдәби әсәрләр турында үзара бәхәсләшүләрен кызыксынып тыңлый. Александрның аеруча рациональ фикер йөртүе Илья Николаевичны бераз борчый, шикләндерә. Аннаның һәрчак канатланып-рухланып сөйләве аны елмайта, ә Володяның тирәннән уйлап әйткән сүзләре шатландыра.

Ульяновлар китапханәсендә матур әдәбият әсәрләреннән тыш иҗтимагый хәлләргә кагылышлы китаплар да, фәнни әдәбият та шактый күп тупланган. Китаплар гына да түгел. Илья Николаевич физика, химия, табигать фәннәрен яхшы үзләштерсеннәр өчен балаларына күргәзмә әсбаплар да җыя, аларны ул я Мәскәүдән, я Петербургтан кайтарта. Катлаулы приборларның эш ысулын, аны нинди галим ачканлыгын әти кеше балаларына үзе үк аңлатып та бирә. Уллары һәм кызлары исә, мондый әңгәмәләрне көтеп алалар, әти кешенең мавыктыргыч итеп сөйләвен кызыксынып тыңлыйлар.

Туган йорты кешегә кай ягы белән, ни өчен шулай кадерле була? Сәбәпләре күп аның. Сабый чакта сине иркәләп үстергән ул, сине монда ихластан ярatkannar, син монда шәфкатьнең ни икәнен аңлагансың, ялгыз түгеллегеңә ышангансың. Күңелләрнең һәрчак туган йортка ни өчен тартылып торуы турында тагын әллә ниләр тезеп китәргә мөмкин булыр иде. Әмма бер хакыйкатькә аерым тукталырга кирәк: кеше үзе үскән гаиләсендә, туган йортында җылылыкны, яктылыкны, шәфкатьлелекне никадәр күбрәк алса, бу сыйфатлар аның тормышында шулкадәр күбрәк, озаккарак, ераккарак тарала. Ульяновлар өендә йөргәндә сине гел шул уй биләп тора. Бу йортта яшәүчеләр бер-берсенә нинди кайнар хисләр багышлаганнар! Һәм шул көчле мәхәббәт аларның һәрберсенә кайгы-хәсрәтләр алдында җебеп төшмәскә, нык булырга көч биргән.

Йорт 1923 елны музейга әйләндерелгән. Ульяновлар гаиләсе Сембердән киткәннән соң, өй кулдан-кулга күчеп тора. Аны Илья Николаевич сатып алган вакыттагы хәленә китерү өчен музей хезмәткәрләре күп көч куялар. Бәхеткә, музей оештырылган вакытта гаиләнең әле үз әгъзаларыннан Анна Ильинична, Мария Ильинична һәм Дмитрий Ильич исән-сау булалар һәм алар тарихчыларга зур ярдәм күрсәтәләр. Нәтиҗәдә музей-йорт тиешле хәленә китерелә. Ульяновск шәһәре бу кадерле өйне күз карасыдай саклый, аның белән хаклы рәвештә горурлана.

Музейда таң атканда, йөзләгән сәяхәтчеләр әле килеп өлгермәгән арада йөрүе рәхәт. Тып-тын. Бүлмәләрдә «шылт» иткән аваз да юк. Утлар кабызылмаган. Почмакларда — эңгер-меңгер. Өй кунаклар каршыларга әзерләнә. Шушы тынлык мизгеле узып, сәяхәтче кунаклар килеп керү алдыннан син гаҗәеп алмашынуны тоеп аласың. Ульяновлар гаиләсенең моннан киткәненә йөз еллар бар бит инде. Әмма, бүлмәләрдә утлар җемелди башлауга ук, чынбарлык үткәнгә кайта да төшә сыман. Гүя өйдәге һәр әйбер сине Ульяновларның ул ерак еллардагы тормышына тартып ала. Озак та үтмәс, залга кадерле кешеләр үзләре дә килеп керер кебек тоела башлый. Сәгать иртәнге җиде. Ульяновлар гаиләсе нәкъ шул вакытта уяна торган булган...

Бөек тормышка алып чыккан олы юлның беренче баганасы. Владимир Ильич Ленинның гомер юлын, хезмәтләрен хәзер миллионнар өйрәнә. Ульяновск шәһәрендәге Музей-йорт исә, халкыбызның иң зур байлыгы буларак, бу даһи образны тирәннәнрәк аңлауда беренче чыганак булып тора.

# ЛЕНИННЫҢ БЕРЕНЧЕ ШӘКЕРТЕ

Бөек Ленин исеме белән бәйле булган күренекле партия һәм дәүләт эшлеклеләре, атаклы әдәбият һәм сәнгать кешеләре арасында демократик юнәлештәге чуваш мәгърифәтчеләренең беренчеләреннән берсе булган Никифор Михайлович Охотников исеме дә бар.

Бөек юлбашчыбызның биографиясендә түбәндәге юллар язылган: «Гимназиянең соңгы классларында укыганда ул чуваш мәктәбе укытучысы Н. М. Охотников белән дәресләр алып бара, аны өлгергәнлек аттестатына имтиханга әзерли. Милләте буенча чуваш, математикадан зур сәләте булган Охотников борынгы телләр буенча имтиханга үзе генә хәзерләнә алмый, ә укытучы ялларга аның мөмкинлеге булмый. Охотниковның авыр хәле турында белгәч, Владимир Ильич һичбер түләүсез аны хәзерләргә тотына һәм ел ярым буена системалы рәвештә, атнага өч тапкыр аның белән дәресләр үткәрә. Охотников өлгергәнлек аттестатына имтиханнарны уңышлы тапшыра һәм университетка укырга керә».

Н. М. Охотниковның тормыш юлы һәм иҗаты әлегә аз өйрәнелгән, ләкин моңа кадәр аның турында белгәннәребез дә чуваш халкының бу талантлы улына карата хөрмәт уята.

Н. М. Охотников 1860 елның март аенда элекке Казан губернасы Чистай өязе Чуваш Чабаксары авылында ярлы крестьян гаиләсендә туган. Бик иртә ятим калган малайны бабасы һәм әбисе тәрбияләп үстерә. Аларны Н. М. Охотников соңыннан тирән рәхмәт хисләре белән искә ала. Үз авылларының дьячогы, ягъни түбән дәрәҗәле чиркәү хезмәтчесе һәм Савруш авылыннан бер татар укытучысы аны укырга һәм язарга өйрәтәләр.

14 яшендә Николай Охотников Сембер (хәзерге Ульяновск) укытучылар мәктәбенә укырга керә. Ул елларда бу мәктәпнең инспекторы булып Ульяновлар гаиләсенең якын танышы булган Н. Я. Яковлев эшләгән. Сәләтле малай мәктәп елларында бик күп укый, бигрәк тә математикага һәвәслеге билгеле була. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Н. М. Охотников туган авылында бер елдан артык балалар укыта. Сембер классик гимназиясендә өяз укытучысы исеме алу өчен имтиханнар тапшырганнан соң, ул Сембер үзәк чуваш мәктәбендә математика укытучысы булып эшли.

Нәкъ менә Сембердә, күренекле мәгърифәтче-демократ И. Н. Ульянов җитәкчелегендә эшләгәндә, Н. М. Охотниковның педагоглык таланты тулысынча ачыла.

1882 елда Н. М. Охотников И. Н. Ульянов белән Мәскәү күргәзмәсен карарга бара һәм башка губерналарда уку-укыту эшләренең торышы белән таныша. Бар җирдә дә бер үк күңелсез картина: мәктәпләр җитешми, укытучылар аз хәзерлекле, чиркәүнең зарарлы йогынтысы сизелә.

Мәскәүгә барган чакта Н. М. Охотников И. Н. Ульяновка үзенең күптәнге хыялы турында — югары математик белем алырга теләвен сөйли. Казан университеты кандидаты И. Н. Ульянов яшь укытучы язмышына кайнар теләктәшлек күрсәтә. Ул Н. М. Охотниковка шәһәр китапханәсенә язылырга булыша, еш кына егетнең дәресләренә килә, педагоглык осталыгының серләре белән бик теләп уртаклаша, үзлегеннән укып белем алу өстендә даими эшләүне таләп итә.

Н. М. Охотников физика һәм математика, астрономия һәм химия буенча дәреслекләрне, һәртөрле кулланмаларны бик тырышып өйрәнә. Ләкин өлгергәнлек аттестаты алу өчен борынгы телләрдән һәм иҗтимагый фәннәрдән дә имтиханнар тапшырырга кирәк була. Язмыш аны гимназист Владимир Ульянов белән очраштыра.

Ул 1888 елның июнь аенда гимназиядә имтиханнарны уңышлы тапшырып, Казан университеты студенты булу бәхетенә ирешә. Ләкин Илья Николаевич белән Владимир Ильич кына егетнең бу шатлыгын уртаклаша алмыйлар, чөнки бу вакытта инде беренчесе исән түгел, ә икенчесе сөргендә була. Ниһаять, Никифор Михайлович үз теләгенә ирешкән кебек була. Зур университет китапханәсе, уку кабинетлары — бар да аның алдында ачык. Ләкин ярлы крестьян егетенә тормыш итүләре кыен була.

Иң актив катнашучыларның берсе Владимир Ульянов булган 1887 елгы студентлар сходкасы ул заманның зур иҗтимагый-политик вакыйгасы була. Бу чорларда университет кайнап тора: студентларның яшерен землячестволары эшли, кулдан-кулга К. Маркс, Г. В. Плеханов, Н. Г. Чернышевскийларның тыелган әсәрләре йөри. Төрле сөйләшүләр вакытында еш кына Николай Федосеев исеме дә телгә алына.

Н. М. Охотников күп кенә студентлар белән таныш була һәм аларның авыр язмышын уртаклаша — атаклы Марусовкада, төрле почмакларда, баскыч асларында яши, хосусый дәресләр бирә. Ә хатыны ике баласы белән авылда яши.

Беренче уку елларында ук «математик җанлы» Н. М. Охотниковка профессорлар игътибар итәләр. Күп тә үтми, ул университеттагы табигать фәннәре белгечләре җәмгыятенә кабул ителә һәм берничә тапкыр аның утырышларында фәнни белдермәләр белән чыгыш ясый.

1890 елда Казан университеты студент Н. М. Охотниковны Амстердамга, халыкара математика конгрессына җибәрә. Ул анда зур уңышка ирешеп, алтын медаль алып кайта. Никифор Михайловичның эшкә сәләте зур була. Ул фәннең төрле тармаклары белән кызыксынган: математика һәм астрономия, лингвистика һәм чуваш халкы тарихы h. б. Татар телен бик яхшы белгән Н. М. Охотников беренче чуваш-татар сүзлеген төзегән. «Татар һәм чуваш телләренең якын кардәшлеге безнең төбәктәге бу ике халыкны шулкадәр үзара якынайткан ки, чуваш өчен мәҗбүри дип әйтерлек рәвештә татар телен белү, монда яхшы тон кебек исәпләнә. Татар телен белгәндә, безгә — чувашларга укуязуны үзләштерү тагын да җиңеләшә төште. Татар телен без, гомумән, уку-язуны үзләштерү чарасына әверелдердек»,— дип яза Н. М. Охотников.

Студент елларында ул М. В. Ломоносов, Н. М. Карамзин, С. М. Соловьев, Й. Бичурин хезмәтләрен ныклап өйрәнә. Күренекле татар галимнәре һәм мәгърифәтчеләре Ш. Мәрҗани, К. Насыйри хезмәтләре дә аңа таныш булган. Нәтиҗәдә ул 350 биттән торган «Чуваш тарихы»н язган. Кызганычка каршы, галимнең күп еллык иҗат җимеше булган бу хезмәт тулысынча сакланмаган. Шул чор матбугатында басылып калган кечкенә генә өзекләреннән күренгәнчә, ул бу хезмәтендә чуваш халкының килеп чыгышы, гореф-гадәтләре турында язган була. Н. М. Охотниковның кайбер хезмәтләре Совет власте елларында гына басылып чыга. «Чуваш баласының үзенең тәрбиясе турында язмалары» 1920 елда Казанда дөнья күрүе бик тә гыйбрәтле хәл.

Мәгърифәтче-демократ Н. М. Охотников И. Н. Ульяновның педагогик идеяләренә теләктәшлек белдергән, хезмәт халкы өчен булган мәктәпләр санын арттыруны, төрле милләт балаларын бергә укытуны яклап чыккан, балаларга тән җәзасын бирүгә каскен рәвештә протест белдергән.

Н. М. Охотниковның бик күп уйланылган эшләре тормышка ашмый кала. Ул 1892 елда, университетны бетерер алдыннан гына вафат була. Ләкин аның эшләгән эшләре дә чуваш мәгърифәтчелеге тарихында сизелерлек эз калдырган.

**Виктор СКВОРЦОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

## Мәгъсум Хуҗин

# ЯРАМЫЙ, ЯРАМЫЙ!

Сугыш... Дүрт ел тула инде сугыш баруына. Кайчан бетәр икән кешелек тарихында тиңе булмаган бу дәһшәтле кырылыш? Без, авыл малайлары, тирә-юнь таң калырлык итеп:

— Җиңдек!— дип кайчан күкләргә сикерербез икән?

Әйе, әйе, без бу изге хәбәрне, бәхет хәбәрен бөтен дөньяга яңгыратачакбыз. Без Җиңүне һәркөнне — иртән дә, көндез дә, кичен дә көтәбез. Җиңүне без генә — балалар гына түгел, аны барлык совет халкы тылда, тиран күл ясалырлык тир түгеп, фронтта, диңгез җыелырлык кан коеп, көрәшеп көтә.

һәм, ниһаять:

— Ишет, дөнья, безнең ил җиңде!!!

Бу хәбәрнең үзен безгә, сука сабы тотып басу түрендә җир сөреп йөрүчеләргә, бездән дә кечкенә малайлар чатыр чабып килеп ирештерде.

— Сөенче!— диделәр алар.— Җиңдек! Без җиңдек!

Аларның хәбәреннән басулар иркенәеп, күкләр биегәеп, көн яктырып китте.

Сөенчегә бәхетебезне уртаклашабыз!

Дөрес, безнең җавап — бүгенге фикерләүдән чыгып әйтелгән сүзләр. Әмма моннан кырык еллап элек сөенчегә әйтелгән сүзләрнең дә төгәл мәгънәсе шул иде.

һәм без сугыш күрсәткән газапларны онытып җибәрдек, аларны бөтенләйгә үк оныттырбыз кебек иде. Чөнки җиңдек ич! Тик өлкәннәр безгә:

— Беркемне дә, бернәрсәне дә онытырга ярамый!— дип катгый кисәттеләр. Алар хәзер дә, сугыш вакытында халкыбыз кылган батырлыкның олылыгын киләчәк буыннарга тулы яктыртып калдырып, тыныч тормышның кадерен белергә өйрәтәләр. Шәһәрләрдә, авылларда куелган һәйкәлләр сугыш каһарманнарына дан җырлау гына түгел, минемчә, ә бәлки сугыш сәхифәләрен мәрмәргә уеп, киләчәккә чын тарихны мирас итеп бирү булып та тора. Халкыбызның фашизмга каршы көрәштәге батырлыгы беркайчан да онытылмасын! Күпсанлы, һәртөрле музейларга куелган шаһит-әйберләр — әнә шушы изге максатның тормышка ашырылуы. Сугыш турындагы яңа документ-материаллар, инде кырык ел узгач та, табыла торалар.

Әмма беркайчан да табылмас булып югалганнары да юкмы икән? Булса... мондый югалтулар, еллар узган саен, ишәя-күбәя бармыймы?..

— Онытырга ярамый!— дигәннәр иде бит өлкәннәр.

Ә без, сугыш чоры малайлары, шулай ук сугыштан соң туып-үскәннәр, кайчакта хәтеребезне сыекландырмыйбызмы? Яки инде мәйданнар уртасына сугышта һәлак булучыларга, исемнәрен язып, һәйкәл куйдык, дип тынычланып калмыйбызмы? Клуб-мәктәпләрдә каһарманнарның фоторәсемнәрен һәм нинди батырлык эшләүләрен язып кую тәэсирлерәк булыр иде. Аларның фоторәсемнәре еллар узган саен тәс бирә бара бит, югыйсә. Югала бара, димәк, алар. Фотога төшмәүчеләр дә булгандыр. Замандашларының телдән сурәтләвен тыңлап, ул якташларыбызның рәсем-портретларын ясарга мөмкин. Вакыт аларны күреп белүчеләрне дә «чүпли» тора. Ашыгырга кирәк! Сугыш кырында ятып калган авылдашларыбыз мондый кадер-хөрмәткә бик тә лаек.

Аерым бер очракка-хәлгә тукталыйк шушы урында.

Казандагы Матбугат йортында Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучыларның исемнәре күптән инде мәрмәргә язып куелды. Әйбәт моңысы. Көрәш җыры булып

мираска калган әсәрләрен фронтта да иҗат иттеләр алар. Шундый җырның берсен искә төшерик:

...Илең турында уйла.
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

Кырык еллыкка әзерлек уңаеннан, сугышта катнашкан һәм бүген дә каләм көчләрен киметмәүче язучыларның фоторәсемнәреннән дәү стенд ясалды. Шулай ук әйбәт эш. Йомышың ни ашыгыч булса да, аның янында тукталмыйча, фашист өерләренә каршы корал да тотып көрәшкән язучыларыбызга баш имичә мөмкин түгел. Алар, шөкер, шактый күп, һәм фоторәсемнәр белән бергә туплану да аларның батырлыгын тагын да олы итә.

Инде килеп.

Сугыштан исән кайтып та гомерләре тиз яки озакка сузылмыйча өзелгән язучыларыбызга шулай ук махсус стенд багышлау мәҗбүри. Алар да, кулларына корал тоткан килеш дошман өстенә ыргылганда, изге көрәшкә җыр-чакыру белән өндәделәр.

һәм язучыларыбыз турында гына да сүз бармый. Тагын искә төшерик әле: сугыштан яраланып яки сәламәт кайткан күп ир-егетләр арабызда юк инде.

Онытмыйк аларны! Беләбез ич: сугыш заманыннан беркем дә, бернәрсә дә онытылмаска тиеш!

Югалтулар ишәймиме, дигән идек. Ишәйтергә ярамый аларны. Шушы җәһәттән кечкенә генә истәлек.

...1954 елның яз башында мин Габдрахман абый Әпсәләмовның өендә булдым. Максатым «Алтын Йолдыз» романына бәйләнештәге кайбер мәсьәләләрне ачыклау иде. Габдрахман абый миңа, студент егеткә, үзенең кечкенә генә бүлмәсендә, иҗат эшен читкә куеп, мине кызыксындырган әйберләр турында озаклап сөйләде. Фронтта үзе эшләгән татарча газеталарның төпләмәсен-тегелмәсен дә күрсәтте. Газеталарның һәр саны икешәр данә иде, алар чиста, ертылмаган, солдат капчыгында озын юллар узуга да карамастан, хәтта читләре дә бөгәрләнмәгән иде. Болары инде Габдрахман абыйның пөхтәлегеннән генә дә түгел, ә аның совет солдаты батырлыгының кадерен белүен дә раслый иде. Һичшиксез шулай.

Ул төпләмәне ябып куйды, сул кулы белән, бармакларын газетага тидерер-тидермәс кенә, төпләмәне сыйпады, уң кулы белән җиңсез сырмасының изүен төзәтте һәм, башын аскарак иеп (ул өстәл артында миңа кыйгачрак утыра иде):

— Бу газеталарның берәр данәсен музейга бирмәкче идем,— диде. Һәм борчылып, сүзнең «ы» авазына басым ясап:— Алмады-ылар,— дип өстәде.

Сугыш дәһшәтләренең онытылмавы өчен, шушы мал-мөлкәтен башкалар белән уртаклашырга әзер булган Солдат! (Әйе, болары да — минем бүгенге фикерләүдән чыгып әйтелгән сүзләр).

Габдрахман абый моңарчы да сугыш турында роман, повесть, хикәяләр язган иде. Моннан соң да бу темага күп иҗат итте. Ул аларда газеталарындагы материалларны, әдәби калыпка салып, бик хаклы файдаланган. Хәер, сугышта аның күргән-кичергәннәре үзе эшләгән газеталарда язылганнар белән генә бетми дә ич әле...

Фронт газеталарының тулы төпләмәләре музейларда, китапханәләрдә хәзер күпләп сакланамы икән соң? Бәлки, безгә аларны әледән-әле укып тору һәм, җаен табып, даими күчереп басу кирәктер.

Татарстан Язучылар союзының проза секциясендә татар әдәбиятында Ватан сугышы темасының яктыртылуы турында сөйләшү булган иде. Анда танылган язучыбыз Атилла абый Расих кызыклы да, шактый ук гыйбрәтле дә бер хәл турында әйтте. Атилла абыйның фронттан җибәргән хатларын әнисе саклаган икән! Менә ул — ананың солдат улын сугыштан җиңеп кайтуын зарыгып һәм олы өмет белән көтүенә дәлил! Һәм Атилла абый, шушы бер йөз егерме (солдатның газиз әнисен яратуына дәлил ич бу сан!) хатны үзәккә алып, Җиңүнең кырык еллыгы алдыннан яңа әсәр язган.

Габдрахман Әпсәләмов һәм Атилла Расих кадерле материал-истәлекләрен югалтмаганнар. Онытырга ярамый чөнки!

Ә мондый документ-материаллар сугышта булган, шулай ук тылда эшләгән һәркемдә бардыр, һәрхәлдә, булырга тиеш. Алар югалмасын. Чөнки онытырга ярамый!

Һәм кешеләр онытмыйлар.

Сугыш бетүгә кырык ел узуга карамастан, апалар (инде әбиләр) ирләрен көтәләр. Ятимлек ачысын татыган балалар (инде үзләре өлкән яшьтә) әтиләренең кайтуына өметләнәләр. Хәбәрсез югалучыларны яки, башта бергә хезмәт итеп, аларны белүчеләрне туганнары эзлиләр.

Сугыштагы һәм тылдагы батырлыклар һаман ачыла торалар.

Шулай. Сугыш күптән-күптән бетүгә карамастан, Җиңүдән соң күп-күп вакытлар узуга карамастан, беркем дә, бернәрсә дә онытылмый. Чөнки онытырга ярамый, ярамый!

Галина Мәҗитова

# МУЗАЛАР ТЫН ТОРМАДЫ

## КАЗАН АРТИСТЛАРЫНЫҢ ФРОНТКА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЕ ТУРЫНДА

Көньяк кояшы нурлары астында тагын да яктырып киткән ак теплоход Зур драма театры артистларын Ялтага алып килде. Театр гастрольләре Кавказда һәм Кырымның көньяк яры тәбәкләрендә зур уңыш белән барды. Һәм менә 1941 елның 22 июнендә кичен артистлар Ялта сәхнәсенә чыгарга тиешләр. Әмма иртән әле уянып та җитмәгән ми күзәнәкләрен хәвефле хәбәр яшендәй сызып үтте: су-гыш!.. Фашистлар Севастопольне бомбага тота башлаганнар...

Яшеллеккә күмелгән Ялта урамнарыннан, күңелгә ниндидер ышаныч биреп, сугышчан отрядлар атлый. Көньяк шәһәрнең һәрвакыт шау-гөр килеп торган кибет һәм кафелары кешеләрсез бөтенләй сәер булып күренә. Анда-монда кабартма сатып торучылар да урамнарга күңеллелек өсти алмый.

1941 ел, 22 июнь... Ватаныбыз өстенә кара афәт ябырылуга карамастан, кичен театр үзенең гастрольләрен башлап җибәрде. Тамашачыларга «Патша Федор Иоаннович» спектакле күрсәтелде. Залда алма төшәр урын да булмагандыр. Билетлар да җитмәде. Спектакльдән соң сәхнәгә бер-бер артлы чәчәк бәйләмнәре яуды.

Сугышның беренче көнендәге спектакль җир йөзеннән барысын да сызып ташларга омтылучы сугышка көчле протест буларак яңгырады. Туплар аткан чакта музалар тын тора... Әлеге латин әйтеменә совет кешеләре төзәтмә кертteләр: туплар аткан чакта да музалар тын тормады, сәнгать халыкны дәһшәтле рухи корал белән тәэмин итте.

1941 ел, 25 июнь... Татар дәүләт филармониясе коллективы ир-егетләрне сугышка озату уңаеннан оештырылган митингка җыелган. Кемдер гармунда уйный башлый. Үзара кушылган җырлау һәм елау авазлары бәгырьләрне өзгәли...

Сугыш елларында культура тормышы аеруча киеренке агышка керде. Яңа концерт программалары, театр премьералары, күренекле культура эшлеклеләренең юбилейлары, фәнни сессияләр һәм конференцияләр, күп төрле күргәзмәләр, йөзләрчә һәм меңнәрчә кешеләрнең игътибарын үзләренә җәлеп иттеләр. Культура тормышында хәтта күпмедер дәрәҗәдә үсеш тә күзәтелде. Әлеге күренеш Казанга илебездәге күп кенә фән һәм культура эшлеклеләренең күченеп килүе белән дә аңлатыладыр. Күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, атаклы галимнәр хезмәт иләре тормышына үзләренчә ямь керттеләр. Зеленодольск шәһәрендә Мәскәү Яшь тамашачылар театры эшләде. Республикабызның партия һәм совет органнары сәнгатьне үстерүне һәм фронтка культура хезмәте күрсәтүне һәрвакыт игътибар үзәгендә тоттылар.

Сугыш әдәбият һәм сәнгать үсеше тарихына үзенчәлекле чор булып керде. Тормыш белән бәйләнеш бөтен зарурлыгында көн тәртибенә куелды. Иҗатчылар катлаулы чорның кырыс хакыйкате, беренчел кичереш-тойгылар, уй-теләкләр әдәбият һәм сәнгатьтә моңарчы күрелмәгән тәэсирлелек белән гәүдәләндерелергә тиешлеген тирәнтен аңлап эш иттеләр. Халыкны көрәшкә чакыручы патриотик җырлар һәм шигырьләр сугышның беренче көннәрендә үк күпләп язылды. Мондый «кече» жанрга, әйтергә кирәк, кытлык булмады, ә менә драма әсәрләре мәсьәләсендә берара мохтаҗлык кичерергә туры килде. Шуңа күрә театрлар совет авторларының моңарчы язылган иң яхшы пьесаларына мөрәҗәгать итте. Татар дәүләт академия театрында, мәсәлән, К. Симоновның «Безнең шәһәр егете» исемле пьесасы куела. Камаллылар 26 июньгә Т. Гыйззәтнең «Таймасовлар»ы буенча эшләнгән спектакльне дә өлгертәләр. Татар дәүләт опера һәм балет театры исә 12 июльдә тамашачыларны Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсы (М. Җәлил либреттосы) премьерасына чакыра. Курчак театры да эшчәнлеген дәвам иттерә. Сугышның беренче айларында ук республикада РСФСРның атказанган артисты С. Лемешов концертлары, М. Пятницкий исемендәге хор, еврей опереттасы, Мәскәү дәүләт миниатюралар театры гастрольләре башлана. РСФСРның халык артисты Вл. Дуров катнашындагы тамашалар циркта көнгә өчәр мәртәбә күрсәтелә.

Артистлар авыр шартларда эшлиләр. Иҗатташларының шактые армия сафларына алына. Культура учреждениеләренә бирелә торган средстволар беренче вакытта сизе-

лерлек кыскара. Автотранспорт фронтка җибәрелә. Кырык бернең зәмһәрир кышы килеп җитә. Биналар ягылмый. Циркта хайваннар үлә. Ашатырга җитәрлек азык юклыктан, атларны сатарга мәҗбүр булалар. Академия театрында эвакопункт урнаша, һәм 1941 елның 4 ноябреннән ул вакытлыча Зур драма театры бинасына күчерелә. Тамашалар бер үк сәхнәдә «алмаш-тилмәш» күрсәтелә: айга 44 спектакль... Шунда ук опера һәм балет театры да эшли. Сугышның беренче көннәрендә үк, төгәлрәк әйткәндә, 24 июньдә Татар дәүләт филармониясе бинасы бөтенләе белән диярлек хәрби госпиталь карамагына бирелә. Кайчак репетицияләрне өйдә дә ясарга туры килә. Музалар тавышын туплар гөрелтесе дә күмә алмый. Авырлык чигенә. Артистлар халык көчен Ватан сугышына туплау, дисциплина һәм оешканлыкны ныгыту, предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча үзләренә куелган бурычны тирәнтен аңлап иҗат итәләр. СССР Халык Комиссарлары Советының Сәнгать эшләре буенча комитеты чакыруын сәхнә осталары һәрвакыт игътибар үзәгендә тоталар: «Театрларның барлык хезмәткәрләре оборонага эшләүләрен аңларга тиешләр. Совет театр сәнгатен дошманны җиңү өчен көрәштә көчле корал итәргә...»

Эшчәнлекләрен тиз арада «хәрби лад»ка корган театрлар, чыннан да, дошманга каршы көрәштә көчле коралга әверелә. Турыдан-туры сугыш тематикасына багышланган пьесалар да күпләп языла башлый. Милли әсәрләр дә туа. Шулар арасыннан Н. Исәнбәтнең «Мәрьям»е (1943, январь), М. Әмирнең «Миңлекамал»ы (1944, апрель) тамашачы тарафыннан аеруча яратып кабул ителә. Сугыш утында чыныккан беренче милли героиня... Спектакльдәге Мәрьям образы турында хаклы рәвештә шулай әйтә алабыз һәм аның йөзендә сынмас рух гәүдәләнешен күрәбез. Каһарман кыз Мәрьямнең һәлакәте, тамашачы күңелен тетрәтеп кенә калмыйча, йөрәгендәге көч-гайрәтен, җиңүгә ышанычын да арттыра. Тылдагы хезмәт батырлыгын, аерым алганда, гаять авыр чорда авылдашларының бөтен көчен бер олы максатка туплый алган коммунист Миңлекамалның фидакарьлеген сурәтләгән спектакль дә фронт өчен армый-талмый хезмәт итүче «шинельсез солдатлар»ның мәхәббәтен казана. Композитор Н. Җиһановның 1942 елда куелган «Илдар» операсында да (М. Җәлил либреттосы) патриотизм темасы дәвам иттерелә, совет кешеләренең авыр сынау чорындагы рух көче бик тәэсирле итеп күрсәтелә. Каһарманлык ыгыналы, әйтик, М. Юдинның «Фәридә» операсында да ышандырырлык рәвештә ачыла. Театр ел ярым эчендә 348 спектакль күрсәтә. Шуларның 93е — татар телендә.

Сугыш елларында казанлыларга Г. Ардаров, Н. Якушенко, Е. Жилина, Ф. Насретдинов, Х. Сәлимҗанов, Ф. Ильская, А. Гусев, М. Булатова, Х. Әбҗәлилов, М. Рахманкулова, Г. Кайбицкая кебек танылган артистлар культура хезмәте күрсәтте. Аларның чыгышларын һәрвакыт көтеп алдылар.

«Кемдә моторлар күбрәк һәм халыкның әхлакый рухы ныграк, шул як җиңәчәк,— дип язды А. Толстой.— Әлеге сугышта әхлак категорияләре хәлиткеч роль уйнаячак. Менә ни өчен безнең көннәрдә күренмәс крепостьлар, халык җаны крепостьларының ташчылары турында сөйләшү аеруча урынлы».

Күренмәс крепость ташчылары... Идеология фронтында армый-талмый эшләүче артистлар да, соңгы исәптә, әнә шундый күренмәс крепостьларны тагын да ныгытуга хезмәт иттеләр. Тирәнтен ышаныч белән хезмәт иттеләр: иң бөек идеалларга нигезләнгән мондый крепостьларны берничек дошман да ала алмаячак!

Хәрби шефлык эше... Филармония, цирк һәм театрлар шушы юнәлештә эшләүне үзләренең беренче чираттагы бурычлары итеп санадылар. Шефлык эше төрле формада алып барылды. Шулай да урыннарда концерт һәм спектакльләр күрсәтүгә күбрәк игътибар ителде. Кызыл Армия частьларында һәм күченеп килгән госпитальләрдә, мәсәлән, бер ел эчендә генә дә 2586 концерт бирелде. Аерым төркемнәргә бүленгән артистлар яки бөтен бер коллективлар Казанда урнашкан хәрби подразделениеләргә көн саен барып тордылар. Хәрби шефлык эше белән профсоюзларның сәнгать работниклары үзәк комитеты һәм шулай ук СССР Халык Комиссарлары Советының Сәнгать эшләре буенча комитеты, Кызыл Армиянең Баш политик идарәсе җитәкчелек итте. Театрларда концерт бригадалары белән идарә итүче штаблар оештырылды. Хәрби частьларга, гадәттә, зур бригадалар, ә госпитальләргә җырчы, музыкант һәм нәфис сүз остасыннан торган группалар җибәрелде. Шефлык эшенең мондый формасын тормыш үзе кулай күрде. Госпитальләр байтак: мәктәпләргә, институтларга, клубларга һәм хәтта филармониягә яралылар китерелгән. «Совет» кунакханәсендә, мәсәлән, Зур драма театры шефлыгындагы госпиталь урнашкан. Бирегә артистлар еш кына балаларны да алып килгәннәр, чөнки аларның чыгышларын яралылар аеруча яратып тыңлаган.

«Яралылар янына килгәндә без һәрвакыт дулкынландык,— дип искә ала җырчы Разия Тимерханова.— Сугыш беркемне дә аямады: яшьләрне дә, өлкәннәрне дә... Бервакыт мин яралылар алдында җырлый башладым. Игътибарым бер солдатның куркыныч рәвештә җәрәхәтләнгән йөзенә юнәлде. Кешелеге калмаган... Хәтта яшен дә чамалап булмый. Миңа авыр булып китте. Солдат ярасының әрнүе, әйтерсең, минем тәнемә күчте...»

Артисткага авыр булып киткән, ә яралыга бәлки күпмедер җиңеллек килгәндер. Шушы уңайдан танк гаскәрләре генерал-майоры Кошуба сүзләрен искә төшереп үтү урынлы булыр: «Мин врачларга яхшы концертны көчле тәэсир итүчән дәва урынына кулланырга киңәш итәм. Артистлар килүен ишеткәч, каты яраланган сугышчылар да үзләрен кичекмәстән залга күчерүләрен сорыйлар. Ә артистлар турыдан-туры палатага килсәләр, күрсәгез икән, яралылар ничек сөенәләр!..»

Культура учреждениеләренең хәрби шефлык эшендә оборона ихтыяҗына спектакль һәм концертлар бирү дә күздә тотылды. Зур драма театры, мәсәлән, шундый фонд өчен 63 спектакль күрсәтте. Шундый ук ихтыяҗга артистларның бер көнлек эш хакы да җибәрелде. Илебезнең оборона куәтен арттыруда башка төрле чаралар да файдаланылды. Самолетлар төзү максатыннан тупланган 363 мең сум акча өчен рәхмәт әйтеп, И. В. Сталин 1943 елда драма театры коллективына телеграмма да җибәрде.

«Совет артисты» эскадрильясы... Башкалабызның Е. Вахтангов исемендәге театры коллективы, сәнгать эшлеклеләре средствосына самолетлар төзүгә чакырып, илебездәге барлык артистларга мөрәҗәгать белән чыктылар. «Кеше кыяфәтендәге ерткычларга эскадрилья көнен дә, төнен дә тынгы бирмәсен,— диелә мөрәҗәгатьтә.— Гитлер белсен: совет халкы — бердәм, һәм ул үзенең ирегең, иҗади хезмәт сөенечләрен, дөнья культурасының иң яхшы үрнәкләрен үзендә сеңдергән культурасын беркемгә дә бирми. Совет халкының куәт-көче тагын да артты. Фашизмны юк иткәнчегә кадәр ул кулыннан коралын ташламаячак...» Вахтанговлылар чакыруына Казан артистлары да бердәм кушылдылар.

«...Җырым белән җиңдем дошманны!...» Каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең әнә шундый сүзләрен һәркем хәтерлидер. Бөек Ватан сугышында, әйе, җыр да атакага барды, фашизм оясы рейхстагны ялкынлы җыр да алышты. Сәнгатьнең җиңүгә рухландыруы, гомумән, гражданнар сугышы елларында ук расланган. Бөтенроссия хәрби комиссарлар бюросы нәкъ менә шушы елларда артистлардан беренче фронт группалары оештыра. Менә шундый традиция соңгы сугышта да дәвам итте. Сугышның беренче көннәрендә ук сәнгать эшлеклеләре сүз бирделәр: үзебезнең корал көче белән совет халкының бөек азатлык көрәшендә катнашырга!..

Гуманизм белән коралланган совет сәнгате тиз арада идеология фронты армиясенең ышанычлы зур көченә әверелде. Утлы сугышның авыр юллары буйлап 42 мең артист солдат йөрәгенә рухландыргыч сәнгатьләрен алып килделәр: К. Шульженко, Л. Утесов, А. Пирогов, И. Козловский, М. Михайлов, Г. Уланова, А. Зуева, А. Тарасова, С. Пилявская, Л. Русланова... Әлеге исемлеккә без хаклы рәвештә Татарстан артистларын да кертәбез. Шулар арасында сугышчан медальләр белән бүләкләнгәннәр дә шактый, әйтик, А. Гусев, А. Люлюкин, Е. Лисецкая, М. Булатова кебекләргә шул чорда ТАССРның халык яки атказанган исемнәре дә бирелде.

Турыдан-туры фронтка хезмәт күрсәтү өчен Казанда 14 концерт бригадасы оештырылды. Әлеге коллективларга филармония, академия, опера һәм балет, Зур драма һәм Яшь тамашачылар театрларындагы иҗат көчләре тупланды. Бригада членнары көче командирлар составы белән «тигезләштереп» каралды һәм аларга офицер паеклары бирелде. Мондый мөнәсәбәт исә партия һәм хөкүмәтебезнең сәхнә осталары турында ихлас кайгыртуын һәм аларны зур көч итеп каравын раслый.

Татар дәүләт филармониясе фронт бригадаларын төзүгә әйрүча зур өлеш кертте. Сугышның беренче елында ук җыр һәм бию ансамбле хәрәкәттәге армия частьларына хезмәт күрсәтте һәм сугышчыларның гаять зур ихтирамын казанды. Бригадалар теләсә нинди авыр шартларда җиңел хәрәкәт итә алырлык итеп төзелде, һәм аларны оештырганда жанр төрлелеге дә исәпкә алынды. Нигездә ун-уникә кешедән торган мондый төркемнәргә музыкантлар, җырчылар, нәфис сүз осталары, драма артистлары, биючеләр, балет осталары кертелде. ТАССРның атказанган артисты Г. Вәлиев бригадасы, мәсәлән, Брянск фронтында шундыйрак составта чыгышлар ясады.

...1941 ел ахыры... Дошман Мәскәүгә якынлаша. Ватан-ана авыр көннәр кичерә. Гомерләрен аямыйча көрәшүче сугышчыларга, корал белән бергә, беренче концерт бригадалары да җибәрелә... Һәрбер кеше шуны яхшы аңлый: рух ныклыгыннан башка җиңүгә ирешеп булмаячак! Менә шуңа күрә сугыш башында ук сәнгатьнең туплау һәм тәрбияләү көченә гаять зур әһәмият бирелә. Кырык бернең ахырына ук Казан хәрәкәттәге армиягә өч бригада җибәрә. Аларның юлы Мәскәү янынннан башлана. Татарстан башкаласыннан җибәрелгән бригадалар, гомумән алганда, унбер фронт сугышчыларына культура хезмәте күрсәтәләр. Тимер ташкын булып хәрәкәт итүче гаскәрләр белән бергә, казанлылар хәрабәле Польша, Көнчыгыш Пруссия, Германия аша үтәләр һәм данлы җиңү көнен Берлинда каршылыйлар.

Концерт бригадаларының «сәяхәтләре» гадәттә 45 көнгә сузыла, ә Казан артистлары аш кына икенче срокка да калалар. Мәсәлән, Н. Ширкин бригадасы алгы сызыкта җиде й (!) бүе концертлар бирә һәм соңыннан фашистлар оясына кадәр барып җитә, шулай итеп, «җан азыгы өләшүнеләр» җиңүне якынайтырга ярдәм итәләр.

«Сезнең концертка рәхмәт билгесе итеп, без, окопка кайткач ук, фашистларга «концерт» оештырырбыз...» Әлеге юлларны 205 фашистны юк иткән снайперлар Куликов, Братилов һәм Минигуров Казан артистларына рәхмәт төсендә язганнар. Солдат рәхмәте... «Күренмәс крепость ташчылары»н ул сугышчан бүләк алгандай горурландырган, чөнки рәхмәт сүзләре җаваплы максатка ирешү турында сөйли.

Казан артистларына рәхмәт белдереп язылган рәсми хатлар да шактый. Мәсәлән, Эстония Компартиясенең Ветсерим уезд комитеты секретаре А. Овсянников ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетына мондый хат җибәрә: «Сезнең бригада тарафыннан азат ителгән шәһәребез кешеләре өчен бирелгән концерт фашист коллыгында өч елдан артык куркыныч кара төн кичергән эстон халкына культура хезмәте күрсәтү итеп кенә түгел, ә татар халкының туганнарча ярдәме буларак кабул ителде...»

«Иҗат итү, димәк, үлемне үтерү...» Совет артистларының дәһшәтле фронт юлларын күзаллаганда, Р. Ролланның әнә шундый сүзләре хәтергә килә.

...Карелия фронты. Госпиталь. Филармония җырчысы Александра Бабенова «Тройка»ны җырлап җибәрә. Ятакларның берсеннән каты яраланган партизан күтәрелергә азаплана. Сугышчы үҗәтләнеп булса да күтәрелә һәм, артисткага кушылып, «Тройка»ны ахырына кадәр җырлый...

Концертлар белән йөргәндә якташлар да очраштыра. Ватаныбыз башкаласына ыргылган дошманны 100—200 чакрым артка чигендергән көннәрдә (1942) Казан артистлары беренче татар балеты — атаклы «Шүрәле»не иҗат иткән композитор Фәрит Яруллинны очраталар. Туган илне фашизмнан азат итеп, Кенигсбергка якынлашканда, алар тагын бер данлы якташыбыз белән күрешәләр: шагыйрь Фатих Кәрим!.. Очрашалар һәм саубуллашалар... Саубуллашу мизгелендә әлеге композитор белән шагыйрьнең халык күңеленә мәңгелеккә китеп баруларын кем дә искәртми...

Карелия фронтында чыгыш ясаган концерт бригадасы җитәкчесе А. Гусев көндәлегеннән: «1942 ел, 13 сентябрь. 8 дә торабыз, тиз-тиз иртәнге ашны ашыйбыз һәм концертка җыенабыз. Сопка тирәли ике-өчәрләп барабыз. Әлеге урын дошман мушкасында тора. Сакчы кисәтә: «Күпердән тизрәк атлагыз!» Күперне үтәбез. Агачлык аша барабыз... 200 метрлап сазлыктан, аннары 300 метр чамасы ташлыктан атлыйбыз. Кыя кырыена ике щит куелган... Ботаклар белән маскировкаланган чишенер-киенер урын да әмәлләгәннәр. Кыяда, амфитеатрдагыча, алгы сызыктагы сугышчан каравылдан килгән солдатлар утырышкан. Башларында — каска, кулларында — автомат... Концерт бирәбез. Салкын. Әле кояш, әле яңгыр. Үтәли җил исә. Дошман артиллериясе ата. Снарядлар баш өстеннән очып китәләр дә кайдадыр ярылалар. Дошман снарядларының кая төшкәнлеген комиссар бик җитдилек белән күзәтеп тора. Хәвефләнерсең дә: концертка 700 ләп кеше җыелган. Концерт башыннан ахырына кадәр туплар дуэле аккомпанементы астында үтте».

Филармония биючесе Хәдичә Хәйруллина Кенигсберг госпиталендә бирелгән бер концертны искә төшерә: «Баксаң, без мина куелган госпитальдә чыгыш ясаганбыз. Соңыннан гына беленде...»

1945 ел. Берлин. «Правда»ның фронт корреспонденты Я. Макаренко репортажыннан: «Бервакыт әле генә сугышып алынган урамда миңа рояль тавышы ишетелде. Каян килеп чыккан ул? Скулковтан машинаны туктатуын сорадым. Тыңлыйм. Чаттан борылып, артиллерия батареясы позициясенә чыктык. Мостовойда, орудиеләр янәшәсендә чыннан да, җемел-җемел килеп, ачык рояль тора иде. Матвей Блантер уйный, ә икенче композитор Тихон Хренников җырлый...»

Кылыч һәм лира... Ватаныбыз гаять авыр сынау чорын кичергән чакта алар, үзара кушылып, тиңе булмаган дәһшәтле коралга әверелделәр. Бөек Җиңүне якынайтуга социалистик сәнгатебез, аерым алганда, совет артисты сәнгате бәяләп бетергесез өлеш кертте. Туплар аткан чакта да музалар тын тормады.

# ҮЗӘК НӘШРИЯТЛАР — КАЗАНДА

(1941—1943 ЕЛЛАР)

Бөек Ватан сугышы башлангач та, совет хөкүмәте карары белән Мәскәү һәм Ленинградтагы СССР Фәннәр Академиясе, Сәламәтлек саклау халык комиссариатының медицина, СССР оборона халык комиссариатының хәрби һәм «Совет язучысы» нәшриятлары бай полиграфия базасы булган Казан шәһәренә эвакуацияләнделәр. Бу вакытта Казанда Камил Якуб исемендәге китап фабрикасы, Татполиграф, Н. Александров исемендәге типографияләр эшли. Казанга күчеп килгән нәшриятларның эшчәнлеге 1941—43 елларга туры килә. Шушы елларда башкалабыз Казанда сәүдә, азык промышленносте, финанс халык комиссариатлары да үзләренең ведомство басмаларын хәзерлиләр.

Үзәк нәшриятлар зур һәм дәрәҗәле авторлар коллективы белән аерылып торалар. Сугышның беренче елларында илебезнең зур галимнәре — 93 академик һәм СССР Фәннәр академиясенең член-корреспондентлары Казанда иделәр. Шулар арасында О. Ю. Шмидт, Г. М. Кржижановский, С. И. Вавилов, Е. А. Чудаков, Е. В. Тарле, Н. С. Державин, В. В. Струве, Е. С. Варга, Б. Д. Греков, А. С. Несмеянов, Л. Е. Орбели, П. Капица, А. Порай-Кашиц, Н. Г. Бруевич, Х. С. Коштоянц һәм башкалар бар.

Шул ук вакытта Д. Бедный, Л. Леонов, Л. Ошанин, К. Федин, М. Алигер, В. Бахметьев, Н. Асеев, М. Исаковский, Ярослав Галан, К. Тренев, Вилли Бредель, Джиовани Джерманетто, Жан Ришар Блок, Сесар М. Араконда кебек күп кенә күренекле совет һәм чит ил язучылары да Казанда иҗатларын уңышлы дәвам иттерәләр. Үзәк нәшриятлар Казандагы эшчәнлек чорында барлыгы 194 исемдә китап бастырып чыгаралар. Шуларның 66-сы — хәрби, 54-е — медицина, 46-сы — СССР Фәннәр академиясе, 13-е — «Совет язучысы» һәм 15 басма союз халык комиссариатлары нәшриятларыныкы. Аларның гомуми тиражы 2,5 миллионнан артып китә. Биредә әле хәрби нәшрият мәгълүматлары исәпкә алынмаган, чөнки аның китапларында тираж күрсәтелмәгән. Аның продукциясе Казанда чыккан үзәк нәшрият басмаларының өчтән берен тәшкил итә. Болардан тыш Фәннәр академиясе ай саен физика һәм химия буенча унбер фәнни журнал бастырып чыгара.

Бөек Ватан сугышы елларында басма продукциянең тематикасы да тамырдан үзгәрә. Күп кенә, хәтта иң әһәмиятле китапларны да басу эше туктатылды. Болар — әсәрләр җыентыгы һәм башка күп томлы әсәрләр. Бөтен игътибар фронт һәм тыл ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән иде. Үзәк һәм урындагы нәшриятлар китап продукциясендә төп урынны иҗтимагый-политик, хәрби-политик әдәбият алып тора.

Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте җитәкчеләренең аерым брошюралар булып басылып чыккан дошманның мәкерле планнарын фаш итүче, аның белән кыю көрәшкә өндәүче чыгышлары, речьләре халык массаларына әһәмиятле тәэсир ясады.

1942 елда Казанда хәрби нәшрият М. И. Калининның «Совет халкының немец илбасарларына каршы Ватан сугышы» исемле, шулай ук К. Е. Ворошилов, Е. М. Ярославскийларның чыгышларын бастырып чыгарды. «Совет халкының немец-гитлер империализмына каршы сугышы — азатлык өчен гадел сугыш» исемле мәкаләләр җыентыгы, академик Г. Ф. Александровның «Гитлер Германиясе үз җинаятьләре авырлыгыннан шартлый» исемле брошюрасы фашистлар башлаган сугыш характерының асылын ачуга багышланганнар.

Совет нәшриятларының басма продукциясендә фашизмның реакцион асылын чагылдыручы, совет халыкларының героик үткәне турында сөйләүче хезмәтләр зур урын алып тора. Шундый эчтәлекле әдәбиятны Татарстан полиграфия комбинатында СССР Фәннәр академиясе аеруча күп бастырып чыгарды. Мәсәлән, бөек пролетар язучы М. Горькийның фашист каннибалларына каршы 1930—1936 елларда үзәк матбугатта дөнья күргән фикерләреннән төзелгән махсус җыентык шул академия тарафыннан хәзерләнгән. Мәскәүдә 1941 елның октябрь һәм 1942 елның апрелендә булып узган Совет галимнәренең фашизмга каршы беренче һәм икенче Бөтенславян митингълары материаллары да Казанда җыентык рәвешендә басылып чыга. Алар нацистлар партиясе һәм аның җитәкчеләренең кабахәт йөзен, җинаятьчел уйларын фаш итүдә зур политик әһәмияткә ия булалар. Бөтенславян митингъсы материаллары җыентыгында Мәрәҗәгать, Бөтенславян комитеты председателе генерал-лейтенант А. Гундаров, язучы Н. Тихонов, композитор Д. Шостакович, украин язучысы А. Корнейчук, белорус шагыйре Якуб Колас, поляк язучысы Ванда Василевская, Чехословакия, Болгария, Сербия җәмәгать эшлеклеләренең чыгышлары урын алган.

СССР Фәннәр академиясе нәшрияты илебезнең күп кенә танылган галимнәренең, мәсәлән, Е. С. Варгиның «Европада фашистик «яңа» тәртип», В. В. Струвеның «Фа-

шистик антисемитизм», Н. С. Державинның «Фашизм — славяннарның явыз дошманы», «Чехословакия халыкларының немец вәхшиләренә каршы героик көрәше», Е. В. Тарленың «Гитлерчылар һәм Наполеон эпохасы», «1812 елгы Ватан сугышы һәм Наполеон армиясен тар-мар итү», шулай ук И. И. Зильберфарбның «Фашизм — культуралар дошманы», В. К. Сивковның «1812 елда Россиядә Наполеонны тар-мар итү», Ф. И. Нотовичның «1918 елда Германия армиясен тар-мар итү», К. А. Зеленскийның «Рус әдәбиятында немец агрессиясенә каршы көрәш», Л. П. Кростыньның «Балтик буе халыкларының немец басып алучыларына каршы көрәше», Д. И. Влаховның «Грек халкының Германия фашизмына каршы көрәше» исемле хезмәтләрен халыкка таратты.

Фашист гаскәрләре оккупацияләгән илләр халыкларының ирексез, җәберләнгән хәлдә булулары турында О. И. Фишерның «Австрия Гитлер Германиясе тырнагы астында» П. Э. Крицманның «Боярлар Румыниясе Гитлер власте кулында», И. П. Фроничның «Сербия Германия оккупантлары изүе астында» һ. б. китаплар сөйли.

Бу хезмәтләр бик зур — 10-50 мең данә тираж белән басылганнар. Камил Якуб исемендәге китап фабрикасында хәзерләнгән Хәрби нәшрият басмалары да югарыда әйтеп үтелгән проблемаларга багышланганнар. «Немец-гитлер империализмы — кешелекнең явыз дошманы», «Немец илбасарларының ерткычлыгы (фактлар һәм документлар)», «Немец армиясенең политик-мораль хәле турында», академик М. Нечкинаның «Рус хәрби героизмының тарихи традицияләре» һ. б. хезмәтләр әнә шундыйлардан.

Бу публикацияләр совет кешеләрендә гитлерчыларга ачы нәфрәт тәрбияләүдә һәм дошманны тар-мар итүгә ярдәм иттеләр.

Китап һәм брошюраларның күбесе Кызыл Армиянең героик көрәшенә, фронттагы көчле сугышларга багышланганнар. Казанда Хәрби нәшрият бастырып чыгарган «Мәскәү», «Гвардия», «Тихвин шәһәре өчен сугышлар» һ. б. очерк китапларын мисалга китерергә мөмкин. Рус халкының героик үткәне, аның хәрби тарихы белән совет кешеләренең кызыксынуы артуны истә тотып үзәк нәшриятлар күренекле полководецларга багышланган популяр брошюралар сериясе чыгаруны да оештыралар.

1942 елда Хәрби нәшрият Казанда хәрби тарихчы Н. Е. Подорожныйның «Кутузов», «Александр Суворов», «Александр Невский», В. Костылевның «Минин һәм Пожарский — безнең бабаларыбыз» китапларын бастырып чыгара. Шул ук вакытта хәрби нәшрият белән берлектә СССР Фәннәр академиясе нәшрияты академик Е. В. Тарленың «Михаил Кутузов» һәм «Нахимов» хезмәтләрен халыкка җиткерә.

Фәнни-техник әдәбият чыгарып, Фәннәр академиясе нәшрияты оборона промышленносте һәм халык хуҗалыгына актив ярдәм итте. Бу юнәлештә Фәннәр академиясенең машиналарны өйрәнү Институты нәтиҗәле эшләде. Биредә академик Е. А. Чудаков һәм Н. Г. Бруевич техника һәм машина төзү мәсьәләләренә багышланган егермеләп китап хәзерләп чыгардылар. СССР Фәннәр академиясенең Бөек Ватан сугышы чорында Казанда чыгарылган басма продукция арасында дөньяның мәшһүр галиме И. М. Сеченовның «Баш мие рефлекслары», күренекле академик Н. Ф. Гамалейның «Грипп һәм аның белән көрәш», академик Н. Д. Зеленский һәм В. С. Садиковларның «Күмер — тынны буучы һәм агулы газлар белән көрәш чарасы», СССР Фәннәр академиясенең булачак президенты С. И. Вавиловның «Салкын төс» кебек зур әсәрләре бүгенге көн укучыларының да игътибар үзәгендә.

Хәрби нәшрият чыгарган басма продукция Кызыл Армия сугышчылары һәм тыныч халык өчен зур практик әһәмияткә ия булды. Хәрби өйрәтүләр максатында бу нәшрият ату һөнәре буенча, автоматик корыла торган винтовкалар, пулеметлар, автоматлар, минометлар, кул гранаталары, танкка каршы миналар, башка төр коралларның төзелеше һәм кулланышы турында күрсәтмәләр бастырып чыгара. Сугыш алып бару тактикасы, кышын елга һәм тауларны кичү, сугыш һәм транспорт машиналарын кыр шартларында эксплуатацияләү, дошманнан яшерену, урманлы урыннарда ориентлашу, дошман танклары белән көрәш, хәрәкәттәге армия сугышчыларының шәхси гигиенасы мәсьәләләре буенча күп санлы кулланма, брошюралар хәзерләде. Кайбер басмалар яндыра торган авиабомбаларны һәм аннан чыккан янгыннарны сүндерүгә, диверсантлар, һава десантлары һәм башка шундыйлар белән көрәштә совет кешеләренең уяулыкларын көчәйтүгә багышланганнар.

Казанда актив эшләгән медицина нәшрияты продукцияләре сәламәтлек саклауны оештыру, гигиена һәм санитария, гомуми терапия, кан күчерү, медицина микробиологиясе һәм паразитология, хирургия, ортопедия, невропатология, психотерапия, аналарны һәм балаларны саклау, хәрби медицина, хәрби санитария кебек әһәмиятле проблемаларга багышланганнар.

«Совет язучысы» нәшрияты да Казанда шактый гына әдәби продукция чыгарган. 1941 ел ахырында ук Н. Александров исемендәге типографиядә Владимир Лидинның «Документлар сөйли» исемле китабы басылып чыга. Немец солдатлары һәм офицерларының үз куллары белән язылган хатларыннан һәм көндәлекләреннән төзелгән бу китап,

автор сүзләре буенча, дошманның рухи нигезен, аның түбән әхлагын күрсәтүне максат итеп куя. 1942 елда К. Якуб исемендәге китап фабрикасында Б. Горбатовның «Иптәшкә хатлар» (сүзгә-сүз тәрҗемә), С. Алымовның «Барысы да җиңү өчен» (анда 13 шигырь басылган), П. Антокольскийның «Ярты ел», М. Матусовскийның «Фронт», В. Вишневскийның «Балтика флоты көрәшә», А. Гайдарның «Ракеталар һәм гранаталар», С. Щипачевның «Фронт шигырьләре», татар шагыйрьләренең «Фронтовик туганнарга» исемле шигырьләр җыентыгы, А. Новиков-Прибойның «Рус моряклырының сугышчан традицияләре» китаплары дөнья күрде. Шул ук вакытта венгр язучысы Иллеш Беланың «Фиорд буендагы авыл» исемле хикәяләр җыентыгы да басылып чыкты.

Бөек Ватан сугышы елларында очерк жанры аеруча киң таралды. Бу оператив жанрны А. Толстой, М. Шолохов, И. Эренбург, Н. Тихонов һәм башкалар фашист илбасарларның мәкерле планнарын, фронттагы канкойгыч бәрелешләрне, геройларны, совет партизаннарының авыр тормышларын, эшче-крестьяннарның тылдагы фидакарьлекләрен тасвирлауда кулландылар.

1942 елда бу нәшриятта А. Толстойның «Туган ил» исемле тематик җыентыгы басылып чыкты. Аңа «Туган ил», «Дошман Мәскәүгә якый», «Без нәрсә яклыйбыз», «Рус сугышчылары», «Геройлар армиясе», «Кыюлар», «Таран», «Халык каны», «Кем ул Гитлер һәм ул нәрсәгә омтыла?», «Гитлер армиясенең йөзе» һәм башка очерклар тупланган.

«Үлемгә нәфрәт» исемле җыентык та укучыларга зур эмоциональ тәэсир ясады. Анда Е. Кригерның «Бөек ант кешеләре», Э. Виленскийның «Билгесез моряк», Н. Тихоновның «Герой хатын», А. Жаровның «Соңгы патронга кадәр», Н. Павленконың «Үч», В. Кожевниковның «Павел Филатович Трошкин», П. Корзинкинның «Смоленск крестьянының батырлыгы», Гавриловичның «Партизан кызы», Г. Рыкдинның «Сугыш күренеше» бар. Басмаларның уртача тиражы 10—40 мең данә.

Гитлер Германиясе белән рәхимсез бәрелеш елларында Казанда эшләүче үзәк нәшриятлар илдәге эре китап басу үзәкләренең берсе — Татарстан дәүләт нәшрияты эшчәнлегенә файдалы тәэсир ясадылар. Бу нәшрият коллективы актуаль темага багышланган басмаларны билгеләүдә, материаллар белән тәэмин ителүдә үзәк нәшриятлар белән тыгыз хезмәттәшлектә тора. Хәрби нәшрият белән элемтәләр аеруча ныгый. Бу ике нәшриятның сугыш-фронт темасына багышланган унлап китап һәм брошюраны бергәләп хәзерләп чыгаруы очраклы хәл түгел. 1941 ел азагында «Кызылармеец китапханәсе» сериясендә күләм ягыннан артык зур булмаган популяр брошюралар басу җайга салына. Аларның максаты — сугышчыларны батырлык, патриотизм рухында, немец-фашист илбасарларына нәфрәт рухында тәрбияләү. Болар арасыннан А. Толстойның «Кыюлар» хикәясе, М. Шолоховның «Нәфрәт фәне» очеркы аеруча зур эмоциональ тәэсир ясый. Алар 1942 елда Хәрби нәшрият белән Татарстан дәүләт нәшрияты тарафыннан чыгарылганнар.

Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә эшләп, СССРның үзәк һәм урындагы нәшриятлары, сугыш чорының кырыс сынаулары каршында нык тордылар, күпмиллионлы совет халкын китап, брошюра һәм башка басма продукция белән тәэмин итеп, фашизмны җиңүгә, социализмның бөек казанышларын саклауга үзләреннән зур өлеш керттеләр.

**Тәлгат НАСЫЙРОВ,**
доцент, тарих фәннәре кандидаты.

Фәтхулла Абдуллин

# ЫШАНЫЧ

ОЧЕРК

Планны «Менә үтибез!», «Менә үтибез!» дип куанышып кына йөргәндә, бер «Андерсен аппараты» сафтан чыкты. Планны үтәү зур сорау астында калды. Ә инде Түбән Кама «Нефтехим» производство берләшмәсе илебезнең ничә-мә-ничә предприятиесе белән бәйле, ничәмә-ничә завод Түбән Кама каучугын көтеп тора. Болардан тыш тагын бик күп төрле чималлар... Ә чит илләр белән төзелгән килешүләр? Бигрәк тә капиталистик дәүләтләр алдында сынатмаска — илнең абруен төшермәскә иде! Шул сәбәпле слесарьлар, механиклар минуты-секунды белән дигәндәй, аппаратны сүтәргә, өзеклекнең сәбәбен ачыкларга керештеләр.

Каучук ясый торган җайланманың болгаткыч редукторындагы өченче буын тешле тәгәрмәч кырылып чыккан иде. Тиз генә заказ биреп кайтартыр идең, безнең илдә бер генә завод та андый нәрсәне ясамый — аларны чит илдән сатып алалар. Дөрес, соңгы вакытта берләшмәнең ремонт-механика заводында кайбер вак-төяк детальләрен ясый башладылар башлавын, әмма катлаулыларын алтын бәясенә чит илдән кайтарырга мәҗбүрләр. Әлеге тешле тәгәрмәчне табу өчен дә чит ил капкасын кагарга туры киләчәк иде.

Берләшмәнең баш инженеры Гаяз Зәмикович Сәхәпов селектор аша ремонт-механика заводы белән элемтәгә керде.

— Вячеслав Васильевич, синтетик каучук заводында — чэ-пэ!— диде ул мөмкин кадәр итәгатьле булырга тырышып.— Бер аппарат сафтан чыккан. Һаман шул каһәр суккан шестерня инде. Запасы да беткән икән. Берәр нәрсә майтара алмассызмы сез анда? Тагын бер талпынып карагыз әле!

Завод директоры Мәскәүдә командировкада, урынбасарның да бу хәл белән беренче тапкыр гына очрашуы түгел иде.

— Эшләп булмый аны, Гаяз Зәмикович,— диде ул баш инженерга.— Нигә бушка көч түгәргә? Барыбер эшләп булмый аны. Аннары, безнең башка заводлардан алган заказлар да җитәрлек.

Баш инженерга аның сүз сөреше ошамады. Ачуташ капкан кеше сыман чыраен сытып тыңласа тыңлады, шулай да бүлдермәде. Ниһаять, урынбасарның тавышы тынды.

—«Булмый» да «булмый». Ул ни дигән сүз, Алексей Семенович? Тагын бер тапкыр белгечләр белән сөйләшегез. Конструкторлар белән киңәшегез. Фрезерчыларны кызыксындыру чарасын табыгыз! Ике куллы кешеләр ясаган ич аны.

Баш инженерның таләпчән тавышы урынбасарны йомшатты.

— Ярар, Гаяз Зәмикович, мөмкин булганның барысын да эшләрбез.

— Мөмкин булганны кем дә эшли, сез мөмкин булмаганны эшләгез!

Шуның белән селекторның уты сүнде. Баш инженерның кырыс тавышы, тымызык күлгә бәреп кергән көчле агымдай, заводның тыныч тормышын дулкынландырып җибәрде. Каты чикләвек булды бу деталь. Күп кешеләрнең теңкәсенә тиде. Заводның алдынгы фрезерчыларыннан Салихов та, Семенов та ясап карады. Икесе дә тырыш егетләр. Ни кушсаң шуны үтәргә әзер торалар. Әмма, ни хәл итәсең, Андерсен аппаратына кирәкле шестерняга берсенең дә теше үтмәде. Боярский да булдыклы егет. Әллә соң?.. Хәер, ул да ике-өч тапкыр тырышып караган иде инде. Нәтиҗәсез. Тәҗрибәле фрезерчылардан тагын Шәйхелмәрданов Фоат бар барын...

* * *

Үз гомерендә нинди генә тешле тәгәрмәчләр ясамады Фоат?! Диаметры төрле-төрле, уйдыклары төрле-төрле... Әмма мондый зурларны! Тегермән ташы диярсең!..

...Фоатның әтисе тегерменче иде. Бәләкәй чакта ул Ык һәм Сөн буйларындагы су тегермәннәрен күреп үсте. Абыйлары-апалары белән тегермән ташына утырып уйнаганнары әле дә исендә. Әтисенең, таза-таза агайлар белән бергәләп, таш тешәгәне — чүкеп сыр-уйдыклар ясаганы бүгенгедәй күз алдында...

Ул өстәл киңәйткән арада электрокар белән бер чуман заготовкалар китереп киттеләр. Күрәсең, токарьлар цехында хәстәрен алдан ук күргәннәр: алай-болай кирәге чыкса дип әзерләп куйганнар иде.

Фоат станокның кунак каршыларга әзерләнгәндәй киңәйтелгән өстәленә түгәрәк тимерне урнаштырды. Сызымга карап, ясаячак тешләрнең үлчәмен алды, тиешле тешәгечне куйды. Тешләрнең санын да төгәл сакларга кирәк иде. Ә аның өчен деталь яткан өстәлнең әйләнү тизлеген хисаплап чыгаралар. Фоат махсус таблицадан кирәкле саннарны эзләп тапты.

Җир казучы механизмның бер сәгатьлек эше, уртача, сигез-ун сум, ә Андерсен аппараты»ныкы — алты мең сум. Шул байлык чыганагы әнә икенче тәүлек тик тора! Шуңа да, синтетик каучук заводы җитәкчеләре Фоатның эше белән сәгать саен диярлек кызыксыналар иде. Аның «хәлен белергә» култык астына папка кыстырган конструктор егет тә килде. Ул күзлеген бер салып, бер киеп, башта Фоатның эшләгәнен карап торды. Аннан соң гына станок янына үтте.

— Берәр ярдәм кирәкмиме?

— Юк.

«Ышанмыйлар ахры миңа», дип уйлады Фоат. Ул станогын туктатып, эшләнә торган детальнең үлчәмен тикшереп карады. Миллиметрның йөздән бер өлешенә кадәр төгәллек белән күрсәтә торган штангенциркуль тешләрнең «гаебен» тапмады. Карап торуга, әллә ни катлаулы нәрсә дә түгел шикелле. Егетләр нишләп булдыра алмаганнардыр? Һәм чыннан да, смена ахырына Андерсен аппаратына кирәкле тәгәрмәч әзер иде. Әзер булганын дүрт күз белән көтеп торган механиклар аны, ашык-пошык кына техник контроль бүлегенә күрсәттеләр дә, җылы килдан алып та киттеләр.

Фоат әкрен генә станогын чистартырга керешә. Аннары күрше станокта эшләүче энесенә дәште.

— Әйдә, энем, киттек!

Миргазиян яшьләргә хас кайнарлык белән җәһәтрәк кыланганмы, станок тирәсен абыйсыннан алда тәртипкә китергән. Ул инде кайтырга атлыгып тора иде.

— Өйгәме?— диде.

— Юк, каучук заводына.— Фоатның үзе ясаган деталь эшен күрәсе килә иде.

Әмма механиклар:

— Ким дигәндә, ике смена җыярга кирәк әле моны, брат,— дип аның кайнарлыгын сүрелдерделәр.

Фоатның сабырсызлануы хәерлегә булмаган икән — бөтен хезмәт, тешле тәгәрмәч беренче әйләнү белән үк, җилгә очты, тешле тәгәрмәч кырылып чыккан иде. Аппаратны кабат сүтәргә керештеләр.

— Менә, эшләп булмый дип әйттем ич мин сезгә!— диде урынбасар кулларын җәеп.— Вакыт кына әрәм итәбез.

Гаяз Зәмикович сәерсенеп аңа текәлде.

— Сез, Алексей Семенович, шатланган кебек кыланасыз әле?!

— Мин шатланмыйм. Бер кешегә ышанып, йөзләгән меңнәрнең җилгә очуына борчылам.

— Башка фрезерчыларны да бу эшкә тартырга иде,— диде баш инженер төксе генә.— Монысы инде сезнең хата. Конструкторлык бюросында бу юнәлештә нилэр эшләнә?

— Үзем эшлим, миңа сезнең ярдәм кирәк түгел дип, Шәйхелмәрданов конструкторны борып чыгарган.

— Димәк, ул үзенә ышанган.

— Үзеңә ышану — әйбәт сыйфат анысы. Нәтиҗәсе дә шулай ышанычлы килеп чыкса иде. Юк бит, юк! Алай булмады бит.

— Тәкъдимегез нинди?

— Юкка вакыт әрәм иткәнче, тизрәк тышкы сәүдә министрлыгына документ әзерләп җибәрергә кирәк, минемчә.

Гаяз Зәмикович теше сызлагандай йөзен чытты. Чөнки ул мондый эшнең айларга сузыласын яхшы белә. Сезгә кирәк икән дип, кем анда сикереп төшсен?

Тагын нәрсәсе килешми икән моның, дип ачынды Фоат. Алдында яткан деталь ватыкларын әйләндерә-әйләндерә карады. Бәлки, тимернең составы башкачадыр?

— Мөмкин булса, миңа ул аппаратның техник паспортын бирегез әле,— диде ул, каучук ясаучы цех начальнигына мөрәҗәгать итеп. Рев Шәрифуллович Хисаев шкафтан калын-калын китаплар тартып чыгарды.

— Рәхим итегез!

— Миңа әлеге шестерня хакындагысын гына бирсәгезче!

Цех начальнигы өстәл өстенә күчкән китаплар арасыннан аралап, берсен Фоатка сузды. Аппаратның характеристикасы инглиз телендә язылган иде. Ярдәмгә тәрҗемәче чакырттылар. Шулай да металл составында бәйләнерлек урын тапмады Фоат. Сәбәбен башка җирдән эзләргә кирәк иде. Ул деталь ватыкларын күтәреп цехтан чыгып китте. Чагыштырып карау өчен чит илдән кайтартылганның да ватыкларын алды.

Миргазиян — абыйсының кәефе юклыгын ул цехка керү белән үк аңлады. Борчылуы йөзенә чыккан. Гомергә тыныч холыклы Фоатны танырлык түгел. Ул энесе белән баш кагып исәнләште дә кулындагы деталь ватыкларын идәнгә томырды. Шкафын ачып, инструментлар арасында шалтыр-шолтыр актарынгач кына, станогына яңа заготовка урнаштырды. Ул да булмады, тимер кисәкләрен өстәлгә ыргытып, каядыр чыгып югалды. Күп тә үтмәде, кулына лупа тотып кабат килеп керде. Миргазиян үзалдына елмаеп:

— Абый, син ул микроскоп белән нишләмәкче буласың?— диде.

Фоат энесенә бирелеп ишетмәдеме, энесенә җавап бирмәде. Кинәт кенә станогын туктатып, тешәгечен алыштырды...

Баш инженерның күрсәтмәсе буенча «Андерсен аппараты»на кирәкле тешле тәгәрмәчне хәзер берьюлы берничә белгеч эшли иде. Фрезерчылар янына Гаяз Зәмикович Сәхәпов үзе дә килеп китте. Әмма күңелгә ятышлы сүз ишетмәде. Тәки Алексей Семенович әйткәнчә эшләргә туры килер микәнни, дип борчылды баш инженер. Инде эш шуңа килеп терәлгән икән, киңәшеп алуың хәерле. Баш белгечләр, бик озак киңәшкәннән соң, кирәкле детальне кайтарту өчен документ әзерләргә дигән карарга килделәр. Берләшмәнең генераль директоры Николай Васильевич Лемаев та документка имза салды.

...Фоат бу серле детальнең ватылу сәбәбен аңлый алмый аптырады. Ташкент экскаватор заводында эшләгәндә дә бер тапкыр шундыйрак хәл туган иде. Африка дәүләтләренең берсенә кирәкле экскаваторларны шул климатка яраклы итеп эшләгәндә... Тукта, тукта!.. Америкада да шушындый ук аппаратлар ясый түгелме соң каучукны? Әйе, нәкъ шундый аппаратлар дип сөйләделәр күреп кайткан егетләр. Ә менә анда ясалган каучук белән бездә эшләнгәненең аермасы бармы икән?

Кайбер кайнар башлар аның соравын ишеткәч, көлеп үк җибәрделәр.

— Монда каучук брикетлары таралмаган ич. Каучук ясаучы аппарат ватылган.

— Сез минем сорауга җавап бирегез әле!— диде ул белгечләргә.

— Түбән Кама каучугы натураль каучукка якын.

— Чыдамлыгы белән аннан да өстенрәк.

— Мин аларын яхшы беләм. Ә менә сыйфаттан тыш, тагын берәр төрле үзенчәлеге юкмы?

— Американыкы сыеграк, безнеке нык, бераз катырак.

Фоат шатлыгыннан кычкырып җибәрә язды. Катырак! Соң алай булгач, редукторның тешле тәгәрмәченә кыенрак икән ләбаса. Менә кайда икән аның еш ватылу сере! Димәк, ул деталь өчен кирәкле металл да катырак булырга тиеш.

Цех буйлап ашыга-ашыга профком председателе килгәне күренде.

— Шестерняның бер теше профкомга да тигән ахры, кабаланып болайга таба килә,— диде Миргазиян абыйсына. Профком председателе, чыннан да, алар янына килеп туктады.

— Сәлам егетләргә!

Фоат станогыннан аерылмый гына аның сәламен алды. Гәүдәгә әллә ни зур булмаса да, эшлеклелеге белән ихтирам яулаган председатель папкасыннан җәһәт кенә бер кәгазь тартып чыгарды да аның алдына куйды.

— Нәрсә ул?

— Мәскәүгә путевка! Махсус синең заказ буенча.

Дөрес. Әйткән иде шул Фоат. Булса, зинһар, безне онытмагыз әле!— дигән иде. Үзеннән бигрәк, унынчы класста укучы улына һәм кызларына башкаланы күрсәтергә вәгъдә биргән иде. Вакытсызрак туры килгән икән, шайтан алгыры! Нишләргә соң хәзер аңа! Нишләргә? Хатынның да мәшәкатьле чагы — яңа ачылган бакчага мөдир итеп куйганнар. Көнне төнгә ялгап бакча кирәген кайгырта.

Профком председателенең вакыты тар иде бугай, ашыктыра башлады.

— Мә, Шәйхелмәрдәнеч, кул куй да, тизрәк кесәңә тык! Притом бушлай!

Фоат станогын вакытлыча автоматка күчерде дә путевканы кулына алды. Аның һәр юлын отып калырга теләгәндәй, әйләндерә-әйләндерә карады. Җомга көн кич китеп, якшәмбе әйләнеп кайту — барысы да әйбәт уйланган иде.

— Мәскәүне күреп кайту начар булмас иде дә... Барып булмас шул, Хәкимулла Нәгимуллович.

Профком председателенең әле генә балкыган йөзеннән елмаю качты.

— Соң заводта синнән башка фрезерчы юкмыни! Мин дә бит уйнап йөрмим,— диде ул җәберсенеп.— Профком утырышында хәл ителгән. Билетларга заказ бирелгән!

— Олы башыгызны кече итеп килүегезгә рәхмәт. Менә монда җитди эш килеп чыкты бит әле.

Һәм ул кулындагы путевканы кире сузды.

— Их, Фоат, Фоат! Әйт кенә, аны бит хәзер кушкуллап алачаклар.

— Ярамас, авыр чакта ташлап китү килешмәс. Тагын булыр әле.

* * *

Бу көннәрдә Фоат алны-ялны белми эшләде. Тешәде, үлчәде, тагын тешәде, тагын үлчәде...

Менә, ниһаять, слесарьлар болгаткыч редукторның соңгы шөрепләрен боралар. Аппаратчылар хәзерлек эшләре белән мәшгуль. Бүген монда завод хуҗалары гына түгел, берләшмә җитәкчеләре дә җыелган. Барысы да дулкынлана. Үзебездә эшләнгән тешле тегәрмәч аппаратка килешерме, юкмы? Һаман шулай алтынга табынучыларга ялынырбызмы? Шулай да монда бөтенесеннән дә ныграк дулкынланган кеше, мөгаен, Фоат булгандыр. Ул ясаган деталь сынатмасмы? Һәр миллиметры җентекләп тикшерелде, төгәллеге җиде кат үлчәп эшләнде эшләвен. Аппаратка куйгач нишләр? Коллектив алдында хур булмасмы?

Әнә аппаратчылар хәзерлек эшләрен төгәлләделәр. Менә, каучук өчен кирәкле чимал бирелде. Аппарат салмак кына гөрләп эшләргә тотынды! Бер, ике, өч... Әйбәт. Ура!

Урынбасар, машина гөрелтесен җиңәргә тырышып, баш инженерга дәште:

— Тагын бер-ике генә көн сабыр иткән булсак... Үтенеч кәгазенең киреге калмады бит.

— Ә ул минем өстәл тартмасында ята,— диде баш инженер гади генә итеп. Әйтерсең, сүз сәлам хаты турында бара.

Урынбасар озак кына итеп башын чайкап торды.

— Ну, Гаяз Зәмикович, йөрәк тә бар икән үзегездә, ә! Тәвәккәлләгәнсез! Әгәр дә Шәйхелмәрдәнов ясый алмаган булса, нишләр идегез?

— Мин аңа ышандым.

Бу урында цех начальнигы да үзенең горурлануын яшереп кала алмады.

— Алексей Семенович, сез — яңа кеше, белмисездер әле: шин заводын сафка бастырганда да вулканизаторлар өчен кирәкле прессформаны Фоат Шәйхелмәрдәнов ясады бит. Ул чагында хәзерге инструментлар да юк иде әле.

Цех начальнигы Фоатның оста фрезерчы гына түгел, яшьләрнең остазы да, заводның һәм заводның гына түгел, профсоюзның өлкә комитеты члены да икәнен һәм тагын ниләрдер әйтмәкче иде, өлгерә алмый калды. Табасын табагачы белән тоткан килеш кенә коймагын сикертеп әйләндерүче җитез җиңгиләр сыман, каучук бөртекләрен сикертеп киптерүче җилләткеч хәрәкәткә килде. Бөртекләр бормалы җилләткечтә, тирбәлү законнарына буйсынып, югарыга сикерәләр. Иң биек ноктага җиткәч, алар, аксыл агым булып, пресслау станына агылалар. Кызлар әзер каучук кирпечләрен үтә күренмәле тышчага төрәләр дә кәгазь капчыкларга ук салып куялар. Ниһаять, каучук әзер! Аңардан әллә ниләр ясап була.

Фоат әле суынырга да өлгермәгән каучук капларына үрелде. Кулларына җылы йөгерде. Бу җылылыктан аның бөтен җанына рәхәтлек таралды.

*Вакыйф Нуруллинга 50 яшь*



# ЯГЫМЛЫ ГЕРОЙЛАР

Вакыйф Нуруллин иҗат эшчәнлеген хикәяләр язудан башлаган иде. Хикәяләре басыла барса да, бу жанр авторга зур уңыш китерде дип булмый. Прозаик буларак ул «Шинельсез солдатлар» повесте (1968) басылып чыккач танылды. Шуннан соң аның һәр әсәре күтәреп алына, яратып укыла торган булып китте.

Моның хикмәте, сере нидә? Җавапны язучының әсәрләрен укып-өйрәнеп кенә табарга мөмкин. «Шинельсез солдатлар» — сугыш елларындагы колхоз тормышы, авыл кешеләре турындагы әсәр. Повестьта сугыш чорындагы авылның беренче елы — иң авыр һәм кыен чоры — аеруча тулы һәм эзлекле итеп сурәтләнә. Автор укучыны сугыш китергән күп төрле кыенлыклар белән таныштыра, аннан да бигрәк, авыл халкының шул кыенлыкларга каршы көрәшен, батырлыгын һәм чыдамлыгын күрсәтүгә нык басым ясый. Дөресен әйтергә кирәк, безнең әдәбиятта сугыш елларындагы һәм сугыштан соңгы авыл турында В. Нуруллин повестена хәтле дә, аңардан соң да бик күп әйбәт әсәрләр язылды. Мәсьәләгә шушы яктан караганда, «Шинельсез солдатлар» повесте белән язучы әдәбиятка өр-яңа материал алып килде, яңа тема күтәрде, дип булмый. Яңалык повестьның язылу алымында, тонында, героенда иде. Хикмәт шунда, сугыш чорындагы авыл тормышына караган башка күп кенә әсәрләрдән аермалы буларак, биредә вакыйгалар үзәгенә ун яшьлек малай образы куелган. Авыр һәм кырыс еллардагы колхоз тормышы, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр шул малай «каланча»сыннан карап сурәтләнә. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларны да, кешеләрне дә без Равил Нәҗметдинов бәясе, аның мөнәсәбәте аша кабул итәбез. «Шинельсез солдатлар» повестеның үзенчәлеге һәм яңалыгы да, аны укучыга якын иткән төп сыйфат та әнә шунда булса кирәк.

Автор бик дөрес яза: сугышның беренче көне Равилләр балачагының соңгы көне булып чыга. Моңарчы үз ишләре белән тәгәрмәч тәгәрәтеп, таякка атланып «ат-ат» уйнап йөргән ун яшьлек ваемсыз малай өчен, рәхәт тормыш бетеп, авыр көннәр, борчулы төннәр башлана. Сугыш чыгып күп тә үтми, аның яраткан абыйсы Искәндәр фронтка китеп бара. Көз җитеп, җирләр туңуга, әнисен окоп эшенә җибәрәләр.

Повестьның төп бер үзенчәлеге шунда, автор Равилне бер минутка да күз уңыннан ычкындырмый, аның һәр эшен, һәр адымын ныклы «күзәтү астында тота». Шул ук вакытта аны берөзлексез яңа сынаулар, яңа киртәләр алдына куя тора. Корычның ныклыгын утта яндырып сынаган кебек, язучы гүя героеның кемлеген авырлыклар белән сыный. (Шул эш белән мавыгып китеп, аз гына арттырып та җибәрә төсле.) Әнисе окоп эшендә йөргәндә, бозавын китерә алмыйча Равилләрнең сыеры үлә, салкын тиеп, баздагы бәрәңгеләре өши. Ул да түгел, яраткан абыйсының хатыны — сугыш башлануга кинәт кенә усалланып киткән әлеге Нәсиха җиңгәсе — чулак Самат белән чуала башлый. Саный китсәң, җанны әрнетә, бәгырьне телгәли торган хәлләрнең очына чыксыз. Әйтәсе дә юк, нечкә күңелле, ихлас табигатьле Равил боларның һәммәсен авыр кичерә. Гаилә эчендәге борчулар янына ил, халык өстенә төшкән олы кайгы өстәлә. Сугыш кырларыннан бер-бер артлы күңелсез хәбәрләр килеп тора. Равил яшәгән утыз җиде йортлы гына шушы авылдан әле кайчан гына кырык өч кеше сугышка киткән булган. Шуларның егерме тугызы турында я «үлде» яки «хәбәрсез югалды» дигән язу да килгән инде. Алар арасында Равилнең Искәндәр абыйсы һәм иптәш малайлары Фәрхетдин белән Миңлеәхмәтнең әтиләре дә бар. Гел шулай барса, тиздән бу

авылның бер кешесе дә исән калмаячак бит... Колхозның һәм авыл халкының да хәле шәптән түгел. Эшләргә кеше җитми, ферма малларының ашарына юк. Авыр кыш узып, яз җитүгә авылда ачлык башлана.

Сугыш чорының шушы барлык кыенлыкларын, алда әйтелгәнчә, язучы үн яшьлек Равил манарасыннан, аның мөнәсәбәте аша сурәтли. Равилнең иң зур егетлеге шунда: кыен чакта, авыр чакта ул сынатмый, сыгылып төшми, киресенчә, сугыш китергән авырлык һәм кыенлыкларны җиңә-җиңә, шактый иркә һәм йомшак табигатьле сыек малайдан ир-егеткә, «шинельсез» солдатка әйләнә бара. Бик яшьли чабата үрергә өйрәнә, сука һәм тырмага йөри башлый. Печән өсте җиткәч, болында печән тарттыра, ашлык сугу башлангач, ындырда ат куалый. Шул ук вакытта белем алуга, укырга булган дәртен дә сүндерми. Укучы Равилне әнә шул тырышлыгы, кыен чакта сынатмаганы өчен ярата, тагын ихласлыгы, эчкерсез булганы өчен үз итә. Геройның шул сыйфатлары укучы күңелендә тирән теләктәшлек, аның хәленә керәсе, кайгысын уртаклашасы килү тойгысын уята. Кабатлап әйтергә туры килә: «Шинельсез солдатлар»ның төп уңышы — әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар барышында формалаша, үсә-үзгәрә килгән Равил образында, повестьның төп яңалыгы — сугыш чорындагы авыл тормышын ун яшьлек малай ноктасыннан карап сурәтли алуда. Шул нәрсә, ягъни авыр һәм кырыс чорны ун яшьлек малай ноктасыннан карап сурәтләү әсәргә үзенчәлекле яңгыраш бирә. Шактый дәрәҗәдә самими һәм ихлас күңелле Равилнең дөнья хәлләренә биргән бәясе еш кына өлкәннәрнекеннән үтемлерәк булып чыга, фашистлар башлаган сугышның фаҗигасен һәм вәхшилеген, аннан да бигрәк, совет кешеләренең шул еллардагы фидакарьлеген һәм патриотизмын тирәнрәк, үткенрәк, тәэсирлерәк итеп ачарга булыша.

В. Нуруллин иҗаты хакында сүз чыкса, без еш кына аны әдәбиятта үз урыны, үз йөзе булган прозаиқ дип атыйбыз. Бай тарихы, зур традицияләре, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Галәү кебек классиклары булган әдәбиятта Вакыйф, чыннан да, үз урынын, үз йөзен таба алган икән, бу — зур нәрсә. Билгеле булганча, язучының индивидуаль йөзен аның иҗатына хас күп төрле сыйфатлардан чыгып билгелиләр. Ул сыйфатларның төрлесе: икенче дәрәҗәдәгеләре, шулай ук беренче дәрәҗәдәгеләре, ягъни хәлиткеч әһәмияткә ияләре була. Әйтик, В. Нуруллин иҗатын кызыклы һәм үзенчәлекле иткән сыйфатлар хакында сөйләгәндә, аның әсәрләренең гади стильдә язылуын, җылы һәм ихлас тонда булуын, башка якларын телгә алырга мөмкин. Әмма әдәбиятта үз урынын, үз йөзен ул, иң элек һәм беренче чиратта, Равил Нәҗметдинов кебек тырыш һәм эшчән, булдыклы һәм уңган, ихлас һәм ягымлы геройлар иҗат итеп тапты. Иң зурысы, хәлиткече — шулар. Әгәр укучы В. Нуруллинның повестьларын әдәби әсәр дип түгел, ә чын тормышның үзе дип кабул итә икән, моның да төп сере — геройлары ифрат дәрәҗәдә тормышчан булуда. Дөрес, алар бер-берсен кабатламый. «Шинельсез солдатлар» әсәрендәге Равил «Күпер чыкканда» повестендагы (1969) Өлфәт Хәкимовтан аерылган кебек, «Яшьнәп үткән яшьлек»тәге (1975) Миңнулла Гайсинны да «Аккан су юлын табар» повестендагы (1979) Булат Вәлиев янына янәшә куеп булмый. Яшьләре белән дә, эшләгән эшләре һәм холык-характерлары белән дә алар бер-берсеннән шактый аерылалар. Шул ук вакытта, бер ата, бер ана балалары төсле, әлеге геройлар үзара охшашлар, бер-беренә якыннар да. Алар барысы да — тырыш һәм уңган, ягымлы геройлар, һәммәсе дә — иң яшерен серләрен укучыга ышанып сөйли торган, үзләрен яраттыра торган мөлаем кешеләр. Бу — аларның төп сыйфаты. Җаена, авторның максат һәм ниятенә карап, әсәрләренең тема-проблемасы, материалы һәм җирлеге, чоры үзгәрергә мөмкин. Әмма В. Нуруллин геройларының әлеге сыйфаты, асылы даими килеш саклана килә, авторның образ иҗат итүдәге төп принциплары, концепциясе үзгәрешсез кала. Моны конкрет мисаллар китереп расларга мөмкин. Әйтик, «Шинельсез солдатлар»да язучы төп игътибарын авыл кешеләренең сугыш елларындагы батырлыгын һәм чыдамлыгын күрсәтүгә юнәлткән иде. Аның дәвамы булып саналган «Әгәр син булмасаң» повестенда исә мәсьәлә шактый үзгәрә. Үзенең элгәресеннән аермалы буларак, бусы — баштан ахырга хәтле мәхәббәткә багышланган повесть. Әмма төп герой — бер үк кеше, аны иҗат итү принциплары уртак дияргә була. Нәкъ «Шинельсез солдатлар»дагы кебек, В. Нуруллин үз әсәренең беренче битләреннән үк укучы күңелен үтә күренмәле ефәк бау белән Равил Нәҗметдиновка бәйләп куя. Төп герой һәрвакыт игътибар үзәгендә, ул бер генә минутка да югалып, әсәрдән «чыгып» тормый. Нәкъ «Шинельсез солдатлар»дагы кебек, автор үз героен өзлексез яңа сынаулар, яңа киртәләр алдына куя тора. Укучыларны да, геройларны да ничек кенә булмасын киеренке халәттә тотарга тырыша. Рухия исемле чибәр шәһәр кызының күңелен һәм мәхәббәтен яулау өчен ниләр генә эшләми Равил! Нинди генә утларга, нинди генә кайгы-борчуларга салмый аны бу чая кыз! Рухия белән көн дә очрашып-күрешү, аның белән бергә мәктәптән кайту ләззәтен кичерү өчен генә, җиденче классны тәмамлап, колхозда эшли башлаган Равил — ташлаган укуын башлый. Әнисенең ялварып әйткән сүзләренә дә колак салмый, мәктәптән кайткач төнге көтүгә чыгу кебек авыр эш тә куркытмый аны.

Автор гүя героен мәхәббәт газаплары белән сыный. Равилне яңадан-яңа сынаулар алдына куя, бер уттан алып икенчесенә сала тора. Кызны мәктәптән утыртып кайту өчен велосипед кирәк була. Велосипедлы булу өчен Равилгә аккордеонынннан колак кагарга туры килә. Рухияләр авылына барып кыйналып кайту дисеңме, Әнәс белән сугышу дисеңме — берсе дә калмый. Эшләр, аяк өшетеп, больницага кереп ятуга хәтле барып җитә. Аңа карап егет әллә ни уңыш казана алмый. Рухия ышанычсыз, вәгъдәсез «партнер» булып чыга. Берьюлы ике-өч егетнең башын әйләндереп йөри-йөри дә, укытучылары Рәмзи Гариповичка кияүгә чыгып, Урта Азия якларына китеп бара.

Равилнең чибәр Рухиягә булган мәхәббәте шулай җавапсыз калган, уңышсыз тәмамланган икән, монда ис китәрлек фаҗига юк, билгеле. Бу — тышкы матурлыкка кызыгудан башланган балалар мәхәббәте, самими мәхәббәт. Әмма шул мәхәббәт, әлеге романтик мәхәббәт Равилнең алга үсүенә, кеше булып формалашуына көчле йогынты ясый. Шул изге хис ихлас күңелле һәм шактый беркатлы авыл малаен хыялланa белергә, тәвәккәллеккә, кыенлыклардан курыкмаска өйрәтә. Ахыр килеп, шул ук хис аңа зур белгеч, атаклы галим, башкача әйткәндә, «кеше булырга» ярдәм итә. Мондый мәхәббәтнең көче шунда. Укучылар тарафыннан ифрат җылы каршыланган «Әгәр син булмасаң» повестеның да төп кыйммәте — иң саф, иң садә беренче мәхәббәтнең кеше тормышында тоткан ролен, әһәмиятен үтемле итеп, сәнгатьчә итеп күрсәтә белүдә.

Нихәтле генә уңган һәм тырыш, нихәтле генә ягымлы һәм ихлас күңелле булмасыннар, В. Нуруллин повестьларының төп геройлары — идеальлектән шактый ерак кешеләр. Алар еш кына ялгышалар, бер минутлык дуамаллык аркасында үкенече гомер буена җитәрлек хаталар эшлиләр. Саксызлыгы аркасында акдар кулына эләгеп, Миңнулла күпме гомерен төрмәдә уздыра, күпме газап күрә. Кеше сүзенә ышанып, Өлфәт хатынын аерып җибәрә. Ахырдан шул юләрлегә өчен үкенеп бетә алмый. Тагын шунысы кызык, укучы авторның нәкъ әнә шундый — ялгыша, хаталана торган геройларын күбрәк ярата, аеруча үз, якын итә. В. Нуруллин үзенең геройларын яраттыра белә, яраттыруның серен, әмәлен белә. Аның повестьларында герой белән автор, герой белән укучы арасындагы мөнәсәбәтләр бик тә үзенчәлекле. Еш кына автор үз героена тәмам кушылып, сеңеп, эреп бетә. Кайчак шундыйрак хәл герой белән укучы арасында да килеп чыккалый. В. Нуруллинның кайбер геройлары укучыга тәмам якынаеп, эреп бетәр хәлгә җитә. «Әгәр син булмасаң» повестендагы Равил, «Күпер чыкканда» повестендагы Өлфәт — шундыйлар.

Өлфәт — халыкның үз улы, аның үз арасыннан чыккан җитәкче. Җиргә, крестьян хезмәтенә булган мәхәббәте шуннан килә. Шуңа күрә дә берәр зур эшкә тотынганда, нинди дә булса җитди мәсьәлә хәл итәргә кирәк чакта, Өлфәт иң элек халыкка, аның ярдәменә таяна. Тагын шул кадәресен дә истән чыгарырга ярамый: кайбер председательләр кебек, ул акыл өйрәтеп, күрсәтмәләр биреп кенә утырмый. Кирәк икән, үзе чаба, үзе таба. Кара эштән курыкмый, нинди эшкә тотынса, шуны булдыра. Өлфәт — тәвәккәл җитәкче, җаваплылыктан курыкмый торган, булсынга эшли, булсынга тырыша торган кеше. Шул сыйфатлары булмаса, ихтимал, авыр, кыен елларда ул үзенә тапшырылган зур эшләрне башкарып чыга да алмас иде. Башка әсәрләрендәге кебек үк, бу повестьта да автор үз героен гел кыенлыклар, авырлыклар белән сыный. Әсәрнең башында ук язучы аңа берьюлы ике зур эш йөкли, ике «камыт» киертеп куя. Берсе — колхоз эше. Икенчесе — гаилә мәшәкатьләре. Берсе дә җиңел булып чыкмый. Колхоз алга китсен, колхозчылар әйбәт яшәсен дип тырыша торгач (вакыт-вакыт крестьянча хәйлә юлына да баскалый торгач) — Өлфәт муеннан шелтәгә батып бетә. Атларга солы ашаткан, печәнчеләргә тана суйган өчен дә, кукуруз чәчүгә, тавык белән үрдәк үрчетүгә салкын караган өчен дә, колхозчылардан сыер җыйган өчен дә җәзага тарталар аны. Ләкин ул бер генә тапкыр да зарланмый, елап-җебеп йөрми.

Шуларның һәммәсе өстенә, ул әле шактый кызу канлы, дуамал холыклы кеше дә. Еш кына хаталар эшләп куя, аннары шулар өчен озак кына үкенеп йөри. Алда әйтелгәнчә, кеше сүзенә ышанып, яраткан хатынын аерган өчен, ахырдан аңа күпме газап утында янарга туры килә. Кызган баштан Рәдифне тукмап ташлый, Тайфә карчыкның бер чиләк йомыркасын әрәм итә, башка төрле юләрлекләр эшли. Әнә шундый катлаулы, чуар йөрәкле кеше ул Өлфәт Хәкимов. Укучы Өлфәтне бигрәк тә кайсы сыйфатлары өчен ярата дип сорасагыз, иң элек, халык, колхоз мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәгәне, авыр чакларда сыкранмаганы-сынатмаганы, ихласлыгы, күңеле чиста, үзәге нык булганы өчен, дип җавап бирергә туры киләчәк. Тагын үз кимчелекләрен яшермәгәне, аларны булдырмаска, бетерергә тырышканы өчен, дип өстәргә мөмкин. Әсәрне укыганда шундый тәэсир кала, гүя герой укучыга җанын ачып сала, якын кешесенә ышанып, аңа иң яшерен серләрен сөйли. Өлфәтнең дә, В. Нуруллин әсәрләрендәге башка геройларның да ышану көче, ул иҗат иткән образларның мөлаемлыгы шуннан килә.

«Аккан су юлын табар» күпмедер дәрәҗәдә «Күпер чыкканда» повестеның дәвамы кебегрәк яңгырый. Безнең алда — колхоз председателе, коммунист Булат Вәлиевнең

әледән-әле төрле чигенүләр, үткән һәм бүгенгене чагыштырулар, уйланулар белән чиратлашып килгән зур тормыш юлы. Автор аның тормышындагы гыйбрәтле моментларга аеруча нык басым ясый. Ул юл шактый дәрәҗәдә Өлфәтнекенә охшаш. Өлфәт кебек үк, председательлек дәверендә аңа күп кыенлыклар күрергә туры килә. Аңа да шелтә арты шелтә бирep торалар. Өлфәт кебек үк, вакыт-вакыт Булат кызып китkәли, дуамаллыклар эшләп ташлый.

Шуның белән бергә, алар арасында аерымлыклар да шактый. Өлфәт бөтен эшкә үзе катнашып йөри. Ул тырышлыгы, физик көч белән алдыра. Булат — башка төрлерәк җитәкче. Ул күбрәк акылына, зирәклегенә таяна. Өлфәт артта калган кечкенә колхозны сөйри. Булат дөнья хәтле техникасы, дисталәгән белгечләре булган күп тармаклы эре хуҗалык белән җитәкчелек итә. Заманы башка, чоры башка.

Ике әсәрдә конфликтның характеры да ике төрлерәк. Өлфәт авыр, кыен заманда эшли. Аңа күбрәк тормышның объектив кыенлыклары белән көрәшергә, шуларны җиңәргә туры килә. Ул район җитәкчеләре белән җитди каршылыкка керми, рухи тетрәнүләре күбрәк гаилә өлкәсенә карый. Бер өйләнеп алгач, Булат исә гаилә белән изаланмый. Аның каравы, Булатка гомер буе авылдашы Шәйхи белән көрәшеп яшәргә туры килә. Шәйхи «Күпер чыкканда» повестендагы Рәдиф кенә түгел, күп тапкыр мәкерлерәк, әшәкерәк кеше.

В. Нуруллин күбрәк үзе күргән вакыйгалар һәм кешеләр, үзе якыннан белгән тормыш хәлләре турында язып килде. «Яшьнәп үткән яшьлек» — аның ерак үткәннәргә багышланган беренче әсәре. Өстәвенә, ул — документаль әсәр. Аны язар өчен, автор Нурулла Айсин (Миңнулла Гайсин) дигән конкрет кешенең тормыш һәм көрәш юлын ныклап өйрәнгән. Гражданнар сугышы вакыйгаларына караган бик күп тарихи әдәбият белән танышкан. Фәнни китапханәләрдә, архив киштәләрендә казынып, бай материал туплаган. һәм шул материалын повестька кертеп бетерергә тырышкан. Бу — әсәрнең бөтенлегенә күпмедер зыян да салган. Шушы ягын күперту аркасында, тәнкыйтьчеләр повестьның уңай якларын күрми калдылар.

В. Нуруллинның башка әсәрләре кебек үк, бу повесть та стиленең гадилеге, самими җылылыгы, тонының ихласлыгы белән аерылып тора. «Яшьнәп үткән яшьлек»тә чынлык хисе көчле. Аннары повестьның төп герое Миңнулла Гайсин — шактый кызыклы һәм яңача эшләнгән образ. В. Нуруллинның Миңнулласы башка әсәрләрдәге Гражданнар сугышы геройларының берсенә дә охшамаган. Корыч ихтыярлы булудан бигрәк, ул гади җир кешесе. Миңнулла еш кына аптырап кала, йомшаклык күрсәтә, өлкән кешегә хас булмаган эшләр эшләп ташлый. «Күпер чыкканда» повестендагы кебек үк, автор моны аңлы рәвештә эшли. Ул Миңнулланы гади халык улы, совет властен, революцияне казанышларын яклап, изге көрәшкә күтәрелгән йөз меңнәрчә халык массаларының бер вәкиле, үз вәкиле итеп күрсәтергә тели. «Яшьнәп үткән яшьлек» әнә шул ягы, ягъни җитәкче һәм массалар арасындагы мөнәсәбәтне яңачарак, заманчарак хәл иткән әсәр буларак та аерым игътибарга лаек.

Повестьның тагын бер принципиаль әһәмияттән басым ясап билгеләп үтәсе килә. Мәгълүм булганча, капиталистик илләрдә яшәүче «советологлар» әле бүген дә татар халкының Октябрь революциясендә һәм Гражданнар сугышы вакыйгаларында тоткан ролен бозып, кечерәйтеп күрсәтергә азапланалар. Алар Казанда һәм Казан губернасында революцияне руслар ясады, Гражданнар сугышында татарлар бик аз катнашты дип расларга тырышалар. В. Нуруллинның конкрет материалга нигезләнеп язылган документаль повесте буржуаз галимнәрнең бу уйдырмасын юкка чыгара. Әсәрдә җитәкче татар большевикларының гына түгел, ә гади халык массаларының да роле ачык күрсәтелә. Язучы Заһит, Зәйнулла, Сәгыйдулла кебек гади халык вәкилләренең чын калырлык, тормышчан образларын тудырган. Аннары ул Гражданнар сугышы чорының сулышын — киеренкелеген, авырлыгын һәм бөеклеген күрсәтә алган. Әсәрне укыганда, шул давыллы чорга хас атмосфераны тоеп-сизеп барасың. Язучы йөз меңнәрчә кеше катнашкан хәрәкәтнең масштабын, колачын һәм киңлеген шактый тулы итеп күз алдына бастыра алган.

Заһит, Сәгыйдулла кебек образлар В. Нуруллинның башка повестьларында да еш очрый: Хәбир карт белән чулак Самат, Нәсиха белән Фәйрүзә («Шинельсез солдатлар»), Сәкинә белән Гөлүсә, Рәдиф белән Закир («Күпер чыкканда»), Рухия белән Әнәс («Әгәр син булмасаң») һ. б., һ. б. Тик нихәтле генә тормышчан һәм иста калырлык булмасыннар, язучының үз йөзен болары түгел, ә бәлки алда без тикшергән Равилләр, Өлфәт белән Булатлар, Миңнуллалар билгели. Шулар аңа исем, дәрәҗә һәм популярлык китерде.

В. Нуруллинның барлык повестьларын асылда бер герой — үзәк геройның тормышына багышланган әсәрләр диярга була.

**Фәрваз МИҢНУЛЛИН.**

библиография

# ЯНУ

*Кисәүгә әйләнә янган барча әйбер,*
*Ә мин яндым да яктырдым — каралмадым!*

Нури Арсланов.

Шагыйрь Нури Арслановның «Идеалым — илем» дип аталган җыентыгына соңгы кырык ел эчендә иҗат ителгән шигырьләр, җырлар, поэма, балладалар һәм әкиятләр тупланган. Китап шагыйрьнең шигъри дөньясы белән якыннан танышу мөмкинлеге бирә. Һәм шул ук вакытта иҗаты соңгы унбиш елда зур сыйфат үзгәреше кичергән әдипнең гаҗәеп тирән мәгънәле әсәрләрен йотлыгып укыганда күңелдә шундый уй да туа; ни генә булмасын, табигый талант барыбер өстен чыга икән.

Шигърият сөючеләр Нури Арслановның әсәрләрен зарыгып көтәләр. Әлбәттә, моның үзенә күрә сере дә юк түгел. Әйткәнебезчә, соңгы унбиш ел эчендә аның иҗаты кинәт яшәреп китте. Сабыр, тыйнак моңнарга яшьлекнең дәртле рухы килеп керде. Көнчыгыш поэзиясенең зирәк, хикмәтле акылы өстәлде. Әйтерсең лә салмак кына аккан елга җир куеныннан тибеп чыккан чишмәләр хисабына баеды да кинәт көчәйде, шауларга, ярсырга тотынды, ургылып, бөтерелеп ага башлады.

Нури Арсланов шигъри бәйгедә талантының чикләнмәгән мөмкинлекләрен раслап кына калмады, рухының зур куәтен дә күрсәтә алды. Шул рәвешчә, шәхестәге табигый талант, зур шагыйрь җиңеп чыкты. Моның сәбәпләре хакында уйланганда, шагыйрьнең дөньяны үзенчәлекле күрү рәвешенә, уйлау-фикерләү киңлегенә, шигъри культурасының югарылыгына, поэтик платформасының ныклыгына һәм идеалының зурлыгына, бөтенлегенә игътибар итү заруридыр. Әгәр игътибар иткән булсагыз, шагыйрьнең башлангыч чор иҗаты белән соңгы елда язылганнары арасында шактый аерма күренә. Аның соңгы чорда иҗат ителгән әсәрләренә уйлау-фикерләү тирәнлеге, хис-моңмуллыгы, предметның үзегенә үтеп керү хасияте, кеше психологиясенә, рухи эчтәлегенә нык игътибар итү хас. Шагыйрьнең киң колачлы иҗаты тематик киңлектән фәлсәфи-психологик тирәнлеккә, гражданлык рухы белән сугарылган күптөсмерле лирикага таба үсүгә йөз тотты. Өлкән шагыйребез Сибгат Хәким, каләмдәше иҗатында өстенлек алган уңай тенденцияләргә сөенеп, болай дип язды: «Нури Арслановның соңгы ун-унбиш ел эчендә язганнарын элеккеге иҗаты белән чагыштырып карагыз. Язганнары бар да үз урынында иде, дөрес иде. Шагыйрьгә дөрес язу гына җитми, күрәсең. Ул шагыйрьлеккә кире кайтып, стартка яңадан басты кебек, хисләр давылы кузгалды, татар, казах, көнчыгыш әдәбиятлары традицияләренең шигырьдәге байлыгы кабат хәрәкәткә килде, шагыйрь үзен тапты. Шагыйрьнең үзенә дә рәхәт, безгә дә рәхәт булып китте».

Бу асыл сыйфат Нури Арслановның Туган илгә багышланган әсәрләрендә матур гәүдәләнде. Гомумән, Ватан темасы аның иҗатына якты бер төс биреп тора. Шагыйрьнең дөнья гаме белән янган тынгысыз йөрәге Туган ил, туган халкы белән аеруча тыгыз бәйләнгән. Бу нисбәттән «Ватандармын» дигән шигырьдә лирик геройның заман рухы белән өртелгән бай күңеле аеруча зур җылылык һәм тирәнлек белән сурәтләнә. Шигырь юлларына олы бер тормыш юлы узган кешенең гыйбрәтле язмышы, ватандарлык хисләре сыйган:

Җик итсә дә, күп борчулар кичерсәм дә,
Туган илдән газиз җирне табалмадым.

Олтан булсам булдым изге туфрагымда,
Чит җирләрдә солтан булып калалмадым.

Нури Арслановның Туган илне, газиз Ватанны чиксез сөю, бар күңелен биреп ярату хисләре ихлас, самими, якты. Ватан төшенчәсе аның күңелендә туган төбәге, әти-әнисе, дуслары, сөйгән яры, җандашлары, халкы рәвешендә береген яши. Шушы изге төшенчә аның рухын җылытып, көч-куәт өстәп тора. Ватанны олылау пафосы белән

җылытылган шигырьләр белән әсәрләнгәндә, колак төбендә нинди дер бер сихри моң, үзәк өзгеч аһәң яңгырап торуын сизәсең. Һич туктамый ул. Шигырь дәвам иткән саен, ачыграк, сурәтлерәк төс ала бара. Каян килә, нинди катламнардан күтәрелә бу, дип гаҗәпләнгәндә күңелдә Дәрдмәнднең сагышлы моңы, җанны тетрәтерлек әрнүле хисләре яңара. Юк, һич кенә дә кабатламый Нури Арсланов аны. Дәрдмәнд моңын кабатлау мөмкин түгел! Шушы моңнан илһам алып, үз моңын, үз аһәңен тудыра. Бай традицияле шигъриятебезнең нык нигезенә таянган Нури Арсланов шулай итеп Тукайлар, Дәрдмәндләр рухын бүгенге көндә дә дәвам иттерә:

Ир ирлеге — ил кайгысын кайгыртуда!
Илем-йортым өчен бөтен җан-арманым[1].

Ир-егетнең Ватан алдындагы зур бурычын шулай аңлый шагыйрь. Бәхетнең башлангычы, җирлеге — Ватанда. Ватан хакына, ил азатлыгы хакына газаплар чигү үзе зур бәхет, күңелне үстерә торган хасият, ди шагыйрь. Лирик герой безгә шушы күркәм сыйфатларның зурлыгына, даимилегенә ишарәли:

Тугрылыклы улы булсам Идел-йортның,
Бөек Совет илендә бер ватандармын!

Туган ил, Ватан төшенчәсе, әйткәнебезчә, Нури Арсланов иҗатында туып үскән төбәкне генә аңлатмый. Аның мәгънәсе киңрәк, зуррак яңгыраш ала. Ул шагыйрь дөньяга килгән Казахстан далалары да, рухи яктан туган Татарстан туфрагы да, фронт юллары узылган гүзәл Ватаныбызның иксез-чиксез кырлары да. Шуңа күрә аның өчен уртак Ватаныбызның һәр карыш җире якын, кадерле. «Билгесез солдат кабере янында», «Уникә батыр турында баллада», «Батырлык турында», «Карт ветеран сүзләре» дигән шигырьләрдә шагыйрь шул хакта сүз алып бара һәм азатлык алып килгән совет солдатына дан җырлый. Ул үзе дә сугыш авырлыгын җилкәсендә күтәрешкән, аның барлык кыенлыкларын солдат башы аркылы уздырган шагыйрь. Шуңа күрә аның иҗатында илне саклау мотивларының өстенлек итүе бер дә гаҗәп түгел. Сугыш — кешелек җәмгыятендәге иң зур җинаятьләрнең берсе, адәм балалары китереп чыгарган акылсызлыкның, мәгънәсезлекнең зурысы. Аның җан әшеткеч сулышы Нури Арслановның «Нигә, нигә?» дигән әсәренә дә үтеп керә. Рига шәһәре янындагы Саласпилс концлагерендә йөз мең кеше һәлак булган. Тетрәнерлек, күңел ышанмаслык җинаятьләр эшләнгән. Тыныч кына укып булмый әсәрне, тамак төбенә кайнар төер утыра, нәфрәттән йодрыклар йомарлана. Үтерелгәннәрнең сүзсез монологы йөрәкләрне әрнетә:

«Онытмагыз моны!»— ди манзара.
Туфрак — җанлы, баскан саен иңә...

һәр тарафтан пышылдыйлар өннәр:
«Үтерделәр безне нигә, нигә?..»

Гаепсезләрнең өне, түшен кулы белән каплаган ялангач кыз баланың оятыннан дерелдәгән иреннәре, өзгәләнеп елаган нарасыйның гонаһсыз күз яшьләре исеменнән, лирик герой җинаятьчел сугышны кискен гаепли, җан коючыларның рәхимсез йөзен ачып сала. Көчле пафос фашизмны гаепләү актына әверелә.

Җирдә шундый вәхшилекләр яңадан кабатланмасын өчен тынычлыкны ныгытырга, аяз күкнең зәңгәрлеген сакларга чакыра шагыйрь. «Чын хуҗа бул!», «Тынычлык турында», «Безнең позиция», «Дөнья яшьләренә» кебек әсәрләрдә ул ветераннар, сугыш дәһшәтен кичерүчеләр исеменнән алмашка килгән яшь буынга эндәшә. «Дөнья яшьләренә» шигыре тынгысыз ветераннарның — тынычлык сакчыларының яшь буынга нәсыйхәте, васыяте кебегрәк кабул ителә. Утны-суны кичкән чыдам солдат, яшь күңелле карт ветеран борчыла:

Аяз итсен планетаның күген
Изге ният, хезмәт, тынычлык!

Әсәрне көчле иткән сыйфат — публицистик кайнарлык, ярсулы рух, гомумән, Нури Арсланов иҗатына хас асыл сыйфатларның берсе. Һәм бу сыйфат әсәрдән-әсәргә үстерелә бара. Иҗатының шундый юнәлешкә борылуы әдипнең «Икенче сулышы»н ачып җибәрде. Аның иҗатына шактый тәфсилле анализ ясаган шагыйрь Зиннур Мансуров сүзләре белән әйткәндә, «үсә баручы политик һәм гражданлык активлыгы, халык алдында үзенең җаваплы итеп тоюу, дөнья язмышы өчен борчылу шагыйрьне үзеннән-үзе публицистик юнәлешкә тирәнәюгә китерә».

Билгеле, моңа С. Рәмиев, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәримнәрнең гражданлык рухы белән сугарылган сугышчан лирикасы да йогынты ясагандыр. Аның иҗатында интернационализм мотивлары ныгыды, поэтик идеалы көрәш рухы белән сугарылды. Нәтиҗәдә Нури Арсланов шигырьләрендә Африка иле Мозамбикның бәйсезлек яулау шатлыгы да, Испаниядәге демократик үзгәрешләргә сөенү хисләре дә, фашизмга баш имәгән Альваро Куньялның батыр рухы да, үлемнән курыкмаган Луис Корваланның олы җаны да, ерткычларча җәзалап үтерелгән җырчы Виктор Харaның легендага тиң батырлыгы да җырланды. Әлеге әсәрләрдә шагыйрь-гражданинның бәгыреннән яралган ярсулы тойгылар шигырь юлларына гына сыймый, яшен утыдай, азатлык таңына кул сузучылар өстендә ялтырый, кискен көрәшнең дәвам итәсенә ишарәли.

Публицистик лирика шулай итеп шагыйрь идеалын заман ихтыяҗларын аңлау югарылы-

[1] Арман — теләк, омтылыш.

гына күтәрә, заман рухын, заман сулышын тоеп яшәргә ярдәм итә. Бу уңайдан аның «Партияле кеше диләр мине» дигән әсәренә игътибар итик. Анда тасвирланган лирик герой — чорыбызның вөҗданы, намусы булган партиябезнең фиркасез бер гади солдаты. Кискен, ярсулы көрәш барган бүгенге заманда, капма-каршы идеологияләр бәрелеше кызган бер чорда илсөяр җанлы Ир дә, ягъни лирик герой да, замандашлары белән бергә алгы сафта атлый. Без аның кискен хәлләрдә дә сынатмаячагына нык ышанабыз.

Партиясез кеше диләр мине.
Дөрес — формаль карамаганда —
Партиясез шагыйрь буламыни
Бөек көрәш барган заманда!

Бу шигырьдә автор иҗат кешесенең гражданин буларак җәмгыять һәм халык алдындагы зур бурычын, җаваплылыгын искәртә.

Нури Арсланов иҗатын яңарткан хасиятләрнең икенчесе — ул да булса көнчыгыш поэзиясе үрнәкләренең шифалы йогынтысы. Көнчыгыш поэзиясе Нури Арсланов иҗатын зирәк акыл белән баетты. Шигырь төзелешенә, аерым алганда, ритмик буыннарга, рифмаларга төрлелек алып килде, сурәтләү чараларын, образлар системасын, ассоциатив фикерләү үзенчәлекләрен яңартты. Бай традицияле шигъриятебез Нури Арсланов иҗатында көнчыгыш поэзиясе хикмәтләре белән очрашты, көнбатышның зур сәнгате белән ярышты. Физүли, Нәваи, Фирдәүси, Хәйям, Мәхтүмколый, Данте, Байрон, Пушкин, Есенин, Кол Гали, Тукай... Дөнья поэзиясе Нури Арсланов иҗатын тагын да үстерде. Бу хакта ул үзе дә горурланып язды:

Татар халкы элек ике арада
Күпер булган. Хәзер яңа замана.

Шулай да мин йөрим иске күпердән;
Барын шунда ишеткән, шунда күргән!

Җыр текстлары шагыйрь иҗатында аерым урынны алып тора, ягъни ул күп санлы матур-матур лирик җырлар авторы буларак та танылды. Бу җыентыгында аның композиторлар тарафыннан көйгә салынган егермедән артык җыры бар. Ә көй сорый торганнары исә тагын да күбрәк. Җырлардан якты оптимизм, күтәренке дәртле рух, күңел көрлеге бөркелеп тора. Тематик яктан шактый төрле булган бу җырларның эчтәлеге бер: ул яшьлек романтикасы, яшьлек дәрте белән сугарылган. Анда иманы нык, кыйбласы анык булган яшь кешенең гүзәл мәхәббәте, фидакарь хезмәте мактала. Илебез, хезмәт сөючән халкыбыз ирешкән уңышларга чын күңелдән сөенү хисләре чагыла, гүзәл кешелек сыйфатларына мәдхия укыла.

Шунысы да игътибарга лаек: халык арасында Нури Арсланов җырларының берничә варианты яши. Бу факт үзе үк шагыйрьнең халык рухын нечкә тоеп, аның теләк-максатларын дөрес аңлап иҗат итүе хакында сөйли. Димәк, халык күңелендә тибрәнгән моң белән шагыйрь күңелендә бөреләнгән хис әнә шулай бергә кушылган.

Юмор-сатира өлкәсендә дә шагыйрь актив иҗат итәргә омтыла. Бу юнәлештәге эшчәнлеге әле тиешенчә өйрәнелмәгән, бәяләнмәгән. Әмма шуны әйтергә була, Нури Арсланов — сатира-юморда бөек шагыйребез Габдулла Тукай традицияләрен дәвам иттерүчеләрнең берсе. Кайбер әсәрләрендә һ. Такташның усал юморы да чагылгалап ала. Ул юмористик әсәрләренең формасына нык игътибар итә. Пародия, фельетон, юмореска һәм башка жанрлардан иркен файдалана. Моңа мисал итеп «Берәүгә», «Сәер параллель», «Күз-колак», «Колхоз базарында ит сатучылар монологы» дигән әсәрләрне китерергә мөмкин.

Моннан кала, җыентыкта дөнья халыклары авыз иҗаты үрнәгендә язылган әсәрләр дә бар. Әйтик, корея халык легендасына нигезләнеп иҗат ителгән «Ай хян белән Ли» легендасы, «Горур Гайшә» әсәре, «Моңсар» әкияте шундыйлардан. Авторның әлеге әсәрләре аның халыкчан, күп төсмерле якты иҗатын энҗе бөртегедәй бизәп торалар.

Җыентык ахырына урнаштырылган «Романтика» поэмасы шагыйрьнең балачак хатирәләре нигезендә язылган. Ул шагыйрьнең балачагы узган Кәрәкәүдә совет власте урнаштыру елларын чагылдыра. Бөек Ленин образы нәни герой күзаллавында гайрәтле, көчле Алпамыш сурәтендә гәүдәләнә. Поэмадан давыллы чор рухы, революция ялкыны сизелеп тора.

...Шагыйрь Нури Арсланов иҗаты бүгенге көндә тагын да активлаша, зирәкләнә төште. Ул илһамланып, дәртләнеп, янып иҗат итә. Туган илен, туган халкын шигырьләрендә, җырларында зурлый, олылый. Яшәешне, гүзәллекне кайгыртып, бәхет яулап януының эзсез югалмавын күреп куана:

Шулай да бер юаныч бар ки: илгә
Бәхет даулап янудан көлгә калдым.

**Әхмәт СӘХАПОВ.**

**Яхъя Абдуллин,**
философия фәннәре докторы,
профессор

# КҮРЕНЕКЛЕ МӘГЪРИФӘТЧЕБЕЗ

Илебездәге социаль-экономик һәм идея-политик үзгәрешләр нигезендә барлыкка килгән күпмилләтле социалистик культура совет халкының искиткеч зур казанышы һәм горурлыгы булып тора. Үзенең формалашу процессында ул илебез халыкларының рухи культура өлкәсендәге барлык кыйммәтле һәм прогрессив казанышларын эченә алган. «Россиядәге алдынгы җәмәгать фикеренең төп юнәлешләрендә,— дип яза В. И. Ленин,— ...шактый зур материалистик традиция бар»[1]. Бу традицияләр һәм демократик культураның тормышчан нигезен тәшкил итүче прогрессив иҗтимагый-политик идеяләр илебездәге теләсә кайсы халыкның милли культурасында булган. Татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле, фикер иясе һәм гуманист Каюм Насыйри шундый демократик культураның һәм прогрессив иҗтимагый фикернең күренекле бер вәкиле иде.

Каюм Насыйриның тормышы һәм иҗаты Россия тарихының давыллы чорына — самодержавиегә һәм феодаль-крепостной мөнәсәбәтләргә каршы актив көрәшнең киң рәвештә җәелеп киткән чорына туры килде. Капиталистик үсеш чорына керүгә карамастан, Россиядә иске иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең нигезе нык иде әле. Патша Россиясендә хөкем сөргән әлеге хәл татарлар арасында да үзен нык сиздергән. Хезмәт ияләрен рәхимсез социаль изү, милли һәм дини эзәрлекләүләр, властьларның башбаштаклыгы һәм шәхес иреген буу белән тулыландырылган. 1861 елгы реформадан соң көчәеп киткән капиталистик мөнәсәбәтләр хезмәт ияләренең тагын да хөерчеләнүенә һәм эксплуатациянең көчәюенә китергән. Шул ук вакытта капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсүе әкренләп эксплуатацияләүне патриархальлектән, политик һәм дини сөрүләрдән арындыра бара, рухи тормышта зур үзгәрешләр барлыкка китерә, яшәп килүче тәртипләрнең иҗтимагый үсеш таләпләренә туры килмәвен ачык күрсәтә. Капиталистик мөнәсәбәтләр тудырган яңа карашлар тәэсирендә, сакланып калган урта гасырлар тәртипләренә һәм социаль-политик изүгә протест йөзеннән татарлар арасында мәгърифәтчелек хәрәкәте формалаша. Каюм Насыйри аның күренекле бер вәкиле була.

Тормыш шартлары, балачактан ук аралашкан кешеләр К. Насыйриның үз халкының ихтыяҗларын, мәнфәгатьләрен аңларлык һәм үз тормышын халкына хезмәт итәргә багышларлык җәмәгать эшлеклесе булып җитешүенә җирлек булалар. Ул 1825 елның 14(2) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында туа. Әтисе заманына күрә шактый танылган укымышлы һәм авылдашлары арасында абруйлы кеше була. Ислам дине һәм шәригать өлкәләрендә тирән мәгълүматлы бу кеше гарәп, фарсы телләрен бик яхшы белгән, рус телендә дә яхшы ук хәзерлекле булган. Киң карашлы кеше буларак, ул ислам диненең катып калган бик күп кануннарын кире каккан һәм хөр фикерлекне яклаган. Аның турында К. Насыйри истәлекләрендә: «Иҗтиһат[2] заманы

---

[1] Ленин В. И. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә. 33 т. Казан, 1963, 212 б. (татар телендә).

[2] Иҗтиһат — искедән килә торган догмаларга гына карап йөрмичә, фән һәм философиядә яңа положениеләр эзләү.

монкариз[1] дигән кешене бер дә яратмас иде. Балалары һәм хәзер дә шул мәзһәптәдер»[2],— дип язган[3].

Башлангыч белемне үз атасыннан алгач, К. Насыйри укуын дәвам иттерү өчен 1841 елда Казанга килә һәм бөтен гомерен шушы шәһәр белән бәйли. Унбиш ел буе Казанның ул вакытта яхшы ук танылган бер мәдрәсәсендә уку белән бергә ул рус телен дә тырышып өйрәнә. Мәдрәсәдән чыккач ирекле тыңлаучы булып Казан университетына лекцияләр тыңларга йөри, рус галимнәре белән элемтә урнаштыра.

Дини мәдрәсә шәкертләренең күпчелегеннән үзгә буларак киң белемле К. Насыйрины муллалык вазифасы кызыксындырмаган. Ул мәгърифәтчелек эшчәнлегендә генә үз халкына турылыклы хезмәт итә алачагына ышанган хәлдә, бөтен гомерен шуңа багышлый. Дини мәдрәсәдә уку аңа урта гасыр схоластикасының асылы ни икәнен бик яхшы таныткан. Шул ук вакытта ул анда мөселман көнчыгышының прогрессив традицияләрен дә үзләштерә, Әл-Фараби, Ибн Сина, Ибн Рөшд, Нәваи кебек фикер ияләренең иҗат мирасы белән таныша. Казан университеты лекцияләренә йөрү, рус галимнәре белән аралашу аңа рус һәм Европа культурасы белән танышу мөмкинлеген ача. Энциклопедист галим буларак, К. Насыйри — татар культурасы һәм иҗтимагый фикер тарихында тирән эз калдырган шәхес. Бер яктан көнчыгыш культурасы традицияләрен яхшы белү, икенче яктан, Европаның фәнни-философик карашларын, бигрәк тә алдынгы рус иҗтимагый фикерен һәм культурасын яхшы белүе аңа татар халкының уянуы чорындагы актуаль проблемаларны тирән һәм һәрьяклап анализларга мөмкинлек бирә. Татарлар арасыннан беренче булып, ул математика, геометрия, география, анатомия, гигиена кагыйдәләре буенча дәреслекләр яза, фәнни терминология нигезләрен тикшерүгә күп көч һәм энергия сарыф итә.

Каюм Насыйри китаплар язып кына калмый, аларны бастыру һәм тарату белән дә шөгыльләнә. Аның күңел түрендәге хыялларның берсе — татар көндәлек матбугатын барлыкка китерү була. Властьларга күп мәртәбәләр газета чыгарырга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итсә дә, тәкъдиме һәрвакыт кире кагыла. Ләкин бу хәл мәгърифәтчене үз уеннан кире чигендерми. Ул утыз елга якын татар көндәлек матбугаты функцияләрен үтәп килүче еллык өстәл календарьлары чыгара башлый. Аларда ел да кабатлана торган гади календарь материалларыннан тыш, төрле темаларга фәнни һәм әдәби материаллар да урын алган.

Каюм Насыйри фәнни тикшеренүләрен педагогик эшчәнлек белән бергә алып бара: рус уку йортларында татар теленнән дәресләр бирә, шул ук вакытта татар балаларына рус телен укытуны оештыра.

К. Насыйриның фәнни-педагогик һәм иҗат эшчәнлеге татар халкының милләт булып формалашу чорына туры килә. Ул аның объектив билгеләре җитлегүен тойган һәм билгеле күләмдә бу процесска ярдәм иткән. Татар тарихы һәм культурасы проблемаларын тикшерү һәм аларны үз хезмәтләрендә популярлаштыру белән бергә ул туып килгән милләтнең этник нигезләре мәсьәләсе буенча да тикшерүләр алып барган. Аның бу мәсьәләдәге төп карашы — болгар концепциясе. Күп төрле тарихи чыганакларны өйрәнү нигезендә ул казан татарлары — Идел-Кама болгарларының варислары дигән нәтиҗәгә килә.

К. Насыйри милләтнең туплануында һәм бердәмлегендә мөһим факторларның берсе буларак татар теленең үсенә зур игътибар бирә, телебезнең лексик байлыгын һәм грамматик нигезләрен фәнни яктан тикшерүгә зур өлеш кертә. Аның 1895—1896 елларда дөнья күргән ике томлы «Ләһҗәи татари» исемле китабы татар теле лексикографиясе буенча җитди хезмәт һәм телебезнең беренче аңлатмалы сүзлеге булып тора, ә татар теленең аваз составын һәм грамматик төзелешен өйрәнүгә багышланган һәм «Әнмүзәҗ» («Үрнәк») дип исемләнгән хезмәте исә чын мәгънәсендә татар теленең фәнни грамматикасы буларак бәяләнә ала. Аның дөрес һәм матур язу кагыйдәләрен күрсәткән кулланмасы —«Кавагыйде китабәт» һәм башка хезмәтләре дә татар тел белеменә багышланган. Тел белеме буенча хезмәтләрендә К. Насыйри татар теленең байлыгын, фәнни һәм әдәби тел булырга сәләтлелеген ассызыклап билгеләп үтә. «Телебезгә игътибар кылып яхшы тикшереп карасак,— дип яза мәгърифәтче-галим,— күрербез ки, телебездә булган бәет вә шигырь вә мәкаль гаять төзек вә рифмалы итеп аерымлангандыр... гайре телләрдән ким түгелдер...»[4]. Татар тел белеме проблемаларын тикшерүгә К. Насыйри гомеренең күп елларын багышлый. Ул татар телен, Бохара традицияләрендә тәрбияләнгән консерватив руханиларга хас булганча читкә кагу, демократик милли культураның нигезләрен какшата, үз телендә укый-яза белми торып татарлар бервакытта да фән һәм мәдәният белән таныша алмаслар дигән фикердән чыгып эш иткән.

[1] Монкариз — үткән, беткән.
[2] Мәзһәптә — юлда.
[3] Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Казан, 1926, 42 б. (Алга таба К. Насыйри хезмәтләреннән китерелгән өзекләрнең теле җиңеләйтеп бирелә).
[4] Насыйри К. Календарь, 1885 ел өчен, 35 б.

Матур әдәбият өлкәсендә К. Насыйриның тәкъдир итәрлек хезмәтләре аеруча күп. Яңа дәвер татар әдәбиятының Көнбатышка йөз тота башлавы да асылда К. Насыйри исеме белән бәйләнгән. Мәгълүм булганча, иске татар әдәбияты Көнчыгыш традицияләре тәэсирендә үскән. Бу традицияне Көнбатышның әдәби практикасы, бигрәк тә алдынгы рус культурасы белән кушуның беренче адымнары да К. Насыйриның әдәби эшчәнлеге белән бәйләнгән. К. Насыйриның бу хезмәтен ассызыклап Ф. Әмирхан болай дип язды: «Әдәбиятыбызның бу гасыры мәрхүм Габделкаюм Әннасыйри белән башланадыр. Насыйри гарәпчә вә русча яхшы белгән зыялы бер зат булганлыктан, әсәрләрендә шәрыктан күп нәрсә истифадә иткән[1] шикелле, рус әдәбиятыннан да файдаланадыр»[2].

К. Насыйриның татар әдәбияты тарихында күренекле урын алып торуын күрсәтүче факт буларак, аның үз әсәрләрен, беренчеләрдән булып, киң массаларга аңлаешлы телдә язуын әйтеп үтәргә кирәк. Ул бөтен көченә татар телен гарәп, фарсы һәм төрек телләре йогынтысыннан азат итәргә тырышты. 1859 елда язылган һәм беренче әсәрләреннән булган «Мәҗмәгыль әхбар» турында ул әлеге хезмәтен теләсә кайсы татарга да аңлаешлы итәргә тырышуын әйтә. Бу принципка ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр тугры булып калды. К. Насыйриның татар әдәбияты алдындагы бу хезмәтен ассызыклап Г. Ибраһимов: «Борынгы хаким — диктатор гарәпчәдән татарчага әйләнүдә Насыйри бездә беренче, ачык кискен, революционер саналырга тиеш. Ул халык өчен, түбән гамма өчен эшләнгәнгә, «татар теле» дигән сүзне башлап мәйданга ташлый. ...Иске имлага каршы беренче көрәш башлап яңага юл сызучы да ул булды»,[3]— дип язды.

Татар әдәбияты тарихына К. Насыйри күп кенә әдәби әсәрләрнең авторы буларак керде. Оригиналь әсәрләр иҗат итү белән беррәттән ул татар теленә тәрҗемә итү өчен гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә дөнья күргән повесть, хикәяләрне сайлап алуда да зур эш башкарды.

Идел буе һәм Урал татарлары арасында урта гасыр Көнчыгышының бөек фикер иясе Ибн Сина исеме күп гасырлар буе популярлык казанды. Аның гомер юлы һәм эшчәнлеге турында ышанычлы мәгълүматлар белән беррәттән халык арасында Ибн Сина әкият герое итеп сурәтләнгән риваятьләр дә йөргән. Шундый риваятьләрдән файдаланып һәм төрек язучысы Сәед Яхъяның «Кәнҗинәи-хикмәт» исемле китабы нигезендә К. Насыйри 1872 елда үзенең мәшһүр «Әбугалисина кыйссасы»н дөньяга чыгара. Әсәрнең баш герое Әбугалисина аның тарафыннан мәгърифәт уты һәм югары әхлакый идеаллар таратучы, дереслек һәм гаделлек тарафдары, золымлыкның килешмәс дошманы итеп сурәтләнгән.

К. Насыйриның иң зур күләмле әсәрләреннән берсе — «Фәвакиһел җөләса фил әдәбият». Башта «Кырык бакча» исеме астында ул аның кыскартылган вариантын, ә соңыннан тулысынча бастыра. Кырык бүлектән торган бу китапта турыдан-туры кешеләрнең тормыш-көнкүрешенә кагылышлы мәсьәләләр яктыртыла һәм төрле ситуацияләрдә ничек гамәл кылырга киңәшләр бирелә. Һәрбер күтәрелгән мәсьәлә автор тарафыннан әйтемнәр, мәсәлләр, хикәяләр, мәкальләр белән иллюстрацияләнгән. Һәрбер бүлек башында К. Насыйри теге яки бу күренекле фикер иясенең анда сүз алып барылачак мәсьәләгә кагылышлы фикерләрен китерә. Китапның соңгы бүлеге татар халык авыз иҗатына һәм гомумән әдәбият мәсьәләләренә, аларның әһәмиятен ачуга багышланган. Монда К. Насыйри халык авыз иҗатына игътибарны көчәйтергә кирәк дигән фикерне үткәрә.

Гомеренең соңгы көннәренә кадәр К. Насыйри әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә. 1868 елда «Кырык вәзир кыйссасы» исемле мәшһүр әсәрен укучылар хөкеменә тәкъдим итә, фарсы әдәбияты ядкаре «Кабуснамә»не, Көнчыгышта киң таралган «Җәваһирел хикәят» исемле әсәрне тәрҗемә итеп бастыра. 1896 елда К. Насыйри «Әфсанаи Гөлрох вә Камәрҗан» исемле китабын дөньяга чыгара. Бу китап роман итеп уйланылган һәм, кызганычка каршы, язылып бетмәгән әсәрнең бер өлешен тәшкил итә. Әсәр Кече Азия төркләре тарафыннан язылган повестька нигезләнгән. Ләкин үз әсәренең героен К. Насыйри Идел-Кама төбәгеннән чыккан кеше итеп биргән.

Публицистик мәкаләләрендә, фәнни хезмәтләрендә К. Насыйри татар әдәбият белеменең һәм әдәби тәнкыйтенең нигез ташларын сала. Аның хезмәтләрендә беренче тапкыр күренекле татар шагыйрьләре Габдерәхим Утыз-Имәни һәм Габделҗәббар Кандалыйларның иҗат мирасларына карата фикерләр әйтелә.

К. Насыйри яңа чыккан китапларга күзәтүләр ясый, аларның эчтәлеген һәм тышкы күренешен яхшырту буенча тәкъдимнәр кертә. «Каюм Насыйри үзенең бөтен гомерен,

---

[1] Истифадә итү — файдалану, куллану.

[2] Әмирхан Ф. Әдәбиятка гамд.— «Әльислах», 1908, 47 сан.

[3] Ибраһимов Г. Каюм Насыйриларның тарихи урыннары.— К-та: Каюм Насыйри мәҗмугасы. Казан, 1922, 116.; ачыкы ук: Имла, тел, әдәбият мәсьәләләре. Казан, 1927, 119 бб.

акылын һәм әдәби талантын туган халкын агарту эшенә, фәнгә, әдәбиятка хезмәт итүгә, томаналыкка, наданлыкка, артталыкка, реакцион феодаль катлауның һәм руханиларның фанатизмына каршы көрәшкә бирде», — дип язды әдәбият белгече М. Гайнуллин. Ул крестьяннарның һәм һөнәрчеләрнең мәнфәгатьләрен чагылдыручы булган, властьларның баш-баштаклыгына каршы чыккан, социаль гаделсезлек, хезмәт ияләренең изелүе һәм фәкыйрьлеге турында ачынып язган. Аның бөтен фәнни һәм әдәби хезмәтләре шушы рух белән сугарылган. «Мал иясе — дип яза К. Насыйри тирән ачыну белән — халык кашыда судан аграк, күктән биегрәк, балдан татлырак... явызлыгы гафу ителгән булып урны югарыдыр... сүзләре никадәр буш булса да колак салып тыңларлар. Әмма фәкыйрь адәм халык кашында булган ялган рәшәдән ялганчырак, кургашыннан авыррак булып мәҗлескә керсә, сәлам бирмәсләр вә сәлам бирсә, сәламен алмаслар, хәл-әхвәлен сорамаслар, артында гайбәт итәрләр... дөрес сүзе дә кабул булмас»[1]. Хезмәт кешесенең аянычлы язмышы мәгърифәтче-галимдә, аны изүчеләргә карата ачу һәм нәфрәт уята. Үзенең хезмәтләрендә һәм хатларында ул хезмәт иясе халкының авыр язмышы, фәкыйрьләрнең «ыңгырашуы», «чамадан ашкан мохтаҗлыгы» турында тирән әрнү белән яза.

Чын гуманист буларак, К. Насыйри шәхесне дин сөременнән арындыру, аны язмыштан узмыш юк, кеше — алла колы, дигән караштан коткару өчен күп көч куя. Аның фикеренчә, кеше алла кодрәте белән түгел, бәлки табигать җимеше буларак барлыкка килгән.

Каюм Насыйри халыклар арасында дуслык һәм үзара аңлашу идеяләренең кайнар тарафдары булды. Ул милли дошманлыкны һәм хәрби бәрелешләрне җәмгыятьнең иминлегенә, кешелеккә каршы булган иң зур җинаятьләрнең берсе дип санады. Аның фикеренчә, сугыш халыкларга бетмәс-төкәнмәс кайгы-хәсрәт, кан-яшь китерә, һәм иҗтимагый прогрессны, фән һәм культура үсешен тоткарлап кына калмыйча кешелек җәмгыятен кирегә этәрә. «...Сугыш мәйданына барган гаскәрләрнең һәрберсе каһарман шикелле адәмнәр корал күтәреп, бугазга бугаз килеп сугышалар. Әгәр дә алар коралларын ташлап, дөньяны төзәтергә тотынсалар иде, сугыш вакытында хәраб, вәйран ителгән шәһәрләр һаман төзек калып, аның бәрабәренә ничә калалар вә шәһәрләр вә авыллар гыймарәт кылырлар иде...»[2] ди ул.

Патша Россиясе шартларында самодержавиенең һәм руханиларның төрле милләт хезмәт ияләренең үзләрен изүчеләргә каршы берләшүен булдырмау өчен аларны читләштерүгә һәм үзара каршы куюга юнәлдерелгән политикасы һәм эшчәнлеге халыкларның үзара якынаю һәм милли чикләнгәнлектән арыну юлында җитди киртә булып торды. К. Насыйри милли һәм дини җирлектә халыкларны бер-берсенә каршы кую политикасын кискен рәвештә кире кага. Җәмгыятьнең нормаль яшәеше өчен ул милләтләр бер-берсе белән күптөрле бәйләнешләргә керергә, фән, культура, җитештерү өлкәсендәге казанышлары белән уртаклашып яшәргә тиешләр дип исәпли. Дин дә, идеологик яки башка төрле уй-ниятләр дә бу бәйләнешләргә киртә булып тора алмыйлар. К. Насыйри фикеренчә дин һәркемнең шәхси эше. «Әгәр дә бер адәм белән мөсахәбәт[3] кылсаң, аның акылына кара, диненә карама. Чөнки аның дине үзенә фәкать, әмма акылы үзенә һәм сиңадыр»,[4]— ди. Димәк, башка диндәгеләрнең рухи байлыкларын һәм культура казанышларын үзләштерүнең бернинди куркынычы юк икән.

К. Насыйри аеруча рус халкы белән якынаю һәм аралашу кирәклеген җентекләп дәлилли. Ул патша самодержавиесе һәм хаким сыйныфлар тарафыннан алып барылган милли изү политикасына протест белдерә, ләкин шул ук вакытта патша хөкүмәте белән рус халкын тиңләштерүгә дә каршы чыга. Патша самодержавиесенең һәм рус халкының бер үк нәрсә булмаганын ул яхшы аңлый, рус крестьянын рус чиновнигыннан, алпавытыннан һәм сәүдәгәреннән аера белергә өнди, халыкның хаким сыйныфлар тарафыннан күргән җәбер-золымы өчен гади рус кешесенең берничек тә җаваплы булмаганын икърар итә. Аның фикеренчә русларның да, татарларның да Ватаны һәм язмышлары уртак. Шулай булгач, алар киләчәк өчен бергәләшеп, үз культураларының казанышлары һәм уй-фикерләре белән уртаклашып хезмәт итәргә тиешләр.

«...Россия кешесе,— дип яза К. Насыйри,— мөселманнар белән бер җирдә (торган) һәм бер җирдә үскән, бер икмәкне ашап үскәнлекләре сәбәпле, бу ике халык бер-берсенең гадәтен вә мөгамәләсен яхшы беләләр»[5]. Рус һәм татар халкы арасындагы тарихи дуслык һәм ярдәмләшүне нигезләгәндә мәгърифәтче үткән заманнарның тарихи ядкарьләренә мөрәҗәгать итә, бу халыкларның күп гасырлар буена үзара тыгыз бәй-

---

[1] Насыйри К. Фәвакиһел җөласа фил әдәбият. Казан, 1884, 99 б.

[2] Мостафа Ногман. Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы. III чыгарылыш. Каюм Насыйри кулъязмалары. Казан, 1958, 16—17 бб.

[3] Мөсахәбәт кылсаң — юлдаш булсаң, сөйләшсәң.

[4] Насыйри К. Кырык бакча. Казан, 1880, 4 б.

[5] Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. 1 т. Казан, 1974, 55 б.

ләнешә булуын һәм үзара бөтен яктан: экономик, мәдәни һәм рухи аралашуда булуын күрсәтә.

П. А. Поляков белән берлектә язылган «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыклар әкиятләре белән чагыштыру» дигән исем белән 1900 елда басылган китабында К. Насыйри Идел буе халыкларының халык авыз иҗаты үзара тәэсир итешүен киң планда тикшерә, конкрет мисалларда күп кенә рус һәм татар әкиятләрендәге образларның уртаклыгын күрсәтеп уза. Татар этнографиясенә багышланган хезмәтләрендә ул шәһәрдә яшәүче татарларның киемнәрендә һәм торак биналар төзелешендә, руслар белән якыннан аралашу тәэсирендә барлыкка килгән кайбер үзгәрешләрне теркәп калдырган.

Татар хезмәт ияләренең руслар белән нинди дә булса каршылыклары булмавын, аларның тарихи дуслыгын һәм мәнфәгатьләре уртаклыгын ачыклау җәһәтеннән караганда К. Насыйриның Е. Пугачев восстаниесе турындагы хезмәте үзенчәлекле урын алып тора. Пугачев йөзендә К. Насыйри хезмәт ияләре мәнфәгатьләрен яклауга күтәрелгән гади рус кешесен күрә. Аның җитәкчелегендә башта рус халкы сыйнфый көрәшкә күтәрелгән, ә аннан соң аңа татарлар, марилар, башкортлар, чувашлар һәм Идел-Урал төбәгенең башка халыклары кушылган. Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышының күпмилләтле характерын мәгърифәтче әнә шулай ассызыклый, татар хезмәт ияләренең рус һәм башка тугандаш халыклар белән бергәләшеп гомуми дошманга — патша самодержавиесенә һәм крепостнойлык тәртипләренә каршы көрәшен тасвирлый.

Каюм Насыйри рус культурасын, тарихын һәм телен яхшы белүне халыкларның үзара аңлашуында мөһим алшартлар дип исәпли һәм ул бу фикерне татарлар арасында армый-талмый пропагандалаучы да булды. Рус тарихчыларының хезмәтләреннән файдаланып ул татарча «Зөбдәт мин тәварихи әр-Руси» («Кыскача Россия тарихы») исемле популяр китап һәм рус теле буенча дәреслекләр язып бастыра. Шуның өстенә ул календарьларында елдан елга рус тарихы, культурасы һәм көнкүреше турында материаллар бастырып килә. Аларда Рус дәүләте үсешенең мөһим этаплары яктыртыла, рус культурасы ядкарьләре тасвирлана, күренекле политик һәм җәмәгать эшлеклеләрен, рус культурасы үсешенә сизелерлек өлеш керткән кешеләрне популярлаштыра. Аның хезмәтләрендә укучы Россия тарихының Невадагы сугыш, Боз өстендәге бәрелеш, Алтын Урда белән көреш, Ливон сугышы, 1812 елгы Ватан сугышы, крепостнойлык тәртипләрен бетерү кебек мөһим вакыйгалары, рус халкының А. Невский, К. Минин, Д. Пожарский, А. Суворов, М. Кутузов, Е. Пугачев кебек күренекле уллары, рус культурасы үсешендәге мөһим этаплар: славян алфавиты кертү, беренче кулъязмаларның һәм законнарның барлыкка килүе, китап басуны уйлап табу, беренче типографияне ачу, газеталар чыгара башлау, университет ачу турында да мәгълүматлар таба алган.

Татарларның рус телен өйрәнүенә К. Насыйри бик зур әһәмият биргән. Ул «...Россия мәмләкәтендә торып русча белмәк дөнья мөгамәләсе өчен гаять зарур вә мөһим эштер»[1], — дип яза. Рус телен яхшы белү мәгърифәтче фикеренчә рус кешеләре белән якыннан аралашу өчен дә, дөнья фәне һәм культурасы казанышлары белән танышу өчен дә бик мөһим. Бу хакыйкатьне тирән аңлаган хәлдә, ул татарларга рус телен өйрәтү эшен оештыруны җәелдереп җибәрә, дәреслекләр яза, татар балалары өчен рус мәктәбе ача һәм анда армый-талмый эшчәнлек алып бара.

Милли киртәләрне ерып чыгуда, рус һәм татар халкы арасында үзара аңлашуга ирешүдә К. Насыйриның русларны татар халкының тарихы, культурасы һәм көнкүреш гадәтләре белән таныштырудагы эшчәнлеге дә шактый әһәмиятле роль уйнаган. Рус җәмгыятен татар халкының үткәне һәм культурасы белән таныштыруның әһәмиятенә басым ясап К. Насыйри болай дип язган: «Рус җәмгыяте, үзенең руслардан башка халыкларын (шул исәптән татарларны да) гомуми кешелек белеме яктылыгы астында агартып өлгергәнчегә кадәр, аларны яхшылап өйрәнергә мәҗбүр булыр... Татарның тормышын ачыкландыруда рус кешеләренә үземнән көчем һәм мәгълүматым җиткән кадәр ярдәм итәргә теләп, күп еллар бу тормышны тикшерү һәм күзәтү өстендә эшләвемнең нәтиҗәләрен матбугатта алар белән уртаклашуны үземнең изге бурычым дип саныйм»[2]. Шушы максаттан чыгып, К. Насыйри татар халкының тарихи үткәне, фольклоры һәм көнкүреш традицияләре турында хезмәтләр язып бастыра, руслар файдалансын өчен татар теле дәреслекләре һәм сүзлекләр төзи. Ул даими рәвештә рус галимнәре белән аралаша, аларга татар халкының тарихи һәм мәдәният ядкарьләрен җыюда һәм тарихи үткәне турында хезмәтләрне әзерләүдә ярдәм итә. Казан университеты каршындагы Археология, этнография һәм тарих җәмгыятенең әгъзасы буларак, рус җәмәгатьчелеге алдында үз халкының тарихы һәм культурасы турында фәнни докладлар белән чыгыш ясый.

---

[1] Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. 1 т. Казан, 1974, 58 б.

[2] Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. 2 т. Казан, 1975, 44 б.

Татар халкының иҗтимагый аңы үсешендә һәм дөньяга фәнни карашының тамыр җәюе өчен шартлар әзерләүдә К. Насыйриның роле искиткеч зур булды. Үз халкының язмышы өчен борчылып, мәгърифәтче-галим урта гасыр мөселман идеологиясе хакимлеге һәм халыкның рухи торгынлыгы нәтиҗәсендә туган тынчу атмосферага каршы кискен протест белән чыга.

Ул динчеләрнең вәгазьләренә һәм дини китапларга сукырларча ышануны тәнкыйть итә. Мәгърифәтче «Бакырган», «Фәзаилешшөһүр» кебек халык арасында киң таралган дини-мифик эчтәлекле китаплардагы мәгънәсез фикерләрдән көлә һәм мондый китапларны укытып кешеләрне алдау һич тә булмаска тиеш дип исәпли. «Бакырган»нан, «Фәзаилешшөһүр»дән ни чыга?— дип яза К. Насыйри.— ...Фән укыганда, андый китапларны уку һәм укытуның кирәге юк. «Арык шайтан белән симез шайтан хикәясе»нең балаларның газиз гомерләрен бушка уздырудан артык ни файдасы бар? Тагын «Фәзаилешшөһүр»дә нәрсә икәнлеге билгеле булмаган — тамуг матчасына асарлар, дигән сүзнең балаларга ни файдасы бар? Мондый нәрсәләрне ник башыгызга алмыйсыз? Сез шуны гыйлемгә исәплисез: «һай-һай, улым мәктәптән ниләр белән кайткан!»— дисез. Тамугның матчасы бар имеш. Тимерденме? Тимер булса — эрер. Агачтанмы? Агач булса — янар. Аңа ник акылыгыз җитми»[1].

Рационалист К. Насыйри мистикага кискен рәвештә каршы чыга һәм татарлар арасында аның төп терәге булган суфичылыкны һәм ишаннарны аяусыз тәнкыйтьли.Суфичылык тарафдарлары булган замандашларын ул икейөзлелектә гаепли. Суфилар, ди ул, кеше алдында үзләрен тәкъва итеп күрсәтәләр, ә чынлыкта исә ясалма тәкъвалыкларын фани дөнья рәхәтлекләренә ирешүгә юнәлдерәләр. Суфиларның «тыйнаклыгы киемнәрендә, тәкәбберлекләре күкрәкләрендә», ди мәгърифәтче. К. Насыйри фикеренчә, суфилар — җәмгыять өчен гомумән файдасыз, яраксыз кешеләр. Һәр кеше тормыш итәр өчен акча, байлыкны үз хезмәте — я сәүдә, я һөнәр, я игенчелек белән табарга тиеш. Суфилар исә хезмәтнең бер генә төре белән дә шөгыльләнмиләр, ә сорыкортлар кебек башкалар хезмәте аркасында яшиләр. Борынгы заманнарда гына суфичылыкка аскетлык хас була, соңыннан ул шау-шуга әверелә, хәзер исә аскетлык та, шау-шу да юк, ә бары тик хәйләкәрлек кенә калды.

Бу тәнкыйте белән К. Насыйри урта гасыр мөселман идеологиясенең авторитетлы юнәлешләреннән берсе булган суфичылыкның чын йөзен ачып салган. Шуның белән ул массаларны мистикадан һәм тормышның реаль проблемаларыннан читләшүдән арындыру эшенә гаять зур өлеш кертә.

Фән һәм галимнәр белән көрәшеп килгән ислам дине тәгълиматларына каршы чыгып, К. Насыйри фәнни белемнең гаять зур көч булуын аңлата, фәнне кешелекнең иң зур байлыгы дип саный. Аның фикеренчә, фән белемнең ышанычлы чыганагы, ә белем кеше эшчәнлегенең зарури нигезе булып тора. «Гыйлемсез эш кылган кеше — юлсыз йөргән кеше белән бәрабәрдер»,— дип яза күренекле мәгърифәтче[2].

Кешелек тормышында фәннең әһәмиятен никадәр тирән аңлавын, К. Насыйриның фәнни белемнәрне пропагандалаудагы күпкырлы эшчәнлеге ачык күрсәтеп тора. Аның «Буш вакыт», «Гөлзар вә чәмәнзар», «Истыйляхате гыйльме һәндәсә», «Ысулы җәгърәфия кәбир», «Мөнәфигы әгъза вә кануны сыйххәт» һ. б. китаплары, календарьлары башыннан алып ахырына кадәр татарлар арасында фәнни белемнәрне популярлаштыруга багышланганнар. Бу хезмәтләрендә ул чынбарлыкның фәнни картинасын һәм табигать законнарын әзерлеге булмаган укучылар да аңларлык төстә бәян итә. Шул ук вакытта мәгърифәтче чынбарлыктагы күренешләрнең, вакыйгаларның объектив табигатеннән чыгып эш итә.

Каюм Насыйри татарлар арасында гелиоцентрик теорияне пропагандалаучыларның беренчеләреннән берсе була. Ул массаларга дөньяның фәнни картинасын аңлатучы һәм чынбарлыкны дини тәгълиматлардан чыгып аңлауны фаш итүгә күп көч сарыф итүче булды. К. Насыйри бигрәк тә медицина белемнәрен пропагандалауга зур өлеш кертә. Ул вакытларда бу бик зур әһәмияткә ия булган, чөнки халык массаларының бу өлкәдә хәбәрдар булмауларыннан им-томчылар һәм һәртөрле шарлатаннар бик оста файдаланганнар (аларны К. Насыйри җәллад ялчылары дип атый.) К. Насыйриның бу юнәлештәге эшчәнлеге дөньяга дини карашны фаш итүдә һәм массаларны шәригать кануннарына сукырларча ышанудан коткаруда да бик зур әһәмияткә ия иде. Дөрес, К. Насыйри дөньяга караш мәсьәләләрендә эзлекле түгел: аңарда табигатьне материалистик бәян итү дини-идеалистик чигенешләр белән үрелеп бара. Ул алланы дөньяны яратучы буларак таный. Ләкин, К. Насыйриның алласы, руханилар фикеренчә, табигать процессларына һәм җәмгыять тормышына даими катнашып, аларны барлыкка китерүче яки юкка

---

[1] Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. 1 т. Казан, 1974, 41 б.

[2] Каюм Насыри (1825—1945). Материалы научных сессий, посвященный 120-летию со дня рождения. Казань, 1948, 83 б.

чыгаручы супранатураль җан иясе түгел. Алланы ул деистик планда (галәмне үзе барлыкка китерсә дә, табигать һәм җәмгыять тормышына йогынтысы булмаган бер илаһи башлангыч дип раслаучы философик тәгълимат нигезендә) аңлата. Алла дөньяны яратучы булса да, кеше аның катнашыннан башка, сәбәплелек принцибыннан чыгып, мөстәкыйль эш итә дип исәпли[1]. Дөньяда бөтен нәрсәнең сәбәбе бар икән, алладан шәфкать көтеп ятмаска, ә чынбарлыктагы вакыйгаларның, күренешләрнең сәбәпләрен танып белергә һәм кешеләргә уңай нәтиҗә бирә торган көчләрне хәрәкәткә китерергә кирәк дигән нәтиҗә чыгара. К. Насыйриның бу фикере деизмга туры килә, ә К. Маркс «деизм — материалист өчен ахыр чиктә диннән аерылуның уңай һәм җиңел юлы гына ул»[2] дип күрсәткән. К. Насыйри, алла бөтен нәрсәнең язмышын алдан билгеләгән, дигән дини тәгълимат йогынтысыннан котылу юлында мөһим адым ясый. Шушы фикергә таянып, К. Насыйри әйберләргә һәм күренешләргә аларның эчке табигатеннән чыгып бәя бирергә кирәк дигән нәтиҗә ясый һәм үзенең тикшеренүләрендә дә шуңа нигезләнеп эш итә. Сүз турыдан-туры иҗтимагый тормыш, фән, культура мәсьәләләре турында барганда һәм табигать процессларын аңлатканда К. Насыйри стихияле материалист буларак чыгыш ясый. Үзенең хезмәтләрендә ул чынбарлыкның бик күп яклары турында фикер йөртә һәм аны хәрәкәттәге материянең чагылышы итеп карый, табигать күренешләрен чынбарлыктагыча итеп аңлата, аларның яшәеш һәм үсеш закончалыкларын ача.

Шулай итеп татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле К. Насыйри чынбарлыкны фәнни-материалистик аңлату юлында бик зур адым ясый. Ул асылда мөселман диненең һәм урта гасыр схоластик философиясенең дөньяга карашы күрсәтмәләре белән араны кискен рәвештә өзә. Фәнни белемнәр тарату өлкәсендәге эшчәнлеге белән ул массалар арасында таралган хорафатларга, юк-барга ышануларга кискен удар ясады һәм дөньяга фәнни карашны урнаштыру өчен шартлар хәзерләүгә үзеннән зур өлеш кертте. К. Насыйри һәм аның фикердәшләренең эшчәнлеге татар халкының рухи тормышында мөһим алга китеш булды. Татар мәгърифәтчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак халкыбызның иҗтимагый фикер тарихында тәнкыйди юнәлеш башлангыч ала.

Күренекле язучы һәм марксист галим Г. Ибраһимов тарафыннан Насыйрилар дип аталган татар мәгърифәтчеләре плеядасының урта гасырга хас дини карашларга һәм мөселман диненә каршы кискен чыгышлары, аларның иске традицион төшенчәләрне һәм рухи кыйммәтләрне тәнкыйтьләве кешеләр аңын рухи катып калганлыктан азат итүгә ярдәм итте. Аларның әйләнә-тирәдәге вакыйгаларга айнык карарга чакырулары халыкның аңына фәнни-материалистик һәм революцион-демократик, ә соңыннан марксистик-ленинчыл идеяләр үтеп керү өчен нигез хәзерләде.

---

[1] Насыйри К. Фәвакиһел җөләса... 93 б.

[2] Маркс К. и Энгельс Ф. Соч., т. 2, 144 б.



# ҖЫРГА ГАШЫЙК ГАЛИМ

*Илбарис Надировка 60 яшь*

Татар халкының рухи культурасын өйрәнүче дистәләрчә тикшеренүчеләр элек-электән үк безнең җырларыбызның мәгънәви байлыгына һәм шигъри гүзәллегенә игътибар итеп киләләр. Алай да, татар халык җырларын аеруча җентекләп һәм нечкәләп өйрәнгән, алардагы хис муллыгын, шигъриятне, рухи сафлыкны һәм фәлсәфи тирәнлекне ачып, аңлатып бирүгә бигрәк тә зур өлеш керткән бер галим бар. Сүз күренекле фольклорчы, филология фәннәре кандидаты Илбарис Надиров турында бара. Фольклористика өлкәсендә ул инде утыз елдан артык эшләп килә. Аның унга якын китабы, йөздән артык мәкалә һәм рецензияләре басылып чыкты. Һәм шулар арасында аеруча әһәмиятлеләре — нәкъ менә халык җырларына багышланган хезмәтләр. Хронологияне саклап тормастан, 1965 елда дөнья күргән «Татар халык җырлары» исемле фәнни җыентыкка мөрәҗәгать итик. Бу басма галимнең шәхси иҗаты өчен генә түгел, бәлки бөтен татар фольклористикасы тормышында мөһим вакыйга булды, безнең җырларыбызны җыю һәм өйрәнү тарихында ул өр-яңа бер сәхифә ачты. Аңа кадәр беркайда да басылмаган 400 дән артык лирик озын җырларны һәм йола җырларын туплаган бу китап фәнни әйләнешкә бөтенләй яңа сыйфатлы фактик материал алып килде. Элекке елларда татар халкының җыр иҗаты нигездә дүртьюллык кыска җырлардан тора дигән караш өстенлек итә иде. Чынлыкта исә, И. Надировның үз сүзләре белән әйткәндә, бездә «халыкның ата-бабадан килгән гореф-гадәтләре, гаилә бәйрәмнәре белән бәйле йола поэзиясе» дә, «күңел ачулар, уеннар, биюләр белән тыгыз үрелештә торучы уен җырлары, бию такмаклары» да, «кеше күңелендәге иң тирән кичерешләрне, хисләр хәрәкәтен энҗе кебек бергә тезеп, шигъри бөтенлектә һәм үзара бәйләнештә чагылдыручы озын лирик җырлар» да бар. Җыентыкка бирелгән зур күләмле һәм тирән эчтәлекле кереш мәкаләдә И. Надиров, яңа фактик материалларга таянып һәм җырларның көнкүрештә тоткан урынын, йола, уен биюләр белән бәйләнешен, поэтик үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларны «йола җырлары», «уен-бию җырлары», «лирик кыска җырлар (дүрт юллы җырлар)», «лирик озын җырлар» дип аталучы төп дүрт төркемгә бүлде. Бүген, егерме ел үткәннән соң да, бу классификация үзенең фәнни-гамәли әһәмиятен саклап килә.

И. Надиров җырларыбызның эстетик кыйммәтен, аларның художество җегәрен ачуга җитди игътибар бирә башлады, фольклор поэтикасына кагылышлы кызыклы күзәтүләр һәм ачышлар ясады. Аның хезмәтләре безнең фольклор фәненә шигърият, лиризм белән сугарылган бер агым буларак килеп кушылды.

Әлбәттә, эстетик анализга игътибарның көчәюе И. Надиров хезмәтләрендә фольклор әсәрләрен идея-тематик, социаль-тарихи яктан карап өйрәнүгә һәм бәяләүгә зыян китерү хисабына эшләнмәде. Киресенчә, аның күп кенә хезмәтләре иҗтимагый-тәрбияви яктан аеруча әһәмиятле һәм актуаль темаларга багышланган. Ул үзенең кандидатлык диссертациясен Бөек Ватан сугышы чорындагы татар халык иҗатын өйрәнеп яклады. 1961 елда шушы диссертация нигезендә «Халык һәм җыр» исемле монография бастырып чыгарды. Бу теманы яратып һәм дулкынланып өйрәнүе, билгеле, галимнең биографиясе белән дә бәйләнгән. Ул, унҗиде яшеннән фронтка китеп, фашист илбасарларга каршы кулына корал тотып көрәшкән, ике мәртәбә яраланган, батырлыклары өчен дүрт сугышчан бүләк алган кеше.

«Халык һәм җыр» китабы Бөек Ватан сугышы елларында татар халкы иҗат иткән әсәрләрне җыю һәм өйрәнү өлкәсендә беренче җитди адым булды. Бу темага И. Надиров

вакытлы матбугат битләрендә дә күп кенә мәкаләләр белән чыгыш ясады. Аларда совет чорында яңа фольклор әсәрләре: җырлар, бәетләр туу, аларның художество үзенчәлекләре кебек теоретик яктан да әһәмиятле мәсьәләләр яктыртылыш тапты.

Галимнең совет чоры фольклоры белән даими һәм якыннан торып кызыксынуы аның халык иҗатында В. И. Ленин образын өйрәнүгә багышланган хезмәтләрендә дә ачык күренә. Бу — кызыклы һәм җитди проблема. И. Надиров аңа кабат-кабат әйләнеп кайта һәм үзенең күзәтүләрен һаман киңәйтә, тирәнәйтә бара. Автор бу юнәлештәге эзләнүләре өчен башка халыклар фольклоры материалларына да мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә, СССР халыклары фольклорында Ленин образы» дигән шактый күләмле мәкалә язылды. Ниһаять, 1970 елда бөек юлбашчыбызның тууына 100 ел тулу хөрмәтенә И. Надиров тарафыннан хәзерләнгән «Иҫеме халык телендә» исемле җыентык дөнья күрде. Китапка илебездә яшәүче 28 халыкның Ленинга багышланган җырлары, поэмалары, әкият һәм легендалары урнаштырылган һәм төзүченең «Кояшлы образ» дип исемләнгән кереш мәкаләсе бирелгән. Бу җыентык совет фольклорындагы лениниананың күркәм казанышларыннан берсе булып саналырга хаклы.

И. Надировның өч дистә елдан артыкка сузылган хезмәт юлы турында сөйләгәндә, аның Идел-Урал регионындагы автономияле республикаларны һәм өлкәләрне аркылыга-буйга гизеп халык авызыннан меңләгән җырлар, бәетләр, әкиятләр, мәзәкләр, мәкальләр язып алуын; Мәскәү, Ленинград, Казан, Тбилиси, Ташкент, Кишинев һ. б. шәһәрләрдә уздырылган бөтенсоюз фольклор киңәшмәләрендә проблемалы докладлар белән катнашуын, фәнни-оештыру эшләренә, яшь белгечләр хәзерләүгә зур көч куюын әйтми калу мөмкин түгел. Ун ел дәвамында ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми секретаре һәм директор урынбасары булып эшләде, ә 1972 елдан бирле — шушы институтның халык иҗаты секторы мөдире. Мәгълүм булганча соңгы елларда бу секторда татар фольклорының 12 томлык фәнни җыелмасы әзерләнә һәм аның 9 томы инде Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде. Шушы фундаменталь басманың фәнни җитәкчесе булудан тыш, И. Надиров — дүрт томның турыдан-туры төзүчесе, кереш мәкаләләр һәм искәрмәләр авторы. Ул төзегән «Кыска җырлар» (1976), «Йола һәм уен җырлары» (1980), «Бәетләр» (1983, соавторлар белән) томнары инде фольклор сөючеләр кулына барып иреште һәм матбугатта уңай бәя алды.

И. Надиров әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә актив эшләп килә. Галим фольклор һәм язма әдәбият бәйләнешләре, әдәбият тарихы мәсьәләләре буенча фәнни мәкаләләр язды. Аның Кол Гали, Акмулла, Г. Тукай, М. Гафури, М. Җәлил иҗатларындагы фольклоризм мәсьәләләрен яктырткан тикшеренүләре тулы бер цикл хасил итәләр.

Шагыйрьләр һәм композиторлар иҗат иткән җырларның сыйфатын яхшыртуда, аларның иң яхшы үрнәкләрен җыр сөючеләргә җиткерүдә И. Надировның хезмәте шулай ук тәкъдир ителүгә лаек. Ул җыеп һәм төзеп бастырган «Җырлар китабы», «Җырлыйк әле» кебек җыентыкларның, йөз мең данә тираж белән басылып та, тиз арада халык арасында таралып бетүе шуңа нигез түгелмени!

Илбарис Надировка 60 яшь тулды. Әмма ул һаман да яшьләрчә өлгер, энергияле. Алда зур иҗат планнары: сектордагы хезмәттәшләре белән рус телендә «Татар фольклоры поэтикасы» дигән коллектив монография язасы бар, халык иҗаты җәүһәрләренең иң әйбәт үрнәкләрен русчага тәрҗемә итеп, 6 томлык басма хәзерләү бурычы алга килеп басты. Ул чын күңелдән бирелеп, иҗади рухлану кичереп 12 томлык җыелманың соңгы томын — «Тарихи һәм лирик җырлар»ны нәшриятка әзерли. Аңа зур уңышлар телик.

**Хуҗи МӘХМҮТОВ.**

# ХАЛЫК МОҢЫНА САРЫЛЫП

*Фасил Әхмәтовка 50 яшь*

*ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның М. И. Глинка исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор Фасил Әхмәтовка 50 яшь тулды. Шушы уңайдан музыка белгече Семен Гурарий тарафыннан оештырылган әңгәмәнең язмасын тәкъдим итәбез.*

**Семен Гурарий.** «Фасил Әхмәтовның бөтен яктан да кызыклы, халык сәнгате чишмәләре белән аерылгысыз рәвештә кушылган җыр, камера-инструменталь һәм симфоник иҗаты бүгенге татар музыкасының күренекле казанышына әверелде...»

Социалистик Хезмәт Герое, СССРның халык артисты композитор Нәҗип Җиһановның «Советская Россия» газетасында чыккан бер мәкаләсендә нәкъ шундый сүзләр әйтелгән. Чыннан да, Фасил Әхмәтович, Сезнең иҗат биографиягез халык музыкасыннан башлана. Сез авылда тугансыз һәм кечкенәдән үк халык моңына сарылып үскәнсез. Татар музыкасы тарихының шушы чорын күз алдына китерик. Гадәти бер авыл малае мөстәкыйль рәвештә нота серләренә төшенгәндә, халык көйләрен гармунда уйнарга өйрәнгәндә татар музыкасында Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһанов кебек художниклар бер-бер артлы үзләренең күренекле әсәрләрен тудыралар. Утызынчы еллар ахырында Татарстан Композиторлар союзы оештырыла, опера һәм балет театры ачыла, беренче...

**Фасил Әхмәтов.** Беренче татар операсы, беренче татар симфониясе, беренче татар балеты иҗат ителә. Әлегә татар профессиональ музыкасы, еллар белән исәплләгәндә, чагыштырмача кыска гына юл үтә, ә ирешелгән казанышлар... Өлкән буын композиторларның милли музыка сәнгате хәзинәсенә керткән өлеше, иҗат традицияләренең дәвамчанлыгы, татар музыкасы үсеше процессының бөтенлеге турында уйланганда, мин зур канәгатьләнү хисләре кичерәм һәм шушы өлкәдә әйдәп барган фидакарьләргә күңелемнән рәхмәтләр укыйм.

**С. Г.** Бөтенлек төшенчәсенә Сез нинди мәгънә салып әйтәсез? Ә бит татар музыкасының үсеше чәчәкле юлдан гына бармады, ул кайчак каршылыклы бәхәсләр дә китереп чыгарды.

**Ф. Ә.** Хакыйкать бәхәссез тумыйдыр. Татар музыкасы сәнгатендә дә яңаны раслау җиңел юлдан гына бармый. Хәзер дә бәхәсләшәбез — алга барыр өчен бәхәсләшәбез. Бөтенлек төшенчәсенә менә шундый бәрәкәтле хәрәкәт мәгънәсен салып әйтүем. Шулай да иң дөрес хөкемне Вакыт үзе чыгара. Минем кебек урта буын вәкилләре балачагына туры килгән чор — утызынчы еллар ахыры, кырыгынчы еллар башы татар музыкасы үсеше турында Вакыт инде үзенең төпле сүзен әйтте: композиторларыбыз алга таба гаять зур адым ясадылар. Әмма, музыкант булу турында бик иртә хыяллансам да, мин ул чакта мондый гомумиләштерүләр ясый алмый идем әле.

**С. Г.** Димәк, авылда яшәгән вакытта, Сез татар профессиональ музыкасын бик үк нечкәләп белмәгәнсез?!

**Ф. Ә.** Мөгаен, шулайдыр. Әлеге елларда мин музыка турында нигездә радио аша алган тәэсирләр буенча гына фикер йөрттем. Башкалабыз Казанга килгәч, минем алда бөтенләй яңа дөнья ачылды. Симфоник-оркестр чыгышын тыңлау, әйтерсең, мине «алмаштырып» куйды. Әле дә хәтеремдә: мин П. Чайковскийның Бишенче симфониясен, А. Глазуновның «Стенька Разин» исемле симфоник поэмасын йотлыгып тыңладым. Оркестрга Исай Шерман дирижерлык итте. Әлеге очрашу күңелне чын мәгънәсендә тетрәтте, һәм мин зур музыка дөньясы серләрен ача башладым. Шушы концерт вакытында башкару сәнгатенең нинди сихри көчкә ия булуын да тойдым.

**С. Г.** Сез бик мөһим теманы кузгаттыгыз — композитор һәм башкаручы. Әлеге проблема музыка өлкәсендә күп гасырлар буенча яши. Башкаручы талантына да ия булган композиторлар хәзер бармак белән генә санарлык. Башкаручы белән композитор арасындагы иҗатташлык, димәк, яхшы әсәр тудыру өчен бик тә әһәмиятле. Үзенең таланты белән Сезнең әсәрләрне танытырга ярдәм иткән башкаручылар бармы?

**Ф. Ә.** Дөрес әйтәсез, музыкаль әсәрләрнең язмышы башкаручы осталыгына да турыдан-туры бәйле. Зарлана алмыйм, күп кенә әсәрләремне башкарганда алар минем ышанычлы фикердәшләрем булып калдылар. Шулай да мин чын мәгънәсендәге соавторлык көчен күренекле совет дирижеры — СССРның халык артисты, профессор Натан Рахлинның башкару таланты аша тойдым. Әлеге дирижерга кадәр «Фәрит Яруллин истәлегенә» исемле симфоник поэмамны Казанда да, Мәскәүдә һәм башка шәһәрләрдә дә башкардылар, әмма әсәр иң зур уңышны Натан Григорьевич ярдәме белән казанды. Минем карашымча, ул музыканы Фәрит Яруллинның фаҗигале язмышы белән органик рәвештә бәйли алды, шулай итеп, әсәрнең рухын тыңлаучыларга төкми-чәчми җиткерүгә

иреште. Тәэсир бик тә көчле булды. Тыңлаучылар әсәр башкарылганнан соң беравык тын тордылар. Музыкамның яңача ачылып китүе минем үземне дә таң калдырды.

**С. Г.** Музыка дөньясына Сез дә башкаручы буларак аяк бастыгыз түгелме?

**Ф. Ә.** Алай ук кычкырып әйтмик. Дөрес, училищеның халык уен кораллары бүлегенә мине баянчы буларак кабул иттеләр. Әмма әлеге уку йортын мин «теоретик-композитор» буларак тәмамладым. Музыка буенча беренче педагогларым Ә. Фәттах һәм А. Бренингны һәрчак зур ихтирам белән искә төшерәм. Гап-гади бер авыл гармунчысы белән өстәмә рәвештә шөгыльләнер өчен алар үзләренең вакытларын беркайчан да кызганмадылар.

Музыка училищесында укыган вакытта күптәнге дустым Мирсәет Яруллин миңа үзенең композиция буенча укытучысы профессор Альберт Леманга мөрәҗәгать итәргә киңәш бирде. Башта мин батырчылык итмәдем. Бәхеткә каршы, өченче курс ахырларында Альберт Семенович училищебызга үзе килде. Шушы очрашу вакытында язганнарымны аңа уйнап күрсәтергә җөрьәт иттем. Тыңлаганнан соң ул кистереп шундый сүзләрне әйтте: «Кичекмәстән минем класска килегез, Сезгә укырга кирәк». Шулай итеп мин А. Леман укучысы булдым, аның классы буенча училище, консерватория, аспирантура тәмамладым. Шундый укытучы кул астында белем алуым белән чиксез горурланам.

**С. Г.** Композиторлык эшчәнлегегезнең башында ук Сезнең иҗатта драматик башлангычның өстенлек алуын билгеләп үттеләр. Соңгы елларда исә әлеге сыйфат әсәрләрегездә бөтен калкулыгы белән ачылды. Әлбәттә, драматизм лиризм белән үрелеп бирелә.

**Ф. Ә.** Барыннан да элек мине кеше кызыксындыра. Кешенең рухи «галәме», рух диалектикасы... Жанр ягыннан чыгып караганда, минемчә, кешене симфоник музыкада тулырак ачып була.

**С. Г.** Сезнең «Казан симфониясе»н тыңлаучылар да, музыкантлар да, сәнгать белгечләре дә яратып кабул итте. Мәскәү дәүләт филармониясе тарафыннан бирелгән аннотациядә мондый юллар бар: «...Аның симфониясе (1976), оркестр серләрен яхшы белүче һәм симфонизмда югары дәрәҗәдә фикерли алучы чын останың өлгергән әсәре буларак, татар симфоник музыкасының иң күренекле казанышларының берсенә әверелде».

Симфониягә кадәр, чыннан да, озын-озак юл үтелә. РСФСР Дәүләт премиясенә лаек булган «Фәрит Яруллин истәлегенә» исемле симфоник поэма, мөгаен, «Казан симфониясе»н язуда мөһим бер этап булып торгандыр. Симфоник поэма жанры, гомумән, татар музыкасында берара чын мәгънәсендә тантана итеп алды.

**Ф. Ә.** Алдагы бер сикереш өчен шушы чорда тәҗрибә тупланган дип уйлыйм. Ә поэма жанрына килгәндә, ул композитор өчен зур мөмкинлекләр ача: интонацион яктан да, драматургик яктан да, оркестрны белү ягыннан да...

Өлкән буын композиторларыбызның симфоник поэма жанрын үстерүгә керткән өлешләре бәяләп бетергесез. «Кырлай» (Н. Җиһанов), «Г. Тукай истәлегенә», «М. Вахитов истәлегенә» (М. Мозаффаров)... Әлеге әсәрләр хаклы рәвештә алтын фондыбызга кертелде.

**С. Г.** Рух диалектикасы... Драматик башлангычка күбрәк таянып язылган «Казан симфониясе»ндәге төп фикер шушы төшенчәдә чагылмыймы? Музыка белгече Евгений Баранкин шушы уңайдан болай дип язды: «...Симфониядә кеше шәхесенең формалашу темасы, яхшылык белән явызлык арасындагы каршылык темасы драматик концепциянең нигезен тәшкил итә».

**Ф. Ә.** Әлеге әсәр турында сөйләү минем өчен шактый кыен. Симфониягә шактый озак «барылды». Гомумән, мондый зур әсәрләр рухи тәҗрибәнең бай булуын, кеше шәхесендәге эчке каршылыкларны, тарихны һәм җәмгыять тормышын тирәнтен белүне таләп итәләр. Симфония — проблема. Әйтик, Д. Шостаковичның унбиш симфониясен унбиш проблема рәвешендә кабул итәргә мөмкиндер.

**С. Г.** Шушы уңайдан әйтеп үтегез әле: кайчандыр Сезне Шостаковичка нәрүдә гаепләүләре дөресме?

**Ф. Ә.** Гомерем буе мин Шостакович музыкасын өйрәнәм. Художник һәм шәхес буларак, ул чын мәгънәсендә үрнәк булырлык композитор! Студент елларымда мин аның музыкасы белән саташып йөргәнемне хәтерлим. Табигый ки, бөек композиторның Казанга килү хәбәре мине бик дулкынландырды. Һәрбер студент-композитор Дмитрий Дмитриевичка күрсәтер өчен үзенең бер әсәрен әзерләргә тиеш иканлеген ишетү бөтенләй каушатып җиберде. Әйтергә кирәк, укыган вакытта мин башкалардан бик ук аерылып тормадым шикелле. Шуңа күрә Шостакович кебек бөек художниктан мактау сүзе ишетергә хыялланып та карамадым. Гаҗәпләнүемә каршы, кыллы квартетым нечкәләр аның игътибарын үзенә җәлеп итте. «Ул — тумыштан симфонист». Шушы сүзләр миңа канат куйды. Һәм мин аларны мөхтәрәм остазның фатихасы буларак кабул иттем.

Ә инде Шостаковичның минем музыкага йогынтысы мәсьәләсенә килгәндә, шуны әйтә алам: әйе, аның «тимер» логикасы, интонацион үсешкә осталыгы мине һәрвакыт сокландырды. Әмма «бер матур таңда», консерваторияне тәмамлагач, Шостаковичта «эреп югалу» куркынычын мин бөтен хәвефлелеге белән аңладым һәм үземне бернинди йогынтыга да бирелмәскә мәҗбүр итә алдым шикелле. Шулай да язганнарымда Шостаковичны яратуым һаман да сизелә бугай. Мөгаен, бу мәсьәләгә Горькийча якын килү иң дөресседер: һәркемнән өйрәнегез — беркемгә дә иярергә тырышмагыз.

**С. Г.** Күпмиллэтле совет сәнгатендә тирән мәгънәдәге иҗади йогынты табигый күренеш буларак карала...

**Ф. Ә.** Мондый процесс татар музыкасында да күзәтелә. Милли сәнгатьләрнең үзара баюына хезмәт итүче иҗади йогынты гәүдәләнеше интонацион, гармоник, драматургик планда бигрәк тә ачык сизелә. Әйтик, күп кенә татар композиторлары иҗатында без башка милләт музыкасына хас ладларны, аерым алганда, казах (З. Хәбибуллин), үзбәк (Р. Яхин), азербәйҗан (А. Монасыйпов), кыргыз, грузин (Р. Еникеев) музыкалары чалымнарын тоябыз. Киресе дә очраштыра. Күпмилләтле музыкаль хорда татар композиторлары йогынтысында туган әсәрләр дә ишетелгәли.

**С. Г.** Татарстан композиторлары музыкасы илебезнең бик күп төбәкләрендә һәм шулай ук чит илләрдә дә яратып тыңлана. Татар музыкасы бигрәк тә вокаль музыка аша күбрәк таныладыр. Ә менә зур жанрларны, әйтик, опера музыкасын яки симфонияләрне республикадан читтә азрак беләләр. Моның төрле сәбәпләре бардыр. Әмма шуның белән килешмичә мөмкин түгел: вокаль музыка профессиональ сәнгать үсешенең беренче чорларыннан ук татар композиторлары игътибары үзәгендә булды.

**Ф. Ә.** Вокаль музыка өлкәсендә, мөгаен, барлык буын композиторлар да эшлидер. Әлеге күренеш, минемчә, халык музыкасы стихиясе белән тыгыз бәйләнгәнлектән килә. Шәхсән үземне вокаль музыка һәрвакыт кызыксындыра. Үзеннән-үзе шулай килеп чыга. Мәҗбүр итүсез эшлим. Күп кенә очракта җырлар теге яки бу вакыйгага мөнәсәбәт белдерү рәвешендә туа. Күңелне дулкынландырган кичереш-тойгылар да күп була.

**С. Г.** Көн-үзәк мәсьәләләргә чын художник гомумиләштерү призмасы аша карарга омтыла...

**Ф. Ә.** Бары шундый очракта гына озын гомерле әсәрләр дөньяга килә. Көн-үзәк мәсьәләләр төшенчәсе, гомумән, җыр жанры табигатенә ятышып тора. Гражданлык яңгырашына ия булган күп кенә җырларыбызда нәкъ менә шушы төшенчәнең югары дәрәҗәдә кристаллашуы күренә.

**С. Г.** Композитор Фасил Әхмәтовның иҗаты күпкырлы. Шулай да музыка сәнгатендә Сезнең үз «кишәрлегегез» бар: симфоник һәм вокаль-инструменталь музыка. Әлеге жанрларга бирелгәнлек ни белән аңлатыла? Опера яки балет язарга уйламыйсызмы?

**Ф. Ә.** Жанрларны үзләштерү шактый четерекле. Вакыт та күп сорала. Шулай да куркып калмаска кирәк. Мәсәлән, мин кыллы квартетлар, агачтан эшләнгән тынлы уен кораллары өчен квинтет иҗат иттем. Әлеге әсәрләрне тудыру симфоник оркестрның аерым группаларын өйрәнү буенча үзенчәлекле мәктәп булды.

Опера яки балет язарга да ниятләнеп карадым. Әбугалисина турында опера тудырырга хыялландым. Хәзер инде Хуҗа Насретдинны опера сәхнәсенә чыгарасы килә. Шагыйрь Һади Такташ әсәре сюжетына балет язу нияте белән дә яшим. Шартлыча исемләнгән либреттосы да әзер: «Җир уллары трагедиясе».

**С. Г.** Бүгенге көндә опера жанры проблемасы үзенең актуальлеген бермә-бер арттырды...

**Ф. Ә.** Татар музыкасында опера жанры үсеше турында сөйләшкәндә, милли культура үзенчәлекләрен онытмаска кирәктер. Татар операсында классик операга йөз тоту шактый ачык сизелә. Әмма безнең халык мондый операга бик үк теләп йөрми. Ә менә музыкаль драма спектаклен карап туймыйлар. Милли опера жанрына, бәлки, халык музыкаль драмасы аша барыргадыр?! Тамашачы мәхәббәтен казанган әлеге жанрны ни өчен операга кадәр күтәрмәскә?! Музыка тормышыбызда мондый тәҗрибә булды: милли симфония тудырыр алдыннан композиторларыбыз симфоник поэма жанры традицияләрен ныклап үзләштерделәр.

**С. Г.** Традицияләр... Әлеге төшенчә һәркемгә дә яхшы таныш, һәм без бу сүзне бик еш кулланабыз. Шулай булуга карамастан, традиция төшенчәсе кайвакыт бөтенләй яңа яктан ачылып китә...

**Ф. Ә.** Бу нидән килә? Һәрбер художник дөньяны үзенчә танып-белергә омтыла. Традиция төшенчәсен дә ул үзенчә күз алдына китерә һәм аны үзенә генә хас төсмерләр белән баета. Әмма бер хакыйкатьне онытмаска кирәк: традицияләр җирлексез булмый, үзләренең тирәнгә киткән тамырлары белән алар халык музыкасына тоташканнар.

## *Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары*

## Роза Кожевникова



Роза Хәби кызы Кожевникова 1950 елда Астрахань өлкәсенең Дельта станциясендә туган. Урта мәктәптән соң, Түбән Кама шәһәренә килеп, комсомол төзелешләрендә ташчы булып эшли. 1977 елда Мәскәүдә М. Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлый, район газетасында, нәшриятта хезмәткәр, корректор булып эшли. Бүгенге көндә ул — Казан телевидениесенең әдәби-драматик тапшырулар редакторы.

Р. Кожевникова — русча язучы шагыйрә һәм тәрҗемәче: ул С. Хәким, Н. Арслан, Ш. Галиев, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, Зөлфәт шигырьләрен тәрҗемә итте.

Быел аның «Миләш тәлгәше» исемле беренче шигырь китабы дөнья күрәчәк.

## Лена Шакирҗанова



Лена Галимҗан кызы Шакирҗанова 1945 елда Актаныш районы Пучы авылында туа. Ул Арча районы Күлле Киме авылында үсә, шунда урта мәктәп бетерә. 1967 елда Казан педагогия институтын тәмамлагач, Казанда укытучы, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә артистка булып эшли. Бүгенге көндә ул Татарстан радиосында тәрҗемәче вазифасын башкара.

Л. Шакирҗанованың шигырьләре «Кызлар җыры» (1977) исемле уртак җыентыкта басылды. 1982 елда яшь шагыйрәнең «Мөлдерәмә күңел» исемле китабы дөнья күрде.

# *Культура тормышы көндәлеге*

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ СЕКРЕТАРИАТЫНДА

КПССның XXVII съездына бөтен ил белән әзерләнү һәм партия Үзәк Комитетының әдәбият өлкәсендәге карарларын тормышка ашыруның бер чагылышы буларак, Мәскәүдә РСФСР Язучылар союзы секретариатында Татарстан Язучылар союзында иҗат һәм оештыру мәсьәләләренең торышына багышланган зур утырыш булды.

Җыелышны кереш сүз белән РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе С. Михалков ачты һәм Татарстан язучылары ирешкән уңышлар, алда торган бурычлар турында сөйләде. Аннары Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллинның доклады тыңланды. Күтәрелгән мәсьәләләр буенча Татарстан язучылары — «Казан утлары» журналы редакторы Р. Харис, шагыйрь С. Хәким һәм Г. Ахунов чыгыш ясадылар, Мәскәү язучыларыннан М. Колосов, А. Коптяева, М. Ганина, Ж. Мостафин һәм башкалар сөйләде. РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретарьлары М. Шевченко, Ю. Сбитнев, М. Годенко, А. Ананьев, Э. Зимин, В. Дементьев һәм Н. Доризолар үзләренең чыгышларында татар әдәбиятына, язучылар союзының иҗат-оештыру эшенә уңай бәя бирделәр.

Утырышта КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев катнашты һәм чыгыш ясады.

Секретариат узган көннәрдә Мәскәүнең В. И. Ленин исемендәге үзәк стадионының «Дуслык» спортзалында шигырь һәм җыр бәйрәме — Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышланган «Гомерем минем моңлы бер җыр иде...» исемле зур кичә уздырылды.

Кичәне РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре Н. Доризо һәм Т. Миңнуллин алып бардылар. Мәскәүлеләр алдында татар шагыйрьләре С. Хәким, И. Юзеев, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, Р. Вәлиев, Зөлфәт, тәрҗемәчеләр М. Акчурин, Р. Бохараев һәм Вадим Кузнецов шигырьләр һәм тәрҗемәләр белән чыгыш ясадылар. Кичәдә шулай ук Татарстанның халык артистлары — җырчылар Х. Бигичев, З. Сәхәбиева, Татарстанның атказанган артисты Р. Сәхәбиев һәм башкалар катнашты.

Шундый ук әдәби очрашу Мәскәүнең И. А. Лихачев исемендәге автомобиль заводында булды: шагыйрьләребез анда төрле цехларга бүленеп чыгыш ясадылар.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫНДА

28 февральдә ачык партия җыелышында Язучылар союзы идарәсе каршындагы китап тарату һәм пропагандалау комиссиясенең отчеты тыңланды. Комиссия председателе язучы М. Маликованың чыгышыннан соң фикер алышуларда В. Нуруллин, М. Хәсәнов, М. Хәбибуллин, С. Сабиров, К. Латыйпов, Г. Ахунов, К. Тимбикова, Ә. Рәшитов һ. б. чыгыш ясап, республикабызда китап тарату эшенә киң җәмәгатьчелекне тарту буенча эшлекле тәкъдимнәр әйттеләр.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

5—8 февральдә Чистай районында Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышланган татар әдәбияты көннәре булып үтте. Язучылар Чистай сәгать заводы эшчеләре белән очраштылар, ә кичен шәһәрнең культура йортында әдәби кичә үткәрелде. 6—7 февральдә язучылар, өч төркемгә бүленеп, районның Тукай, Жданов исемендәге, «Каргалы», «Ударник», «Дружба» һәм «Кутлушкино» колхоз һәм совхоз хезмәтчәннәре белән кызыклы очрашулар үткәрделәр.

Культура йортларында, китапханәләрдә, мәктәпләрдә әдәбият бәйрәмендә катнашучы әдипләрнең иҗатына багышланган китап күргәзмәләре, стендлар оештырылган иде.

Әдәбият көннәрендә Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары шагыйрь Р. Вәлиев, китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов, язучылар А. Гыйләҗев, Ш. Рәкыйпов, М. Хәсәнов, Р. Батулла, С. Сабиров, С. Шакир, Р. Кәрами, Роберт Әхмәтҗанов һәм яшь шагыйрь Л. Зөлкарнәев катнашты.

## КАЮМ НАСЫЙРИГА БАГЫШЛАП

18—23 мартта Зеленодольск районында татар халкының бөек мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның тууына 160 ел тулуга багышланган әдәби атналык үткәрелде. Ленин, Вахитов, Киров, Ильич, Тукай исемендәге һәм «Искра» колхозы хезмәтчәннәре һәм мәктәп укучылары белән очрашуларда язучылар Р. Кәрами, С. Шакир, Р. Гәрәй һәм Э. Шәрифуллина катнашты.

Каюм Насыйриның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге турында тәнкыйтьче С. Маннапов сөйләде.

## ИЛҺАМ ШАКИРОВНЫҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

25 мартта Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илһам Шакировка 50 яшь, аның сәхнә эшчәнлегенә 25 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе булды.

Кичәне ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты.

Кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев чыгыш ясады.

И. Шакировның иҗаты һәм тормыш юлы турында ТАССР культура министры М. М. Таишев сөйләде.

Юбилярны республикабызның партия, совет һәм профсоюз оешмалары, хезмәт коллективлары вәкилләре котлады.

Аннары И. Шакиров катнашында республикабызның сәнгать осталары концерты булды.

Юбилей кичәсендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ш. Шәймиев катнашты.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

15 мартта Казанның Актерлар йортында шагыйрь Зөлфәтнең иҗат кичәсе булды. Анда Зөлфәт үз шигырьләрен укыды, тамашачыларны кызыксындырган күп санлы сорауларга җавап бирде.

Кичәдә Мәскәүдән килгән кунаклар — шагыйрьләр һәм тәрҗемәчеләр М. Акчурин, Ю. Ласки катнашты. М. Акчурин Зөлфәтнең рус телендә басылып чыгачак китабыннан тәрҗемә үрнәкләре белән таныштырды. Кичәдә шулай ук шагыйрь М. Әгъләмов, язучы Р. Батулла, җырчылар М. Сөнгатуллин, Г. Сафиуллина һәм композиторлар З. Гыйбадуллин, Риф Гатауллин чыгыш ясадылар.

Кичәне шагыйрь Р. Гатауллин алып барды.

18 мартта Актерлар йортында композитор Ш. Тимербулатовның иҗат кичәсе булды. Анда шагыйрь Р. Фәйзуллин шигырьләренә язылган җырлар башкарылды.

Кичәдә Татарстанның халык артистлары Х. Бигичев, З. Сөнгатуллина, ТАССРның атказанган артисты Р. Сәхәбиев, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары А. Гайнуллина, И. Әхмәтҗанов композитор һәм шагыйрьнең әсәрләрен башкардылар.

## ЭШ КҮРСӘТКӘН ИРНЕ ИЛ ОНЫТМАС

28 февральдә Оренбург шәһәренең «Россия» культура сараенда Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар шагыйрьләре Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Рәхим Саттар, Хәйретдин Мөҗәйнең тормыш һәм иҗат батырлыклары турында Х. Ямашев исемендәге китапханә каршындагы әдәбиятсәнгать түгәрәге җитәкчесе Зиннур Шакиров чыкты. Бөек Ватан сугышы ветераннары Шәүкәт Буркеев, Мәхмүт Әмиров, Сабир Якупов сугыш кырларында узган яшьлекләре турында истәлекләр сөйләделәр.

Кичәнең икенче бүлегендә патриот шагыйрьләр әсәрләреннән төзелгән зур концерт булды.

Бу турыда безгә укучыбыз Ф. Бәширов хәбәр итте.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Күпьеллык нәтиҗәле һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен язучы Гомәр Бәширов, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 15 февраль Указы нигезендә, РСФСР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Күпьеллык нәтиҗәле әдәби һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен язучылар Нәкый Исәнбәт һәм Сибгат Хәким, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 25 февраль Указы нигезендә РСФСР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнделәр.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен композитор Мирсәет Яруллинга, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 15 март Указы нигезендә, «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре һәм озак еллар нәтиҗәле эшләве өчен язучы Равил Фәйзуллинга, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 20 март Указы нигезендә «РСФСРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

# ҖИҢҮ ЯЗЫ ТАҢЫНДА

Татарстан сынлы сәнгатендә Бөек Ватан сугышы темасына даими мөрәҗәгать итүче рәссамнар байтак, һәм аларның күбесе фронт авырлыкларын үз башыннан кичергән. Табигый ки, турыдан-туры рухи тәҗрибәгә, күргән-белгәннәренә таянып язылган әсәрләр аеруча ышандыручан һәм тәэсирләндергеч булалар. ТАССРның халык художнигы Александр Родионов — әнә шундый иҗатчыларның берсе.

«Художник буларак мин сугышта формалаштым...» Үзенең иҗат юлы турында сөйләгәндә, Александр Миронович әлеге сүзләрне еш кабатлый. Чыннан да сугыш рәссам күңелендә тирән эз калдыру белән берәттән, халык батырлыгын сынлы сәнгать образларында чагылдыру омтылышын да тудырды, иҗатының бөтен бер юнәлешен билгеләде. Танкист лейтенантның Сталинградтан Берлингача юл үтүе аны шәхес буларак чыныктырып кына калмады, ә күңелендә гомер буе иҗат итәрлек ялкын да кабызды.

«Солдат язы» (1960), «Тормыш җиңә» (1962), «Икмәк» (1972)... Әлеге картина-хатирәләр солдат тормышы турындагы хикәятнең аерым сәхифәләре буларак кабул ителә, аларны геройларның рух ныклыгы, җиңүгә ышанычы бербөтен итеп берләштерә. Әсәрләрнең сюжет нигезен, югарыда искәртелгәнчә, баштан кичкән эпизодлар билгели. Солдатлар арасында авторның үзе дә күренә шикелле. Талчыккан йөзләр, сугыш утын «күргән» көчле куллар, уйчан-хыялый күзләр... Җиңүне иҗат итүчеләр!.. Рәссамның «Солдат язы» исемле картинасында нәкъ менә шундый сугышчылар гәүдәләндерелгән.

Шунысына игътибар итәсең: полотнода табигать детальләренә аерата тирән мәгънә салынган. Менә җиргә Җиңү язы килде. Каеннар баштанаяк кояш нурларында коена. Аларны сугыш сөреме дә каралта алмаган. Әлегә тулысынча җылынып өлгермәгән туфракны тишеп чыккан умырзаялар матурлыкның яшәүчән булуын искәртәләр шикелле. Каеннарның тагын да нурланыбрак киткән кәүсә-ябалдашлары, салют балкышыдай, җиңү язын каршылаучы солдатларның кырыс һәм шат йөзен яктырта, күңелләрен очындыра: җиргә Яз килүен, илгә Җиңү килүен бернинди көч тә туктата алмый!..

**Вера ЦОИ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның
бүлек мөдире.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның М. Глинка исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор Фасил Әхмәтов.

Рөстәм **МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)